# КАЗАН УТЛАРЫ

7
ИЮЛЬ
1982

## КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ
## ҺӘМ
## ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1982 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирү турында


*Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:*

*1982 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирергә:*

*Нуруллин Ибраһим Зиннәтовичка, язучы — «Тукай» («Молодая гвардия» нәшрияты, «ЖЗЛ» сериясе, 1977 ел, рус телендә) һәм «Габдулла Тукай» (Татарстан китап нәшрияты, 1979 ел, татар телендә) китаплары өчен.*

**КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. М. МУСИН.**

**Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе Г. И. УСМАНОВ.**



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**7**

ИЮЛЬ
1982

## *Бу санда*

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

**Р. ГАТАУЛЛИН.** Яңа җырым... Шигырь . . . 3
**М. ХӘБИБУЛЛИН.** Сулар үргә акса да. Роман . . 4
**Р. ХАРИС.** Хәбәр. Шигырьләр . . . 42
**Г. АФЗАЛ.** Алты дистәнең өстеннән. Шигырьләр 50
**Х. ӘЮПОВ.** Чакыру. Шигырьләр . . . 55
**М. ГАЛИЕВ.** Ерак урман авазы. Повесть . . . 58

**Бездә кунакта: Төньяк Осетия шагыйрьләре** . 117

МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**М. ЗАРИПОВ.** Сыеры барның сые бар. Очерк 125

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. МУСИН.** Дуслык, туганлык җепләре . 138
**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Идея-эстетик офыклар киңәйгәндә . . 147

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

**М. ГАЙНЕТДИНОВ.** Бетмәс гамем, нидәндер бу! 155

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Т. ӘЙДИ.** Үз йөзен саклап . . . . 162
**Р. СВЕРИГИН.** Төсләр һәм кешеләр . . . 165

МАТБУГАТ ҺӘМ КУЛЬТУРА

**Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ.** Китап — чорыбыз көзгесе 168

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

СӘНГАТЬ

**Е. КОЗДОБА.** Чишмә җыры . . . . . . 174

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**М. ВӘЛИЕВ.** Кем ул Сабир Шәрипов! . . . . 179
**Х. КУМЫСНИКОВ.** Нәҗип Гайнуллинның тууына 70 ел . . . . . . . . . . . . 182
**Ф. САФИУЛЛИНА.** Исемнәрнең серен ачучы . 184
Ә. Шәминның тууына 70 ел . . . . . . 186

ТӨРЛЕСЕННӘН

**С. ШАКИР.** Долматовский татар сугышчылары турында . . . . . . . . . . . 187
**С. ХӘЙРЕТДИНОВ.** Сөенечле юллар . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 191

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ (*баш редактор урынбасары*), РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 25/III-1982 ел. Басарга кул куелды 7/VI-1982 ел. ПФ 09025. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65.049 экз. Заказ Ю-127. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Рәдиф Гатауллин

*
* *

Яңа җырым, син — ватандар хисем!
Заман рухын сиңа сакларга!
Бул син оран, бул син өндәү бүген...
Бар илләргә, бар халыкларга!

Якты җырым минем! Ил сүзе бул —
Иминлекне сиңа якларга!
Биеклектән, мәйданнардан эндәш...
Бар илләргә, бар халыкларга!

Оптимистик һәм романтик җырым!
Синең урын алгы сафларда:
Дөреслекнең үзе булып, җит син
Бар илләргә, бар халыкларга!

Партияле җырым! Ахыргача
Тугры бул син олы идеалга.
Иң югары гуманистик рухны
Исән илтик якты елларга.
Бар илләргә, бар халыкларга!

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# СУЛАР ҮРГӘ АКСА ДА

РОМАН

### I



Кәримәнең битенә кояш нуры төшә. Якты, җылы нур гүя аны иркәли, назлый, күренмәс куллары белән битеннән йомшак кына сыйпый иде. Шул наздан рәхәтләнеп, күзләрен дә ачмыйча ята бирә Кәримә. Кухняда әнисе аш пешерә, шул яктан тәмле ис килә, күрше караватта төш күрә-күрә апасы Зөлфия йоклап ята. Әниләре Зөлфияне өстәл хәзерләгәч кенә уятачак, анда да кече кызы Кәримәгә дәшкән кебек: «Кәримә, кызым, тор!» дип түгел, иркәләп, тавышына әллә ниткән наз төсмерләре салып, хәтта бераз гафу үтенгәндәй, ялваргандай: «Зөлфия, бәбкәчем, сиңа да торырга вакыт инде, тугыз тулып килә, репетициягә соңга калуың бар»,— дип дәшәр.

Кәримә төнге сәгать бергә кадәр имтиханга хәзерләнеп утырды. Бүген соңгы фәнне — тарихны бирәсе. Аннары, аннары өлгергәнлек аттестаты һәм ай ярымнан туп-туры Алабуга шәһәренә — кайчандыр әтисе укыган һәм күпмедер вакыт укыткан милиция мәктәбенә. Нигә анда? Нигә кыз башы белән милиция мәктәбенә? Кәримә тәгаен генә әйтә алмый, бәлкем әле тиз генә әйтә дә алмастыр. Әмма милиция подполковнигы Якуб Азатовның кызы Кәримә бары тик шунда гына барачак.

Ишектә әниләре күренде, балаларының изрәп-таралып йоклауларын бертын күзәтеп торды да, тыенкы гына:

— Кәримә, кызым, тор әле, ипиебез беткән икән бит, апаң уянганчы алып керер иең,— диде.

Ипи магазины күрше йортта гына, йөгерәсе дә төшәсе, төшәсе дә алып менәсе югыйсә, әллә нигә торасы килми, Кәримәнең дә апасы кебек үк иркәләнәсе килә — йоклаганга сабышып ята.

— Кәримә, сиңа әйтәм түгелме, тор инде!— дип кабатлый әниләре.

Кәримә түземи, күзләрен ача, әмма шундук икенче ягына әйләнеп ята.

— Зөлфияң барсын!

— Әй, балакай, ни дигән сүз инде ул тагын. Бүген апаңның концерты...

Ни ачуы чыкса да Кәримә тора, дәшми-тынмый гына ваннага кереп китә, юына, көзге алдында чәчен тарый, киенә һәм ишек янына килеп баса.

— Акча бир,— ди ул әнисенә.

— Акча минем сумкада, үзең карап ал шуннан,— ди әнисе кухня ягыннан.

Кәримә әнисенең эшкә йөртә торган сары сумкасыннан берничә тиен көмеш таба һәм аларны күлмәк кесәсенә коя, кулына киндер капчык ала да чыгып китә.

Подъезд ишегеннән чыгу белән ул иркенләп сулыш ала. Рәхәт ана шул ишегалдында. Өйдәге кәефсезлек монда юкка чыга. Ул сикерә-атлый магазинга таба китә. Шул вакыт үзенә төбәлгән чит карашны тоя. Күрше өй каршында утыручы егет шулай карый аңа. Ул гел шулай подъезд төбендәге эскәмиядә утыра. Кәримәнең ишегалдына чыгуы була, гел аңа төбәлә, аны күзәтә. Башта Кәримә моңа игътибар итмәде, соңыннан үзе дә каш астыннан гына егеткә күз салып үткәли башлады. Аларның күзләре очраша. Егет тутсылрак йөзле, озынча юка борынлы, чем кара чәчле. Алар күрше өйгә күптән түгел генә күченеп килделәр ахры, Кәримәнең элек бу егетне күргәне булмады. Сәер, нигә ул гел Кәримәне күзәтә икән? Кәримә кая бара, егетнең күзе шунда. Аннары нишләп ул гел подъезд төбендә дә, подъезд төбендә?.. Нигә бер дә йөрергә чыкмый?.. Соңгы вакытта Кәримәне әнә шул сорау борчый башлады. Әмма егетнең үзеннән сорарга базмады. Үткән саен егетнең карашын тоеп, Кәримә адымын тыя төшә, хәтта туктап: «Нигә сез гел шунда утырасыз?» — дип сорарга тели, мәгәр соңгы чиктә барыбер сорамый, китеп бара.

Кәримә тирә-юньгә күз йөртеп чыкты. Барысы да гадәттәгечә иде: күрше өй янында малай-шалай туп тибә, арырак ике кыз бала туп тәгәрәтеп куыша.

Кәримә, киндер капчыгын селки-селки, йөгерә-атлый ипи магазинына юл тотты. Әнисе дә инде Кәримәсен гел күрмәс булды. Зөлфия кызым да, Зөлфия кызым. Кәримә бүген соңгы имтиханын бирә, ул турыда ник бер уйлап карасын... Беренче тапкыр концертка бара, имеш. Барса ни, Кәримә кызың соңгы имтиханын бирә түгелме бүген...

Ипи алып чыккач та Кәримә өйгә кайтырга ашыкмады. Күрше өйне урап кына чыгасы иде югыйсә, юк, әйләнебрәк кайта: газета-журнал киоскасына сугыла, төче-мөче, мороженый ларекларына кагыла. Шул тирәләрне әйләнеп чыгып барганда Кәримә көч-хәл белән сумка күтәреп кайтучы күршеләре Юлия Борисовнаны күрде. Күрде дә шундук куып җитте һәм җәһәт кенә кулыннан аның авыр сумкасын алды.

— Ох,— диде карчык, куркынып, искәрмәстән кулыннан сумкасын алгач.— Кем дип торам, син икәнсең, Каракүз!

Юлия Борисовнаның Кәримәгә беркайчан да исеме белән дәшкәне юк. Каракүз — аның Кәримәгә биргән кушаматы.

— Ашыкма әле син алай, Каракүз, сабыр ит дим. Менә рәхмәт сиңа. Әниең өйдәме соң? Зөлфия тордымы? Әй, иркәләнә белә дә соң апаң, Каракүз. Ярый, иркәләнеп калсын, кияүгә чыккач иркәләнү тәтемәс. Кыен булачак аңа кияүдә, бик кыен. Ә сиңа җиңел булыр, син эш яратасың, игелеклесең, синдәйләрне ирләр дә яратучан, Каракүз.

— Зөлфия апа да торып ята инде,— дип, апасын хурлатырга теләмичә әйтеп куйды Кәримә.

— Торып ятамы, тора да ятамы, ятып торамы? — дип сорады көлемсерәп Юлия Борисовна һәм Кәримәнең аркасыннан ләпи-ләпи сөеп алды.— Ә син молодец, апаңа да сүз әйтергә бирмисең. Молодец, уңган кыз булдың. Бүген соңгы имтиханны бирәсеңме?

— Әйе. Бер тарих калды.

— Тарихны бирерсең,— пенсионер карчык читкә карап алды һәм тавышын әкренәйтә төшеп: — Әнә күрәсеңме теге егетне, подъезд төбендәге эскәмиядә утырган мескенне,— диде.

— Кем ул, Юлия Борисовна?

— Кем. Менә дигән акыллы егет. Ләкин гарип. Хулиганнар кыйнаганнар. Бер кешене дүртәү. Умыртка сөяген имгәткәннәр, рәтләп йөри дә алмый. Ни өчен?.. Ни өчен кыйныйлар хәзер. Бер кызны яклап чыккан бугай. Кызы качып котылган, ә бу, мескен, әнә нинди көнгә калган.

— Кемнәр кыйнаганны да белмиме?

— Яшерәмедер, күргән кешеләрем түгел, дигән була. Әйтергә теләмидер. Тегеләрнең кызга бер-бер нәрсә эшләп ташлауларыннан куркадыр, күрәсең.

— Ни дип куркырга, ди?

— Ни дип, сөйгән кызына бер-бер яманлык кылулары бар. Мондаен егетләр үлгәндә дә андый хурлыкка бармаячаклар.

— Сөйгән кызы янына киләме икән соң?

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, Каракүз, килми дә, күренми дә. Ә бу, бичара, аның намусын саклап калу өчен гарип кала. Әтисе-әнисе бик тә әйбәт кешеләр, беркөнне тагын чәйгә дәштеләр үземне. Әчләр бушаганчы сөйләшеп утырдык... Әйдә, кузгалыйк, әниең көтәдер.

— Бүген апа беренче тапкыр концертка катнашачак.

— Бик әйбәт. Сине медицина институтына керергә уйлый, дип сөйләде әниең, хакмы шул?

— Белмим әле. Әнигә түгел бит, миңа укырга. Медицинаны нигәдер мин яратып бетермим.

— Үги әтиеңнең кайтканы бармы, Хәлилнең?

— Күптәннән күренгәне юк инде аның. Эчә бит, инәки рәнҗи. Сирәк кайта ул.

— Кайтмавы хәерлерәктер дә... әниең өчен дә, сезнең өчен дә. Дорфа адәм. Сәләтсез дә, җитмәсә эчә дә. Кайчак талантлар эчә, аларны әле гафу итәргә була, мондыйларны — юк!

Юлия Борисовна Каменская гаҗәеп төстә саф итеп татарча сөйләшә. Ул үз гомеренә татар һәм рус ансамблендә җырлый, халык артисты, хәзер пенсиядә. Семьясы, бала-чагасы юк, ире күптән дөнья куйган, ике бүлмәле фатирда бер ялгызы яши! Консерваториядә укучы Зөлфия, Каракүз Кәримә дә аңа үз балалары кебек. Еш кына алар бергәләп кич утыралар, җырлар җырлыйлар. Зөлфияне консерваториягә димләүче дә ул булды. Кыскасы, күрше карчык алар өчен дәү әниләре кебек инде.

— Юлия Борисовна,— дип сорады подъездга кергәч Кәримә.— Теге егетнең әниләре кайда эшли?

— Әнисе — инженер, заводта эшли бугай, әтисе тегүче. Әйбәт кешеләр, матур, тату яшиләр. Бердәнбер бала әнә нинди фаҗигага дучар була, хәзергеләр бер дә итәк тутырып бала үстермиләр шул. Син кияүгә чыксаң, кара аны, бер бала белән генә калма, Каракүз. Гаилә күрке — балада, ди халык.

Юлия Борисовна шулай диюгә, Кәримә колакларына чаклы кызарына, ни сәбәпледер аңа оят булып китә.

— Ә син оялма,— ди аңа Юлия Борисовна.— Хатын-кызга бала табу оят түгел, тапмау оят.

«Нигә соң үзегез, Юлия Борисовна, бер бала да тапмадыгыз?» — дип сорыйсы килә Кәримәнең, әмма яхшысынмый, дәшми кала...

Кәримә сумкасын өстәленә куя һәм аяк киемен салып, апасы йоклап яткан бүлмәгә уза һәм әле булса торырга иренеп яткан Зөлфиянең өстеннән юрганын сыдырып ала.

— Тор, җитте сиңа, йокы симертеп ятма!

— Инәки, күр әле бу тилекәеңне,— дип чырылдый Зөлфия һәм яңадан юрганын ябынмакчы итә.

— Ярар инде, кызым, тор инде. Күпме ятсаң да йокы туймас ул, йокының нәзере юк,— дия-дия йокы бүлмәсенә әнисе килеп керә. Зөл-

фиянең аркасыннан сөя-сөя, күтәреп диярлек караватына утырта, аягына чүәкләрен кигезә.

— Ими дә бирмисеңме үзенә, инәки,— дип кала аның артыннан Кәримә.

Ләкин аңа Зөлфия дә, әниләре дә бер сүз дә әйтми.

Юынып керә дә Зөлфия караватына утыра һәм кулына Мопассан китабын ала. Кәримәнең янә җен ачуы чыга.

— Иртә таңнан Мопассанга ябышмасаң да ярыйдыр. Бир минем китапны,— дип ул апасы кулыннан китапны тартып диярлек алып куя.

— Подумаешь,— ди Зөлфия, исе китмәгәндәй, күзгә каршына утыра, бизәнергә тотына.— Беләсең килсә, Кәримәкәй, Мопассан үзе дә бөрәк итен ашап яшәүчеләрдән булган. Мин шул чорда яшәсәмме, күрсәтер идем мин аңа...

— Ялгышма, наданлыгың күрсәтмә, язучы андый булмаган, ул шул чорның социаль чынбарлыгын сәнгатьчә сурәтләп кенә биргән.

— Акыл сатма. Бу хәтле мөрит булырсың икән, сеңелкәем. Болай булсаң, сине бер егет тә яратмаячак.

— Яратмаса. Ә мин алардан яраттырырга җыенганым да юк әле.

— Юк ди бит әле җитмәсә,— дип торып, киерелеп-сузылып алды Зөлфия.— Әчке нәфислек житенкерәми сиңа, апаем.

— Синеке артыкмы әллә? Бар әле, чык бүлмәдән, мин тарихны кабатлыйм.

— Тарих та булдымы фән.

Шул чакта ишектә Юлия Борисовна күренде.

— Исәнмесез-саумысез, нигә кәҗә саумыйсыз. Әйтегез: Кәҗәбез бар, сөте юк, нигә сыер алмыйсыз? Шулаймы, кызлар. Каяле, кая, җырчы кызыбызга күз салыйм. Әйбәт йоклагансың, бит-чыраең саф. Артисткага ул бик кирәк сыйфат, йокы туймаса чырайда төс булмый, аны һичнинди грим белән дә китерә алмыйлар. Артист булу бар кешегә дә килешми ул, Зөлфиякәй. Кызганыч, концертыңа бара алмыйм. Мәгәр ышанам, йөземә кызыллык китермәссең. Менә нәрсә, Каракүз,— дип Кәримәгә таба борылды Юлия Борисовна.— Минем өчен син бар. Имтиханыңны биреп өлгерәсең, бишле алырыңа мин ышанам. Әйт, барасыңмы апаң концертына?

— Юлия Борисовна, әйдәгез чәйләп алыйк,— дип килеп керде әниләре.

— Рәхмәт, Гөлбикә, яңа гына өстәл яныннан тордым.

Кәримә бер сүз дәшми кухня ягына уза, өстәл янына утыра, духовкадан омлет бүлеп ала, берүзе ашый башлый. Аның ачуы чыга, әнисенә үпкәли. Нигә Зөлфия дә Зөлфия, Кәримә дә бүген соңгы имтиханын бирә ич. Кызның күзләре яшь белән тула. Шунда әнисе керә һәм:

— Кызым, апаңа да омлет салып бирер идең,— ди.

Кәримә дәшми, башын тагын да ия төшеп ашавын белә, күз яшьләре бәреп чыга. Әнисе аның елап утыруын күрми.

— И-и, бала-бала,— дип сөйләнә-сөйләнә духовканы ача әнисе, тарелкага омлет бүлеп сала һәм өстәлгә куя.— Апаң бүген беренче концертына бара, кәефен бозмасаң иде, балакай.

— Ә мин соңгы имтиханга барам, инәки!

— Бәй, шулай бит әле, гел онытып торам тагын. Юлия Борисовна,— дип кычкыра әнисе кухнядан.— Килегез әле бире. Минем кече кызым да сынауга бара бит бүген.

— Каракүзгә мин ышанам, сынавын бишлегә бирер. Зөлфия өчен кайгырам мин. Тамашачы алдына беренче тапкыр чыгу уен эш түгел ул,— дип Юлия Борисовна өстәл янына утыра, көйләп куйган чәйне эчә башлый.— Үзең ашадыңмы соң әле, Гөлбикә?

— Ашадым-ашадым, хәзер менә бергәләп чәй эчәрбез.

Ул арада Зөлфия дә кереп Юлия Борисовна янәшәсенә утырды. Карт артистка аның иценнән кочып, иркәләп, коңгырт төскә буялган чәченнән сыйпап алды.

— Иң мөһиме каушамау,— диде ул ашап утырган Зөлфиягә.— Мин ышанам сиңа, балакай. Син әле зур-зур конкурсларда катнашырсың. Ләкин беренче концерт тәэсире барыбер күңелеңдә мәңге сакланыр.

Кәримә калак-тарелкаларын кирәгеннән артык шалтыратып, юарга илтеп куя. Аның бу кыланышына әнисе дә, Юлия Борисовна да игътибар итәләр, әмма күзгә-күз карашудан битәр сүз әйтмиләр.

— Миңа төнгә эшкә, Юлия Борисовнага ерак йөрергә ярамый. Имтиханыңны биреп кайткач концертка син барырсың инде, кызым, Кәримә дим! — диде әнисе.

Кәримә дәшми, шалтыр-шолтыр савыт-саба юа.

— Кәримә, сиңа әйтәм түгелме?!

— Инәки,— ди Кәримә үртәлеп.— Әллә имтиханны бирә алам, әллә юк. Бармыйм, мин болай да аның тавышыннан гарык. Атаклы җырчы, талант...

Ләкин әнисе тавышын күтәрмәде, сабыр гына:

— Мин сиңа ышанам, кызым. Синдә атаң сабырлыгы бар, атаң үҗәтлеге бар, бирерсең имтиханыңны,— диде.

Кәримә имтиханга сәгать икегә барырга тиеш, ул бераз хәзерләнгәч, йөреп керергә дип һавага чыкты. Күк йөзе чалт аяз, көн июнь аеның бөтен хозурлыгын үзенә җыйган диярсең, кояш назлап кыздыра, өй каршындагы тупыл яфракларыннан әчкелтем хуш ис тарала, гадәттәгечә күрше өй подъездындагы эскәмиядә таныш егет утыра. Ул китап укый иде, әмма Кәримә подъездан килеп чыгуга, китабын бер читкә куеп, кызга карап тора башлады. Кәримә аны күрмәмешкә салыша, эченнән генә тарих билетларын кабатлый. Ни өчендер тарих фәне аңар һәрчак кызык булды. Әллә инде абый кеше укытканга. Җитмәсә укытучы абыйлары кай ягы белән дер этисенә охшаган иде. Аны тыңлавы үзе бер дөнья, үзе бер сәяхәт. Тарих ул — тормышның үзе ди укытучы абыйлары. Аның дәресе җиттеме, Кәримә куанып бетә алмый. Сораулар хәзерли. Классташ кызлары аңа: «Интектермә инде юк-бар сораулар белән Салих абыйны»,— диләр. Кәримә аларга Салих абыйсы сүзләре белән: «Тарих кешене дөньяда гадел итеп яшәргә өйрәтә»,— ди.

Имтиханны ул чынлап та бик җиңел бирде, беренче булып керде, беренче булып бишле билгесе алып чыкты. Өйгә канатланып кайтып керде. Зөлфия концертка хәзерләнә, әнисе эшкә китәргә җыена, шаулап килеп кергән Кәримәгә ул:

— Тс-с, апаң хәзерләнә,— диде.

Кәримә тирән сулыш алды һәм:

— Их, инәки,— дип, түр бүлмәгә узды.

Берүзе бер бүлмәдә калгач, ул иркенләп сулап куйды, тәрәзә каршына килеп басты, баюга таба тәгәрәгән кояшны күзәтә башлады. Имтиханнан соң алар класслары белән «Ял» кафесына кереп мороженый ашадылар, мәзәкләр сөйләделәр, көлештеләр; кайгылары таралган, бер гамьнәре дә калмаган иде, шунда аларның чыр-чу килүләрен күреп, бер апа:

«Көлешеп калыгыз, балалар, иртәгә үк башыгызга кайгы төшәчәк. Кая укырга, кайсы заводка эшкә барырга... Күз яшьсез дә булмас. Көлешегез-көл, көлешеп калыгыз»,— дигән иде.

Апа хаклы, дип уйланды Кәримә, минем дә башка уй төште: ничек сиздерми генә Алабугага китеп барырга?

Күрше бүлмәдә Зөлфия шыңшына, жырламый да, нәкъ менә шыңшына, бүлмәдә биклән калдырылган ялгыз көчек диярсең. Ул да түгел ниндидер көйгә җырлап җибәрә, аны ташлый да икенчесен башлый. Кәримә аны тыңлый да, тыңламый да, аның үз хәле хәл, тиздән кулына өлгергәнлек аттестаты алыр, кай тарафларга китәргә?.. Күңеле белән ул әллә кайчан инде Алабуга милиция мәктәбендә. Ләкин аның бу турыда беркемгә дә әйткәне юк, әйтмәс тә, бу бары тик аның сере һәм аның сере булып кына калыр. Бүген иртән әнисе аның янә ачуын китерде, әмма ул инде әнисен гафу итте, рәнҗеми. Ә шулай да күңелдә юшкыны калды. Әллә бар, әллә юк Кәримәсе, кече кызын тәмам күрмәс булды әниләре. Һич югы күңел өчен: «Кызым, ничегрәк укыйсың?» — дип сорасын иде. Шуңа әйтми китәчәк Кәримә әнисенә, кече кызында гаме булмаган өчен. Яшәсен әнә Зөлфиясе белән. Әлбәттә, ул качып китмәс, нинди дә булса язу калдырыр, ә бәлкем калдырмас та әле...

Кайчан килде соң әле Кәримәгә милиция мәктәбенә укырга керү теләге? Хәер, ул моңа үзе дә кисәк кенә җавап бирә алмас иде. Бу теләк анарда кыш көне мәктәпкә килеп чыгыш ясаган хатын-кыз милиция лейтенантын күргәч туды бугай. Лейтенант өстендә килешле итеп тегелгән күксел-зәңгәрсу төстәге форма, башында шул төстәге берет, күкрәгендә «Батырлык өчен» дигән медаль иде. Милиция лейтенанты Әкълимә Сиражиева ниндидер каракларны тотуда катнаша, батырлык күрсәтә. Шул турыда сөйләде. Ул шактый катлаулы операцияләрдә катнашкан икән инде. Мондый хәлләр турында сирәк ишеткән укучылар милиция лейтенантын тын да алмый тыңладылар. Чыгыштан соң аңа Кәримә сорау бирде. Милиция лейтенантына кайда укып була? Нәкъ шул сорауны биргән өчен җор телле классташ егетләре лейтенант дигән кушамат тактылар аңа. Сәер хәл, Кәримәнең моңа мыскал да ачуы килмәде, киресенчә, кем дә булса, кемне дә булса нахакка рәнҗетсә, араларга керде һәм этәчләнүчеләрне гадел итеп хөкем итте. Милиция мәктәбенә барырга ниятләвенең икенче сәбәбе, бәлкем әле иң төп сәбәбедер, этисенең шунда укуы, күпмедер вакыт укытуы да иде. Дөрес, ул анда күп эшләмәгән, Казанга күчергәннәр, әмма барыбер Кәримәгә этисенең анда укуы һәм эшләве кызның ниятен акларга бер сәбәп иде.

Кәримә бүлмәсенә Юлия Борисовна керде.

— Сезгә кузгалырга вакыт, кызлар,— диде ул, нигәдер Зөлфиягә түгел, Кәримәгә төбәп.— Җыена башла. Артист соңга калса мең кешенең кәефе кырыла, пешекче соңга калса йөз кеше ач кала, чәч кыркучы соңга калса, нибары бер кеше поп була, ди торган иде минем ирем. Николай Юрьевич концертка соңга калуны свиданиегә соңга калу белән бер күрә иде.

Сәер кеше дә соң бу Юлия Борисовна. Гомер буена бер тапкыр кияүгә чыга, гел шуның белән яши, ярatканы, өзелеп сөйгән егете яшьли үлә, әмма бар хатирәсе гомер иткән ире турында булмас, шул егет турында булыр. Бер тапкыр шул турыда сорагач: «Син аңа бер дә шаккатма, Каракүзкәй, хатын-кыз өчен үз иреннән дә кадерле кеше юк, мәгәр яшьли сөйгәннәр яхшы төш кебек һәрчак истә калыр. Хатын-кызга ир кадерле, чөнки ул аның юлдашы гына түгел, кайгыртучысы, бердәнбере».

Ул арада Зөлфия дә киенеп, хәзерләнеп бетте.

— Инде китәбезме? — дип килеп керде.

Юлия Борисовна аларны подъезга кадәр озата чыкты.

— Каушама, иркен тот үзеңне, ишетәсеңме, Зөлфия,— дия-дия озата калды Юлия Борисовна җырчы кыз белән Каракүзне.

— Подъезд төбендә утыручы егетне күрдеңме, Кәримә? — дип сорады Зөлфия, тукталышка житәр-житмәс.

— Күрдем. Инвалид икән бит ул. Әллә беләсеңме син аны?
— Юк,— диде Зөлфия ашыга төшеп.
Троллейбуска утыргач, кемдер аларга урын бирде, танышы егет икән.
— Һәлло, Барый,— диде Зөлфия.— Син кая болай?
— Синең концертыңа. Афишаңны күрдем дә. Бер сәгатькә якын чират торып билет алдым.
— Шыттырма. Беренчедән, концерт минеке генә түгел, мин катнашам гына бу концертта, икенчедән, синдәй егеткә, әйтеп куйган булсаң, чакыру билеты җибәргән булыр идем.
— Мин сине бу кадәр юмарт, дип уйламаган идем, Зөлфия. Хәтереңдәме, бишенче класста укыгандамы шунда, алтынчыдамы, сез кышкы каникулга бабаларыгызга кунакка килгәч, ике якка бүленеп кар атышлы уйнаган идек. Беләсең килсә, бу сеңелеңә мин шул вакытта ук әсир төшкән идем инде. Оныткандыр да инде үзе ул хәлләрне.
Кәримә озын буйлы егеткә күтәрелеп карарга да оялып утырды. Чынлап та, нәрсәдер Кәриманең дә хәтерендә. Кар атышып уйнадылар, аннары дошман ягындагы бер егет алар ягына әсир төште.
— Барый, син телефон сузучы булырга укыйсыңмы?
— Нишләмәк кирәк, берәүләр кешеләрнең йөрәкләрен йөрәк белән бәйләү өчен телефон суза, син, әйтик, җырлап күңелләрен ачасың. Кәриманең кем булырга исәбе инде? Ялгышмасам...
— Ялгышмыйсың, Барый — песи тәпиен ялый, бүген соңгы имтиханын биреп кайтты. Аттестатлы кыз ул хәзер, булачак врач.
— Врач,— дип гаҗәпләнгәндәй итте Барый.— Менә диген һөнәр, иң изге һөнәрләрнең берсе.
— Слушай, Барый, безнең күрше карчыкка да телефон кертергә иде бит.
— Нигә, була ул. Әйтик, сиңа atказанган артистка исеме бирелү чамаларына кертәбез аны.
— Нахал булдың, Бoрау, нахал булып калырсың да.
— Тәрбия чамалырак булды шул, шайтан алгыры.
Тукталышка җитүгә, Зөлфия Кәриманең кулыннан алды.
— Әйдә тизрәк,— диде ул.— Минем аның белән барасым килми.
Зөлфия троллейбустан төшкәч тә тынычлана алмады.
— Техникумда укый. Неудачник. Беләсең килсә, ул минем белән консерваториягә кереп караган иде. Хәсрәт. Тамак ертып җырлый, җыр кадерен белмәгән ахмаклар утыра ди анда. Моңа караганда Котбые мең өлеш артык. Анысы хет ухаживать итә белә. Гел бергә дә, гел бергә йөриләр иде, нигәдер тегесе күренми бүген.
— Котбый һаман сине озата йөриме?
— Озатса ни. Бетәсеме хулиганнар хәзер. Саклый апаңны. Бүген юк, зато икенчесе килгән.
Троллейбустан төшкән халык арасында буталыбрак калган Барый аларны куып та җитте.
— Карале, Зөлфә, юкка качкан буласың. Бүген Котбыең юк, озатып куйган була идем үзеңне.
— Син мине озатма, Барый, мине бүген машина белән илтеп куячаклар, әнә сеңелемне озат...
— Сез дигәндә мин — идәндә.
— Мин үзем дә юлны беләм,— диде Кәримә, апасының тәкъдимен ошатмыйча.
— Тик тор,— дип, Кәриманең кулыннан тартып куйды Зөлфия.— Озатсын. Карале, Барый, телисеңме, мин сезне бергә утыртам...
— Миңа да бер изгелек эшләрсең микәнни, Зөлфә...
Зөлфияне ишектән үк каршы алдылар. Сары чырайлы, житен чәчле, кирәкмәгән зур борынлы егет Зөлфияне култыклап та алды.

— Зөлфия, сине режиссер көтә.

Зөлфия Барый кулына чакыру билеты тоттырды, карашы белән генә Кәримә сеңелесе ягына таба ымлады. Барый белән Кәримә залга кереп киттеләр, чакыру билетында күрсәтелгән урыннарына килеп утырдылар. Халык җыела башлаган иде инде. Алар янәшәсендәгеләр пышын-пышын сөйләшәләр. Кәримә дә, Барый да су капкандай тик утыралар. Кая ул күзгә-күз карау яисә сөйләшү. Кәримәнең бу «Төзүчеләр сарае»на икенчеме, өченчеме генә тапкыр килүе. Хәтерендә, беренчесе Яңа ел чыршысында булды. Бәйрәмгә алар дәртәүләп килделәр. Зөлфия апасы ялтыравыклы уенчыклар белән бизәлгән чыршы янына чыгып җырлады. Аңа Кыш бабай уч тутырып кәнфит бирде, нигәдер Зөлфия апасы ул кәнфитләрне Кәримәгә китереп биргән иде. Кәримәнең әтисе янында басып торган бер апа: «Менә ичмасам тәрбияле бала»,— дигән иде. Кәримә аңа: «Апаның теше сызлый, аңа кәнфит ашарга ярамый»,— диде. Олылар көлештеләр, әтисе Кәримәнең аркасыннан сөйде, Зөлфия апасы әнисе белән янәшә басып тора иде. «Минем тешем сызламый, кәнфит тамагыма ярамый»,— диде. Әнисе шунда, үрелеп, Кәримәнең беләген чеметеп алган иде.

Икенче тапкыр унынчы класста укыганда булды, былтыр гына әле. Аларны күренекле шагыйрь кичәсенә мәктәпләре белән алып килделәр. Ул вакытта Кәримәгә бу зал, сәхнә гаять зур булып күренгән иде, хәзер исә әллә үзе дәү үсте, әллә зал шулай кечерәйгән — бөтенләй үзгәргән сыман. Шушы сәхнәгә чандыр гәүдәле шагыйрь чыгып баскач, ул бөтенләй бик кечкенә булып күренгән иде. Соңыннан коридорда автограф алырга янына килгәч, кечкенә буйлы шагыйрь аның күз алдында үсеп, зураеп киткән кебек күренгән иде. Кәримә ул автографлы китапны кат-кат укып чыкты, хәтта кайберләрен яттан да өйрәнгән иде...

Өченче кыңгыраудан соң зал тынып калды. Сәхнә ачылды. Сәхнә уртасына сүз остасы чыгып басты. Ул ашыкмый гына залга күз йөртеп алды да тамашачыларга сәламен җиткерде. Кул чаптылар. Кәримә беренче җырчыны рәтләп тыңлый да алмады. Консерваториядә укучы егет болай моңлы гына җырлады сыман, әмма ни сәбәпледер кул чаблар бик сыек чыкты. Җырның соңгы өлешен артык суза төште бугай ул. Халык бит ул табигыйлекне ярата, ә монда җырны үзенчәрәк ясарга тырышты кебек җырчы. Апасы бу җырны бер дә алай башкармый торган иде. Кәримәгә апасы бу егеттән күп тапкыр моңлырак, матуррак җырлый сыман, шуңамы, ул тизрәк аның җырлавын теләде. Бәлкем аның апасы кабатланмас талантлы җырчыдыр? Ә нигә?! Күрче никадәр тамашачы җыелган. Кемне тыңларга җыелганнар?.. Аның, Кәримәнең апасын.

— Зөлфия апаң чыга, аның чираты,— диде әлегә кадәр сүзсез утырган Барый.— Матур җырлый апаң. Сандугач та сандугач, ул да сандугач. Кодрәтемнән килсә, мин аны гел җырлатып кына тотар идем.

— Кеше түгел, сандугач та гел сайрап тормый.

— Сандугачларны көнләштерердәй итеп моңлы җырлый синең апаң. Шул сәләте янына ходай аңа акылны да кызганмаган булса...

— Минем апа җүләр түгел.

— Анысы хак. Горур ул, артык горур.

Күксел-соры күзле, озынчарак йөзле, аксыл-сары чырайлы, кай ягы беләндер һинд егетләренә охшаган Барый, апасы әйткәнчә бер дә тупас кешегә ошамаган иде. Бер мәлдә Кәримәнең аңа хәтта ягымлы итеп сүз әйтәсе, сөйләшәсе килеп китте. Ни өчен ул аңа кисәк кенә ошап китте соң әле?.. Бик күп еллар элек бу егет Кәримәгә үзе теләп әсир төшкән иде, хәзер исә Кәримәнең аңа әсир төшәсе килеп китте. Ни өчен?.. Юк-юк, ни уйлап утыра ул, җүләр баш.

Кәримә егетнең ияк очындагы чокырга, озын керфекләренә игътибар итте. Келт итеп Кәримәнең исенә «Барый — песи тәпиен ялый» төште. Кар атышлы уйнаганда аның яклы малайлар Барыйны шулай ирештерәләр иде. Котбыйны ничек үртиләр иде соң әле?.. Котбый — безне тотмый, капкасыннан чыкмый, Котбый — безне тотмый, капкасыннан чыкмый... Ә малай-шалайдан өч-дүрт яшькә зуррак булган Котбый малайларны куып китеп берсен булса да тота иде дә, колаклары кызарганчы тегене кар белән уа иде. Шунда малайны якларга гел Кәримә ташлана иде һәм, әлбәттә, ни сәбәпледер Котбый малайны шундук җибәрә, бер якка да катнашмыйча бер читтә басып торган Зөлфия янына китеп бара иде.

— Димәк, врач булырга исәп, Кәримә?

— Кем булсам да сезгә барыбер түгелмени?

— Гафу итегез, апагыз дип белүем. Без аның белән «син»ләп... Минем апагыз белән түгел, сезнең белән дуслашасым килә. Зөлфә минем белән дорфа сөйләшә, аңа карап мин дә,— егет Кәримәгә иелә төште, Кәримә аның хәтта кайнар сулышын битендә тойды.— Риза булсагыз, менә минем кул, — кыз алдына кулын җәеп салды Барый.— Мин сезгә тагын бер тапкыр әсир төшәм. Онытмагансыздыр шәт?.. Юкмы?!

Кәримә көлемсерәп аска карады, ул да нәкъ шул турыда уйлый иде түгелме соң.

— Әсир кеше — ким кеше, дегет ләгәненә тиң кеше, ди безнең бабакай.

— Мин бит дошманыма әсир төшмим, йөрәгемне әсир иткән кешегә төшәм...

— Әйтегез әле, Барый, Зөлфия апа Котбый белән чын-чынлап йөриме?..

— Белмим. Мин хәзер Котбыйны сирәк күрәм. Кайчандыр без дуслар идек. Бер хикмәтле хәлдән соң мин аны яратмый башладым.

— Нинди хикмәтле хәлдән соң? Сез бу турыда миңа сөйләрсезме?

— Чын-чынлап дуслашып китсәкме. Чын дуслардан яшерә торган серем юк минем.

Ниһаять, сәхнәгә Зөлфия чыгып басты, халык ара-тирә генә кул чапты. Барый Кәримәнең колагына иелә төшеп:

— Белмиләр әле апаңны, тыңлаганнары булмаган. Бер белсәләрме, гөрләтеп кул чабып каршы алачаклар,— диде.

Кәримә, Барыйның сүзләре белән килешеп, кул чапты, берочтан егеткә, ризалыгын белдереп, ияк какты. Күрче берәүне, өйдә җырыуены белән туйдырып бетергән Зөлфия апасы өчен ни тамаша кайгырып, дулкынланып утыра. Үз кыланышына үзе гаҗәпләнде Кәримә, әмма барыбер дулкынлануын җиңә алмады. Апасы җыр башлауга, ике куллап утыргыч терәгенә ябышты. Зөлфия кызыл панбәрхет күлмәк кигән. Бу күлмәк алар семьясына әниләренең айлык хезмәт хакына төште.

Ниһаять, Зөлфия җырлый башлады. Бераздан башын алгарак сузып, куллары белән артыграк җилләнә төшеп, йөзендәге мимиканы кирәгеннән артык уйнатыбрак җырлаган апасын күрми башлады Кәримә, хис ташкыны үз арбасына утыртып Ык елгасы буена алып китте аны. Күңеле белән ул әрәмәлектә, ямьле Ык буенда йөри иде инде, болында чәчәкләр җыя һәм, иң гаҗәбе, янәшәсендә кемдер бар сыман. Кем? Әлбәттә инде бабасы. Күрче, алар арбада баралар икән бит, бабасы вак-вак атлап юыртып баручы кола биягә: «На-на, малкай!» — дип йомшак кына дәшеп ала. Күкнең зәңгәрлегеннән, һаваның сафлыгыннан баш әйләнмәле, җитмәсә тургай сайрый, басу өстендә рәшә тибрәлә, җете ал чәчәге белән бал кортларын кызыктырып утырган шайтан таягында сары чәберчек сайрый — җыр тыңлаганда бо-

ларның һәммәсе бик тиз алышынып, Кәримә өчен гүя татлы бер төш булды. Кешеләр кул чаба, ә Кәримә, күз алдындагы сурәтләргә әсир төшеп, утыра бирә. Мона хәтта янәшәсендә утыручы Барый да игътибар итте... Апасы икенче җыр башлады, Кәримә исә күңеле белән һаман авылда. Алар бабасы белән чишмә буенда икән. Сусаганнар. Бабасы да, ул да уч тутырып салкын су эчәләр, тешләр камаша, ә бер читтәрәк кола бия башын чайкый-чайкый чебен-черки куа. Кәримә сәхнәдәге апасын да, пианинода уйнаучыны да онытып хәтер сурәтләренә кереп чумган иде. Җыры да «Салкын чишмә» булган икән. Кәримә, халык янә гөр килеп кул чаба башлагач кына исенә килеп, кул чаба башлады. Янәшәсендә утыручы Барый янә моңа игътибар итте.

Концерттан соң алар һавага чыктылар, халык агымы белән троллейбус тукталышына килделәр. Шул араны үткәнче бер-берсенә ике авыз сүз әйттеләр микән, юктыр. Барый, ни сәбәпледер, кинәт үзгәрде, җитдиләнде, Кәримәне егетнең бу хәле кызыксындырса да сорашырга базмады.

Бәлкем, нәкъ менә шул хәл Кәримә күңелендә бу егеткә карата үзе дә аңлап бетермәгән хис дулкынын кузгатып җибәргәндер. Сәер, ни өчен апасы Барыйны түгел, аның дусты Котбыйны сайлады микән? Кинәт аның апасы тарафыннан кимсетелгән бу егеткә ниндидер изгелек эшлисе килеп китте. Тик ул изгелекне ничек эшләргә? Шулай уйлана-икеләнә атлый торгач, алар Кәримәләр подъезды янына җиттеләр. Кәримә ничек тә егеткә якынрак басырга тырышты, ләкин үз хәрәкәтеннән үзе үк куркып, шундук читкә тайпылды, караңгы булса да, колакларына хәтле кызарынды.

— Гафу итегез,— диде Кәримә, акланырга теләп.

Барый аның бу хәрәкәтен күрмәмешкә салышты.

— Шунда торасыз мени инде?

Көтмәгәндә Барый аның кулыннан тотты. Кәримә егеткә күтәрелеп карарга оялды, киресенчә, читкәрәк тайпылырга теләп, кулын тартып алмакчы итте. Әмма тәүге теләге барыбер җиңде. Ни әйтер икән? Ни әйтә икән егетләр кызлар кулыннан алгач? Кул, әсир төшкән кебек, егет кулында калды, Барый һичбер сүз катмый тора бирде. Кәримә тынычлана төште, Барыйны ут яктысынарак тартты. Әсир төшкән кул артыннан Барый яктыгарак күчте, ләкин кызны өенә кереп китәр дип куркыпмы, кулны ныграк кысып алды. Кәримә: «Ой!» дип кычкырып җибәрде һәм кулын тартып алды.

— Сез дә апагызга охшагансыз икән.

Кәримә түшен киеребрәк басты, кызның күңеленә горурлык хисе килеп тулды.

— Ә кемгә охшарга тиеш соң мин? Сезнең әнигезгәме, әллә булмаса сеңелегезгәме?

— Юк, мин бөтенләй алай дип әйтергә теләмәгән идем. Гафу итегез, каушаудан бу. Ышаныгыз, сез бөтенләй башка, апагызга бөтенләй охшамагансыз.

Кәримә дәшмичә тора бирде.

— Зинһар, үпкәли күрмәгез тагын. Менә бу арада гаять кыен. Вөҗдан газабы кичерәм мин. Була бит шулай, ниндидер яман эш эшләп ташлыйсың да, шул хәл күз алдыңа килгән саен, вөҗдан газабы кичерәсең. Менә шул нәрсә әзәрлекли мине бу көннәрдә.

— Ә сез эч серегезне бушатырдай дуслар табыгыз.

— Чын дуслар юк шул менә. Чын дуслар табу мәхәббәт табудан да кыенрак, диләр бит. Инәй шулай ди минем. Иртәме, соңмы мәхәб-

бәт килер ул, ә менә чын дусларны кайберәүләр үз гомерләренә таба алмый интегәләр, ди.

— Бәлкем, әниегез хаклыдыр да. Миңа калса, яхшы кешегә дуслар табу кыен түгелдер сыман.

— Киресенчә, яхшы кешегә дуслар табылмый, Кәримәкәй.

— Нигә сез миңа алай дисез? Нигә ул «кәй»?

— Буйга кечкенә кеше үзен кечерәйтеп әйтүдән курка, диләр, хак икән.

— Мин курыкмыйм, шулай да... Сез менә вөҗдан газабы кичерәм дидегез. Вөҗдан газабы кичерү әйбәт сыйфат ул. Димәк, сез начар кеше булмаска тиешсез.

— Укытучыгыз шулай диме?

— Мине сабый итеп күрергә теләвегезме, әллә булмаса үзегезне акыл иясе итеп күрсәтергә исәбегезме?

— Юк-ла, зинһар дөрес аңлый күрегез, күңелем саф минем. Яшь чактагы дусларымны югалттым. Ә яңаларын табу елдан-ел кыенлаша бара.

Ул яңадан Кәримәнең кулыннан алды. Кызның күңелендә бу мәлдә ике тойгы дулады: беренчесе, аңа гаять дәрәҗәдә рәхәт булып китте, икенчесе, моңа кадәр үзе дә төшенеп җитмәгән горурлык хисе уянды аңарда. Гаҗәп икән бу горурлык дигән нәрсә. Буең кечкенә булса да кинәт үсеп китәсең, синең каршыңдагы сорнай буйлы егет гел кәрлә булып кала.

— Миңа вакыт,— диде, ниһаять, Кәримә. Барыйның йөзендә канәгатьсезлек билгесе күреп.— Вакыт,— дип кабатлады һәм үзе: «Тагын ниләр булыр икән», дип уйлады.

— Биш минут кына түзегезче, зинһар.

— Нигә инде, зинһар, нигә зинһар түгел?

— Минем сезне җибәрәсем килми, Кәримә.

— Ә минем китәсем килә.

Кәримә үзе алай дип уйламый, бу аның горурлыгы шулай сөйли иде.

— Мин иртәгә сезгә шалтыратам.

— Безнең телефон юк. Бар, ләкин нигә кирәк ул?..

— Әйдә «син»гә күчик, Кәримә?

— Ярый соң,— дип, җилкә җыерып куйды кыз.

— Мин сиңа һәркөн иртән шалтыратырмын.

— Башта син күршебез Юлия Борисовнага телефон керт.

— Егет сүзе бер булыр, кертермен дә...

— Мин китим инде.

— Кәримә, мин сине эзләп-эзләп тә таба алмасам...

— Табарсың. Егет мин, диден ич.

Бишенче катка менгәндә дә, өйгә кергәч тә, нидер исенә төшеп, Юлия Борисовналарга юнәлгәч тә Кәримә тиз генә тынычлана алмады. Гүя аяк астында җир юк иде, гүя аңа канатлар үскән иде.

— Юлия Борисовна, Юлия Борисовна, мине бер егет озатты. Ул сезгә телефон кертәчәк. Ышандырды, вәт...

Ишекне ачкач ук кыз йөзендә гадәти булмаган шатлык галәмәтләре күреп, аптырабрак калган Юлия Борисовна, үзе дә бик еракта калган яшьлеген исенә төшереп, көлемсерәп куйды.

— Шатлык өләшкән җирдә булган бу, бер дә бүтән түгел. Кер-кер, түрдән уз, хәзер чәй куеп җибәрәм, аннары барысын да берәмләп сөйләрсең. Зөлфия апаң, Зөлфия апаң ничек җырлады?

— Во! — диде Кәримә, имән бармагын тырпайтып. — Ярты сәгать кул чаптылар.

Үз гомерендә бик күпне күргән пенсионер карчык унҗиде яшьлек кызның илаһи шатлыгына чын күңеленнән куанды. Юлия Борисовнаның яңа чәчәк атып килгән кыз балага әйтәсе сүзе бар, шуңа күрә ул Кәримәне тизрәк өстәл янына әйдәде. Өстәлгә бал, вареньe, печенье, чак-чак китереп куйды.

— Чәй эч, аша, житеш һәм сөйлә.

Юлия Борисовна ихлас күңелдән, әмма бераз моңсулана калып, Кәримәне тыңлады. Яшь кызның дәртләнеп, күзләрендә очкыннар уйната-уйната Зөлфия апасы турында сөйләве, бигрәк тә озын буйлы Барый атлы егетнең үзен ничек өйгә кадәр озатуы, Юлия Борисовнага телефон кертергә вәгъдә итүе, һәркөн шалтыратып торачагы турындагы хикәяте ошады карчыкка. Атаклы җырчы Юлия Борисовна Каменская яшь чагында үзе дә берәүне генә яратты. Сабыр холыклы, бухгалтер булып эшләүче оялчан егетне. Ни өчен нәкъ менә Николай Кабушкинны? Бер алла үзе белә. Интуиция. Начар яшәмәделәр. Дөрес әйткәннәр дә соң борынгылар: ир сайлый белмәгән хатын, рәтле гомер дә итә белми дип. Бу мәсьәләдә хатын-кызда гасырлар буена канына салынган сиземләү булырга тиеш, аннан мәхрүм хатын-кыз яхшы гаиләдән дә мәхрүм.

«Их, Кәримәкәй-Каракүзкәй, бу әле синең мәхәббәт тылсымына кагылып кына китүеңдер. Килер бер көн, шушы коры куанычка корылган мәхәббәтең гел курчак уены булып кына калыр, барысын да күмеп, каплап китәрдәй чын мәхәббәт килер, ә ул, Каракүзкәй, еллар үтә-үтә генә, тормышта тәҗрибәң үсә-үсә генә килә. Шул чордагы мәхәббәтнең кадерләрен белсәң икән, мәңгеләштереп булса икән шул мизгелләрне! Әйе, мәхәббәт ул, Каракүзкәй, дөньядагы иң изге, иң саф хис. Ул бик сирәк кабатлана, кабатланган хәлдә дә ниндидер дәрәҗәдә яңара гына ала. Ә миңа ул бәхет, Каракүзкәй, очар кош сыман, унҗиде яшемдә килде. Мин дә синең кебек үк хыялга бай кыз идем. Яшь чакта без барыбыз да хыялга гаять дәрәҗәдә бай булабыз. Ләкин тормыш дигәнең синнән һәрчак корбан таләп итә. Мин сәнгать кешесе идем, күп нәрсәне корбан итәргә туры килде, синең апаң да әнә шул юлдан китеп бара. Җиңел булмас аңа. Күп хыялларын корбан итәргә туры килер. Сиңа ул килмәс, син — башка. Син менә дигән гаилә кора аласың. Ә чын артистларга ул — йөк, бик авыр йөк. Мин башта: «Өлгерермен әле» дип йөрдем, аннары курка калдым. Шулай үз гомеремә берьялгызым калсам? Бу уйлану миңа курку салды һәм мин Николайга кияүгә чыктым. Мин аңа бик теләп, яратып чыктым, Каракүзкәй. Әмма безнең балабыз булмады. Башта мин үзем теләмәдем, аннары соң иде инде. Шулай гомер узды. Менә хәзер сиңа карап торам, Каракүзкәй. Апаң да, син дә минем куанычым, юанычым булып киттегез. Бигрәк тә апаң. Мин аңа бөтен артистлык тәҗрибәмне бирергә тырыштым. Һәм мин моңа ирештем кебек. Аның бүгенге җыры, халыкның аны алкышлап каршы алуы артист өчен зур бәхет ул, Каракүзкәй. Гафу ит, мин сиңа бер ягым белән дә үрнәк була алмыйм. Синең әле алсу иреннәреңә күбәләк тә кунмаган, син әле сабый, бары тик сабый гына. Зөлфия апаң башка, Зөлфия язмышы — минем язмыш. Минем язмышка тәңгәл үк килмәс, әмма охшаш булыр. Чөнки артист кеше бу дөньяны бөтенләй башка күзлектән күрә, бөтенләй башка юнәлештә фикер йөртә, хәтта күзаллавы да башкачарак аның...»

Истәлекләрен бер якка куеп, Юлия Борисовна кызны чәй белән сыйлый башлады.

— Эч әйдә, миңа, карчыкка, карап утырма, миңа тәңгә каршы чәй ярамый. Әнә вареньелардан житеш. Сөю-ярату килә дә китә ул. Сагындырганы — яшьлек мәхәббәте... Яндырганы, көйдергәне — бәлигъ булгач, тагы да татлырак кичерелә ул, Каракүзкәй...

Юлия Борисованың карашы Кәримәнең өстәл читенә тотынган кулына, нәни баланыкы кебек буынланып торган бармакларына төште, аннан буыннары кантарланып беткән үз кулына карап алды. Менә ул ике гомер, берсе — яшьлек, дөньяга яңа аяк баскан кыз һәм яшен яшәп, ашын ашап, тешләре коелып, буыннары кантарланып беткән картлык. Карчык та өстәл читенә ябышты. Шушы өстәл, бу өйдәге һәммә әйбер аның белән бергә картайды, аның өендә мебель дә Юлия Борисовна кебек үк карт иде. Картлык, борынгылык тулган өйгә көтмәгәндә мөдерәп тулган яшьлек килеп керде. Өйдәге җиһазлар бик искергәннәр иде инде, әмма Юлия Борисовнаның ул мебельдән һич тә аерыласы килмәде. Чөнки өйдәге һәр урындык, диван, өстәл аның җан кисәгенә әверелгән иде. Бер әйберемне сатсам да, әллә никадәр истәлекләремне югалтырмын дип коты алынды карчыкның.

— Юлия Борисовна, сез ирегезне яраттыгызмы?

— Яратмый буламы, Каракүз, яратмый буламы, юләр,— Юлия Борисовна күрше бүлмәгә чыгып, иренең шактый зур портретын алып чыкты.— Менә ул. Ир уртасы иде. Үз гомеренә авызыннан өзмичә тәмәке тартты. Берсе сүнүгә, икенчесен кабыза торган иде. Үпкә рагыннан китеп тә барды, мәрхүмкәй.

Кәримәнең бу рәсемне күргәне бар иде инде. Ябык, озынчарак чырайлы, нечкә иреннәрен кысып торган кеше карап тора иде аңа. Йөзендәге сарысу төсне хәтта рәссам да яшерә алмаган, бәлкем ул аны бөтенләй яшерергә дә теләмәгәндер, чөнки саргылт төс портреттагы иренең күзләрендә дә бар. Юлия Борисовна аңа кияүгә чыкканда Николай Юрьевичка утыз биш яшь була, ундүрт яшь аерма, ундүрт яшь, дип гаҗәпләнеп утырды Кәримә. Әмма портретны тотып утыручы карчык өчен ул яшь булган. Чөнки ул аны яраткан. Башта Юлия Борисовна аны квартирга кертә, ике елга якын язылмыйча торалар. Сөйгәненең эштән кайтканын көтеп сәгатьләр буе тәрәзәдән карап торган көннәре була яшь артистканың. Соңра, еллар үтеп, үз-үзенә аптырап куйгалый икән. Шулай ук тилереп яраттымы ул аны?.. Яратты.

— Менә шулай,— ди Юлия Борисовна, портретны кире бүлмәгә кертеп куя да, янә өстәл янына килеп утыра, чәй яңартып җибәрә, ләкин Кәримә торып баса.— Утыр әле, утыр, ашыкма... Мин сиңа тагын бер нәрсә күрсәтәм.

— Кайтыйм инде, Юлия Борисовна.

— Утыр дим. Мин хәзер... Менә шул,— Юлия Борисовна түр яктан бер шкатулка алып чыга.— Менә,— ди ул, шкатулканы өстәлгә куйгач, чылбырга таккан ачкыч чыгара һәм шкатулканы ача.— Менә миңа Николай Юрьевич калдырган хәзинә, Каракүзкәй.

Кәримә күрде дә таң калды. Шкатулкада зиннәтле, затлы йөзекләр, алтын кулоннар, беләзекләр, асылташ белән бизәлгән алкалар һәм көмеш җсә сәгате ята иде.

*

* *

Аякларын итәк астына җыеп, Кәримә диванда утыра. Кулында китап. Ул китапны укымый, уйга чумган. Кәримәнең күз алдында әтисе. Алар паркта. Кәримә алга йөгереп китә дә, кире борылып, җан фәрманга әтисе каршына йөгерә, килү җаена әтисе аны эләп ала да, үчтекәй итеп, сикертеп җибәрә. Кәримәнең җаны күккә аша, кош кебек очып китәр сыман тоела, аннары әтисе аны җилкәсенә утырта. Кәримә аның сумаладай кара чәченә тотына.

Әтисе ничек һәлак булган? Юлия Борисовна Кәримәгә еш кына: «Синең әтиең әүлия иде»,— ди. Әүлия булгач, нигә әтисе, фаҗига булачы көн алдыннан, өйдән әнисе белән ачуланышып чыгып китә? Кәримә әтисенең йөз-кыяфәтен томанлы гына хәтерли. Әтисе чыгып киткән көнне әнисе аның бер фотосын калдырмый ертып бетергән. Бу турыда ул Кәримәгә үзе әйтте. Нигә әнисе шулай кыланган? Ничек кенә булмасын, ул Кәримә белән Зөлфиянең әтиләре булган ич! Һич югы алар истәлегенә... Кайчак Кәримә әнисенең йөзенә сиздерми генә карап тора. Тәүге эшеннән китеп, больницага күчкәч, әнисе кисәк кенә картаеп китте, чәчләре агарды, күз төпләренә җыерчыклар өелде, авыз читенә тирән сызык төште. Җитмәсә үги аталары кайтып, җанын кыйнап китә.

Бер тапкыр шулай Кәримә әтисе турында сорагач, әнисе ачуланып: «Ул минем өчен бездән чыгып киткәч тә үлде»,— диде. Кәримә башта моңа таң калды. Үз постында һәлак булган кешене шул дәрәҗәгә җитеп куралмау мөмкинме. Юктыр, мөмкин түгелдер. Әнисе ачуы чыкканда гына әйткәндер бу сүзне. Соңгы вакытта әнисе ачулы, үги аталары көн-төн эчә, өйдә тынычлык юк. Әйе, Кәримә әнисенең хәленә керә иде, шул ук вакытта бик үк аңлап та бетерми иде ул аны. Нигә, кемгә шулай ачулы әниләре?.. Соңгы төнне әтисе нигә дип өйдән чыгып китте икән?..

Кәримә боларны белми. Ләкин моны белү теләге аңарда бик куптән яши. Килер бер көн, ул барысын да белер, һәм әнисе белән янәшә утырып, аңлашыр, сөйләшер.

Ишегалдына ни өчен чыкканын Кәримә тәгаен гына белми, бәлкем ул әнә шул инвалид егет белән саубуллашырга чыккандыр. Ул, бичара, һаман шул эскәмиядә утыра. Кәримә бүген юри аңа таба күз галды; кыз килеп җитәр-җитмәс, егет елмая башлады, хәтта аягүрә басарга итте, әмма яңадан утырды.

Кәримә аңа бүген беренче тапкыр дәште.

— Исәнмесез!

— Исәнмесез, күрше.

— Ә мин кичә соңгы имтиханымны бирдем.

— Котлыйм,— егет елмайды, бит очындагы мәхәббәт чокырлары тирәнәеп китте.— Чын күңелдән котлыйм. Мин Сезнең өчен шат, Кәримә, бик шат.

— Минем өчен! — дип гаҗәпләнүен белдерде кыз. Әлбәттә, юри генә гаҗәпләнгән булды, чөнки Кәримә уйлавынча, көннәр буена подъезд төбендәге эскәмиядә утыручы егет аның инде исемен дә ишетеп белергә тиеш кебек иде. Кәримә, кыюланып китеп, егет янына килеп утырды.

— Мин Сезне күптән беләм,— диде егет. Ул кара кашлы, кара чәчле, куе чәйдәй кук күзле иде. Кара чәчләре маңгаена сибелеп төшкән, сизелер-сизелмәс кенә мыек төкләре тырпаеп тора. Иреннәре калын да, юка да түгел, борынгы грек рәсемендәге кебек классик йөз, елмайганда бит очына мәхәббәт чокырлары куна. Егетнең аягында өр яңа туфлиләр. Кәримәнең карашы аягына төшүгә, егет үзалдына кызарынып китте.

— Сезнең аякларыгыз йөрмиме? Нидән алай ул?

— Мотоциклдан егылдым,— диде егет, түбән карап.

— Мотоциклдан!.. Ә... Әй-е, аңлыйм. Рульдә идегезме?

— Рульдә. Арткы урындыкка бер кыз утырткан идем. Ашыга иде. Дәрвишләр поселогы ягына илтеп куярга куштым... Мин исән калдым...

— Ә кызга ни булды?

— Ул да исән-сау. Мин аңымны җуйганмын, ул, күрәсең, телефон әзләп киткәндер. Ул тирәдә телефон юк...

— Шуннан соң ул кызны күргәнегез булмадымы?..

— Юк, булмады,— диде егет, бит очларына хәтле кызарынып.— Аның ни гаебе булсын, мин үзем гаепле. Мин аның хәтта исемен дә белми калдым...

— Сезнең исемегез Бәхтияр бит?

— Бәхтияр.

— Беләсезме, Бәхтияр, әйдәгез бүгенге көннән дуслар булыйк. Ни өчен дип сорамагыз...

— Беркайчан да сорамам,— дип елмайды Бәхтияр. Егет кызның балаларча ихласлыгына, беркатлылыгына аптырабрак калган иде бугай.

— Бер сер әйтимме? — кыз егет янынарак күчте.— Беләсегез килсә, милиционер буласы кеше мин... Алабуга шәһәрендәге милиция мәктәбенә укырга китәчәкмен. Инәки мине медицина институтына димли, ә мин мыштым гына милиция мәктәбенә юл тотачакмын. Минем әтием, беләсегез килсә, Бәхтияр, бер бандит кулыннан һәлак була. Подполковник иде ул... Мин ул бандитларның барысын да тотып бетерәчәкмен. Безнең җәмгыять паразитлардан арынырга тиеш...

Бәхтияр үзалдына елмаеп утырды, әмма кыз йөзендә кинәт үзгәреп киткән тәвәккәллек, ихласлык күреп, авызын кулы белән каплады.

— Килешерме соң әнигезнең рөхсәтеннән башка... китүегезне әйтәм...

— Егерменче гасыр кешесеме без?! Инәки түгел, мин шулай телим, мин!..

— Ә күршегез Юлия Борисовна бу турыда беләме?

— Белсә дә ул инәкигә әйтмәячәк. Мине ул үз кызы кебек ярата. Кичәгенәк кенә үзләрендә икәүләп чәй эчеп утырдык. Әлегә хәтта мин аңарга да әйтмәскә булдым. Ә сез, сез, Бәхтияр, беркемгә дә әйтмәссезме?

— Кирәк дип табасыз икән, ант эчә алам...

Кәримә шикләнебрәк егеткә карап алды, аның иреннәрендә җинелчә генә елмаю галәмәтләре күреп, җитдиләнде, тураебрак утырды.

— Беләсегез килсә,— диде кыз серле генә итеп,— мин дөресен беләм. Мин аларны да табачакмын, Сезне рәнҗеткән кешеләрне. Көлмәгез, әле соң түгел. Явызлыкны фаш итү беркайчан да соң түгел. Укып кайткач та мин шуңа керешәчәкмен. Менә әйтте диярсез...

Бу юлы инде егет түзмәде, көлеп үк җибәрде, ләкин кызның йөзендә җитдилек һәм бераз гына үпкә күреп, шундук шым булды.

— Гафу ит, син дип дәшүемә ачулана күрмә тагын. Кинәт кенә бик якын булып киттең син миңа... Ә тегеләр мәсьәләсендә мин үзем аның ачылуын теләмим.

— Әһә, сиңа теге качак кыз җалкымы!

— Кәримә, аларның фаш ителүе белән генә минем аяклар йөри башламас.

— Битарафлык — шул ук җинаять ул. Битараф булып калырга исәбең! Их, син?!.

Бәхтияр бу кыздан моны көтмәгән иде, аның чынлап та шулай тәвәккәл, үз-үзенә ышанган яп-яшь кызны беренче тапкыр күрүе иде. Кызның шулай тәвәккәлләп сөйләшүенә ул хәтта дулкынлана башлады, култык таягын алып, дөк-дөк асфальтны төйде. Шул тавышкамы, подъездда Бәхтияр кебек үк кара чәчле ир кеше күренде.

— Гафу ит, эти, кермим әле. Болай гына төелде.

— Исәнмесез! — дип Кәримә аңа баш какты.

— Исәнме, сеңелем,— дип, ир кеше борылып китте.

— Синең әтиеңме? — дип сорады Кәримә.— Шартлы сигналга чыктымы?

— Әйе. Син мине гафу итә күр, Кәримә. Мин бик шат синең милиция мәктәбенә укырга китүеңә. Исәнлек булса мин үзем дә шунда

укырга китәр идем. Мин аны үз башыма төшкәч кенә аңладым. Соң инде. Барысына да соң. Син миңа хат язырсың, Кәримә. Минем үлеп үчем пошкан чаклар була. Мин сиңа Казанда булган барлык яңалыклар турында да язып торырмын... Язарсың бит?..

— Язармын. Вәгъдә,— диде Кәримә.

— Исәбең тикшерүче булыргамы?..

Кыз баш какты.

— Мин әтием кебек...

— Тикшерүчедә зур түземлек, үҗәтлек, ихтыяр көче булырга тиештер инде ул...

— Мин барлык кыенлыкларга да түзәчәкмен. Әтиемне үлеп ярата идем мин, Бәхтияр.

— Дөрес, милиция мәктәбен генә бетереп тикшерүче үк була алмассың, университетка керергә туры килер. Син укырсың, Кәримә, мин сиңа ышанам,— диде егет һәм чынлап та ышаныч белән кызга карап куйды.

Бүгенле-кичәле генә унны тәмамлаган кызның матур булып керфекләре кайтарылып тора, тутсыл чыраенда әйтеп бетермәслек самимилек, балаларча садәлек. Каян килә бу кызга шушындый кыюлык һәм таваккәллек. Шул хәл бераз аптырашта калдырган иде бугай егетне. Моңа кадәр аның янына килеп утырганнар аны кызганалар гына иде, хәленә керергә тырышалар, ә бу, менә шул тутсыл-кара йөзле, керфекләре кайтарылып торган кыз егетне әллә нишләтте, ул аңа кинәт кенә ышанды. Әйе, ул милиция мәктәбенә китәр, укып чыгар, Казанга кайтып университетка керер, аны тәмамлар һәм үз теләгенә ирешер — тикшерүче булыр.

Кыз да үз чиратында егеткә текәлебрәк, сынабрак карады. Чибәр күренде аңа егет. Гарип булмаса, яныннан кызлар китмәс иде. Ләкин язмыш бу егетнең яшьлеген башкача хәл иткән. Һәм хәзер ул подъезд төбен сакларга мәҗбүр. Сәере шул иде: нигә дип ул үзен ташлап киткән кызны яклый, аннары булган хәлнең чынын нигә дип яшерә? Ә бит теләсә, ул кыз хулиганнарны тоттыра да ала иде. Туктале, Кәримә бу турыда икенче тапкыр уйлый түгелме инде? Уйласа соң. Уйланырлык нәрсә ич булачак тикшерүче өчен!

Егет дулкынлана, таяк тоткан бармаклары җиңелчә калтырана. «Үткәне өчен үкенә,— дигән нәтиҗәгә килде Кәримә.— Үкенмәслек хәлме. Шушы яшеңнән...»

Егет чынлап та бер мәлгә үз дөньясына бикләнеп, уйга чумган иде. Күз алдыннан балачагы тәгәрәп узды. Аның карашы стена буенда акча бәреп уйнаган малай-шалайларда иде. Аның да бит нәкъ әнә шул малайлар кебек гамьсез уйнап йөргән чаклары бар иде. Сәере шул иде: әле өлгергәнлек аттестаты да алмаган кыз аның күңел төренә яшерелгән иң нечкә, хәтта бик зәгыйфь горурлык хисенә кагылды. Үзен кыйнаган кешеләрдән үч алырга куша. Хәтта кыздан да... Юк-юк, аның турында ул беркемгә дә, беркайчан да әйтмәячәк. Нишләде ул кисәк кенә, моңа кадәр аңа барыбер кебек иде ич, бу кыз хулиганнарны табам дигәч, күңеле әллә нишләде дә китте. Бит аңа моңа кадәр берәү дә: «Табыйк шул хулиганнарны»,— дип әйтмәде. Аның гариплеге гүя шулай булырга тиеш, шулай булган кебек кабул ителгән иде инде. Хәтта дәвалаучы врач та аңардан: «Кемнәр кыйнады соң үзеңне, ни өчен?» — дип сорамады. Хәтта ул да аның гариплеген табигый бер хәл дип кабул итте. Бу хәлгә инде шактый гомер узды. Соң инде,— дип уйлады Бәхтияр.— Соң...»

Ләкин сәбәбе, әлбәттә, анда түгел иде. Сәбәбе аны танымаска тырышып йөргән кызда иде.

Бәхтияр кыз алдында торып китәргә оялды, гарьләнде, ни кылырга белми гасабиланырга тотынды. Бу халәтеннән арынырга теләп, ул

әүвәл бая Кәримә әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә теләп к
рады, ләкин кинәт кенә нервылана башлагангамы, тыныч кына уйлы
алмады. Егетнең кара кашлары җыерылды, ике каш арасында тирә
сызык ятты. Бәхтиярдәге бу хәлне күреп, Кәримә урыныннан кузгалды

— Я, хушыгыз. Мин китим инде.

— Тукта,— диде Бәхтияр, нәни баладай өзгәләнә калып.— Ми
сиңа адресымны бирмәдем бит.

— Әйе, бирегез. Мин сезгә чынлап та хат язармын.

*

* *

Кәримә акрен генә, өйдәгеләргә сиздерми генә юлга җыена башла
ды. Әнисе һәркөн медицина институты дип тецкәсенә тиде, Кәрим
каршы дәшмәде. Аттестатын алып кайткач, әнисе «Казан» торты алы
керде, Юлия Борисовнаны дәштеләр һәм бергәләп чәй эчтеләр. Табы
янында да әнисе медицина институты турында сүз кузгатты. Ул инд
анда булып, белешеп тә кайткан, имеш, быел конкурс былтыргы кебе
үк зур булмаячак, гел бишкә генә укыган кызы һичшиксез керәчәк
Больницада эшли башлаганнан бирле врач һөнәренә гашыйк булга
әнисе медицина институтын өзмәде дә, куймады да. Һәр көнне дияр
лек: «Кәримә, сиңа да вакыт инде документларыңны илтергә, бар д
тапшыр»,— дип тукып торды. Кәримә әйе дә, юк та димәде диюен, әни
се Алабугага китәсен сизенсә, өйдә зилзилә кубасын аңлап, ияк ка
гып, килешкәндәй итеп утырды.

*

* *

Вакыт уза торды. Иртәгә китәм дигән көнне Кәримә өйдә берүзе
калды. Кич якта Зөлфия апасы белән әнисе Юлия Борисовналарга ке-
реп киттеләр. Апасы бүген анда йоклаячак, өлкән артистка яшь ар-
тистканы дөнья күтәргә, җыр серләренә өйрәтәчәк, аннары ярты төнгә
чаклы йокламый ятачаклар. Бүлмәдә берүзе калгач, Кәримә акрен
генә чишенде, эчке күлмәктән генә калып, көзге каршына килеп басты
Зифа иде Кәримәнең гәүдәсе, җиденче класста укыганда аны һәм
классташы Зөбәрҗәтне гимнастика секциясенә язганнар иде. Кәримә
хәтта елга якын анда хәзерләнеп тә йөрде, ләкин тренерлары кияүгә
чыкты һәм Төмәнгә күчеп китте. Ул китүгә, җыелып, укмашып кына
килгән гимнастлар секциясе үзеннән-үзе таралды да бетте.

Ятса да, күзенә йокы кермәде Кәримәнең. Әнисенә әйтмичә Алабуга
милиция мәктәбенә укырга китеп баруы — куркыныч та һәм инде ни-
ятеннән дә кире кайтасы килми, уйланасы уйланган иде инде. Әни-
се, әлбәттә, орышыр, хәтта Алабугага ук килеп җитәр, ләкин ни генә
булмасын, Кәримә үз ниятеннән кире кайтмас.

Вак-төяк, кирәк-ярак әйберләр күптән җыелган, төйнәлгән, бары-
сы да Зөлфия апасының юлга йөртә торган сумкасына тутырылган
иде. Иң мөһим, иң авыр мәсьәлә — акча табу. Дөрес, Алабуга шәһәре
ерак җир түгел, ничек тә барып җитәр, әмма барыбер — юлы бар,
яшисе бар. Уйлый торгач, Юлия Борисовнадан акча сорап торырга
ниятләде. Ләкин бераздан бу уеннан кире кайтты. Юлия Борисовна
әнисенең мәңгелек ахирәте, әнисенә әйтми калмас, әйтмәгән хәлдә дә
шәп килеп чыкмас, әнисе күрше карчыкка үз гомеренә үпкә-ачу сак-
лар. Иртәгә әнисе иртәнге якта эшли, Зөлфия апасы консерваториядә,
димәк, һичкемнән курыкмыйча иркенләп чыгып китәргә була. Әйе,
акча, акча... Әллә соң Бәхтиярдән сорап торыргамы?

Иртән күзен ачуга, Кәримә өйдә берүзе генә булуын, әнисенең эшкә, апасының укырга китүен абайлады. Караваттан тормастан, ул китү хәлләрен өр-яңадан уйлап чыгарга булды. Пальто алмаскадыр, кирә кала икән, барыбер форма бирәчәкләр, кирми икән, көннәр суыткалаганчы әйләнеп кайтачак. Хәер, кире кайтмаячак ул, һичшиксез укырга керәчәк. Ә менә плащ, җылы кофта кебек әйберләрне алырга булыр. Болай барысы да уйланылган иде югыйсә, тик менә Бәхтиярдән акча соравы гына әллә ничегрәк. Акчасы булмаса, дигән шик тә бар.

Торып юынганда да, чәй куеп, йомырка тәбәсе кыздырып ашаганда да Кәримә акчаны Бәхтиярдән сорарга дигән фикердә булды. Бу нияттен тәмам ныгыту өчен ул, чәй дә эчеп тормыйча, йөгереп урамга чыкты, әмма Бәхтиярне гадәттәге урынында күрмәде. Кәримә юри алар подъезды алдыннан берничә тапкыр узып китте, хәтта бер мәл туктап, тәрәзәләргә карап та торды. Менә ул, тәвәккәлләп, подъездга таба юнәлде, шул мәлдә ул ишектән чыгып килүче Бәхтиярне күреп алды. Егет стенага елыша-елыша, тыңлаталмас аякларын көч-хәл белән сөйрәтеп, чыгып килә иде. Бит алмалары алсуланган, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бөртекләре бәреп чыккан. Моны күрүгә, Кәримә аңа ярдәмгә ташланды, егетне иңенә таяндырып, эскәмиягә китереп утыртты.

— Мин сине күрдем,— диде Бәхтияр, эскәмиягә утыруга җиңел сулап куйды.— Исәнме. Әти-әниләр эштәләр. Өйдә берүзем.

— Бәхтияр,— диде кыз егетнең янәшәсенә утырып.— Минем сиңа бик зур йомышым бар.

— Миңа?! — дип гаҗәпләнә калды егет.

— Сиңа, Бәхтияр. Син миңа йөз сум акча биреп тора алмассыңмы? Әҗәткә. Мин аны кайтарып бирермен. Озак тотмам.

— Әйдә!

— Кая?

— Әйдә, өйгә керәбез.

Бәхтияр торырга омтылды, Кәримә аны култыклап алды, алай уңайсыз булгач, егетнең кулын муены аша алып, керергә ярдәм итте.

— Ничәнче катта торасыз?

— Икенче катта.

— Нигә беренче каттан квартир сорамыйсыз?

— Биргәннәр иде дә, мин теләмәдем.

Ишек төбенә менеп җиттеләр, Кәримә сәерсенеп егетнең күзләренә карады. Кулы Кәримәнең иңбашында, гүя ул иләнгән классташына ярдәм итә, ә монда кинәт әллә ни булды, шул хәрәкәттән сискәнеп китте. Бәхтиярнең күзләрендә дә нурлар бии кебек иде. Нигәдер кулны да җибәрми тора, югыйсә ишек төбенә дә килеп җиттеләр бит инде.

— Рәхмәт. Хәзер.

Бәхтияр стенага терәлеп, кесәсеннән ачкыч чыгарды, ишекне ачты. Ул ишекне ачканда да, ачкач та, Кәримә шушы мизгелдә үзе белән ни булганына төшенә алмый торды. Әйтерсең шушы минутта кемдер аның күңел түрендәге иң нечкә, әле беркем тимәгән кылына кагылган кебек иде. Кәримәнең дәшми-тынмый гына басып торуы хәзер генә булып алган сәер халәттән чыга алмыйча җәфалануыннан иде.

— Әйдә, кер,— диде Бәхтияр.

Егет ишекнең эчке ягында тора иде инде, кай арададыр кереп тә өлгергән, күзләре һаман шулай ук яна, бит алмаларына кызыл тимгелләр кунган.

— Кер инде, кер, курыкма,— диде егет.

— Уф, нишләп куркыйм ди мин синнән,— диде Кәримә, тик бусага аша атлавы булды, тәүге курку хисе янә кузгалып куйды.

— Уз әйдә, түрдән уз. Мин хәзер.

Кәримә, кыяр-кыймас кына узды, баягы тәвәккәллеген аның гүя җил алды, аяклары кургаштай авырайды, кунак бүлмәсенә керүгә, туктап калды.

Ишек янагына, стенага, буфет, китап шкафларына тотына-тотына Бәхтияр түргә узды, комод тартмасын ачып, аннан ниндидер шкатулка алды, санап, Кәримәгә акча сузды.

— Мә. Йөз сум җитәрме соң? — дип сорады егет.

— Җитәр. Рәхмәт, Бәхтияр, мин аны тиздән кайтарырмын.

— Ашыкма кайтарырга. Эшли башлагач. Акча минеке.

Кәримә кызыл унлыкларны кулына йомарлап тотты да чыгу ягына таба бер адым ясады. Бәхтияр бу хәлне күреп, агарынып китте.

— Китәсең дә мени?

— Җыенырга кирәк, соңга калуым бар. Мин сиңа китешли кагылырмын, Бәхтияр. Акчаң өчен мең-мең рәхмәт. Баргач та хат язармын.

— Уңышлар сиңа,— Бәхтияр стена буйлап аның янына килә башлады.— Хатны минем исемгә яз. Ни пуха, ни пера диләрме әле,— дип елмаерга тырышты егет, әмма аның карашында Кәримә беренче көндәге гадилекне күрмәде, ул аңа ничектер кызыксынып, аны аңларга теләп, ул гынамы, кыздан нидер өмет итеп карый сыман иде. Бу караш, Бәхтиярнең бу кызыксынуы Кәриманe янә куркыта калды. Яңа гына күргән кебек, ул өйдәге җиһазларга күз йөртеп чыкты. Бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәл дә, биек артлы урындыклар да, уң як стенада торган зур көзге дә, өстен бәрхет япма белән каплаган телевизор да, тәрәзәдәге моңсу күксел төстәге пәрдәләр — һәммәсе дә аңа ниндидер мөнәсәбәт тоталар, бу өйнең хуҗасы кебек үк тәүге карашларын үзгәрткәннәр кебек иде. «Нәрсә булды соң әле?» — диде ул үз алдына, Бәхтияр ишеккә таба килгән арада. Ул, әлбәттә, аның белән саубуллашырга, аңа милиция мәктәбенә уңышлы керү теләгән әйтергә дип килә иде. «Нәрсә булды соң әле миңа?» — дип сорады ул янә үз-үзеннән. Ул үзенең ни өчен бирегә килеп керүен дә, моның шактый кыю адым булуын да уйлап куйды. Ә бит күңеле белән ул моңа каршы иде, шулай да керде, чөнки иң кыен вакытта аны аңлардай, аның тәүге адымын, фикерен ныгытырдай бердәнбер кеше Бәхтияр булып чыкты.

Ул арада Бәхтияр аның кулыннан алды.

— Бәлкем, бергәләп чәй эчәрбез.

— Чәй,— дип кинәт айнып китте Кәримә.— Чәй. Мин дә чәй куйган идем бит. Рәхмәт. Я, хуш, Бәхтияр.

Кәримә егетнең кулына кагылып алды, сыйпагандай итте һәм, күзен күтәреп карарга да оялып, йөгереп чыгып китте. Икешәр баскыч аша сикерә-атлый төште, ишегалдын җан фәрманга йөгереп узды, янә аңарда ниндидер хис ялкынланып алды һәм аңа шул ялкынлануын кем дә булса күрер, күрер дә аның иң кадерле нәрсәсенә кагылыр кебек иде. «У-рра! — дип кычкырды ул эченнән, подъездларына килеп керүгә.— Ур-ра! Акча булды. Китәм!»

Квартирларына кайтып кереп артыннан ишек ябылуга, йөрәге дөпдөп типкән килеш, бер тын туктап торды. Өйдә тынлык иде. Димәк, энисе дә, Зөлфия апасы да кайтмаган, ул әле алар кайтып кергәнче җыенып чыгып китәргә дә өлгерәчәк. Бүлмәгә ташланды, җыеп куйган әйберләренә күз йөртеп чыкты. «Ашап тормыйм,— диде үзалдына.— Кайтып керүләре бар. Кая булса да капкалап алырмын әле Аэропортта»,— дип сөйләнде ул, ишекне яба-яба. Ачкычларны почта әрҗәсенә төшерде, тимер ачкычлар шалтырап әрҗә төбенә бәрелгәч, әллә нишләп дерт итеп китте, астан кемдер менеп килә иде. Аяк тавы-

шына колак салды. Юк, әнисе дә, Зөлфия апасы да түгел, Юлия Борисовна бу. Булмагае. Кәримә сумкасын алып, түбән төшә башлады.

— Кая син болай? — диде Юлия Борисовна. Кәриманең битләренә гүя ут капты. Зиһенен: «Әллә беләме бу Юлия Борисовна?» — диган уй көйдереп узды.

— Авылга бәрәңге алырга җибәрәләр,— диде Кәримә.

— Иртәрәк түгелме соң әле бәрәңге алырга?

Кирәк бит, бер алдашырга тотынгач, Кәриманең зиһене ачылып киткәндәй булды.

— Башта ашлык чистартуда катнашачакбыз.

— Ашлык чистартуда!? Изге эш, бик тә изге эшкә барасың,— дип сөйләнә-сөйләнә менүен дәвам итте Юлия Борисовна, ләкин Кәримә белән тигезләшкәч, кисәк туктады, кызга текәлебрәк карады.

— Әнинең өйдәме соң?

— Эштә ул.

— Эштә мени,— дип гаҗәпләнгәндәй итте Юлия Борисовна.— Бар инде, бар, йөгер, соңга калуың бар...

— Юлия Борисовна...

— Бар диләр сиңа... Әниеңә әйтмәм. Бар диләр сиңа, иптәшләреңнән калырсың.

Кәримә аяк астында баскыч тоймады, подъездан чыгуга, башын күтәрмичә, троллейбус тукталышына йөгерде.

## 2

Гөлбикә идарәдә эшли башлаган елны Якубны бер елга Ленинградка укырга җибәрделәр. Ул елда Гөлбикә аңардан авырлы булып калды. Якуб кайтканда балага өч ай булган иде инде. Кайтып ярты елга якын эшләмәде, Якуб янәдән (бу юлы инде Мәскәүгә) укырга китте. Әле булса оныта алмый, ир авызыннан бу хәбәрне ишеткәч, Гөлбикә Якубы белән ике көнгә якын сөйләшми йөрде. Сөйләшерлек идеме, хатыны кулында яше тулмаган бала, ә ул тагын укырга китә. Ирме ул аңа, әллә студентмы! Бала үсә төшкәнче сабыр итәргә дә була иде лабаса. Кайнарланып китеп, шул турыда әйткәч, ире тәкәллефсез генә, шулай булырга тиешле сыман: «Милиция сезнең коллектив түгел, бездә корыч дисциплина»,— дип кенә җибәргән иде.

Бәлкем шулайдыр да, милициядә корыч дисциплина булуга Гөлбикә куана гына, шуңа карамастан, иренең бу сүзләренә Гөлбикәнең җен ачулары чыкты, чәчрәп кереп, нидер әйтергә дә теләгән иде, өлгерми калды. Тегесе сизенеп булса кирәк, тиз генә киенде дә чыгып китте. Бер-береңә ачу килү, әйтешү гаиләдә булгалый торган хәл, кич якта ире эштән кайткач, һәм дустанә матур итеп дәшкәч, житмәсә, килеп, кайбәтме хәлләр, бәләкәчебез йоклыймы»,— дип тә дәшкәч, эрепләр киткән иде тагын. Ире шулайрак дәшүгә җаны эресә дә күңелгә сеңеп калган үпкә тиз генә җуелмады, Якубы тагаен Мәскәүгә җыена башлагач, Гөлбикәнең янә буасы ташып чыкты. Имеш, синең генә эшең эш, безнеке, ягъни аныкы, курчак уены. Әмма ир аның бу дулавын гүя ишетмәде дә, Гөлбикә нинди эшкә генә керешмәсен, кулыннан алып диярлек эшен башкарды, үтә игътибарлы булды, назлы итеп күзләренә карады. Шулай, бер-берсенә булыша-булыша, балайы йокыга салгач, сабыйлары тәмле йокыга талгач, күзгә-күз карашып алдылар һәм үзләре дә сизмәстән бер-берсенең кочагына сеңделәр.

Иренең киң күкрәгенең, җылы куенын тоеп яткан Гөлбикә барысы турында да онытты. Менә шул мизгелләр өчен үлепләр китәргә әзер ул Якубның кочагында. Җитмәсә Якубы: «Семьяга тагын бер милиционер киләчәк, әнисе»,— дип, болай да нечкәреп, йомшарып киткән хатынының күңелен тәмам эретеп ташлады.

...Малай тапмады Гөлбикә, икенче баласы да кыз булды. Беренче кызына исемне Гөлбикә куштырган иде, икенчесенә исемне Якуб үзе сайлады. Гөлбикә каршы төшмәде. Әйдә, Кәримә икән Кәримә булсын, исемне ата кушса кыз бала бәхетле була, диләр. Үзе исем кушкангамы, Якуб икенче кызларын кулыннан да төшермәде. Ахыр бер тапкыр: «Юк инде, энисе, кыз булса да, милиционер булыр бу, күрәмсең, кулга ни тамаша ябышкан»,— дип, Гөлбикәнең күңелен кузгатып, ачуын чыгарган иде.

«Тузга язмаганны сөйләмәсәнә әле, Якубҗан. Нинди милиционер ди инде ул тагын, берсеннән дә гарык...»

Әйе, үтте, үтте гомер, үтеп бара. Әле булса хәтерендә: Зөлфияне үзе кая барса, шунда йөртте. Декрет ялы бетеп, үз исәбенә ял алып, бала карап өйдә яткан вакыты иде, көтмәгәндә-сорамаганда Гөлбикәне идарә начальнигы чакырып алды. Гөлбикә тугыз айлык Зөлфиясен күтәрде дә идарәгә китте. Начальник кабинетына ул баласын күтәреп килеп керде. Хатын кулында бала күреп, начальник бер мәлгә аптырап калды бугай, ни әйтергә белми өстәлдәге кәгазьләрен актарган, рәтләгәндәй итте.

— Гөлбикә Әхмәтовна, минем бик зур үтенечем бар... Садрый Галәветдинович кисәк кенә авырып китте, ә тормыш дәвам итә — Әлмәттә әнә зур эш чыкты. Барып, ревизия үткәрәсе иде. Ярдәмгә шул өлкәдәге ике кешене билгеләдек. Берсе — тәэминатчы, икенчесе — исәп-хисап белгече. Сездәй тәҗрибәле кеше башкарып чыга алыр дигән фикергә килдек.

— Мине кая куярбыз, абый,— дип, баласына күрсәтте Гөлбикә.

— Караучылар булыр, исәп-хисап белгече — кыз кеше, һич югы аңа йөкләрсез.

— Яңа тәпи баса башладык бит әле, абый. Андый ерак юлга чыгарга куркарак төшәбез шул.

— Мәсьәлә җитди булмаса, Сезне чакырмаган да булыр идек, Гөлбикә Әхмәтовна. Сездән башка кешегә ышанып тапшыра алмыйбыз ул эшне, ышаныгыз...

Якубы өйдә булса да, булмаса да, идарә начальнигы бик үтенгәч, Гөлбикә барыбер барган булыр иде. Ул тәмам туйган иде инде өйдә утыра-утыра. Риза булды булуын, әмма начальник кабинетыннан чыккач, курка калды: кулында тугыз айлык бала һәм ул, җүләр баш, нинди җитди ревизия уздырырга Әлмәт кадәр Әлмәткә барырга риза булды... Мәгәр ризалык бирелгән, кире уйлау мөмкин түгел иде. Хакыйкатьнең асылын ачу өчен җанын җидегә бүләргә торган КРУның өлкән ревизоры урынына аны җибәрәләр икән, димәк, чынлап та аңа ышаналар, ышаныч белдерәләр. Ә бит өлкән ревизор булып эшләү теләге Гөлбикәнең бу өлкәгә килеп эшли башлагач та хыялланып йөргән теләге түгелме соң! Бармый буламы, җүләр.

Белә-белештергәннән бирле Гөлбикә ният иткән эшен җиренә житкермичә калганы булмады. Тәвәккәл холкы аркасында авызы пешкән чаклары да булгалады булуын, әмма барыбер үзенекен итте. Якубка кияүгә чыгуы да шулайрак килеп чыкты. Очраша торгач, егет (ул вакытта Якуб өлкән лейтенант кына иде әле) аңа: «Чык миңа кияүгә, Гөлбикә»,— дип ычкындырды. Икенче көнне үк булмаса да, ялга каршы көнне Гөлбикә чемодан-сумкаларын күтәреп, милиция өлкән лейтенанты Якуб Азатовның ун квадратлы бүлмәсенә килеп керде. Ишекне ачып җибәрүгә, бусагада чемодан-сумка күтәргән Гөлбикәне күрде дә агарынып китте өлкән лейтенант, тәмам телсез калды. Хуҗадан рөхсәт-фәлән сорап тормастан, Гөлбикә кыюланып бусага аша атлады.

«Менә, Якубҗан, мин килдем дә,— диде.— Әйтүең чын булгандыр бит, куып чыгармассың шәт!?»

Башкарган хезмәте, дөньяга карашы, җитдилеге белән күпләрдән аерылып торган, җиде исәпләп бер кисәргә өйрәнгән Якуб тәмам таралган, каушап калган иде ул көнне. Башта ул кызны шаяра дип уйлады, егермедән узган кыздан барысын да көтәргә була. Ишекне бәреп кергәне өчен гаепләр иде — үпкәләр дә борылып чыгып китәр дип курыкты. Кыз аңа ошый, әгәр дә кызның нияте изге икән, ул аңарга чынлап та өйләнергә әзер.

Һәм шулай итте дә.

Өйләнешкәннән соң күп тә тормый, аларга ике бүлмәле фатир бирделәр. Якуб капитан дәрәҗәсенә иреште. Кулы җиңел булдымы Гөлбиканең, Якубы хезмәтендә бик тиз югары үрләде. Хәвефле һәм куркыныч иде милиция капитанының хезмәте. Кайчак атналар буена өйгә кайтып кермәде, кайта алмыйм дип, телефоннан гына шалтыратты, ә кайвакытта шалтырата да алмады. Ул көннәрдә Гөлбикә әллә ниләр уйлап бетерә торган иде. Кайчак исә шикләнеп тә куя: нинди дә булса кәнтәй янына ияләшеп китмәдеме бу ир? Ревизор булып эшләү дәверендә андый капитаннарны иреннәрен кишер төсенә буяган җиңел холыклы хатыннар белән рестораннарда күргәләде, шулар күз алдына килә идеме, аның Якубы да шулай берәр кәнтәй белән ресторанда кәеф ачып утырадыр сыман тоела башлый иде. Ләкин ире исән-сау кайтып кергәч, бу турыда оныта. Ә инде ире йокыга киткәч, аның керләрен юганда күлмәк киемендә кан таплары күрер иде дә йөрәге жу итеп китәр иде: «Якубҗан, бу кан таплары каян?» — дип сорар иде. «Бер бандит пычак белән селтәнде, кулга тиеп киткәндер, күрәсең»,— дип, һични булмаган кебек җавап бирер иде ире.

Аның шул сүзләреннән соң, Гөлбикә күз яше белән елап утырыр, ә Якубҗан килер иде дә аның аркасыннан сөя-сөя аны юатыр, назлар иде.

Ә бер тапкыр Якуб агарып калган йөз белән кайтып керде. Иңбаш турыннан костюмы умырылган, кул аркасына хәтле кан агып чыккан. Гөлбиканең коты алынды.

— Нишләттеләр сине, Якубҗан!?

— Әллә ни юк. Ваннага су җибәр әле. Пычрандым, юынасы иде.

— Чишен тизрәк. Ай аллам, кулыңда кан түгелме соң?

— Чәнчелеп китмәсме, бетәр. Икенче каттан сикергән идем, койма якын булган икән, шундый иттереп килеп орылдым. Пустяк, бетәр. Кая, чиста күлмәк-ыштан бир дә...

— Күрче моны, нигә врачка күренмәдең?! Кайлардадыр икенче каттардан сикереп йөри. Нинди дә булса... Чит-ят хатыннар янына кергән идеңме әллә? — дип көлемсерәде Гөлбикә, ирне чишендерә-чишендерә.

— Бер карак кисәге, эчкән, берәүнең квартирына кергән. Куркытып әйберләрен алып китмәкче булган. Күрше бүлмәдә икенче класста укучы бала утыра икән, тоткан да безгә шалтыратты. Без килеп җиттек, теге әйберләр күтәреп чыгып килә. Исерек дисәң дә... безне күргә, шундук әйныды, тәрәзәне бәреп икенче каттан сикерде. Мин аның артыннан. Чак өстенә килеп төшмәдем...

Гөлбикә ирне рәтләп тыңлап тормады, шул арада ашыгыч ярдәм машинасы чакыртты.

— Гөлбикә,— дигән булды ир.— Кирәкмәс иде, бетәр иде әле. Ни хәтәр яраларның төзәлгәне бар.

— Сөйләп торма юкны, столбняк булса... Мине кемгә калдырмакчысың?..

Врачлар чыгып киткәч, Гөлбикә яңа иренә ябырылды.

— Якубҗан, кит бу эшеңнән. Зинһарлап сорыйм, кит. Табылыр әле эш. Мине генә түгел, булачак балаңны да ятим итәсең бит, җүләрем.

Хатыны шулай диюгә, ир Гөлбикәне күтәреп алды да диванга утыртты.

— Күр әле моны. Ярасын әле генә бәйләп киттеләр... Җуләр дә ин де, билләһи, бу ирләр. Я, сизәсеңме? Тибешә башлавына бер атна бул ды инде. Син күрми сизми йөргәч тә. Менә икәү генә булыйк әле, тың латырбыз без сине, тыңламый беркая да китә алмассың, ярпач әтекәй.

— Күр әле, әнисе, ни тамаша тибешә, бер дә бүтән түгел, милицио нер булыр бу. Күр әле күр, үзең ишетәсеңме хет,— ир Гөлбикә кары ныңдагы бала тибенүен колагын куеп тыңлый, ә хатын аның кара чәч ләреннән сыйпый.— Билләһи дип әйтәм, малай булачак бу, малай бул маса, шул тамаша тибешмәс иде.

— Хәзерге кызлар да бик оста тибешә, Якубҗан. Якуб, Якуб дим... Бу эшеңнән китсәң... мин сиңа тагын бер малай табып бирәчәкмен... Әнә Юлия Борисовна, мин балага узганмын дигәч, кыз булса, җырчы итәм, диде.

— Кайсы Юлия Борисовна ул тагын?

— Минем бер таныш инде шунда. Вишневский урамында яңа өй салалар икән, сезнекеләр. Шуннан квартир сораган, ышандырганнар. Сез дә шуннан сорагыз, ди. Берьюлы ике малай тапсаң икән ул, аны сы, синнән тора инде, әтисе, синең яратуыңнан. Миңа калса, кешене бик-бик яратканда гына игезәкләр туа... Сөйләмә юкны дип... Дөрес анысы, син дә яратасың...

Якуб аның битләреннән, күзләреннән, колакларыннан үбә, аннары битен хатыны битенә тери дә тынып кала. Ул дәшми, ул барысы белән дә килешә. «Әйдә, шулай булсын, тап биррәттән ике игезәк малай... Дө рес, квартирны бер бала тапсаң да бирерләр... Чөнки ул турыда сүз барды инде...»

— Квартирны алырбыз аны, бирерләр,— диган иде шул вакытта Якуб, һәм күп тә үтми күченеп килделәр дә.

V

Шулай да теге чакта Гөлбикәгә өйдән чыгып китүләре бик авыр бул ды. Әйтерсең, кай тарафтандыр Якубы карап тора иде.

— Карале, Якубҗан, барып җиту белән мин сиңа шалтыратырмын. Борчылма син безнең өчен. Борчылмассың бит?.. Менә шулай. Ярый, Якубҗан, мин китим инде.

Баласын күтәреп өйдән чыгып барганда әнә шулай дип сөйләнде Гөлбикә, күңелен юатса да, җаны тыныч түгел иде хатынның.

Көн бозылып киткәнгә күрә самолетлар очмый икән. Бу хәбәрне ишеткәч, Гөлбикә баралмам ахрысы, дигән иде, начальник әллә каян гына автобуска билетлар тапты һәм барыбер озатып җибәрде. Кар сал ган юлда автобус берничә тапкыр тукталды, пассажирлар төркем-төр кем булып кар көрәргә чыктылар. Автобусның тирбәтүенәме, буранлап торгангамы, бала Казаннан чыккач та йокыга талды. Автобус туктауга, аның юлдашы Хәлил бүтәннәр белән бергә кар көрәргә төшеп китте, машина кузгалуга, керде һәм борчылып сорады.

— Йоклыймы?

— Йоклый. Нигә алай дип сорыйсыз?

— Ачып күрсәтер идегез, яшь бала исен үлеп яратам. Әллә нинди хуш исләр килә шул нәни балалардан.

— Сөт исе,— диде Гөлбикә һәм үз сүзеннән үзе үк оялып китте. Лә кин нәкъ менә шулай сөйләшеп алганнан соң Гөлбикә егеткә ягымлы рак итеп карады. «Ярдәмчелме шулай, әч пошуданмы сораша?» — дип уйланды Гөлбикә, кырын күз белән генә үзе җитәкләгән группага кер телгән, арткы рәтләрнең берсенә утырган яшь хисапчы кызга күз төше реп алды. Кыз берьялгызы утырып бара иде.

— Тиздән барып та җитәрбез, күп калмады инде,— диде егет.

Гөлбикә дәшмәде. «Сиңа, егетем, әнә шул ялгыз барган кыз янына

утырырга иде дә бит»,— дип уйлады. Яшьлекнең кадерен белмидер бу, дип хөкем чыгарды ул Хәлил турында. Соңыннан, күпмедер вакыт үткәч тә әле аның һаман үз артыннан йөрүенә сәерсенми булдыра алмады. Ул аны кызгана да иде, нинди дә булса изгелек эшлисе килгән чаклары да булгалады, әмма нинди изгелек эшли ала иде соң ул. Ә менә Хәлил ага һәрчак дефицит әйберләр табып китерә, Гөлбикәне шатландырырга тырыша иде. Дөрес, Гөлбикә аңардан бер әйберне дә бушка алмый. Әмма моннан һични үзгәрмәде, күңелдә шушы егеткә изгелек эшләү теләге барыбер кала килде.

Юл гаять озын булгангамы, әллә инде янәшәсендә утырган егетнең күзе тиеп, бала, ниһаять, уянды. Башта сыкранып кына, аннары кычкырып ук елый башлады. Салкынча автобуста күкрәк чыгарып имезү турында уйларга да ярамый, шуны сизепме, Хәлил шоферга нидер әйтеп килде. Күп тә үтми автобус эче җылыныбрак киткәндәй булды.

— Имезегез Сез аны. Җылы бит,— дигән булды Хәлил.

— Тик еласын, җырчы буласы кызым ул минем. Безнең күршедә мина концертларга билетлар табып торучы бер апа яши, шул аны җырчы итәм диде.

— Харап икән Сезнең эшләр. Зөлфия исемле атказанган артистканың концертларына йөрисебез бар икән әле.

— Шулай, абый. Әтиебез безнең милиционер, ә без җырчы булачакбыз.

— Баланның эче катуы бар, имез, шыңшытма,— диде күрше утыргычта утыручы бер апа.

Гөлбикә ояла-тартына гына күкрәген чыгарды һәм балага имчәк башын каптырды.

Янәшәсендә утырган егетне яңа гына күргәндәй күзләрен шарландырды.

— Хәлил, оят түгелме Сезгә. Китегез моннан, әнә Сария янына күчеп утырыгыз,— диде Гөлбикә күкрәген каплый төшеп.

Ниһаять, автобус Әлмәт шәһәренә килеп керде. Өйләр арасында буран басыла төшкәндәй булды. Гөлбикә баланы әйбәтләп киендерде дә ут алынган өйләргә карап бара башлады.

— Автовокзалдан такси алырбыз,— дип, Хәлил янә аның янына күчеп утырды.

— Шулай итәрбез,— дигән булды Гөлбикә. Ул белә иде: аларны кем дә булса каршы алырга тиеш. Һәм ялгышмады, автобус туктауга, кайры тун кигән бер егет алар каршына килеп басты.

— Иптәш Азатова Сез буласызмы? Миңа сезне гостиницага озатып куярга боерылды,— диде.

— Безне дә,— дип өстәде Хәлил.

— Әйе, сезне дә,— егет борылып карауга, Хәлил янында басып торучы кызны күрде дә, елмаеп. — Исәнмесез! — диде.

— Без исән, Сезнең менә машинагыз күренми,— дип, Хәлил һаман саен әрсезләнә барды.

Егет аларны «Жигули»га утыртып гостиницага җилле генә китереп житкерде.

— Гостиница бүлмәләре суык, Гөлбикә Әхмәтовна, бәлкем мин сезне Иске Әлмәттәге апама илтермен? — диде егет, кунак йорт каршына килеп туктауга.

— Барыгыз, Гөлбикә Әхмәтовна. Салкын гостиницада я балагызга салкын тидерерсез,— дип, ниһаять, телгә килде Сария.

— Ярый соң. Тик үпкәли күрмәгез тагын.

— Нинди үпкәләү ди ул. Туктагыз, мин Сезне озата барам,— диде Хәлил һәм машинага кереп ялт итеп кереп тә утырды.

Каршы алучы егет бер сүз дә әйтмәде, нигәдер Сария ягына кызыксынуын яшермичә карап алды. Егетнең исем-фамилиясен сорамады

Гөлбикә. Ревизор булып эшләү дәверендә ул мондый каршы алучыларны гына күргәләгән иде. Гадәттә аларны Гөлбикә тикшерәсе оешмаларның начальнигы җибәргән була. Егет чибәр булыр, яшь булыр һәм Гөлбикә ни әйтсә, шуны үтәргә генә торыр. Билгеле инде, кем дә начальнигы исеменә тап төшерергә теләми. Каршы алучы егетләр арасында аңа гашыйк ролендә уйнаучылары да булмады түгел. Әмма бүгенге егет аларның берсенә дә охшамаган иде. Ишетә белә иде Гөлбикә, аксак Садрый тикшерергә килгәндә, аны каршыларга чибәр-чибәр кызларны җибәрә торган булганнар. «Ә менә мине егетләр каршы ала»,— дип үзалдына көлемсерәп куйды Гөлбикә. Аксак Садрый анда да аксак Садрый булып калган диләр, каршы алучы кызларга ичмасам күтәрелеп тә карамаган, хәтта алар белән бер өстәл янына ашарга да утырмаган дип сөйлиләр иде.

Каршы алучы егетнең апаларына да килеп җиттеләр. Машинасын ишегалдына ук кертеп туктаткан егет, руль артыннан чыгып Гөлбикәгә ишек ачты.

— Рәхим итегез,— диде ул. Шунда ук: — Апа, чык әле! — дип кычкырды.— Кунаклар алып килдем үзеңә.

Болдыр ишегендә иңнәренә шәл салган апа күренде.

— Рәхим итегез, керегез әйдә. Кая, булмаса, баланны үземә бир,— болдырдан менүгә, хуҗа хатын баланы Гөлбикә кулыннан алды.

Өйгә керделәр. Өй эче җылы, якты иде.

— Ә Сез нигә килдегез инде, Хәлил? — диде Гөлбикә өйгә кереп килгән егеткә.

— Саклангінны саклармын, дигән аллаһы тәгалә.

— Димәк, Сез минем җан сакчым булып чыгасыз.

— Нәкъ күзенә бастыгыз, Гөлбикә ханым,— диде Хәлил.

Өйгә керүгә, бала шыңшый башлаган иде, чишендереп җибәргәч, күзләрен зур ачып, ялтыравык нәрсәләргә караштыра башлады, шым булды. Аннары өстәлдәге самавырны күрде дә: «Ә-ә-ә»,— диде.

— Чәй эчәсең килдемени, бәбкәчем, хәзер, хәзер самавырны куеп җибәрәм, әнкәңнең дә карны ачкандыр,— дип сөйләнә-сөйләнә хуҗа хатын чәй куя башлады.

— Күр әле моны, елмая, җылыга тарды бераү,— диде Хәлил.

Гөлбикә ишек ягына әйләнеп карады. Машина йөртүче егет китеп барган, Хәлил бер ялгызы басып тора иде.

— Син нишләп калдың? — диде ул. — Нигә китмәдегез инде, Хәлил?

— Биредә концерт була,— диде каршы алган егет. — Барырбыз. Сез үзегез концерт тыңларга яратам дидегез түгелме?

Ни ачуланырга, ни үпкәләргә белми аптырады да калды Гөлбикә. Ул арада мич алдына кереп киткән хуҗа хатын күренде.

— Бәй, Хатип кая китте? Күр әле бераүне... Ә син чишен, өстеңне сал, берәр чәшкә чәй эчәрсең,— диде ул ишек яры ни чыгып китәргә, ни түргә узарга белми аптырап калган Хәлилгә.— Ирең-фәлән түгелдер бит. Түгелме?.. Бәй, шаяртып кына әйтүем... Әй шул шәһәр катыннарын, шулай тоталармыни баланы. Бир әле үземә, бир. Бәй, шулай диими, ике бала үстереп очырды инде апаң. Игезәкләр ие, икесен тиң армиягә алдылар. Икесе бер частьтә хезмәт итәләр. Ирең кая эшли соң үзеңнең?..

— Иптәшем бик әйбәт кеше минем, апа.

— Бәй, Сездә иптәш буламыни ул ир дигәнең?

— Ипкә килгән ир булгач, иптәш инде,— дип көлде Гөлбикә.

— Китерерсең ул ирләрне ипкә. Аны ипкә китерә-китерә үзең ипсезләнеп бетәсең. Ирләр алар көйсезне көйләргә яраталар. Бер ходай үзе белә, ниемә аллаһы тәгалә шулай итеп яраткандыр. Иптән чыккан.

көйдән узган катын күрделәрме, күзләре тона. Минеке дә китте әнә, бер үксез катынга йортка керде. Катыны көйләнде, хәзер әнә үзе көйсезләнеп киткән, ди. Көн-төн эчә икән, алкаш булган, булнистларда ук ятып чыккан. Чыккач та тагын эчә башлаган, ди әнә. Шулай була ул кәефләрне кайли-койли. Хәзер әнә тегесе куа, монысы китми йөдәтә, ди. Милициягә әйтеп утыртам мин сине дип әйтеп әйтә, ди. Шулай ул дөньяда, акыллым, бер бетен, бер... күрсәтә дә тора. Сөйрәлчек ир-аттан сөелгәнче, сөелми яшәвең мең артык. Бәй, исеме ничек диден әле? Зөлфиямени әле син, бәбекәчем. Менә чәй дә кайнады. Хәзер табын хәстәрлим дә... Шундый буранда, я ходаем, бала белән тәвәккәлләп чыгуыңны да әйтер идем инде...

Хуҗа хатын тиз-тиз табын хәзерләде, өстәлгә әллә ниткән ризыкнигъмәтләр китереп куйды.

— Танышмадык та бит без, апа?

— Хатимә минем атым, акыллым. Җитешеп кенә утырыгыз әле. Син дә бер дә тартынып торма, егетем. Хатип кына әллә кая китеп югалды. Йөргән кызын алырга китkәндер инде. Концерт була бит бүген бездә, кызы шәһәрдә яши, шуны алырга киткәндер.

— Без дә концертка барырбыз дигән идек,— диде Хәлил.

— Бәй, бара гына күрегез. Балаң турында кайгырма, шундаен итәреп карармын... Беренчесеме?

— Әйе.

— Озакка сузма, рәттән икенчесен дә табып куй да рәхәтләнеп яшәрсең. Бер тапкач, үсә ул, илдә кеше түгел, чыпчык та үлми, диләр.

Чәй эчкәннән соң Гөлбикә баланы имезде дә урынга салды.

— Моннан егылмасмы икән соң, Хәтимә апа?

— Егылмый, егылмый. Үзем карармын, бер дә борчылма. Хәтимә апаң баш бала иде, җиде апаен карап үстерде. Тегеләрнең җылаулары бик аптыраганда буш күкрәгемне суырта торган идем...

Хәтимә караватта йоклап киткән бала тирәли мендәрләр салды.

— Апа, без чынлап та концертка барыр идек.

— Бәй, нинди сүз ди инде ул тагын. Барыгыз, бар... Бер дә борчылмагыз. Тушындый буранда Әлмәт кадәр Әлмәткә кил дә. Эшегезне дә әйтер идем инде, балакай.

Концертка җыенганда да, киенеп тышка чыккач та Гөлбикә хуҗа хатын әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә тырышып карады. «Эшегезне дә әйтер идем инде»,— дип кабатлады ул Хәлил белән янәшә атлаганда. Әйтәсеме, Якубы өйдә булган булса, җибәрер идеме шушындый озын юлга, авыз да ачтырмас иде. Ник шунда начальнигың алдына килеп тезләнми, җибәрмәс иде. Ә бит Гөлбикәне эшендә яраталар, ана ышаналар һәм өлкән ревизор Садрыйга кадәр аны хөрмәт итә. Бирегә җибәргәндә дә, кемне җибәрик, дип начальник аның белән киңәшкәч, Азатованы, дигән. Моны Гөлбикәгә сер итеп кенә начальникның секретаре әйтте. «Юк инде, Якуб, без икебез ике өлкәдә эшләсәк тә, максатыбыз бер шикелле миңа. Син бандитлар тотасың, мин исә каракларны фаш итәм».

Концертларга йөрүе дә аның җыр яратуыннан, үзенең дә җырларга теләвеннән иде. Мөслим Могамаев Казанга килгәч, Гөлбикә аның рәттән ике концертында булган иде. Үзебезнең Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова кебек җырчыларның концертларына йөрүе турында әйтеп торасы юк.

Килгәне өчен үкенмәде, ошады аңа концерт. Опера һәм балет театры артистлары да килгәннәр иде, рәхәтләнеп тыңлап утырды. Шунда, уйланып, җыр моңнарында күңеле тибрәлеп утырганда ул үзенә төбәлгән карашны тойды. Юк, ул аны күрмәде, эчке бер сизенү белән тоеп утырды, ахры. Күр әле бу Хәлилне, сәхнәдәге артистларга түгел, ә күз алмый Гөлбикәгә текәлеп утыра. «Әнә җырчыны тыңла, җүләрем, бер балалы

хатынга күзең төбәп утырма, яшьлегеңнең кадерен бел. Бая син Сария янында калмадың, ә мин сине кызгандым. Гомер ике килəме, тилекәй. Яшь гомерләр кире кайтмый, сулар үргә акса да, дип, тикмәгә генә җырламаганнардыр ата-бабаларыбыз».

Гөлбикә аңа ачулы караш ташлады. Чибәр иде егет. Дөрес, Галиябану Хәлиле үк түгел, шулай да коңгырт чәчле, саф ачык йөзле, зәңгәр күзле. Бөтен тотыш-кыяфәтендә гадилек, табигыйлек. Бер тапкыр аңа Якуб: «Гөлбикә, беләсеңме сиңа ни җитми? Табигыйлек»,— дигән иде. Нигә шулай диде икән? Нәрсә ул табигыйлек? Болай да гади тота кебек бит инде үзен. Туктале, нигә килде соң ул бу концертка Хәлил белән?.. Кайтам, кайтам, хәзер торам да китәм. Балам елыйдыр, Хәтимә апа орышадыр...

Гөлбикә әкрен генә күтәрелде дә ишеккә юнәлде. Тышта буран басылган, күк йөзе тулып йолдызлар җемелди иде. Аяк астында әллә ниткән көйләр чыгарып кар шыгырдый. Шунда ул үз аяк тавышы көенә икенче берәүнең килеп кушылуын ишетте.

— Мөмкин булырмы?

— Хәлил!

Хәлил Гөлбикәне култыкларга итте.

— Болай гына атлыйк, Хәлил, янәшә генә.

— Кая болай ашыгасыз?

— Балам янына, Хәлил, балам янына.

— Мин Сезнең өчен нигәдер гел куркып йөрим.

— Хәлил, мин Галиябану түгел, син Хәлил булсаң да... Нигә бу төчелек. При всем уважении к вам... Ишетәсезме, Сез минем белән ул апага кайтып кермисез, хакыгыз юк!

— Ярый, кайтмам. Мин Сезне озатып кына куям. Чит-ят җир...

— Авыл бит бу!

— Авылда да төрле хәлләр булгалый.

— Нинди кеше син, Хәлил?

— Обыкновенный, самый ни на есть обыкновенный.

— Минем ирем бар, балам. Ирем милициядә хезмәт итә.

— Мин милициядән курыкмыйм, чөнки минем ниятем изге.

— Я-я, нинди изге ният инде ул?

— Мин Сезне яратам.

— Ха-ха-ха, их-ма, егеткәй, бу бит тиле яшьлек хыялы. Узар ул, узачак. Кешегә күп вакытта ихласлык җитми, ди минем күршем Юлия Борисовна. Яраткан кеше яратуы турында авыз ачып әйтә аламы, тилекәй.

— Әгәр дә мәгәр ирегездән бүген китәм дисез икән, ике дә уйламый мин Сезгә өйләнәчәкмен.

Гөлбикә хәтта адымын акрынайта төште. Егетнең сүзләрендә шул кадәр ихласлык ята сыман тоелды аңа, туктап ук калды.

— Менә тиле димәсәң тиле инде. Беткәнме сиңа кызлар, балалы хатынга яратам димәсәң!

Гөлбикә аңа башка сүз әйтмәде, рәхәт иде, салкын кышкы һавада, атлавы. Көнозын котырган бураннан соң дөнья тынып калган. Күк йөзендә ай да йолдызлар, ни бер болыт кисәге булсын.

Алты почмаклы өйнең бар тәрәзәләрендә дә балкып утлар яна, бала күтәргән хуҗа хатын ишекле-түрле йөренә. Моны күргә, Гөлбикә адымнарын тизләтте. Хәлил, йөгереп менеп, болдыр ишеген ачты.

— Хәлил, син кермә инде, акыллым,— диде Гөлбикә.— Бар, гостиницага кайт. Хуҗа хатынның әллә ни уйлавы бар.

Бәхетенә каршы, бала бер дә елап карамаган иде, хуҗа хатын тәэсирләнеп китеп, ниндидер җыр мыгырдый, ә бала аңа кушылып «ә-ә-ә» дигән бер аваз суза.

— Әллә жырларга да өйрәнә инде бу кыз,— диде Гөлбикә, итекләрен салды да түргә узды.

— Башта кулларыңны җылыт,— диде хуҗа хатын, тавышын күтәрә төшебрәк.

— Хәзер, хәзер, апа җаным,— Гөлбикә җылы мичкә барып сыенды.— Менә җылындык та. Я, кил инде, кил, Зөлфия-ү, кызым.

Бала, үрсәләнеп, әннә-әннә, әннә, дип аңа үрелде.

Гөлбикә баланы кулына алды да, тынычланып, имезергә дип эчке якка кереп китте.

Баланың «ән-нә» дип өзгәләнүеннән Гөлбикәнең җаны эреп киткәндәй булды. Бу дөньяда балаңның шул бер «ән-нә» дигәне өчен дә яшәргә була. Гөлбикә Якубка кияүгә чыгуын, ир-ат белән хатын арасындагы матди тормышның ыгы-зыгысын, гаиләмәшәкатьләрен бер сүзгә — «әннә»гә кайтарып калдырды. Шул сүзне ишетер өчен генә дә тагын бер бала табып куярсың. Аннары балада үзенә генә хас булган тәмле ис Гөлбикәне дә иләсләндерер дәрәҗәгә җиткерә иде, кайчак аңа шул исне искәп кенә дә яшәп булыр сыман тоела башлый. Шундый мәлләрдә ул үзе дә сизмәстән моңсулана, ләкин бу — ана өчен үзе генә белгән рәхәт моңсулану, тынычлану, яшәү кадерен тою иде.

Яше дә тулмаган баласын күтәреп, Гөлбикәнең Әлмәткә барып кайтуын Якуб белми калды. Бәхеткә каршы Якуб кайтып җитмәгән иде әле. Гөлбикә кабаланып квартира ишеген ачты, юлда ук йокыга киткән баланы диванга салды да, бүлмәләрне йөреп чыкты. Аллага шөкер, барысы да үз урынында, ул ничек калдырып киткән булса, шулай тора. Беренче эше итеп, Гөлбикә бүлмәләрдәге мебельләрне дымсу чүпрәк белән сөртеп чыкты, аннары идәннәрне юды, шуннан гына күршесе Юлия Борисовнага кагылды. Күршесе аңа телеграмма тоттырды. Анда: «Ике атнага тоткарланам, Якуб»,— дип язылган иде. Гөлбикә телеграмманы тоткан килеш, квартирына әйләнеп керде. Керде дә шаккатты: баласы диваннан төшкән, идән уртасында басып тора иде. Димәк, юл йөрү файдага булган, тәпи йөри башладык, әнисе дә бераз дөнья күреп кайтты. Һәм ул янә Хәлил турында уйлап алды. Үз-үзенә ачуы чыкты. Нигә дип ул егет аның хәтеренә килеп керә?!. Шунда бала:

— Ән-нә! — дип аңа таба атлады.

— Кайттык, өйгә кайттык, Зөлфиякәй. Үз өебезгә. Әйдәле, кызым, тәпи-тәпи кил әле, кил, чишеник тә коенып алыйк, аннары түгәрәгеңә кереп утырырсың. Әтиең бүләге. Әтиең милиционер булгач, кешене кая яшерергә белә. Ә менә без икәүләшеп дөнья күреп кайттык. Шулаймы, Зөлфиякәй. Зөлфия-ү дим!

Баланы коендыргач, аш куеп җибәрде, радионы борды, өй эченә җыр моңы тулды, шуңамы, өй тагы да җанланып китте. Гөлбикә бөтенләй тынычланды, баягы куркуның эзе дә калмады. Якуб, өйдә булса да, берни әйтмәгән булыр иде булуын — шулай да әллә ничегрәк иде шунда.

Якуб, әйткәненчә, ике атнадан соң гына кайтып төште. Ире кайтып кергәч, Гөлбикә нигәдер башта аның таныш йөзен түгел, җилкәсендәге алтын погоннарын күрде. Менә шул алтын погоннар ниндидер мизгелдә ирне бөтенләй ят кеше итеп күрсәтте, һәм ул иренә килеп җитәр-җитмәс туктап калды. Сәер хәл, Якуб бөтенләй үзгәргән кебек, Гөлбикә гүя чит-ят берәүне күрә иде. Ияк очындагы чокыр да, батып торган яңаклары да, елмаюы да, өстендәге формасы да аның үзенеке түгел сыман. Ләкин бу икеләнеп калу, шикләнү Якуб телгә килүгә, шунда ук юкка чыкты.

— Гөлбикә, танымыйсың дамы әллә Якубыңны?

— Юу-к, Якубҗан! — Гөлбикә килеп ирнең күкрәгенә капланды күзләрен йомды. — Нигә болай озак йөрдең, Якуб?

— Беләсең бит инде минем эшне. Менә,— диде Якуб иңбашын жыера төшеп,— укыдым, майор иттеләр.

Якуб хатынын ныграк кысты бугай, күкрәк турында нәрсәдер шытырдап китте.

— Күзлек ватылды, ахры,— диде ир.— Күзлек кия башладым, күзлек алган идем. Я, ватылмагае. Ничек, кызыкаем исәнме?

— Үзе тәпи баса инде, әннә, ди.

— Әттә димимени?

— Әттәсе кайтып кына төште бит әле. Хатыны белән кызын шулай озаклап ташлап йөрсә, бөтенләй дә онытып куярлар әле үзен.

— Кая, кая әле үзе,— диде Якуб, ул хатынын тыңламый иде инде.— Кызым, Зөлфияү!.. — Тупакта уенчыклары белән мәш килеп утырган баланы кулына алды. — Кил әле, кил...

— Якуб, Якуб дим, нишләвең бу! Хет өстеңне салыр идең.

— Юк, салмыйм, погоннарны ул да күрсен. Менә, кызым, кара әле әтиеңнең погоннарын. Кем булды әтиең?

Ата кызының кул бармакларын берәм-берәм үбеп чыкты.

— Якуб, дим, сал өстеңне башта.

— Күр әле, күрче берәүне, әнисе, тагы да теш чыгарып ятабыз икән бит әле. Харап икән эшләр. Утырып тор әле, кызым. Мин хәзер. Беләсеңме мин сиңа ни алып кайттым. Тиң-тиң курчак,— баланы куйды, тиз генә өстен салды, чемоданын ачып, тиң-тиң итеп кыңгырау уйнап торган курчакны бала янына куйды, селкетеп җибәрде. Курчак чайкалган саен моңлы кыңгырау тавышы чыкты, моны ишеткән бала шым булды, аннары: «Тәт-тә»,— диде.

— Ай аллам, ни ди бит әле, әттә ди, күрче, Бикә, моны!..

Гөлбикә аңа һаман аптырабрак карап тора иде.

— Ә син, Якубҗан, үзгәргәнсең димме. Формаңмы, погоннарыңмы үзгәрткән үзеңне.

— Капитан погоннарын күргәч тә шулай дигән идең башта, боларына даияләнерсең әле. Я, килешәме?

Якуб төз гәүдәсен тагы да турайта төшеп, ишекле-түрле йөреп килде.

— Барыбер әллә ничек шунда...

Шулай дисә дә, Гөлбикә бик яхшы белә иде, хикмәт формада түгел, гомумән, хикмәт ирдә түгел, Гөлбикәнең үзендә иде. Хатын ирен кем беләндер чагыштырды бугай, кисәк кенә ул үзеннән-үзе уңайсызланып китте. Һәм моңа үзе дә курка калды. Чит кеше белән концертка баруын ире беләдер шикелле тоелды, шуңа оялып китте. Хатынның бу халәтен ир сизеп алдымы, шикләнебрәк карагандай булды. Ирнең бу карашын хатын күтәрә алмады, күзләрен яшерде, нindидер эш табып китеп барды.

— Бикә, Бикә дим, әллә ул-бу булдымы? Нигә алай?..

Якуб аңа ияреп кухняга керде.

— Берни дә булмады, чәй әзерләргә чыктым. Коймак куйган идем.

Якубны хәзер эшенә машина белән генә килеп ала башладылар. Ул эшендә артык тоткарланмый, үз вакытында кайта, тоткарланган көннәрендә Гөлбикәгә алдан шалтыратып әйтеп куя. Гөлбикә аны аш пешереп көтеп алды, булдыра алган кадәр тәмле ризыклар хәстәрләде. Ир ул пешергән ризыкларны ашады, әмма мактап бер сүз дә әйтмәде, әйтерсең шулай булырга тиеш, әйтерсең хатынның семьядагы вазифасы гелән шуннан гыйбарәт иде. Мондый хәлләр кабатлана торган саен

Гөлбикәнең күңеле кимсенде, үпкәләгән чаклары да булгалады. Дөрес, ире Якубтан тәмле ризыклар хәзерләгәне өчен рәхмәт көтмәде, ирләр тәмле ашарга бик тиз өйрәнә икән, ул иренә эше турында сорашмаганы өчен үпкәле иде. Балага бер яшь тулды, яслегә биреп була, Гөлбикәгә дә эшли башларга вакыт. Ә ир бу турыда ләм-мим. Айга якын бу турыда дәшми-тынмый йөргәч, көннәрдән бер көнне Гөлбикәнең дә буасы ташыды, эштән гадәттәгедән соңрак калып кайткан иренә ул:

— Синең генә эшең эш, башкалар сиңа кем дә түгел, өй хозяйкасы,— дип пырлап китте.

— Ни булды сиңа, әнисе,— дигән булды Якуб, белмәгәнгә сабышып.— Я, ни җитми тагын сиңа? Өстең бөтен, квартираң адашырлык.

— Мине бер томанага санныйсың бугай син, Якубҗан. Минем дә бит эшем бар. Минем дә кеше арасында буласым килә, эшлисем килә.

— Җитмәсме икән, балаңны кая куймакчысың?

— Яслегә урнаштыр.

— Урнаштыр. Ярый, урнаштырдым да ди. Шуннан ни? Бер яшьлек балаңны ташлап, шәһәрдән-шәһәргә ревизиягә йөрерсеңме?

— Иң әүвәл балаң түгел, балабыз, хөрмәтлем Якубҗан. Ә инде балабыз булгач, син дә җарый аласың. Атасымы син ул баланың, юкмы?

— Я-я, нигә әле син буза куптарасың? — ир хатын янына килде, иценнән кочты.— Начармы сиңа өйдә. Бала бераз үсә төшсен, яслегә бирденме авырый башлар, башың больницадан чыкмас.

— Нигә әле бала белән больницага мин ятарга тиеш? Нигә син түгел?

— Ну-у, әнисе, ни дигән сүз инде ул тагын. Кем инде...

— Син, Якубҗан, син.

— Ярый, ятармын,— диде ир һәм читкә китеп утырды.

Ир шундый төсмер белән әйтте бу сүзләрен, әйтерсең, чит-ят бер кеше турында сүз бара иде.

— Ярый,— диде Гөлбикә,— ярый, Якубҗан, син дигәнчә итәрмен.— Шулай диюгә, аның эче жу итеп китте. Кичә ул гинекологка барган иде, врач аңа: «Балага узгансыз»,— диде. Һәм иң гаҗәбе: табарга киңәш итте. Имеш, рәттән ике бала табып куясыз да, аннары җырлап йөрсәгез дә була. Семья булгач, кимендә өч бала кирәк, дип котыртты хәтта. Гөлбикә аның белән килеште дә, килешмәде дә. Килеште — семья булгач, чынлап та бала кирәк инде ул, килешмәде — күңелен эше тарта, ә бала табарга ният итсә, янә ике елга эштән аерылачак. Җан эчендә җан яралганда үз мәнфәгатең өчен җан ату хатын-кызга килешми, дигән булды врач. Ул аны Гөлбикәнең икеләнеп калуыннан, төс-йөзе алышынып китүеннән күреп әйтте бугай. Врачның шул сүзе Гөлбикәне тетрәндереп җибәрде. Ә бит ул аңарга справка сорарга дип килгән иде. Гөлбикә врачтан дәшми-тынмый гына чыгып китте, юл буена шул турыда уйланып кайтты. Әмма Якуб белән эш турында сүз кузгаткач, ул аңа врачта булуы турында әйтергә онытып җибәргән иде.

Ул торды, ире янына килде. Аның тезенә утырып:

— Җүләрем, юри генә әйттем ич мин сиңа. Беләсеңме, беләсеңме нинди сөенче әйтәм мин сиңа хәзер. Тагын бер балабыз булачак безнең. Бу юлы малай табам...

Кай арада Якуб сикереп торды, кай арада Гөлбикәне кулына күтәреп алды һәм кай арада зырылдатып әйләндерә башлады...

## 3

Икенче баласын алырга Якуб ике яшь тә тулмаган Зөлфияне күтәреп килде. Ир кулында яшь бала күреп, икенче кызын алырга килгән атага ишек янында торган хатын:

— Ашыга халык, ни дип ашыгадыр,— дип үзалдына сөйләнеп калды. Ике баласын ике кулына күтәреп бала табу йортыннан чыгып барган Якуб бу сүзләрне ишетсә ишетте, ишетмәсә юк. Ул шат иде. Гөлбикәсе ирен чите белән елмая. Иренә малай табам дигән иде, кыз булды. Ә Якубҗаны барыбер шат.

Машинага утыргач, Якуб баланың йөзен ача башлады.

— Кирәкмәс, Якубҗан, җил кагылыр.

Подъезд төбендә аларны Юлия Борисовна көтеп тора иде.

— Я ходаем, әйткән булсагыз ни була иде инде, бала белән үзем калган булыр идем,— диде Юлия Борисовна, машина тирәли кабаланып йөренде.

Башта ук бәбинең битен күрәсем килә, дип Якубның теңкәсенә тигән Зөлфия, баланы өйгә алып кереп, караватка салуга:

— Бәбәй, инәки бәбәй алып кайтты,— дип бала янында бөтереләбашлады. Гөлбикә түзмәде, әллә сагынудан, әллә инде исән-сау өйгә кайтып керүдән Зөлфиясен кочаклап алды да елап җибәрде. Якуб белән Юлия Борисовна моңа аптырабрак калдылар.

— Куанычтан бу, Юлия Борисовна, куанычтан, борчылмагыз,— диде Гөлбикә.

Аннары ул нәнине кулына алды, имезергә вакыт дип, баланың чүпрәкләрен сүтә башлады. Моны күзәтеп торган Зөлфия нигәдер күпсенә төште.

— Инәки, мәм-мәм минеке, бәбинеке түгел,— дип еларга тотынды. Әтисе аны юатып та карады, кулына алды, ул бит кечкенә, дигән булды, әмма Зөлфия һични аңларга теләмәде, ул, күрәсең, имчәк капкан баладан көнләшә иде.

— Китсен бәби, кирәкми,— дип үртәлде Зөлфия.

Тышта июль ае булса да Юлия Борисовна ишек-тәрәзәләрне тикшереп чыкты, янәсе, җил кермиме, балага җил кагылуы бар.

Диванда бала имезеп утырган Гөлбикә авыр сулап куйды. Күзләре белән Якубны эзләде. Ире бала чүпрәкләрен рәтли иде, хатынының карашын үзендә тоеп елмайды.

— Менә бер өйдә өч хатын-кыз булдык. Үсик кенә әле, әткәй, күрмәгәнеңне күрсәтербез,— диде Гөлбикә. Якуб, эшен ташлап, хатыны каршына килеп тезләнде.

— Гөлбикә, менә дигән итеп яшәрбез. Кызлар булса ни, үртәләм дип уйлавың түгелдер бит?

— Мин вәгъдәмне үтәдем, Якуб, ике бала таптым.

Якуб бер сүз дә әйтмәде, баланың имүен күзәтте. Аннары:

— Күр моны, ни тамаша күкрәккә ябышкан, чынлап та милиционер булыр бу,— дип көлде.

— Кыз кеше — милиционер. Кит әле, сөйләмә тузга язмаганны!

— Нигә, менә дигән хатын-кызлар эшли милициядә.

— Сиңа ошагач, шәпләрдер инде.

— Шәпләр,— диде ир, үртәлгәндәй,— ләкин берсен дә сиңа алыштырмас идем.

— Ярый, Якубҗан, шаяртмасаң мең рәхмәт, инде шаяртсаң...

Гөлбикә бүлмәне күздән кичерде, күптән таныш, кадерле әйберләрне күрүгә, күзләре янә дымланып чыкты. Якуб Ленинградтан алып кайткан люстрадан, почмактагы телевизор өстендәге сөяктән ясалган чебурашкадан, буфеттагы савыт-сабалардан, өйдәге һәммә нәрсәдән, комодта яткан сәдәфләр савытыннан башка да тормышын хәтта күз алдына да китерәсе килми иде. Ул сәдәфләр савытында ниләр генә юк, булавкалар, төсле төймәләр, алтын кармаклар дисеңме, хәтта Зөлфиянең имезлек боҗрасы да шунда ята — аларның барысы да кадерле иде Гөлбикәгә. Алардан аның аерыласы килми, шушы квартирадан да, ире Якуб-

тан да. Үзе тапты ул аны, үзе «өйләнде». Беркемгә дә бирмәячәк ул Якубын. Тукта әле, ниләр уйлап утырган буласың тагын. Кем аннан ала Якубын? Кем?! Беркем дә алмый, алырга да җыенмый...

Гөлбикә бала чүпрәкләре юучы Юлия Борисовнага, кухняда чәй куеп мәш килгән иренең хәрәкәтләренә колак салды. Кисәк аңа рәхәт булып китте. Нәкъ менә шулай булганга рәхәт иде аңа. Бала еламый гына имә, өйдә тынычлык.

Гөлбикә беркайчан да һуштан язардай хәлгә җитеп әйбер дигәнгә мөкиббән китмәде. Әмма үзе тапкан әйбер аңа гаять кадерле иде, сатып алган бер сәдәфе генә югалса да өй бетереп эзләде, кәефе кырылды. Хатынының бу гадәтен белеп алган Якуб, алган әйберләрен һәрчак кире үз урынына куярга тырышты. Күп вакытта ир вак-төяккә кагылмый, Гөлбикәнең үзеннән сорап ала. Өйдәге вак-төяк әйберләрне туздыручы хәзер Зөлфия. Шуның өчен, әниләре кайтыр алдыннан, Якуб, кызы белән икәүләп (тегесе аңламаса да), бар әйберне дә Гөлбикә больницага киткәндәгечә итеп җыештырып куйды. Өйдәге пөхтәлек хатынның да күзенә чагылмый калмады, әлбәттә. Баланы караватына салгач, Гөлбикә бүлмәләрне йөреп чыкты. Әйе, бар нәрсә дә үз урынында иде. Хәтта мендәрләрне дә Якуб нәкъ аныңча кабартып куйган, япманы да фәкать Гөлбикәчә итеп япкан. Тәрәзә төбендәге гөлләр генә Гөлбикәгә урыныннан кузгатылган сыман тоелды. Гөлбикә тәрәзә катына килде, гөл савытларын күчергәли башлады. Шунда аның кулына алтын булавка әләкте. Мондый булавканы Гөлбикәнең күргәне дә юк иде әле. Булавка чит илнеке иде ахры. Гөлбикә, нигәдер, булавканы иснәп тә карады. Французларның «Фидже» хушбуй исләре килә иде ул булавкадан. Гөлбикә андый хушбуйны Юлия Борисовнада күргән иде, исе шундый татлы, күңелгә рәхәт иде ки, хәтта бәләкәй генә сөртеп тә караган иде. Нәкъ шул «Фидже» исе. Димәк, бу булавка бөтенләй чит бер хатынныкы һәм ул биредә булып киткән? Авылга баргач бер хатын аңа: «Ирләргә ышанма, Иделгә таянма»,— дигән иде. Моңа каршы Гөлбикә көлде генә. Ул үз ирен зур урындагы кеше итеп белә, аның кыек юлларда йөрергә вакыты да юк, дәрәҗәсе дә кушмый, дип уйлый иде. Бактың исә, аның ире дә изгеләрдән түгел икән. Җитмәсә палатада ятучы хатыннарга Гөлбикә: «Минем ирем — изгеләрнең изгесе», — дип мактанган иде. Димәк, юкка мактанган булып чыга, Якубның да кемедер бар.

— Гөлбикә, кая син, әйдәгез чәйләп алыйк.— Якуб хатыны янына килде, иңеннән иплэп кенә кочты һәм кухня ягына алып чыгып китте.— Хәлең юк димме, әнисе?..

Гөлбикә Якубның күзләренә сынап, текәлеп карады.

Якуб ир-аттагы фәкать өч сыйфатны таный: яраткан хезмәте, тату гаиләсе, чын дуслары булса, бу ир — бәхетле. Болардан мәхрүм ителгән ир кеше чын мәгънәсендә ир-ат була алмый, аңа һәрчак нәрсәдер җитми. Ә менә Якубның барысы да ул дигәнчә бара. Гөлбикәне ярата, хатыны аңа менә дигән ике кыз табып бирде. Юк, Якуб үзен һич кенә дә заман арбасыннан төшеп калган ир-ат исәбенә кертәсе килми. Кыскасы, Якуб җиргә нык басып, хезмәтендә бик тиз уңышларга ирешеп, үсеп килгән ир уртасы иде. Шушындый ирдән дә канәгать булмасамы Гөлбикә?! Сабыр, сабыр, кем әле аңа: «Хатын-кызга синең дәрәҗәң кирәкми (дөрес, ирен яраткан хатын-кызга диде бугай), ә синең аны яратуың кирәк»,— дигән иде. Кем әйтсә дә барыбер түгелмени, хак әйткән, шул гына. Беренче баласын табып та өлгермәде Гөлбикәсе, Якубны укырга җибәрделәр. Аннан ул майор дәрәҗәсе алып кайтты. Майор. Бу дәрәҗә аңа күп нәрсәләр йөкли иде. Гомумән, ул эшеннән канәгать, бәхетле иде. Тик күңел дигәнең гаять сизгер нәрсә икән бит, бала табу йортыннан икенче баласын алып кайтуга, Гөлбикәсе кинәт кенә үзгәрде дә куйды. Моны, әлбәттә, ир күрми-сизми калмады.

Булавка турындагы хәлне ачыклау күршеләре Юлия Борисовна чыгып киткәч башланды. Бала эчке бүлмәдә йоклый, Гөлбикә алтын булавканы өстәл уртасына салды. Янәсе, бак әле шуңа, Якубҗан, каян килеп кергән булыр бу хикмәтле әйбер безгә. Якуб һичнн аңламый өстәл уртасында яткан булавкага карап торды. Ул шунда ук эшенең асылына төшенде, ләкин юри белмәмешкә салышты. Булавканы, әлбәттә, Вәсилә Хакова калдырган булса кирәк, шушы бүлмәне ул җыештырып маташкан иде. Ләкин Якубның намусы саф. Вәсилә Хакова күршеләре Юлия Борисовна монда чакта килде һәм ул монда чакта ук чыгып та китте. Әмма, барыбер булавканы күргәч, тәгаен каушап калды ир.

Милиция капитаны Вәсилә Хакова өйне җыештырырга, ярдәмгә дип килгән иде. Килеп керүе булды, Юлия Борисовнаның идәннәр юып йөрүен күрде һәм шунда ук рөхсәт сорамый-нитми өстен алыштырды да, тәрәзәләрне юарга кереште. Тәрәзәләргә бик нык тузан кунган иде. Аларның бу эшкә ныклап керешүләрен күреп, Якуб үзе дә булышты. Гөлбикәсе ялтырап торган өйгә кайтып керсен әле. Бу идеяне аңа Юлия Борисовна биргән иде. Ләкин аның бер үзенә шул хәтле эшне башкарып чыгу турында уйлап та карарга түгел иде. Вәсилә кайдандыр Гөлбикәнең халатын табып алып киде. Шул халаттан бүлмәдән бүлмәгә йөри башлагач, Якуб әллә нишләп киткән иде. Әйтерсең, өйгә Гөлбикә үзе кайтып кергән, әйтерсең, халат кигән Вәсилә Хакова түгел, хатыны Гөлбикә иде.

Бәлкем, нәкъ менә шуңа Гөлбикәгә биредә Вәсилә Хакованың булуы турында әйтергә курыккандыр? Бик ихтимал ич. Болай да шиккә калган хатынның әллә ни уйлап куюы бар. Якуб булавканы кулына алды, әйләндереп-тулгандырып караштырды. Гамьсез калырга теләде, гамьсез кыланды.

— Ни карап каттың. Танымагандай буласыңмы?! Онытып калдырдымыни? Сөяркәң дим...

— Нинди сөяркә ул тагын?

— Алтын булавка хуҗасы, чит ил кәнтәеме әллә үзе, килде дә киттеме? Ленинградныкымы? Хатының больниска ятуга, чакырып та өлгердеңме?..

Өй-бүлмәләргә тулып шатлык кайтканда көтмәгәндә әллә ниткән ачу китергеч, ул гынамы, күңел рәнҗеткеч нәрсәләр турында сөйләшеп утыру Якубның күңелен кимсетте. Ул ни кылырга белмәстән бер мәлгә телсез калды. Ләкин бер гаебе булмагангамы, Якубның ачуы кабара башлады. Кем белә,ниләр әйтеп ташламас иде ир-ат кызу баштан, әмма нидер сизенгән кебек, янәдән әйләнеп Юлия Борисовна килеп керде.

— Уянмадымы? — диде ул шыпырт кына. Ишекне киң ачып кечкенә көпчәкле бәләкәй арба кертте.— Миннән бүләк бу наныйга.

— Юлия Борисовна,— дип сикереп торды Якуб, сәбәп чыгуга шатланып.— Бу ни дигән сүз инде. Мин бит үзем дә шушындый ук коляска заказать иткән идем. Күр инде берәүне.

— Чү-ү, баланы уятасың, шауламa. Гөлбикә, имезергә вакыт житте түгелме?

— Кәефе юк әле аның,— диде Якуб.

— Юләр баш, түбәң күккә тияр вакытта. Ни булды? — дип сорады Юлия Борисовна таләпчән һәм басынкы тавыш белән.

— Ни булсын, менә тәрәзә төбеннән алтын булавка тапкан.

— Шуннан?

— Шуннан шул инде. Имеш, миндә шул булавканың хуҗасы булган. Нindидер хатын-кыз...

Дөньяда күп җәнҗаллар, бинахакка рәнҗетелүләр күргән Юлия Борисовна, тәҗрибәле кеше буларак, эшнең асылына шунда ук төшенеп алды. Ул башта Гөлбикәгә карады. Хатынның аскы ирене бүлтәеп чыккан, кашы-күзе җимерелгән, өстәлгә караган да утыра бирә. Аннары

Юлия Борисовна Якубка карады һәм аның йөзендә каушау күреп, тизрәк ярдәмгә ашыкты.

— Акылың җуйма, җуләркәем, булавка минеке,— дип изге ялганга керешге Юлия Борисовна.— Минеке. Николай Юрьевич алып биргән бүләк. Кая куйдым икән дип, өй бетереп эзләдем. Юк кына. Тәрәзәләрең юган идем бит, шунда алып куйган булганмын, күрәсең. Югалды дип, котларым алынган иде. Рәхмәт инде. Сөенчегә ни бирим? Кайсыгыз тапты?

— Мин,— диде Гөлбикә һәм торып, бала янына чыгып китте. Якуб белән Юлия Борисовна күзгә-күз карашып алдылар.

— Теге хатынныкымы? — дип сорады пышылдап кына Юлия Борисовна.

— Юлия Борисовна, бу ни дигән сүз инде тагын! Аныкы булса соң...

— Бетте, бетте. Әйдә, янына керәбез.

Якуб иркен сулап куйды. Әмма ни генә булмасын, күңел түрендә әллә ниткән рәнҗү кебегрәк бер нәрсә кереп укмашкан иде. Бала имезеп утырган Гөлбикә янына кергәч, Гөлбикә аңа теләр-теләмәс кенә елмаеп алды. Бу елмаюдан шуны аңлады Якуб: Гөлбикә Юлия Борисовнаның сүзләренә ышанып җитмәде. Еллар буена бер семьядай торып, бер күрмәсә бер күргән булыр иде Гөлбикә аны. Ә Юлия Борисовнаның моңа кадәр ул алтын булавканы күрсәткәне, чәченә кадаганы да булмавы аның өчен сәер иде.

Якуб эшкә ашыкты. Коридорга чыккач ул:

— Юлия Борисовна, кадерлем, алтын кеше сез, Юлия Борисовна,— диде.

— Алтын түгел, көмеш тә була алмадым шул, Якубҗан. Я, бар, борчылма, иң мөһиме үз күңелең саф булсын...

4

Сәер хәл кичерә иде Якуб. Элек аның Вәсилә Хаковага күтәрелеп караганы да булмады. Гөлбикә аның булавкасын тәрәзә төбеннән тапкач, үзе дә сизмәстән бу хатынга карата әллә ниткән кызыксыну уянуын тойды ул. Башта Вәсилә Хакова аңардан алтын булавка турында үзе сорар дип өмет итеп йөрде. Соңыннан Хакова һични югалтмаган кебек йөрүен дәвам иткәч, аны бердәнбер көнне үзенең кабинетына чакырып алды.

— Бәлкем, үзегез керерсез, иптәш майор,— дип шаяртты Вәсилә.

— Була ул,— дигән булды Якуб, әмма кузгалмады. Аларның дәрәҗәләре бер түгел, кем кемгә керсә дә барыбер түгел иде. Шулай да Якуб ир-ат бит, ә ул хатын-кыз. Димәк, аңа барырга туры килер.

Якуб өстәл артыннан торып кузгалган гына иде, кабинетка, ялтырап, Хакова үзе килеп керде.

Өйдә булып алган хәлдән Якуб әле булса тынычланып җитмәгән иде. Гөлбикә аны бинахакка рәнҗетте, бөтенләй булмаган хәлне булган дип исбатларга тырышты. Гөлбикә алдында аның гөнаһы юк иде, әмма Якубта барыбер ниндидер борчу кузгалды. Шактый еллар тикшерүче булып эшләгән кеше өчен сәер хәл иде бу. Югыйсә бит аның гаебе юк, әмма ул үзен гаепле кеше кебек тоя. Димәк, бик күп тапкырлар гел бер нәрсә турында тукып торсалар, бер гаепсез кеше дә үзен гаепле кеше кебек хис итә башлый икән. Кечкенә генә бер деталь: аның үзен гаепләү өчен булавка да бик җиткән булып чыкты.

Чынлап та, һич булмаган нәрсәдә гаеплиләр ич аны һәм, әйтергә кирәк, республиканың шактый тәҗрибәле тикшерүчесе шушы нәрсәгә гаҗәпләнеп утыра, җитмәсә (бусы инде үз-үзен акларга теләп булса кирәк), шушы эштә мыскал да гөнаһы булмаган Вәсилә Хакованы үзе-

нə чакырды. Ни əйтə ала ул аңа? Алтын булавкагызны бездə калдыр гансыз диярме? Ə ул сиңа: «Əйе шул, бирегез əле, мин аны дөнья бете реп эзлим», дисə. Ə ул булавка Юлия Борисовнада бит əлегə.

Битеңə бəреп əйтерлек гаепме? Юк. Əмма күңелне əллə ни кымть рыклап тора. Вəсилə Хакованы ул бары тик ярдəмгə, өй җыештырырг чакырды. Бер мəктəпне тəмамлаган кешелəр, бер университетта укыдь лар. Бер бүлектə эшлилəр; Вəсилə Хакова аның дусты, хезмəттəше, фи кердəше иде, фəкать шул. Хак анысы, шəхси тормышыннан сабакта шына зарланган чаклары да булгалады. Мəгəр зарланса да үзен кыз гандырырлык итмəде. Хатын-кыз ир-атны кызганмаска тиеш, дип бар иде Якуб, тол хатыннан үзен кызгандырасы килми иде аның. Беркөнн өй тəмам ат абзары булды, бүлмəлəрне җыештырырга кул җитми, ди зарлангач, Хакова килеп булышырга булды. Бик күңелле иде югыйсə Ялтырап калган бүлмəлəргə тиздəн бəби кайтачак. Соңыннан бергəлə чəй эчтелəр. Вəсилə Хакова, əлбəттə, алтын булавканы тəрəзə төбенд юри калдырмагандыр, мөмкин хəл түгел бу.

Шулай уйланып торганда кабинетка Вəсилə Хакова килеп керде.

— Якубҗан, əйдə миңа керəбез, чəй сораттым, чəй эчə-эчə сөйлə шербез.

— Ə-ə, хəзер,— диде Якуб.— Гел онытылып киткəнмен.

— Кем белəн котлыйм үзеңне?

— Кыз инде. Артыгына ярамадык булып чыга...

— Хəзерге заман ата-анасы өчен иң зур хəзинə — ул кыз бала, Якубҗан.

Хакова аңа Якубҗан дип үзлəрендə өй җыештырып киткəч əйтə башлады. Күрəсең, Юлия Борисовнадан отып калгандыр. Энə карагы хəтле алтын булавканы хатыны дөя итеп күрмəгəн булса, бəлкем əле Якуб Вəсилəне кабинетына чакырмаган да булыр иде, ул гынамы, аңа чəй эчəргə кермəгəн дə булыр иде. Аның күңелендə үҗəтлек хисе кабын ды. Юк, үҗəтлек тə түгел иде бу, элек-электəн үк күңел түрендə йөрт кəн телəгенең тышавын чишеп җибəрергə телəве иде бугай. Хатын-кыз га соклану һəр ир-атка хас сыйфат, лəкин əле моны мəхəббəт дип əйтеп булмый. Соклану үтүчəн, мəхəббəт үтмəскə дə мөмкин. Вəсилəгə моңа кадəр Якуб сокланып кына йөргəн иде. Ə менə кичəле-бүгенле ул телə сə-телəмəсə дə Вəсилə турында уйлап йөри башлады. Бу соклануда ма выгуга хас нəрсə юк, Вəсилə аның белəн дөньяви хəллəр турында сөй лəшми, ана яңа келəм дə, чех хрустальлəре дə, ГДР стенкасы да ки рəкми, сувенирлар да җыймый ул хатын, Якуб белəн гел эш турында гына сөйлəшə иде.

Вəсилə Хакова кабинетына чəй эчəргə кергəч тə сөйлəшү эш хəллə ре турында барды. Якуб аңардан булавка турында берничə тапкыр со рарга дип ымсынса да, ни сəбəптəндер, сорый алмады, чəй өчен рəхмəт əйтеп чыгып китте.

...Иртəнге эш сəгатьлəре бик тиз уза, оператив сводкалар белəн та нышып алган арада Якуб янына берничə тапкыр тикшерүче Хикмəтул ла кереп чыкты. Гомерен тикшерүче булып уздырган бу кеше һəр җи наятьченең исемен, фамилиясен, хəтта ата-аналарын да хəтердəн белə иде. Феноменаль хəтерле тикшерүче буларак, күп кеше аңардан киңəш сорый. Якуб эшкə килгəч, җитмəсə аның кабинеты белəн янəшə урнаш кач, Хикмəтулла аңа еш кына керə торган булып китте. Ик-өч ел элек хатынын җирлəгəн Хикмəтулла бер ялгызы яши, бер үзенə күңелсез булгангадыр, күп вакытын эштə уздыра һəм аның Вəсилə Хаковага карата булган җылы мөнəсəбəтен барысы да сизə иде. Хатын риза булса, ул аңа ике дə уйламыйча өйлəнəчəк, əмма Вəсилə Хакова ни сə бəпледер Хикмəтулла белəн рəтлəп сөйлəшми, хəтта бүтəннəр кебек өлкəн тикшерүче янына киңəшкə дə керми иде. Бу турыда белгəн Якуб бер сүз белəн: «Яратмый ул аны»,— дигəн нəтиҗəгə килде.

Хикмәтуллага илле яшь тирәсе, кирәкмәгән зур борынлы, озынча ияклы, бит-йөзен гел борыны каплап тора сыман, иреннәре калын, яшькелт-соры күзләре тирәнгә кереп утырганнар. Чәченә чал кергәнен гел белмәле түгел, бакыр сары колакларын локатор канатлары диярсең. Шунысы гаҗәп, шушы зур башлы ирдә бөтенләй нечкә хатын-кыз тавышы иде. Борыны, йөзе, баш тирәсе зур булгангамы, әүвәл аңа бу тавыш моңардан чыгамы дип шикләнебрәк карыйлар. Әмма нишләмәк кирәк, тавыш шушы хөрмәткә ия, тәҗрибәле ир-аттан чыга иде. Якубка калса, Васил Хакова аны нәкъ менә шул нечкә тавышы өчен яратмыйдыр шикелле.

— Якуб, әйдә ашап киләбез, әллә нигә кәеф китеп тора,— диде ул кабинетка килеп керүгә түр яктагы креслога чумып.

— Хәзер, Хикмәтулла абый.

— Абый ук түгел әле мин сиңа, Якубҗан. Яшь арабыз нибарысы биш ел. Син бәхетле, Якубҗан. Синең ике балаң бар. Ә мин үземнең хатын белән егерме елга якын яшәдем, бер бала китереп куандыра алмады, мәрхүмә. Ә бит ир-ат хатын-кызга бала өчен дип өйләнә. Менә кайбер хатыннар шуны аңламый, мать якасына. Ир белән яшиләр, бала тапмыйлар. Синең хатын ул яктан уңган булып чыкты, берсе артыннан берсен китереп кенә тора. Күпләргә тәтемәгән бәхет ул, Якубҗан. Я, барасыңмы әбиткә. Васил Хакова китеп тә барыр. Бергәләп утырасы иде. Теләсәң ни уйла, Якубҗан, мин ул хатынга гашыйк. Менә мин аның белән яшәр идем...

Якуб эшен бер читкә куеп, Хикмәтуллага карады.

— Шулай дисең инде, ә, Хикмәтулла абзый.

— Әйтмә әле шул абзыеңны, ачу китереп. Абзый да абзый. Картайтып бетердегез инде шулай дип. Борын зур дигәч тә, борынга карап кына картаймыйдыр бит инде кеше!? Юктыр бит?!

Икәүләшеп көлештеләр.

— Ә шулай да әйт әле, Хикмәтулла абзый, кыенмы бер ялгызың яшәве?

— Ялгыз калган кеше аккош белән бер икән ул. Ялгызлык картайта мине хәзер, Якубҗан. Ә күңел яшь, шайтан алгыры. Хәтта яшьләргә күз төшә. Чыкмый бит әнә шул Хакова үзәмә, югыйсә сиздереп тә караган идем. Башта хатынымның кырыгы үтсен, дигән булды, аннары елы, хәзер әнә гел дәшми, әйтер сүзе калмады, күрәсең.

— Әйтер әле, сабыр ит.

— Әйтер сиңа, сизмиммени, тикшерүче лә мин. Алай да шайтан өметсез диләрме әле, мин көтәргә булдым. Хатын-кызның күңеле гел эт кояшы кебек бит ул, җайланыр әле бер.

— Җайланыр, җайланыр, Хикмәтулла абзый. Әйтте диярсең, җайланыр, чөнки яраткан кешең ихлас булса, киткән коштай бер кайта ул,— диде Якуб. — Хакованы алабызмы соң?

— Алсак шәп булыр иде, һич югы күзенә карап утырыр идем, чибәр хатын, гел алиһә инде менә. Нишләп ире белән торалмагандыр, бер Алла белә.

Ишектән чыгулары булды, аларга Васил Хакова очрады.

— Менә ичмасам бәхет,— диде Хикмәтулла.— Көткәннең кулына, чыгарып салыр юлына, диләрме әле. Исәнмесез, Васил ханым. Менә син шуңа игътибар ит әле, Якубҗан. Мин дә Хаков, ул да Хакова. Минем әтинең исеме Хакович, Василәнең дә Хаковна. Уйлабрак карасаң, без Васил Хаковна белән бер җепкә уралганбыз. Хаков, Хакова, житмәсә, икебез дә милиция капитаны. Дөрес, мин өлкән тикшерүче, ләкин моннан ни үзгәрә, башкарган эшебез бер, максатыбыз бер, тик теләкләр генә икебезнеке ике...

Хакова формадан түгел иде. Өстендә зәңгәр йон күлмәк, аякларында биек үкчәле туфлиләр. Муенында гәрәбә муенса, колакларында да

гага охшатып ясалган алтын алкалар, чәчен күпертеп, бик килештереп, баш түбәсенә өеп куйган, күз төпләренә сизелер-сизелмәс кенә шәмәхә иңдерелгән, иреннәрендә чия төсендәге помада. Мондый киемдә сирәк күренгәнгәме, Хакова Якубка бүген аерата чибәр күренде, ул хәтта һич урынсызга Хикмәтуллага карата көнләшү кебек бер нәрсә тойды.

— Бүген ашханәдә балык кына,— диде Вәсилә Хаковна.

— Балык әйбәт ул. Фосфор баш мие өчен бик кирәк матдә.

— Сез ул фосфорны күбрәк тә кулланасыз бугай, Хикмәтулла Хакович?

— Алай димәс идем. Узынган юк кебек. Менә Якубҗан артыграк ашый булса кирәк ул балык дигән ризыкны. Озын колаклардан ишеттем, имеш, аны тагын укырга җибәрәчәкләр, алты айга диме.

— Кайтып өлгермәде,— диде Хакова гаҗәпләнүен яшермичә.

— Бер үсә башладымы, үсә дә үсә инде ул кеше дигәнең.

Бу турыда Якуб үзе дә беренче авыздан ишетә иде. Тагын уку тисә шәп булыр иде ул, тик Гөлбикә риза булырмы? Болай да укудан башы кайтып кергәне юк.

— Кызлар үсәме, Якуб Гатович?

— Җылаштырабыз.

— Булгач-булгач өч булсын инде, Якуб, әйдә, өченчегә куала,— диде Хикмәтулла.

— Болай да икесе тиң итәктәләр. Хатын да эш дип җанга тия. Бер уйлаганда ул да хаклы.

Көлештеләр. Якуб үзе дә сизмәстән Вәсиләнең терсәгеннән алды, ишектән кергәндә хатынны үзеннән алда уздырып җибәрдě.

— Җитмәде инде шул сыйфат безгә,— дип сукранып алды өлкән тикшерүче Хикмәтулла.— Бер сүз белән әйткәндә, егет син, Якубҗан.

Кирәкмәгән юан гәүдәле, әмма кай ягы beләндер җитез хәрәкәтле киноартистны хәтерләткән аш өләшүче ир-егет килеп аларны бер өстәл артына әйдәде, утыртты һәм заказ алырга дип блокнотын чыгарды, язарга хәзерләнде.

— Якуб, без бу ашханәгә сирәк киләбез, бирегез әле үзем заказ бирим. Тәк, туганкай, иң әүвәл менә ни, хөрмәтле ханымнан сораек, ни ашарга тели микән? Безнең табында утыручы хөрмәтле ханым, мәгез әле,— диде Хикмәтулла.

— Миңа токмач ашы, ярты порция җитәр, икенчегә тавык, өченчегә чәк-чәк белән чәй,— дип Якубка карады хатын. Бу хәл Хикмәтуллага янә ошамады.

— Ашау мәсьәләсендә генә дә аңардан киңәш сорамасагыз сана, Вәсилә Хаковна.

— Дөрес анысы,— диде Вәсилә.— Хак әйттегез, нигә мин гел Якубтан сорарга тиеш соң әле. Ярты порция аш һәм тавык белән чәй.

— Ничек инде тавык белән чәй. Тавык һәм чәй диегез. Ату китерер ул сезгә чәйгә тавыкны салып,— дип көлде Хикмәтулла.

Аш китерүче егет Вәсиләгә карап торды-торды да:

— Гафу итегез, минем квартирны караклар баскач, эшне сез алып барган идегез түгелме?

— Фамилиягез ничек әле, ә-ә, Батыргалиев бит. Булды андый хәлләр.

— Рәхмәт инде сезләргә. Бар әйберем табылды. Тоттыгыз бит үзләрен тәки.

— Тотучы мин түгел, мин тикшерүче генә идем.

— Барыбер рәхмәт. Я, ни белән сыйлыйм үзегезне.

— Карале, ни, туганкай, заказ бирдек түгелме инде. Шулаймы, шулай булгач тагын тыңла: бер сухой вино да алып кил әле син безгә. Якуб абзаңның икенче кызы бар. Ничек инде аның тәпиен юмаска,— диде Хикмәтулла.

— Гафу-гафу, Хикмәтулла абзый, алай булгач, заказны мин бирәм булып чыга. Менә нәрсә, егетем, китер бер әйбәт сухой вино һәм үзен теләгән һәйбәт ризык. Аңлаштыкмы. Ә син, Хикмәтулла абзый, торып тор инде. Чынлап та, мин кызның тәпиен юмаган бит әле, түмгәк кебек утырам тагын. Вәсилә Хаковна, сез каршы түгелсездер бит?

— Мин хатын-кыз, Якуб.

— Әйе шул. Менә ул әдәпнең чамалы булуы. Ярый, бар, егетем.

— Боларны сыйларга җай чыкты дип кенә йөри идем, барыбер бу мәртәт алдырды,— диде Хикмәтулла, Якубка таба ым кагып.— Ярый, миңа да бер җае чыгар әле, сабыр итик, сабыр төбе сары алтын диләрме әле.

— Сары алтын эзләүчеләрне эзәрлекләүчеләр бит инде сез, Хикмәтулла Хакович,— диде Вәсилә.

— Әйе шул.

Өстәлгә бер шешә вино, нигъмәт-ризыклар китерделәр. Хикмәтулла виноны бокалларга койды.

— Мин эчмәс идем, Хикмәтулла Хакович, минем әле эшлисем бар,— дип борылыбрак утырды Вәсилә.

— Эчмичә ярамый, күгәрченкәем, кешенең кызы бар, тәпиләрен юа, юкса тәпиләре ямьсез булуы бар, ә кыз кешегә нәфис тәпиләр бик кирәк ул, беләсегез килсә. Исеме ничек булачак инде? — дип сорады Хикмәтулла. Өлкән тикшерүче өстәлгә ята төшкән, бөтен гәүдәсе белән Вәсиләгә якынлашкан иде.

— Кәримә дип кушарга исәп. Мәктәптә шундый исемле бер кызны яратып йөргән идем...

— Гөлбикәң белсә моның шулай булуын?

— Ул аны белә.

— Менә бәхет кешедә,— диде бокалын күтәреп, ашарга керешкән Хикмәтулла.— Хатыны бу әйткәннең барысына риза, хәтта йөргән кызының исемен куштырырга да ризалык биргән.

— Бирмәде әле, әмма бирер дип ышанам.

— Беләсеңме, нәрсә дип әйтәсем килә минем сезгә, ирләр. Мин шуның өчен эчәм: Гаталар династиясе дәвам итсен.

— Бик изге теләк,— диде Хикмәтулла.— Ләкин мин күтәреп өлгергән идем шул инде.

Болар өчесе дә бер нәрсә турында сөйләшеп утырсалар да, өчесе өч нәрсә турында уйлыйлар иде.

Хикмәтулла: «Их, Вәсилә, Вәсилә,— дип уйланып утырды.— Һич югы бер күз сирпеп карап алсаң икән. Ялгыз кеше бит мин, ялгызлык талкый мине, ә син...»

Якуб: «Сәер, нигә бу Хакова булавка турында сорамый икән. Үзем әйткәнне көтәме?»— дип уйланып утырды.

Вәсилә: «Ә бит ул нидер яшерә, мине белми, күрми дип уйлый, күрәсең. Һай, наив та соң бу ир-ат,— дип әүвәл Якуб турында уйлап утырды Вәсилә.— Булавканы мин юри калдырмадым, Якуб. Зинһар алай дип уйлый күрмә. Онытылган, тәрәзә юганда урам якка төшеп китмәсен, дип алып кына куйган идем, онытылган. Әлбәттә, син аны тапкансыңдыр, я булмаса хатының тапкандыр, әлләниләр уйлап бетергәндер. Мин аны гаепләмим, Якуб, аның урынында булсам, мин дә нәкъ шулай уйлар идем. Без, хатын-кызлар, ул мәсьәләдә сезгә караганда фантазиягә баерак халык. Күрче әле бу Хикмәтулла абзыйны, күзгә керә бит инде. Ялгыз, имеш, булсаң соң. Яши бир бер ялгызың, миңа гына тимә, чөнки минем күңелем башка берәүдә...»

*Дәвамы киләсе санда.*

## Ренат Харис

### Хәбәр

Йолдызлардан Җиргә бик аз якты,
Йолдызлардан якты — акылга.
Әнә берсе минем күзләремә
керер өчен төбәп атылган.
Тик әлегә безгә күренми ул,
йолдызлыклар аша үткәндә
минем өчен мөһим хәбәр җыя —
бөек хәбәр көтәм күптәннән.
Я «Бар!» дисен,
я «Юк!» дисен Йолдыз,
тынычлансын күңел бу хакта.
Йолдызларда кардәш эзлибез шул,
кеше булып җирдән тусак та.
Ул хәбәрдән, бәлки, безнең яшәү
үзгәрмәс тә,
калыр шулай ук...
Ә кешелек аңы,
тәне кебек,
ике аякка басып тураер.
Күктә хәбәр янды...
Аңламыйча калдым.

●

Һәрбер кеше — Җир-тәгәрмәчнең бер теше,
күк тәгәрмәче тешенә тигән төше!

Кайчак мин дә башым белән Йолдыз этәм,
хәтта кара бушлыкларга тиеп үтәм.

Җир-тәгәрмәч алга таба минсез күчми —
галәм механикасында олы көч мин!

Уем тулы тере йолдызлар ялкыны...
Ә йөрәктә фанилыгымның салкыны...

Ул эреми... Эремәсен... Кирәкми дә...
Җир хакына һәрбер кеше Җирдән китә:

кайберәүләр юл ташына — башы белән...
Ә кайсылар Йолдызларга бәрелеп үлә.

## Даһи хис

Уңдырышлы планета мин, үземә күрә,
миңа тигән һәрбер нәрсә шытым бирә:

көн нурыннан терелеге тән-бәдәннең,
Ай нурыннан — бөек хисем — мәхәббәтем.

Йолдыз нуры тудыра хыял, серле өмет...
Мин бит орлык көткән язгы туфрак кебек.

Беравыктан бөтен нурлар кинәт сүнә...
Миңа космик караңгылык шулчак сеңә.

Һәм барлыкка килә иң чын даһи хисем —
«Мин аң чиксезлеген тойган бөек җисем!»

## Янган йөрәк

Йөгереп кил дә син диңгезгә ташлан —
ялкыныңны биреп, ал дымын...
Әй йөрәгем, яргаланып бетеп,
ачык яра булып калдың син.

Яраларны ерта заман җиле..
Үтеп акыл чиген-ызанын,
салкын сугыш тәкерәге аша
тула сиңа нейтрон тузаны.

Сиңа кереп аңны агулый ул,
һәм канымның боза телен үк.
Җаным белән мин аңлаша алмыйм,
ялгызлыкта калам бүленеп.

Кара төндә кайчак атлап узып
уйларымның кара сызыгын,
мин шулай да табам бу дөньяда
кеше булып яшәү кызыгын.

Без көчлерәк барлык яралардан,
барлык сугышлардан... барыбер...
Син, йөрәгем, янып яргаландың,
диңгезеңә таба бар, йөгер.

Барып җит тә дулкыннарга ташлан —
тоз ачытыр бераз... Ачытсын!
Агуланган яраларны саклап
кеше булып ничек яшик соң?

●

Кан тамырындагы тынлык
уйдагы давыл аша,
кайвакытта галәмдәге
тын тынлыкка тоташа.

Шул вакытта сеңә миңа
дивана зирәклеге..

Сызлана-сызлана аңлыйм
тын көрәш кирәклеген

Җирдәге зур чиргә каршы,
ә чир һаман үр менә —
кешенең тынлыкка булган
мәхәббәте сүреле...

## Кара таракан

«Сугыш» сүзе керсә,
шигыремнең
җыерылып куя юллары.
Сулыш алсаң, эчкә «сугыш» үтә,
бигрәк тә бу соңгы елларны.

Ул үзе юк,
ләкин кемдер аның
Җир буйлата рухын тарата...
Планетаның ул аш өстәленә
килеп төшкән кара таракан.

Барысы да аңа суга:
кашык,
пычак,
сәнәк,
махсус шапалак...
Үлде дисәң — исән. Йөгереп китә
антеннасы белән кабалап...

Ә өстәлдә затлы тәлинкәләр,
хрусталь ваза,
фамиль фарфорлар
чәлпәрәмә килеп өелеп кала
табын ямен урлап, аш хурлап.

Ә шигырьнең пакь, саф асылына
үтә алмагандыр таракан...
Рифма белән мин рифмага суктым —
чәчрәп керде сүзгә кара кан...

●

*(Кеньяктагы курортта)*

Ил күләме басуларда
арыш, бодай бетте көеп...
Тугарылып бии халык,
тугарылып бии!

Безнең теплоходлар чит портларда
ашлык төйи...
Халык бии,
тугарылып бии!

Эче тулы борчу күтәреп
бии ала тугарылып!

Төшми,
төшми
ачлыкларны,
сугышларны
кичкән рухи югарылык!

## Болыт күләгәсе

Болыт күләгәсен күреп:
«Харап — черек тап!..»— диеп,
Җирне тиргәүче, сүгүче,
каргаучы да табылыр.

Күләгәдә кала калсак,
без дә кимен куймабыз:
гавам белә — кушылыйк,— дип,
телебезне тыймабыз.

Җил исәр дә болыт тузар!
Күләгәләр вакытлы.
Шулчак ничек сипләрбез соң
намустагы ватыкны?

●

Кораблар диңгезгә китә
хыялларны өстерәп.
Ә хыялдан калышырга
әллә нинди көч кирәк.

Ярда ялгыз басып калдым...
Офыкта соңгы кораб...
Чынбарлыктан югалып ул
әкияткә кереп бара.

●

Күңел минем ничек тыныч булсын?
Төне буе диңгез котыра —
бернинди җил!
Күктән, ахры, Айдан
чиный-чиный ялгыз эт өрә.
Илаһилар мәллә сугышалар?
Айны мәллә Йолдыз үтерә?
Мине мәллә уятмакчы булып,
ярдәм сорап,
диңгез үкерә?..
Баткан чакта салам да ышаныч —
илаһилар ябыша адәмгә!
Мин, күрәсең, салам гына түгел,
мин, күрәсең, кораб
Галәмдә!

●

Син хаклы, диңгез дулкыны,
хәрәкәттә — бәрәкәт!
Җил туктаса исүеннән,
аның өчен һәлакәт.

Син хаклысың, тау кыясы,
селкенмәү — ныклык көче.
Ава калсаң — ватыласың,
һәлакәт синең өчен...

Ансы белән дә килешәм,
бусын да хуплый күңел —
каршылыклар сыйдырмыйча
яшәүләр мөмкин түгел!

## Көзге төн

Мендәреңә ят та тыңла:
нәрсә сөйли көзге төн?
Кыштыр-кыштыр яфрак коела...
Син, мин һәм көз — бер бөтен.

Тәрәзә пәрдәләрең ач —
көзен төнге күк кара,
төшкән һәр яфрак урнына
йолдыз кабына бара

Ә йолдызлар мәңге язгы,
алар коелмаячак —
яшьлектә сайлаганнары
маяк булып яначак.

Һәм аларның ялкын төсе
беркайчан бетмәячәк,
көзге өзек яфракларны
күңелгә кертмәячәк.

Мендәреңә ят та тыңла:
нәрсә сөйли көзге төн?
Кыштырдап йолдыз кабына...
Син, мин, йолдыз — бер бөтен...

## Гаграда, октябрьда

Алтын көзне быел күрми калам —
диңгез дулкыннары саргаймый...
Ә ярдагы төрле пальмаларда
елы буе җылы май ае.

Күнегелгән инде елына бер
сары яфрак таптап йөрергә...
Тәнне ташлап яшел дулкыннарга,
сары көзгә җаным йөгерә.

Һәрбер агач хакыйкать күк шәрә!
Һәр агачның уе югары:
«Ботакларым — тамыр... Зәңгәр күктә...
Ябалдашым хәзер — Җир шары...»

Анда хәзер һәрбер агач — хаким,
һәрбер яфрак әзли варисын.
Килә икән кайчак хәтта яфрак
варисы да булып карыйсы.

## Юл читендәге үлән

Тау түбәсендәге үлән
йолдызларга сүз дәшәдер.
Елга ярындагы үлән
диңгез белән сөйләшәдер.
Имән төбендәге үлән
беләдер карурман телен...
Мин тауларда,
урманнарда,
ярларда
яшәргә телим,
чөнки мин — гасырлар салган
юллар читендәге үлән —
кешеләр маңгаендагы
сырлар серен генә беләм...

●

Дулкынга аркаңны бирмә,
дулкынга күкрәк терә —
ир-егетнең йөрәгенә
мена шулай көч кирә.

Арттан килеп капласа ул
тончыктыра, батыра.
Улым, безгә иртә... диңгез
төпләрендә ятырга.

Дулкынны авызлыкларга
тырышма — булма әрәм:

аларны җил генә түгел,
аларны Җир күтәрә.

Без тормыш дулкыннарында
икәү хәзер, янәшә...
Дулкыннарга каршы дулкын
җибәрә белү — яшәү!

## Кайда?

Кайда безнең ташка басып
ташны уалткан чаклар,
мизгел өчен уйламыйча
башны югалткан чаклар?

Кайда сөйгән яр янына
уктай ашыккан чаклар,
ашыкканда таулар ишеп,
Идел ташыткан чаклар?

Кайда соң гыйшык утыннан
канга капкан учаклар,
түзалмый Иделгә төшкәч,
Идел кайнаган чаклар?

Кан аша еллар агышы
барысын эзгә керткән:
хыялны язда калдырып,
йөрәкне көзгә керткән...

## Чал сандугач

Яфрагына сары төшкәч
чәчәк аткан гөл ич син!—
сиңа кем сандугач булсын?
Ширбәтеңне кем эчсен?...

Мин!
Мин — давылдан, утлардан
канатын талаттырып,
назлардан, үкенечләрдән
йөрәген канаттырып,

сине күргәч,
китә торган
кошларга кушылмаучы
чал сандугач!
Миңа дигән
соңгы илһамчы тамчы
синдә икәнен күрүче
һәм күзләрдә калучы,
сары күзләрдә дә язгы
җырлар җырлый алучы!

## Renatus[1]

Инде мин дә артка борылып карыйм:
үткән юл бар —
заман өлеше.
Ә башыма Киек каз юлының
төште инде салкын көмеше,
сүнгән йолдызларның көле төште...
Миллион еллар элек суынган...

[1] Renatus — латинчадан — яңадан туган, дөньяга кайткан.

Терелмәсләр дидем.
Терелделәр
хәтеремнең терек суында!
Алар белән җаным әй сөйләште
аңлашылмый торган бер телдә...
Кайдан миндә Йолдыз телен белү?
Әйтә алмас Җирдә беркем дә!..
Нигә миңа андый бөек ачкыч,
мәңгелекнең ачкач ишеген,
үзең кералмагач,
күрәлмагач
аң-зиһеннең ерак бишеге?
Нигә миңа андый бөек көймә —
дәверләрне урап кайтырлык —
үлемсезлек диңгезенә кертеп
утергәчтен мине батырып?!.
Ә шулай да кеше булу бәхет!
Мин — Йолдызның җанлы күмере —
кабат кайтып яшим...
Әйләнештә
хәтеремнең чиксез гомере!

## Давылдан соң

Давылдан соң чыккан кояш
көндәгедән кадерлерәк.
Аны күргәч, кан җылына,
ышаныбрак тибә йөрәк.

Миндә мең һөҗүм чигереп
исән калган батыр хисе —
тоям, тоям, тоям, тоям
кояш нурының хуш исен!

Чоңгылда калган өметләр
кояшның ак нурларына
ябышып өскә калкалар
һәм чыгалар җырларыма.

Алар көчле, алар якты,
аларны кем танымасын?! —
давылдан соң кояш булып
чыккан яшәү тантанасын!

## Гамил Афзал

# АЛТЫ ДИСТӘНЕҢ ӨСТЕННӘН

●

Башыңны текә күтәр дә
Текәлеп кара мең елга
Гасырлар үтәр-үтәр дә
Әйләнеп карар Ленинга.

Гыйлем һәм тизлек аларда,
Акыллар адашыр юлда.
Заманнар агар-агар да,
Әйләнеп карар Ленинга.

●

Үземә тигән озын юл
Һәм үз туксаным-туксан.
Кешеләр кеше була ул,
Үзең дә кеше булсаң.

Таңнары матур кичennән,
Күңелле, ямьле заман.
Алты дистәнең өстеннән
Сәламнәр әйтеп калам!

## Авылым

Ай сүрелеп кенә көн яктыра.
Ядкарь итеп сагынып сөйләргә,
Өянкеләр сәлам әйтеп тора,
Таң алдыннан искән җилләргә.

Сизгер сулар серле сандык кебек,
Камыш төпләрендә моң тулы.
Юллар уйчан, зәңгәр күкләр биек,
Һаваларда киек каз юлы.

Оныттылар диеп үпкәләмә,
Карурманнар үскән илләрдә
Сине сагынып җаннар өзгәләнә
Айлы әкият кебек төннәрдә.

●

Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь язмый тора алмаганга.
Каләмемне ай нурына манам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Айлы кичтә зәңгәр утта янам,
Күкрәгемдә хисләр кайнаганда.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь укыр дуслар калмаганда.

Каләмемне таң нурына манам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь язмый тора алмаганга.
Чәчәкләрдән нәфис төсләр алам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Хыялымны тормыш алдаганда.

Каләмемне үт суына манам,
Йөрәгемдә нәфрәт кайнаганда.
Яшен булып яшел тауда янам,
Болыт килеп, давыл шаулаганда.
Әҗәл упкынына каршы барам,
Акыл, намус җирдә аунаганда.
Ядрә кебек кайнар шигырь язам...
Мәхлук булып тора алмаганга!

●

И урман, таулар өстеннән
Каралып килгән болыт,
Кеше кешегә эшләгән
Явызлыкларны оныт,
Вәхшилекләрне оныт!

И басу, кырлар өстеннән
Агарып килгән болыт,
Кешенең яхшылыгына
Ышануларны ныгыт,
Ышануларны ныгыт!

●

Кайнап тора Казан каласы,
Таш урамнар буйлап барасы...
Такташ юк, ямансу.

Мәйдан белән мәйдан арасы,
Ыгы-зыгы адәм баласы...
Әнвәр юк, ямансу.

Әллә ничек авыр бу еллар...
Бәлки әле Сибгат кул болгар,
Елмаер Илдар...

●

Ямансу гомер кичләре,
Моңсу чорга керәм.
Зиһеннең үткер тешләре
Төшә берәм-берәм.

Үзгәрде мәгънә төсләре,
Офык яшькелт-керән,
Хәтернең үткер тешләре
Төшә берәм-берәм.

●

Уйлар тирән, күкләр биек
Чаллы чайкалган урында.
Чаяларны җаның сөеп,
Сөйлә мәхәббәт турында.
Тиеш диеп, кирәк диеп,
Сөйләмә акча турында.
Уйлар тирән, күкләр биек
Чулман чайпалган урында.

●

Хисләнә күңел, шомлана
Шаулы урманда йөреп:
Һәр имән эти кебек тә,
Һәр тирәк әни кебек.
Хушлана күңел, сафлана
Яшел урманда йөреп.
Үткәннәр белән күрешеп,
Серләшеп йөрдем кебек.

●

Бу чапкын елларга
Нинди җыр җырларга,—
Моң белән йөрәкләр яралы.

Озын сүз сөйләмә,
Вакыт юк тыңларга,
Озын уй, кыска сүз заманы.

●

Бер яфрак та хилаф юлга төшми,
Һәр күбәләк тиеш эшен эшли —
Шаклар катырлык.
Җәе-кышы, язы-көзе булган,
Алмашынып һәм яңарып торган,
Мыскаллап үлчәнгән матурлык.

●

Тырышып эшлә, янып эшлә, балакаем,
Бәхет килә яшьлектә бер, картлыкта бер.
Уңышлардан баш әйләнеп, күз акаеп,
Биһуш булып торсаң иде шатлыктан бер!

●

Сүзләрең күңелгә тиде,
Уйларыңны беркетмәдең.
Күзләрең мөлдерәп килде,
Тирбәлделәр керфекләрең,
Сау бул инде, сау бул инде,
Алмадай булды битләрең!

●

Анда мине беркем дә юксынмый,
Искә төшермиләр күптән инде.
Кичке җилләр колакка пышылдый:
Син эчкән чишмәләр кипкән инде.
Сукмакларда яшь каеннар шаулый,
Ләкин алар бүтән инде...

●

Дус-ишләрнең, кардәш-ыруларның
Каберләрен карап китәсең дә,
Бик кадерле түгел иде, дисең,
Бу егетләр гомер иртәсендә:
Аларны да үпкәләтте кемдер.
Мин гаепле кебек ни өчендер...

●

Шатлыгың күп, көлә-көлә сөйләшәсең,
Һәр кешегә әйбәт кәеф өләшәсең.
Үзең матур, сүзең матур, күзең матур,
Матур җаның көлә-көлә йөз яшәсен!

●

И барасы, и барасы, и барасы...
Ерак икән офык белән күк арасы,
Тау битләрен күреп талды күз карасы,
Кул ярасыннан да ачы тел ярасы.
И барасы, и барасы, и барасы...

●

Кем уңа да, кем туңа бит,
Эчләрем поша шуңа.
Тау башына менеп җиткәч
Моңлырак була дөнья:
Түбәнгә юллар шома.

●

Офтансын, соклансын каласы-саласы,
Мактаулы юллардан барасы.
Түземлек, чыдамлык кайлардан аласы,
Сөйләп бир, сандугач баласы!

●

Үтте, бетте, тузандай таралды
Вак белемә өчен ызгыш-талаш.
Сөйкемле күз белән бер карады,
Гомергә онытылмый шул бер караш.

●

Ышанмаган гел шикләнеп тора,
Ышыкланып һәм бикләнеп тора,
Миннән булмас диеп юрап тора —
Һәм оттыра.

Ышанган җан ташка кадак кага,
Кулы белән утлы күмер тота,
Аждаһаның күзенә карап бара
Һәм иблисне ота.

●

И аһәңнәр тибрәтим дим,
Әй гомерне гөрләтим:

Ил казанына бер ярма
Булып төшсен хезмәтем!

●

Шигырь — иман, шигырь — дога, шигырь — агу,
Хис кырында чәчү кебек, уру кебек.
Илһамсыз һәм рухсыз гына шигырь язу
Яратмаган хатын белән тору кебек.

●

Бархannардан бархannарга күчеп,
Сахра, чүлләр гизеп алга барам.

Бер аваз яңгырый илләр кичеп:
— Гомәр Хәйям, Гомәр Хәйям!

## Харрас Әюпов

### Чакыру

Әллә сагыш, әллә язмыш булды —
Сизмәдем дә кемнәр дәшкәнен...
Шушы җырда бер күрешик әле,
Урамдашлар, чирәмдәшләрем!

Ераклардан килгән шушы җилдә
Яланаяк калыйк, яланбаш.
Бергә чакта төрле-төрле идек,
Бер моң булдык менә, таралгач.

Ишетәсезме икән, югалтышкан
Казлар кебек кыйгылдашканын?—
Җаннар бергә сарылсыннар әле,
Шатлыкташлар, кайгыдашларым!

Бу сезнең дә сагыш кәне мәллә —
Таңнан бирле яңгыр сибәли?
Бер җылыныйк бүген, җырдашларым,
Җыйналышып Сагыну тирәли.

...Үсмер чакта бер җырлаган идек,
Җырлыйк әле чәчләр чаларгач.
Ераклардан моңлы бер җил килә —
Яланаяк калыйк, яланбаш!..

### Атлар килә

Әллә инде җәйләр кыска булган,
Тар булганмы әллә болыннар —
Безнең җанга килеп кермәс иде
Җан-фәрманга чапкан колыннар.

Туктый алмый, безне балачактан
Алып чыгып китте шул шәпкә;
Шуннан бирле менә бәйгедә без,
Тын алу юк, булмый нишләп тә.

Ә колыннар күптән ат булдылар,
Иярләрдә инде — ил йөге,
Йөрәгеңдә атлар йөртер өчен
Күңел кирәк — болын киңлеге!

Тезгеннәрен кысып кына тотам —
Ни булса да әзер бу атлар.
Утка-суга басып атлар килә,
Атлар белән бергә — ир-атлар...

## Каз кычкыра

*Әнкәм сөйләгәннәрне искә төшереп*

Шәһәргә дә күнегелде бугай,
Авыл хәзер — бары истәлек.
Тик җанымда менә каз кычкыра,
Кычкыра каз... Куям сискәнеп.

Гомер иткән ала казым калды...
Сизгәндерме минем китәсем:
И кычкырды җан ачысы белән
Шул язны ул кичен-иртәсен.

Ничә оя бәбкә үстергәндер —
Авылда бер үрчем каз иде,
Каңгылдашыр-куанырлар иде,
Ишегалды тулы наз иде.

Һәм... өй тулы нарасыйлар иде —
Сыңар канат ничек күтәргән?
Казлар белән бергә очып үттек
Кара болыт баскан күкләрдән...

Каз кычкыра...
Мескен ала казым,
Әллә оча, әллә куна ул —
Казаннарга кадәр ишетелә...
Ничек түзә икән бу авыл?!

## Гомер сандыгы

Ак калайлы гади зәңгәр сандык,
Сандык эчләрендә ни ятыр? —
Ачкан саен, үткән кире кайтыр,
Керфек очкайларың чылатыр.
Кыз чакларның олы истәлеге —
Ука күлмәк, көмеш беләзек;
Булган икән ай-һай билләр нәзек,
Кадерләрен, ахры, белмәдек...
Кершән-иннек бүләк иткән иде,
Тотылмаган гел дә диярлек.—
Әйтелмәгән икән күпме сүзләр,
Тынып калган шуңа ияреп...
Тәүге чәче, нәни башлыгы бар,
Ләкин улың күптән үзе юк,
Болыт түгел Көнбатышка аккан,—
Хәсрәтләрең бара сузылып.

Кызларыңның язган хаты исән,
Орден-медаль — ирең калдырган...
Хәтер кебек, тулган тыгызланып,—
Шул сандыкта икән бар булган!
Өләшәсе күптән барлап куйган,
Әзер инде үлемтегең дә;
Тик... җибәрми тартып тора һаман,—
Нәрсәдер бар сандык төбендә:
Ачкан саен кагылыр ул җанга,
Төшләреңә кереп уятыр,—
Оныкларга кала гомер-сандык,
Эчләрендә аның ни ятыр?..

## Җәйге агым

Яп-якты көн.
Идел буйларыннан
Сулап туймас дымлы җил килә,
Аксылланып тузгый яшел таллар,
Тирбәлә җәй моңлы бер көйгә.

Урамнарга керә җәйге агым.
Газоннарда ауный, юлларда,
Сабырлыгын җуеп, сарыла ул
Җиңел күлмәк кигән кызларга.

Айкап уза ишек алларыннан,
Йолыккалый ап-ак керләрне;
Сизми сабый, ачык тәрәзәдән
Нинди төшләр агып кергәнне.

Алып чыга шәһәр өсләренә,
Уйнаклатып карлыгачларны;
Елатканчы, юатканчы чайкый
Моңлы җанны, зарлы башларны.

Мәңгелек җил җирдә, мәңгелек сил —
Беркемне дә юктыр онытасы.
...Башларымнан сыйпап уза гомер.
Яп-якты көн.
Җәйнең уртасы...

..............

Марсель Галиев

# ЕРАК УРМАН АВАЗЫ

ПОВЕСТЬ

## 1



Каравыл өендә сөякләреңне эретерлек җылы. Ишекнең калҗайган төшеннән кысылып кергән салкын һава, мич авызыннан бөркелгән кайнарлык аша түргә үтәлмичә, юашланып кала. Мичтән ерак түгел генә бер-берсенә сыенып, идәндә ике эт ята. Яшь эт алгы аякларына башын салган да тәмен белеп кенә изрәп йоклый. Карт эт исә, алгы гарип аягын читкәрәк җибәреп, уңайсызрак яткан. Вакыт-вакыт ыңгырашып куя (төш күрәме?), әледән-әле кузгалып урынын алыштыра — тынычсыз йоклый.

Чит-читләре тетелеп, каешланып беткән сарык тиресе җәелгән сәкедә Моратбакый ята. Ул сәке такталарын шыгырдатып кымшануга, яшь эт сискәнеп башын күтәрә һәм томырылып хуҗасына карый. Карт эт тә үз чиратында башын калкыта, каш астыннан гамьсез ризасызлык белән карап ала да яңадан тынычлана. Күзләре кысыла, әмма йомылып бетми. Йоклаган чагында да карт этнең күз кабаклары арасында ачык калган каралҗым сызык Моратбакыйны өшетеп-өшетеп куя торган иде. Кайчакларда Моратбакый, юри сынар өченме, шапылдатып идәнгә ни дә булса төшерә, тавышка яшь эт кисәк сикереп тора, хуҗасының һәр теләген үтәргә әзер булып аңарга омтыла. Ә карт эт күзләрен әкрен генә ача, мин барысын да күреп тордым, искитәрлек берни дә юк дигән шикелле, салкынмәкерле карашын хуҗасының күз турысыннан әллә кая, еракка төбәгән була.

Манма тиргә батканчы бер кыйнар иде аны Моратбакый, исәнгерәткәнче, тәмам хәлдән тайдырганчы кыйнар иде, кайчандыр, баганага бәйләп, дилбегәне катлый-катлый ярган кебек... булмый шул. Гөнаһысыннан курка. Этнең дә, үзенең дә яшьрәк чаклары булса иде.

Моратбакый сөякләрен шыгырдатып торды, ямаулы оекбашлары белән чаштыр-чоштыр килеп, мич авызына чүгәләде. Бирчәйгән каты бармаклар көл каплаган күмерләрне актара башлады. Астан, әле сүрелергә өлгермәгән, тетрәп торган күмерне ике бармагына эләктереп, тәмәкесенә китерде. Утны тәмәкегә күчергәндә күмер дә ялкынсулап чак кабынып китмәде. Моратбакый тирән итеп эчкә алды да төтенне борын тишекләреннән ашыкмый гына өреп чыгара башлады. Мичнең кара юллыгына тәмәке төтененең савылып кереп китүен күзәтергә ярата иде ул. Моржа да эчпошыргыч итеп уламый инде бүген. Тып-тын. Күк

белән җирне тоташтырып өч көн буе кайнаган буран бүген иртәдән үк тынды. Җанны оета торган тынлыкка һаман әле иялэшеп булмый, әбарыбер рәхәт.

Инде сүрелеп, көл белән өртелгән күмер өеме астыннан кинәт ялкын бәреп чыкты, акшарлары керләнгән стенада, ажаган уйнаклаган дай, кызгылт-моңсу шәүлә уйнаклап алды. Ялгыш кына терелеп чыккан ут теле, шушы йокымсыраган кечкенә дөнья каршында уңайсызланган сыман, тиз генә йомылып сүнәргә дә өлгерде. Шуннан соң әллә ни булды Моратбакыйга: әле генә хозурланып тарткан тәмәкенең тәме китте, караңгылыкның сере бетте. Бары тик ялкын теле генә үзенең кабатланмас тирбәнешләре белән яктысын җуя алмыйча торды. Хәтерендә... яктысын җуя алмыйча...

Моратбакый, күңелендә кузгалган рәхәт авыртуны сузарга теләмичә, тәмәкесен көлгә ыргытты да аягына басты. Җиде тавышка шыгырдаган ишекне каерып ачып, ярты гәүдәсен тышка сузды. Утырып яуган бүгенге яшь кар салкыны, алдавыч бер дәрт өстәп, бөтен тәненә таралып өлгерде. Караеп күренгән зират наратлары турысындагы йолдызларның утлы күмер сыман балкып китүе, чиста кар салкыны, ишек җиленнән сукыр лампа утының менә сүнәм, менә сүнәм дип, шелтәле бөргәләнүе, этләрнең колакларын кош канаты сыман тырпайтып баш күтәрүе — барысы да гүя Моратбакыйга билгесез бер халәтне төшендереп бирергә әзер шаһитлар иде.

«Ярый әле хәтер сау,— дип уйлады Моратбакый.— Хәтер исән чакта китеп калу да... Тәндә көч бетеп бара, хәтер булмаса, яшәүнең кызыгы күптән инде исраф ителер иде. Ә эчтә дәрт һаман кимеми, колын кебек уйнаклап чабарга дәртсенеп тора — җан дигәне шулдыр инде. Дөньялыкта бөтен нәрсә дә искерә, туза, картая барып, соңыннан үлемгә дучар ителә. Ә җан дигәне, җан?» Моратбакый, чал кергән сакал төкләрен шыкырдатып, ияген сыпырып куйды — кырынмаганлыгы исенә төште. Түш кесәсеннән чылбыры булавка белән эләктереп куелган, сап тезелгән йөзе саргаеп беткән көмеш сәгатен чыгарды. «Көн сүнгәнгә байтак икән инде, соң булса да кырынып алырга кирәк». Бу эшкә ул нииндидер бик кадерле кешесенә мәҗлескә җыенгандай ясканып тотынды. Хәнҗәр кынысыдай озынча савыттан борынгы бритвасын алды. «Мөгаен, җанның өлгерүе өчен тәннең картая баруы кирәктер. Күпләрнең үләр алдыннан нигә дип әле зиһене тарала, аңы бетә башлый. Ә бәлки җанга тәнне калдырганда бөтен нәрсәдән чистарып, онытылып чыгу кирәктер?..» Моратбакый, шулай уйлый-уйлый, калай кружкадагы суны мич алдындагы күмерләр өстенә утыртты. Стенадагы көзгене алып, өстәлгә — сукыр лампа кырыенарак терәтеп куйды. Чит-читләре кара агачтан бизәкләп эшләнгән бу көзге Моратбакый үскән гаиләнең бердәнбер исән калган ядкаре иде. Рамындагы кайбер бизәкләре чатнап төшкән, көзгенең кырыйлары эчтән купшаклаган, тутланып тора, бары тик урта бер җирендә генә су кебек чиста өлеше сакланып калган, йөзне ачык күрсәтми, томан аша караган кебек иде. Озаграк текәлеп карасаң, көзгегә кереп китәрсең шикелле, әллә нинди караңгылык, серле тирәнлек бар иде аның эчендә. «Көзге дә картая икән,— дип уйлады Моратбакый.— Әйберләр дә хуҗасы юклыгын сизәдер, ахрысы. Бәләкәйдән үк искәргәнем бар: хуҗалары шау-гөр килеп яшәп ятканда көлеп торган өй, тәрәзәләрен кадаклап, күченеп китүгә үк күзгә күренеп иңә, туза, искерә башлый. Әле шушы елларда гына иске тегермәнне сүткәннәр иде. Тегермәнче дә өй нигезен кубарып, авыл уртасынарак күченеп утырды. Шуннан соң күп тә үтмәгәндер, арык кырыенда үскән бинниһая зур тал күзгә күренеп корый башлады, ботаклары елдан-ел сирәгәя барып, хәзер инде шәрә каусәсе тырпаеп күккә кадалып тора».

Мул итеп кайнар күбек сыланган яңак тиресен теле белән бүлтәйтеп, Моратбакый кырына башлады. Көзге каршында шулай дикъкать белән кырынганда, шикләнеп, артына борылып-борылып карау гадәте бар иде аның. Кемдер мыштым гына килеп баскандыр да сиздермичә генә күзәтеп торадыр сыман тоела аңа. Ярый әле этләр бар...

Япон сугышы чорында булган бер хәл исенә төште. Взвод белән бераз ял алырга дип монгол тирмәсенә тукталганнар иде. Куй сарыклары тупланган төштә, кое чиләгенә ватык көзге кисәген терәтеп, Моратбакый шушылай кырынып тора иде. Мышнау ишетеп артына борылып караса, җәлпәк йөзле, керпе энәседәй тырпайган чәчле бер малай килеп баскан. Авызын ачып катып калган малайның нәрсәгә шулкадәр гаҗәпләнүен Моратбакый бер мәлгә аңышмады. Малай, нидер әйтеп, көзге кисәген алды да кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде. Тавышка тирмәдән аның абыйсы йөгереп чыкты. Алар икәүләп бер көзгегә карыйлар, бер йөзләренә төртеп күрсәтешәләр, тамак төбе белән кырачлый-кырачлый, аңлашылмаган телдә гаҗәпләнүләрен белдерәләр иде. Иң кызыгы шунда: әйләндереп-әйләндереп көзгенең артын да карап алалар иде. Соңыннан бу малайларның этиләре аңлатып бирде: баксаң, малайларның гына түгел, үзенең дә чын көзге күргәне булмаган икән. Шушы пыяла кисәге чиксезлекнең һәм мәңгелекнең үзе шикелле япан далада гомер кичергән бу монгол гаиләсе өчен искиткеч яңалык иде. Бу көзге өчен күпме куй сорасагыз да бирәм, диде хуҗа. Моратбакый аны бер кызганусыз бушлай биргәч, аларның шатлануына чик-чама булмады. Ә шулай да хуҗа кичен бөтен взводны куй ите ашарга чакырды...

Моратбакый кырынып бетергәч тә көзгене үз урынына элмәде. Сукыр лампаны гына каршысынарак этәреп куйды. Әйтерсең лә көзгенең караңгы тирәнлеге бер мизгелгә яктырыр да, Моратбакый хәтерендә инде төш кенә булып калган күренеш чагылып китәр иде сыман... Менә әтисе, шәһәрдән киләсе кунакларны көткән арада, көзге каршында бер тукталып ала, жилет кесәсендәге сәгать чылбырын рәтли һәм көлгән рәвешле авызын ерып карый. Ябык, чирләшкә, зәгыйфь тавышлы әнисе кунак бүлмәсендә берәү дә булмаганда гына көзге каршына килә. Үз-үзе белән сөйләшкән шикелле, иреннәрен кыймылдатып, изге әйбер каршына килгәндәй, бик озак басып тора, шул чагында берәрсе килеп керсә, сискәнеп, уттан курыккандай, читкә тайпыла.

Юк, боларның кабатлануын түгел, ә бер мәлгә генә, ерактан чагылып китүен генә тели иде Моратбакый. Әмма көзге дәшми. Болганчык суга охшаш пыяланың салкын ялтыравында кешеләр хәтереннән көлү бар сыман...

Чистарып алганда була торган канәгатьлек белән, шома иякләрен сыпыра-сыпыра, Моратбакый сәкегә килеп ятты. Сәке кырыендагы стенага эленгән мылтык шәүләсе сукыр ут яктысыннан биеп тора. Тамырланып торган авыр кул мылтык түтәсенә үрелде. Күпме кошларның очышын кискән, күпме җәнлекләрнең гомерен аямыйча кыйгандыр бу борынгы мылтык. Мирас...

Моратбакый түшәмгә текәлде. Матча янындагы ботак эзе авызы ачылган бүре башын хәтерләтә иде.

Үз гомерендә шушы мылтык белән бүре атарга да туры килгән иде аңа. Ул чагында Моратбакыйга унбиш яшьләр чамасы булгандыр. Бүре атарга ук дип өметләнеп чыкмаган иде урманга. Болай, сунарчы булып карыйсы килүдән генә чыккан иде. Йөри-йөри тәмам арыган иде, тарлавыкны гына үтәсе дә кайту ягына борыласы иде. Һич көтмәгәндә... чытырманлык арасында... өненнән арты белән чыгып килгән

бүрене күреп алгач, ул каушауданмы, куркуданмы, үзе дә сизмәстән, тирләгән башындагы бүреген йолкып алып читкә ыргытты да ике көппәле мылтыгын иңеннән шудырып төшерде. Ара әллә ни ерак түгел иде, атарга да була, ләкин нинди дер мәҗүси бер уй — арты белән чыгып килгән бүрегә ату егетлек булмас, гәүдәсен болайга борсын әле дигән уй — аны күтәргә мәҗбүр итә иде. Әмма секундларны елга әйләндергән курку үзенекен итте: бүре өненнән чыгып җитеп башын борырга өлгердеме-юкмы, калтыранган бармак чакмага басты. Шартлау тавышы һәм бүренең җан ачысы белән чинап җибәрүе — икесе дә бер мизгелдә булды бугай. Шушы ике тавышның кушылуыннан аңгыраеп калган Моратбакый үзенә таба үлем шашынуы белән ташланган бүрегә карап катты да калды. Хәвефле секундның меңнән берендә туган әметсез курку мылтыгын күтәрергә, чигенергә мәҗбүр итте Моратбакыйны. Ишеткәне бар иде: мондый чакта икенче тапкыр ата алмый калсаң... ишеткәне бар иде! Бүре, шартлау дулкыны белән бергә икенче ядрәне күкрәгенә алганда, бөтен гәүдәсенә тетрәп, бер омтылды да каршыдагы беләк юанлыгы каен кәүсәсенә тешләрен батырды, яшен кебек бер бөтерелеп чыкты һәм... калтырап... тынып калды. Моратбакый, шыгырдап авып төшкән каеннан читкә тайпылды да, әле һаман аңга килә алмыйча ярсынып, бүренең маңгаен мылтык түтәсе белән төя башлады. Бүренең инде тәмам үлгәнлегенә ышангач кына куллары салынып төште. Күзләреннән яшь ага, үзе эчтән өнсез сулкылдый — кызгану идеме бу, әллә инде канында борынгыдан калган кыргый тантананың уянуы идеме?.. Шунда ул чытырманлык арасыннан чиный-чиный чыгып килгән бүре балаларын искәреп алды. Капшана-капшана килгән, күзе дә ачылмаган бүре баласын кулына алуга... якында, колак төбендә бер-бер артлы коточкыч шартлау тавышы яңгырады. Шартлау тавышы артыннан ук баягыча кыргый чинау, пычак йөзеннән киселгәндәй, кинәт өзелеп калды. Моратбакый, һушы китеп, җиргә чүгәләде. Үзенең үлеме-тереме икәнен аңлаганчы аңа еллар үткәндер шикелле тоелды.

— Гомерең җәл түгелмени синең, ачык авыз?

Якасыннан умырып селеккәнгә Моратбакый күзләрен ачты. Каршысында гомере буе кордонда яшәгән урман каравылчысы Иләмән карт тора иде. Тирә-юньдә һәммә кешегә билгеле Котлыкаев малаен курүгә карт юашлана төште.

— Син, Морат... Бакый улым... каян болай?

Моратбакый чабуына тырнакларын батырган бүре баласын калтыранган кулы белән сыйпап утыра, һаман да телгә килә алмый иде әле.

— Минем янга киләсең калган, бергә-бергә чыккан булыр идек.— Иләмән карт кесәсеннән янчык чыгарды, чеметеп кенә тәмәке алып трубкасын төйде дә кабызып җибәрде.— Сунардан кайткан бүре чәйнап ташлый иде бит үзеңне.— Карт, төтенгә тыгылып, ютәлләп алды да Моратбакый аткан бүре гәүдәсен әйләндереп-әйләндереп карый башлады. Соңыннан канга буялган кулын күнитек кунычына сөртеп куйды.

— Пөрәгенә тидерә алмагансың. Атаң кайтуга батырлык эшләп ташларга уйлагансыңдыр инде.— Иләмән карт Котлыкаевның кызыл мал артыннан ерак сәфәргә киткәнлеген белә иде. Моратбакыйның әтисе аны «Кыпчак бабай» дип йөртә, килгән чакларында өйдә аңа гына тәмәке тартырга рөхсәт итә иде.

— Бүре атарга дип чыкмаган идем.

— Чыпчык атаргамы бүре ядрәсе белән! — Иләмән карт кысык күзләрен җыерчык арасына яшереп елмайды.

Кырыйда бүре балалары үзәк өзгеч итеп шыңшыйлар, калтыраналар иде. Иләмән карт, тырмашкан бүре балаларын кулына алып, ягымлы сөйләнә-сөйләнә сыпыра башлады.

— Теләсәң берсен үстереп бирәм мин аның, менә диган усал э була. Көзен килеп алырсың.
Иләмән карт аткан бүрене дә барып карадылар. «Йөрәгенә ти гән»,— диде карт.

Агач ботаклары арасыннан кыелып төшкән кояш нурларында көп шәкләнеп ярмаланган кар җемелди. Яз исе, урманның оеган тынлыгы Иләмән картның трубкасыннан ялкау гына күтәрелгән тәмәке төте не... Моратбакыйга рәхәт иде. Ятим калган бүре балаларының кызга ныч тавышын да ишетмәде ул. Үзендә ул әле моңарчы сизелмәгән нин дидер көч тоя, самими хыялына чалкан ятып, киләчәк тавышларын тыңлый-тыңлый талгын гына йөзә иде.
Иләмән картның инде чын аучыларга гына хас кайнарлыгы сүрелә төшкән, ул, каратут йөзен тагын да җәйпәкләндереп, аяз күккә карап алды да, сүзләрен тәтенгә аралаштырып, әкрен генә әйтеп куйды:
— Әйтмәгәнем булсын, аллаһы тәгалә җирдә адәм балаларын яра тып ялгышмады микән, ә?! Бу урманнар, бу җәнлекләр нинди тыныч иминлектә яшәр иде дим, әгәр кеше дигәнең кыйратып тормаса... Ялгышкан алла, кешегә акыл биреп ялгышкан,— дип як-ягына тө кереп куйды.
— Акыл бирмәгән булса, аның ялгышканын каян белер идең соң, Иләмән бабай?
— Кузгалдыкмы? — Иләмән карт аңа каш астыннан гына карап алды да, трубка көлен учына кагып, урыныннан торды.

Моратбакыйның кулы мылтык түтәсендәге уелып кергән урынны капшады. Әтисеннән калган шушы мылтыкка кагылып алгач ул ел лар артында калган вакыйгаларны исенә төшерде.
Колхозлашу чоры башлангач, Котлыкаев пошаманга калды. Россиянең ерак шәһәрләреннән кызыл мал төяп кайтучы, урам тутырып тройкада җилдереп үткәндә авылдашларына канәгать елмаеп, эшләпә сен күтәреп сәлам биреп үтүче Котлыкаев соңгы арада кара коелып, беркем белән дә сөйләшмәс булды. Ике көннең берендә өяз юлын таптады. Бөкре кешеләрне дә турайтып җибәрерлек көр кәефле, таза бәдәнле, кинәнеп яшәр өчен туган әтисенең канаты салынуын малай һич тә кабул итә алмады. Мәдрәсә белеме алган һәм шәһәрдә бераз русча да укып кайткан Моратбакый әтисенең кул арасына керерлек иде инде. Ләкин әтисе үзенең көченә артык ышангангамы, Моратба кыйга серләрен бик чишми, хәтта аңа баласытыбрак та карый иде бу гай. Аңа йорттагы кара эшләрне генә куша, малайның дөньясы биек коймалар белән чикләнә, ә койма аръягында ниндидер үзгәрешләр ба ра, шул яңа дулкынга кушыласы, аңлыйсы, көчеңне сынап карыйсы иде дә бит, әмма әтисенең усал карашы капка бигеннән катырак — аны чарасыз калдыра, рухын ала. Ул, үзен чылбырга бәйләнгән бүре эт Карабай белән тиңдәш итеп күргәнгә, әтисенә эчке бер рәнҗү сак лый иде. Моратбакый ярлылыктан курка, чиркана, ләкин мал артты ру хиреслеген дә үзендә сизми иде.
Кайвакытны әтисе Моратбакыйны кочаклагандай итә, чәчләрен авырттырып кирегә сыпырып куя да:
— Йомшак агачның яфрагы да йомшак була шул,— ди, авыр су лап, трубкасына тәмәке төя башлый. Моратбакый аның мыскыллы тел төбен сизә, эчтән үртәлә, бары тик аңа, аңа гына охшап үсәргә дигән эчке бер теләген сүндереп куюына җәберсенә. Менә әтисе канәфи ар касына сөялә төшә, трубкасын кабызып җибәрә. Аның һәр бөртеге дүрткырланып торган эре куе кара чәчләре ут яктысында зәңгәрләнеп китә. Шул вакыт пыялалы ишек ачыла, тас тоткан әнисе палас өстен-

ган тавышсыз гына килә, тасны бер кырыйга куеп, иренең оекбашларын салдыра, чалбар балакларын сызгандырып, аякларын җылы суга тыга һәм тырышып юа башлый. Котлыкаев, кәнәфи артына башын куеп, күзләрен йома. Кулы белән капшанып, кырыйда өчаякта торган көмеш көл савытына трубкасын куя. Моратбакый тын да алмыйча күзәтә: энисенең бер учма юка, йомшак чәче колак артыннан төшә, баш хәрәкәтеннән тирбәлеп тора башлый. Моратбакый төсе белән дә, йомшаклыгы белән дә нәкъ энисенекенә охшаган чәчләрен ачу белән сыпырып куя.

Бабасының үләр алдыннан Котлыкаевка әйткән сүзләрен ишетеп белә иде Моратбакый: «Нәсел чылбырын өздең, улым. Сүземне тыңламадың. Мин димләгәнгә өйләнгән булсаң... Канны затсыз токым белән болгаттың. Яхшыга булмас бу, яхшыга булмас».

Моратбакый, ябык, авыру йөзле энисенә, беренче кат күргәндәй, озак кына текәлеп торды. Энисе аңа игътибар да итми, күнегелгән хәрәкәтләр белән иренең аягын җылы суда тырыша-тырыша юа бирә.

Бая, этисенең кул кагылышыннан чәч төбендә калган җиңелчә авырткан урынны сыйпый-сыйпый, Моратбакый көзгедән этисенең тупас шәрә аякларын күзәтте. Затлы токым билгеләрен тышкы кыяфәттә генә эзләгән Моратбакыйга бу бик сәер тоелды һәм ул үзалдына елмаеп куйды.

Менә энисе иренең аякларын мамык сөлге белән сөртә башлады. Айтуган бай, иркә ыңгырашып, күзләрен ачты, үрелеп трубкасын алды. Хәзер ул аны кабызыр, тәмәкенең хуш исе туклык, иминлек хөкем сөргән бүлмәгә таралыр...

Авыл советыннан Котлыкаев агарынып кайтып керде. «Гомер буе тавык булып чүплектә казынганчы, бер мизгел этәч булып яшәп үлүең яхшырак» диярргә яраткан ата кинәт кенә сүлпәнәйде дә калды. Бер минут та тынгы белмәгән, нәрсәдер кору, нәрсәдер җимерү өчен яратылган җанның сүрелеп калуы бөтен гаиләне пышылдап яшәү хөкеменә китерде.

— Әгәр минем белән бер-бер хәл булса... рәнҗемәгез. Сезнең читят җирләрдә каңгырып йөрүегезне теләмим. Туган туфрактан аерылмаска кирәк.— Этисенең картлар сабырлыгы белән, уен әйтеп бетермичәрәк сөйләве Моратбакыйның хәтеренә уелып калды.

Ул чакта ут алынмаган өйнең җанны тарыктырган караңгылыгы, тәрәз артындагы куаклар аша чәрдәкләнеп күренгән ай алда торган язмыш кинаясе шикелле сагаюлы, мәкерле иде.

Моратбакыйның әле башланган гына гомерен үзе аңлап та бетерә алмаган дөнья мәшәкате белән чиклисе килми иде. Ул, олыларга сиздермичә, мыштым гына чыкты да атлар торган аранга юнәлде.

## II

Ыргакка эленгән кул фонаре яктысында шәүлә кыймылдап куйды. Айтуган байның кучеры Сафуан агай Моратбакыйны искәреп тамак кырып каршылады.

— Җирән кашканы алып чык әле,— дип, Моратбакый келәткә кереп китте. Иңенә мылтык асып — төнлә урман юлында ни очрамас — ияр тотып чыкканда Сафуан агай җирән кашканың тезгенен тотып тора иде инде.

— Кордонгамы? — диде ул, күзләрен хәйләле елтыратып, ияр каешын бәйләште дә яратып кына ат сыртына сугып куйды.

— Этигә белдермә,— диде Моратбакый.

Сер сакчысы итүдән канәгатьләнеп, Сафуан агай яраткан сүзен кабатлады:

— Инде...

Мәчетне узуга, Моратбакый инеш күперенә чыга торган олы тыкрыкка борылды. Биле сынган аттай, уртасы сыгылган салам түбәле өйләр чүгеп артта калды. Төнге чыктан авырайган тузанны тузгытып тупырдаган тояк тавышы зәгыйфь яктылык саркыган тәрәзәләрне калтыратты.

Үр менүгә еракта офык сызыгы күренде. Кара-кучкыл дулкын рәвешле күтәрелгән урман якынайган саен биегәя, офыкны каплый бара иде.

Моратбакыйның күңеле инде анда — дөнья мәшәкатьләренә катышмыйча, хыянәтсез урман куенына сыенган гади генә йортта — Иләмән картның ярлылыгы белән бай, ярлылыгы белән иркен тыныч йортында.

Урман авызына керүгә Моратбакый атыннан төшмичә генә һавага атып җибәрер. Мылтык тавышын ишетүгә, Зарима, бабасына сиздермичә генә җыенып да, Атау су буендагы карт зирек төбенә килеп торыр.

— Зарима...

Моратбакыйның сак колаклы урман да ишетмәслек итеп әкрен эндәшүенә каршы ул җавап бирмәс, тын гына торып, инде ничә тапкыр ишеткән сүзнең дәвамын көтәр.

— Син кайчан үсеп җитәрсең инде, Зарима?

Бөтенләй уйламаган яктан — агач артыннанмы, үлән арасыннанмы, ниһаять, аның тавышы килер:

— Үссәм ни була?

— Мин сиңа өйләнәм.

— Чынлап әйтәсеңме?

Нәкъ моннан өч ел элек, бүре аткан көнне, Иләмән карт өендә шундый сөйләшү булган иде. Иңенә чуклы шәл салып, сәке йөзлегенә беркетелгән поши мөгезен каба итеп, җеп эрләп утырган кызчыкны күргәч, Моратбакый башта гаҗәпләнеп калган иде. Иләмән картны урманда бер ялгызы яши дип белә иде ул.

— Туганымның кызы,— дип таныштырган атлы итте аптырабрак калган егетне Иләмән карт.— Асрамага алдым. Монда ашаганы да, киеме дә урманнан. Ходаның кодрәте киң.

Кызый, кызыксынуын яшермичә, Моратбакыйга зур кара күзләрен төбәде. Кояшта янган озынча йөзле, чокырланып бүленмичә, маңгаеның дәвамы булып төшкән туры борынлы бу кызыйда шәрыктан килгән ниндидер борынгылык чалымнары бар, һәм егетне сәерсендергәне шул иде: аның күзләре кара урман кебек, сине кечерәйтеп, адаштырып калдыра, олыларча җитди, бәлигъ булган карашында күңелдәге иң яшерен уйларыңны да хәрәкәткә китерердәй үтемле очкын бар иде. Моратбакый үзеннән кечерәк (бер генә яшькә икәнен белми иде әле) бу үсмер кызның карашына каршы тора алмыйча күзләрен читкә алды, матчага себеркеләп эленгән төрле үләннәргә, нарат ботаклары буйлап сикерешеп уйнаган тиеннәргә караган булды. Кыз аны мыскыллы көлемсерәп күзәтәдер шикелле иде. Иләмән картның Айтуган байга сөйләп утырганы бар, аларның нәселе кайчандыр Кавказ якларыннан күчеп килгән, имеш. Бу кызыйның исеме дә, йөз рәвеше дә бу як кешеләренә охшамаган булуы шул ерак бабаларының мирасыдыр, дип уйлады Моратбакый.

Иләмән карт бүре балаларын өйгә алып керде, кызына күтәрелеп карамыйча гына, кыенсынгандай: «Сөт эчерт әле шуларга, Зарима, малларны ашатыйм инде мин», дип тагын чыгып китте. Зарима бабасының киек җәнлекләр атуын өнәп бетерми иде, күрәсең, бер тын сүзсез аптырауда утырды да урыныннан купты. Кече яктан таш тәлинкәдә сөт алып чыкты, бөтерелмәле күлмәк итәген тезләре арасына җыеп,

бүре балалары янына чүгәләде. Иңеннән сузылып төшкән калын толым очы, песи койрыгыдай бөгәрләнеп, идәнгә ятты. Зарима шыншып елашкан бүре балаларын сыйпарга, үзалдына сөйләнергә кереште:

— Ах, сезне, бәләкәчләрем, ятимнәрем минем, әти-әниегездән аердыларны явызлар. Әйе шул, кешеләрне әйтәм. Бәләкәй шул әле сез, берни дә белмисез. Ах, беләсезмени әле, шуңа җылыйсызмыни?..

Моратбакыйның авыр, тере толымны сүтеп карыйсы килә иде. Бүгенге бүре атуның хәвефле киеренкелегеннән соң туган рәхәтлектән ул тын гына утыра алмый, үзе дә аңлап бетермәгән бу халәт аны каядыр алгысыта, нәрсәгәдер кызыктыра иде. Кайчандыр ау маҗараларын мөкиббән китеп тыңлаган Моратбакыйга, өй белән абзар арасында киләп сарып йөргән Иләмән карт та кечерәеп калды, кызыксыз булып тоелды. Бу халәттә ул бөтенләй кирәксез иде.

Тизрәк үсеп җитсен иде бу урман кызы. Ак тәнле каеннар арасында чәчләрен таратып җибәрсен иде дә, адаштырсын иде үзенең тәнендә, киек җәнлек халәтенә кайтарсын иде тылсымлы карашында...

— Син кайчан үсеп җитәсең инде, Зарима?
— Үсәм ни була.
— Мин сиңа өйләнәм.
— Чынлап әйтәсеңме?!

Кызның шулкадәр ышанып һәм таләп итеп төбәлгән карашыннан Моратбакый, уйламыйча, шаяру катыш әйтелгән сүзеннән үзенең тайчына алмаячагына ышанып, курка калды. Ул бит, югыйсә, өстенлегеен тоеп, кыргый бер җәнлекне иркәләп юаткан кебек кенә, кәефен саклар өчен генә әйткән иде.

— Ә мин кияүгә чыкмыйм.
— Нигә?
— Син бай малае, ә мин...
— Малае гына шул, бай түгел.
— Әнә, нинди матур атың бар.
— Этинеке.
— Мылтыгың бар.
— Этинеке.— Моратбакый кулларын җәеп җибәрде.— Бөтен байлыгым — мин үзем.

Зарима, чәтертән кызларча, чыркылдап көлә башлады.

— Нигә дип сиңа ике кеше исемен кушканнар? Мо-рат — ба-кый.
— Минем бер генә абыем исән. Морат, Бакый исемнәләре үлгән. Шуңа...
— Бакый дип кенә йөртермен мин сине, яме?!
— Ярый.

Беренче тапкыр уянган теләк тыйнаклык чиген уза алмады: кызның маңгай белән борыны кушылган турын — ике күз арасын үбеп аласы килгән иде аның...

Шул елның җәендә тагын бер тапкыр күрде ул аны. Күрде... Һәм инде Иләмән карт өенә юлны оныта алмады.

Бакый атын салмак юырттырып, дегет буялган үләнле юлдан үз болынлыкларына таба бара иде. Бинһаян эре усаклары өскә аварга торган дымлы иңкүлеккә җитәрәк, сулыгып-сулыгып елаган тавыш ишетеп, тукталасы итте. Куркынулы елау тавышы чикләвек куаклары каплаган күләгәле караңгылык эченнән килә иде. Бакый атын юл буенда калдырды да, куакларны аралап эчкә үтте. Кулын авызына куеп кычкырып та карады, әмма тавышы яңгырап китәлмичә, авыр тынлыкта йотылып калды. Бераздан соң гына, юлдан эчкәре кергәч, зәңгәрсу күлмәк кигән кыз янына барып чыкты. Караса... Зарима. Корыган ботаклар сынудан Зарима дерт итеп артына борылды, елавыннан капылт туктап Бакыйга төбәлде.

— Каян килеп чыктың монда?

— Адаштым.

— Адаштың. Урман кызымы?! — Бакый көлеп җибәрде. «Ни сабый бала, ни җиткән кыз түгел, балланып алдыннан кызарган әче алма кебек, нинди сүз кушарга инде моңа», дип уйлады егет.

— Елан артыннан кердем дә адаштым. Ул мине ак елан янына алып барырга тиеш иде.

— Ак елан?..

— Еланнар патшасы. Аны күргән кеше бәхетле була, ди.

— Чаккан булса үзеңне.

— Мин аның күзенә туры карадым.

— Еланның да күзе бармыни?

— Шуны да белмисеңме! — Зарима, әле сабыйлыгы чыгып бетмәгән чыркылдау белән, көлә башлады.

Юлга килеп чыккач, Бакый кызның биленнән кочып ияргә күтәреп утыртты, тезген очын аңа тоттырды да үзе янәшәдән атлады.

— Өйгә кайтмыйм әле мин, бабайлар Сарлаклан болынында печән өяләр.

— Көпә-көндез адашып йөрисең шунда.

— Әллә нинди җенле җир бу.

— Кайчан үсеп җитәсең инде, Зарима?

— Нигә?

— Синнән башкага өйләнмим мин.

— Алдыйсың син.

«Син алдыйсың», әле кайчан гына бу сүзне белми идең бит әле, дип уйлады Бакый. Аның бердән үрелгән толымын учына алып, үлчәргә теләгәндәй тирбәтеп карады. Зарима, аның кулын читкә тибәреп, ияр дән алгарак авышты.

— Чәчеңә пәрәвез җебе уралган.

— Үсеп җиткән көнне мин үзем сиңа килермен...

Бераз тын гына баргач, Зарима кинәт, ай, дип кычкырып җибәрде, ияр дән шуып төште дә: «Кадалды, кадалды!» — дип, елый-елый, юл буйлап алга таба йөгерде. Арба эзендә кызыл эчле галошлары гына торып калды.

Аптырап, гаҗәпсенеп калган Бакый аңа эндәшеп тә, кычкырып та карады, әмма кызый артына да борылып карамыйча, чаба бирде. Бакый атын юырттырып Эстәрле суын чыкты, урне менде, кызның зәңгәрсу күлмәге беркайда да күренми иде. Сирәк агачлыктан уңга каерып, хәтсез баргач кына ул Сарлаклан болынына килеп чыкты.

Печән чүмәләсе янына җитеп, андагы хәлгә төшенгәч, Бакый хәйран калды. Чүмәлә башында торучы кулыннан сәнәген ялгыш ычкындырып җибәргән дә сәнәк җәбе Иләмән картның җилкәсенә кадалган икән. Киндер күлмәкләре манма тирдән күкрәкләренә сыланган чабаталы авыл агайлары арасыннан бер яшьрәге еламсыраган тавыш белән:

— Мин күрмәдем бит... ялгыш... ни хәл итәсең инде... ялгыш бит,— дип өзгәләнә. Картның ярасын Зарима ниндидер яфраклар ябып, чүпрәк белән бәйләп маташа иде.

— Хәзер, бабакаем, түз инде, яме, хәзер була, бабакаем.

Ерак арадан, урман эченнән үк шушы хәлне алдан сизенеп, Зариманың: «Кадалды, кадалды!» дип ачыргаланып йөгерүеннән тәмам әсәрләнгән, зиһенен җуйган Бакый Иләмән картка иелде:

— Ничек, бабай, хәлең?

— Түзәрлек, улым. Син дә мондамыни? — диде Иләмән карт, гыжылдавык тавыш чыгарып.— Кызым тотынгач булдыра инде ул.

— Өязгә, врачка алып барырга кирәк, хәзер үк!

Бакыйның тәвәккәл тәкъдимен Зарима бер карашы белән сындырып куйды:

— Беркая да җибәрмим бабайны!

Иләмән картны күтәреп диярлек җигүле арбага салдылар. Шушы хәлдә калуына уңайсызланган карт, ат кузгалыр алдыннан Заримага:

— Сәнәк-тырмаларны онытма, кызым, белгән урыныңа яшер,— диде.

— Мин гаепле, бабакай. Адаштым да сине бөтенләй онытып җибәргәнмен. Янында булсам...

Зарима әчтән, яшьсез генә елый иде.

Әнә шулай итеп, үзенә генә хас сәерлеге беләнме, теге чактан ук Бакыйны урман юлына тартты ул...

— Бүген киләсеңне белдем мин, Бакый.

Ачык тәрәзә каршында, сукыр лампа яктысында утырган Зарима кызара төшкән йөзен каплады. Бакый, өйгә керергә кыймыйча, урман кызын беренче тапкыр күргәндәй онытылып басып торды. Болдырга бәйләнгән ат пошкырып куйды. Чылтырап коелган чык тамчыларыдай, урман ешкынлыгыннан сандугач сайраулары ишетелә. Юк, ишетелми, ә җемелдәп күзгә күренә сыман иде.

— Бабай кайтмый бүген.— Зарима муенына аскан гәрәбә төймәләрне бөтерергә кереште. Бакый аның яңа күлмәген дә, толымын сүтеп, шәмәхәләнеп торган кара чәчләрен иңенә сибеп салуын да тәүге тапкыр күрә иде. Кыргый җәнлек сыман һич тә якын китермәс, үткен карашы белән күзләреңне читкә юнәлтә белгән кызый бүген әллә нишләгән — сабыр, оялчан, эчтән балкып, үзгәреп киткән.

— Мылтык тавышы ишетелгәч тә лампадагы ут калтырап куйды.

— Нигә зирек янына килмәдең?

— Урманга кергәч, атың сөрлегеп, чак егылмый калдың. Мин шундый курыктым.

Зариманың гайре табигый гадәтләрен белгәнгә һәм артык ышанып та бетмәгәнгә Бакый үз уен онытып пышылдады.

— Син чынлап та пәри кызы.

Аңа карап соклануын яшерә алырлык хәлдә идеме соң ул? Хатынкыз үзе дә белмәгән, үзе дә сизмәгән бер вакытта, нәкъ өлгереп җиткән вакытында, эчке матурлыгын йөзенә, тавышына, һәр хәрәкәтенә тигез таратып, табигатьнең үзе тудырган затка карап тантана итү мизгеле була. Бу мизгелнең шаһите була алган ир кеше яшәү дәвамында аның картая, сула баруын да искәрми, хәтер аша шул якты халәт белән тулыландырып тора. Юк, моны белми иде әле Бакый. Аның соң дәрәҗәдә соклануы бөтен тәненә калтырау булып таралган иде. Ул Зариманың оялып куюын да аңлап бетерми, урман телен өйрәнгән, җәнлекләр, үсемлекләр горефен белгән кызның күңелендәге хәтәр кыюлык, кыргый бер табигыйлекнең ниләр китереп чыгарасын да уена китерә алмый иде.

Бакый, тәрәзә тупсасына таянып, эчкә сузылды. Сукыр ут тирәсендә бөтерелгән күбәләкләр, сулыштан өрелгәндәй, читкә тайпылдылар.

— Син куркытма аларны. Күбәләкләр — үлгәннәрнең кире кайткан җаны диләр.— Канаты көеп, өстәлгә егылып төшкән күбәләкне Зарима учына алды.— Утка кушыла алмадыңмы, мескенем.

Менә ул утны өреп сүндерде дә, Бакыйга кулын биреп, ачык тәрә-

зәдән ефәк кулмәге белән шуып кына чыкты. Бакый атын тышаула
килгәнне көтеп, болдыр янында торды.

Урман аланы яшькелт яктылык белән өртелгән, хәрабәләр сыма
тырпаеп торган кара кучкыл агач башларына тияр-тимәс кенә а
карый — күкнең сәер елмаюы сыман...

Ай, агачлар арасыннан тиен кебек күчә-күчә, җитәкләшкән парг
нярең бара, ачыклыкка килеп чыккач кына тукталып, чиксез күк йө
зендә бер ялгызы өметсез елмаю булып оеп кала.

Ул Зариманың ай нурыннан көмешләнгән чәчен, сары күлмәген ге
нә күреп бара. Кеше биеклеге үләнне ерып барган Зарима бер сүз дә
дәшми, чык тамчылары биткә чәчри, юеше тәнгә үтә. Тоташ җемел
дәүле чыктан алар манма су булып, җылы төн кочагына кереп күмел
деләр. Син дәшмә, син берни дә сорама, дия кебек кызның кайнар
кулы.

Куе үләнлектән кинәт кенә ачыклыкка чыгуга, Бакый капылт тук
тап калды. Алга бер адым гына атласаң да төпсез, тирән күккә чу
марсың шикелле. Бакый хәтта артка чигенеп куйды. Каршыда — куе
урман белән каймаланган түгәрәк күл, убылып киткән тирән күкнең
бер кисәге шикелле, илаһи тынлыкта җәйрәп ята иде. Уртасында — күз
күреме җитмәс тирәнлектә, суның иң төбендә үк — чалкан яткан ай.
Яр сызыгы беленмидә. Куе караңгылык эченнән саркып кына ябал
дашлары тоташ үрелеп киткән каен кәүсәләре чагылып китә. Кайсы
чын урман — күлдәгеме, әллә ярдагымы, кайсы чын ай — күлдәгеме, әл
лә күктәгеме — һич аерырлык түгел. Бу шомлы матурлыктан тынсыз
калган йөрәкләрне куллар гына берләштерә иде: «Син дәшмә, син бер
ни дә сорама...»

Ауган агач өстеннән алар куаклар каплаган бәләкәй генә утрауга
керделәр. Аяк астында җир тирбәлеп куйгандай булды.

Аларның шәүләсе бер-беренә кушылган хәлдә әкрен генә йөзеп
бара. Кырыйда, кул сузымы гына арада — ай тирбәлеп калды.

— Миңа бүген уналты яшь, Бакый. Кайчан үсеп җитәрсең инде
дип бүтән әйтмәссең инде... Гел шулай кабатланыр кебек иде...

— Сине төштә күрдем бүген, Зарима.

— Әгәр без бүген ай каршында, күк каршында гөнаһлы булмасак,
күк безне үзенә алыр иде. Ә минем әле җирдә яшисем килә, Бакый...
Озак итеп. Мин синнән алда үләрмен, яме.

— Без беркайчан да үлмәбез шикелле, Зарима.

— Исемең кызык синең — Бакый...

— Мәңгелек дигән сүз.

— Мин синең күзләреңнең нурын үземнекенә кушармын, Бакый.
Тавышыңны бүлеп алырмын, йөрәгеңне... Синең күзләреңнең нуры
на үземнекен кушармын, Бакый. Тавышымны, йөрәгемне бүлеп бирер
мен. Язмыш безне аерса да, бер-беребезне оныта алмабыз. Мин ул ча
гында үземдә калган синең тавышыңны тыңлармын. Дөньяга синең
күзләрең белән карармын, синең йөрәгең белән яшәрмен... Минем кай
чакларда син булып карыйсым килә. Үземне бөтенләй күрәсем килми
башлый, ташлап качасым килә. Шулкадәр кызыгам сиңа, шулай атта
чабасым, мылтыктан атасым, синең кебек сөйләшәсем килә. Ә син
үзеңне минем урынга куеп карыйсыңмы?

— Нигәдер куркам синнән, Зарима.

— Җуләр, авылда бүре җитәкләп йөрисең үзең...

Өстә дә, аста да бер үк төстәге гөмбәз. Шулар уртасындагы нәни
генә утрауда калган Бакый, бер онытылу белән Заримага сыенды.
Аның чәчләреннән ромашка исе килә иде. Урманның ялангач, сагаю
лы тынлыгы аның бөтен күзәнәкләренә үтеп кергән, ул үзен шушы
җылы туфракка тамыр җибәргән үсемлек хәлендә итеп тойды. Сүзләр
гә әйләнә алмый калган күпме теләк сулкылдый иде аның күңелендә.

— Бик күп вакытлар үтәр. Син җиргә үзең рәнҗеткән, үзең аткан җәнлеккә — бүрегә әйләнеп яңадан кайтырсың. Сине дә атарлар. Җаның тагын бүредән көчсезрәк җәнлеккә күчәр. Тагын үтерерләр сине. Шулай үзгәрә-үзгәрә, иң соңыннан, җаның күбәләк булып очып килер. Без менә шул чагында күбәләкләр хәлендә очрашырбыз. Бер көнлек гомер безгә коточкыч озын тоелыр. Зарыгып көткән төн җиткәч, без бергәләп утка ташланырбыз.

— Ул дәвердә бу күл, урман беткән булса, без нишләрбез, Зарима?

— Ул чакта инде без бу төшне хәтерли дә, таба да алмабыз.

— Урман-сулар бетсә, ут тергезүче кешеләр дә калмый бит.

Җиргә тезләнеп утырган Зарима чәчләрен аркасына селтәп төшерде дә күккә төбәлде. Битләре буйлап күз яше ага, мәҗүси кыяфәттә кулларын сузып, ерак йолдызларга дәшәргә, тотынырга теләгәндәй, ярым пышылдап сөйләнә башлады:

— Тәңрем, бу җирне, бу урманны яраткан өчен мин гаепле түгел. Без гаепле түгел. Син бу җирне калдырырга кушып миңа канат биргәндә дә, соңгы минутымда, шушы җиргә бер әйләнеп карармын, яңадан кайтыр өчен. Тик хәтеремне генә алма!

Бакый аны җирдән торгызып кочаклады, яшьтән чыланган битеннән үбә-сыйпый башлады.

— Әллә нинди хорафатларга ышанасың, Зарима. Урманда яшәп хыялланачаксың син. Әйдә, китик моннан — кешеләр арасына, еракка.

— Олы җирдә кешеләргә урын тар, Бакый. Бер-берсенә бәрелеп йөриләр, бер-берсен үтерәләр. Анда кешеләр үсеп утырган агачлардан да күбрәк, кешеләр агачлардан күбрәк җирдән, беләсеңме, агачлар... күчеп китә...

— Син монда кала алмыйсың, Зарима.

— Вакыты җиткәч үзем әйтермен, яме. Син тыныч бул.

Бакыйның башын тезләренә куеп ул җайлап кына яткырды, чәчләрен, яңакларын йомшак кына сыйпый башлады.

— Син тыныч бул... менә шулай... менә шулай...

Бакый кайнар сулышын бәреп торган учак янында ята. Өстә — караңгы күк гөмбәзе. Каеннар белән түгәрәкләнгән алан уртасында тере учак яктысы. Ут телләреннән йөгереп чыккан шәүләләр, шүрәлеләргә әйләнеп, каеннарга сарыла-сарыла бии башлыйлар.

Бакый учакка карап ята.

Шул чак кемдер: «Син утның сул ягына кара, утның сул ягын күрә алганнар сирәк, сул ягына кара...» — дип пышылдый. Бакый шунда учак янына шуышып килгән еланны искәреп ала. Елан калкынып, ыспай бөгелеш ясый да, газаплы ыңгырашып, кабыгын сала башлый. Күз алдында ялангач кызга әйләнә бара. Кара толымы тулган ай шикелле яктырып торган күкрәкләре арасына төшеп яткан. Ялангач кыз, курыкма дигән ишарә белдереп, кулын сузган килеш Бакыйга таба килә.

— Абага чәчәген күргәнең бармы? — дип сорый толымлы кыз.

— Юк, — ди Бакый.

— Абаганың беркайчан да чәчәк атмаганын беләсеңме? — дип сорый толымлы кыз.

— Беләм, әмма чәчәк атарына ышанасым килә, — ди Бакый.

— Син әкияттән килдеңме? — дип сорыйсы килә Бакыйның, ләкин аның шулкадәр чын, җылы күз карашын тоюдан тыелып кала. Толымлы кыз, ком өстендә күләгәле эзләр калдырып, аңа якынлаша. Бакый кызның ялангач тәненә бер мәлгә ятсынып карый. Аның әле хатын-кызның тән бөгелешләрен яшереп, каплап торган гадәти күлмәк эчен-

дәге ялангач гәүдәнең шушындый булуын беренче тапкыр күрүе. Бары тик кулы белән, ирене белән, бөтен тәне белән кагылгач, кайнарлыгын тойгач кына 'аның матурлык икәнен, моңа кадәр яшәве яшәү түгел, ә шушы олы мизгелне кабул итәргә әзерлек кенә булганын аңлый...

Караңгы күк гөмбәзе йөзтүбән әйләнә. Учак та йөзтүбән карап яна. Һәммә тереклек бу мәлдә үзенең чагылышына, рухи яртысына күчә.

— Син төшкә генә кердеңме? — дип сорыйсы килә Бакыйның, тик, икенче карауга, кызның өстендәге тегелгән җөйләренә кадәр беленеп торган гап-гади күлмәген, тез йомшакларына кунган ком бөртекләрен искәреп, тагын сүзсез кала.

— Син бәхетле,— ди толымлы кыз.— Күпләр монда вакыты үткәч, картайгач кына киләләр. Моннан чыгу юлын мәңге таба алмасыңны беләсеңме соң син?

— Белмим,— ди Бакый,— әмма чыга алырыма ышанасым килә.

— Алайса, синең янда калам мин,— ди толымлы кыз.— Бу аланның исеме — күңел.— Һәм ул елан кабыгын алып учакка ыргыта.

Бакый балкып киткән учак яктысыннан чагылган күзләрен кулы белән каплый.

Инде таң беленгән. Агачларда күпме яфрак булса, тирә-юньдә шуның кадәр кошлар авазы. Әйтерсең лә иртәнге нарасый кояш нурларының яшеллек дөньясына кагылуы шулай мең яңгырашка бүленеп таркала иде.

Зарима, ялан аякларын суда чайкап, яр читендә тора, күлмәк итәге бөгәрләнгән, үреп муенына ураган толым очын тешләгән. Бакыйның уянуын күргәч:

— Килеп җиттек,— диде.

Бакый аның ни әйтергә теләгәнен аңламады. Тирә-якка күз салгач кына гаҗәпләнүдән чак кычкырып җибәрмәде. Ничек алар монда соң әле? Кичә бит алар бу утрауга күлнең теге ягыннан кергәннәр иде. Ә бүген утрау бөтенләй икенче якта, яр читендәге каеннарга ук килеп терәлгән. Утрау шул ук, югыйсә, куаклары да шул.. Аның аптыраулы кыяфәтенә карап Зарима көлеп куйды.

— Мин ул кадәр үк тылсым иясе түгел. Белми идеңмени? Бу йөзеп йөри торган утрау бит. Бәләкәй чагымда чумып мин аның астыннан чыгып уйный идем. Хәзер куркам. Ул вакытта әле минем беркемгә дә кирәгем юк иде...

Әле һаман да кичәге саташулы, хыялый төннең ләззәтен сулаган Бакый көн яктысында ничектер гадәти, аңлашылыр дәрәҗәдә якын тоелган кызны иңеннән кочып алырга теләде. Әмма ул шуып кына куллары арасыннан чыкты да читкә тайпылды. Җитдиләнеп, боеручан тавышка күчеп:

— Бар, кайт инде,— диде.— Мин утрауны теге якка чыгарып куям.

— Бүген кич зирек янында...

— Юк, юк, Бакый. Килмә. Хуш,— дип колга белән этеп, утрауны урыныннан кузгата башлады. Бакый инде ярга чыккан иде, кинәт кенә әллә нәрсә булды, күзләре кайнарланып китте. «Бу кызый гел генә шулай үҗәт, үз дигәнен генә итә торган, буйсынмас зат булыр микәнни! Нишләп әле мин!..» Бакый ярсудан ыргытылып утрауга менде.

— Сине барыбер монда калдырмыйм! Калдырмыйм...

Әмма горур сын шикелле басып торган кыз каршында кисәк көчсез калган Бакый тезләнеп, Зариманың аякларын кочып алды.

Зарима да тезләнеп, аңа сыенды. Бакыйның керфекләре арасында калтырап торган яшьне сөртеп алды.

— Рәхмәт сиңа... Кичә без бәхетле йолдыз астында янадан тудык, бер көнлек күбәләкләр булып. Утка ташлана алмадык. Хәзер инде яшәргә кала... Бар... Мин үзем чакырырмын сине...

Шулай күпме утырганнардыр. Тулышкан күңелендә җиңеллек тойган Бакый аңа күтәрелеп карый алмады, утраудан ярга сикерде дә каеннар арасына кереп китте. Әйләнеч сукмаклар белән күлнең икенче ягына, кайту юлына чыккач кына артына борылып карады.

Күл өсте төтенсу томан эчендә иде.

### III

Каравыл өендә сукыр лампа мыштым гына яна. Ике тәрәзә арасында күздән үк ябышып калган күбәләккә текәлгән Моратбакый, аны уятырга теләгәндәй, пыяланы шакып карады. Үзе дә әле ул татлы хатирәләреннән айнып дөньялыкка яңа гына кайтып төшкән, акшарлары купкан стеналарга, башын-башка куеп яткан этләргә, беренче кат күргәндәй, күз йөгертеп алды. Аларның тереме, үлеме икәнлекләрен дә бер мәлгә аңламый торды. Томан белән өртелгән күзләре күрә дә, күрми дә иде аның.

«Чынлап та булдымы соң ул төн?»

Тарыккан җанына урын эзләп, ул ишекне төбенә кадәр каерып ачты, калкына башлаган этләренә бер генә кычкырды — тегеләр берберенә сыенышып яңадан сеңделәр. Моратбакый кар шыгырдатып, эрезре атлап китте, күкрәк тутырып сулу алды, чатнап-чатнап киткән яшел балкышлы йолдызларның сыкылы салкынын тойган шикелле булды ул — тәнен рәхәт кытыклап, чымырдау үтте.

«Чынлап та булдымы соң ул төн?»

Ачык ишектән төшкән кызгылт ут яктысы тирән эзләргә пәрәвез кебек җиңел күләгәләр ташлаган. Бер якка ямьшәйгән иске каравыл йорты читтән шулкадәр бәләкәй күренде ки, бу калҗайган ишектән сыеп бүтән инде эчкә үтәлмәс сыман тоелды Моратбакыйга. Кырыйда гына менә дигән таш каравыл йорты торгызылган. Бөтен уңайлыклары бар: мич урынына кайнар су килгән торба белән җылытыла, тәрәзәләре зур, якты, түшәме биек, ә шулай да нидер җитми үзенә. Моратбакыйга гына шулай тоеламы, ни җитми дисәң, ул үзе дә тәгаен генә әйтеп бирә алмас иде. Кемгәдер исбат иткән сыман: «Стеналары шома, идәне тигез, энә ташласаң да күренә, җанны куеп торыр урыны юк»,— дип мыгырданды ул.

Яңа йортка инде бүген-иртәгә күченергә дип торалар. Шуңа күрә моннан ут чыбыгын да өзделәр. Ләкин Моратбакый кучүне һаман суза килде, ызбаның вак-төяк җитешсезлекләрен казып чыгара торды. Үзеннән яшьрәк алмашчысы күптән инде күчәргә дип төчергәләнеп йөри югыйсә. Электр уты урынына сукыр лампаны кабызгач, башта иялэшалмәс кебек булган иде Моратбакый, әмма тиз күнекте, әйтерсең, гомере буе сукыр ут яндырган. Ә нигә, менә дигән икән бит, кирәкне күрсәтә, күзне чагылдырып авырттырмый — яктысы йомшак. Электр утыннан ниндидер салкын тораташлык бәреп тора, ә бу лепердәп кенә тирбәлеп яна — җаны бар, моңы бар, күз карашыңны ялмап алып әллә нинди тирәнлекләргә алып кереп китә ул, хәтереңдә адаштырып, бер яшәртә сине, бер картайта...

«Чынлап та ул төн булдымы соң?»

Сукыр ут аның үзе генә белгән яшерен хатирәсенә, теге төнгә кайтарды. Аны искә төшерер алдыннан ул тәүлекнең нинди генә вакыты

булмасын, иркенләп, бүгенге кебек бик пөхтәләп кырынып ала иде. Моратбакый шома, чиста ияген канәгатьлек белән сыпырырга дип кулын иягенә китерде һәм... ишек ягына тотынып, катты да калды. Йөгерә-атлый кереп су салынган кружканы, бритвасын әйләндереп-әйләндереп карады, нәрсә булды соң әле бу, бер-ике сәгать элек кенә кырынган иде бит ул. Көзгенең болганчык яшькелт тирәнлегеннән аңа кара тут йөзле, чал сакал-мыек төкләре җемелдәп торган ир карап тора иде.

— Кичә кырындым микәнни,— дип үзалдына сөйләнде ул.— Вакытны бутаганмын...

## IV

Айтуган байның урыс капкасы киерелеп ачылды. Ихатага көпчәкләрен шыгырдатып җигүле ат кереп туктады. Аның артыннан бер төркем кешеләр ияртеп партячейка секретаре Шәмсуаров килеп керде. Шәмсуаров киндер кожанын җилбәгәй җибәргән, авыр иякле озынча йөзе аның гадәттән тыш агарып чыккан иде. Ул арада чылбырга бәйләнгән Карабай куе тавышка камалый-камалый өрергә тотынды. Колагын шомырайткан ат аңа карап-карап куя, арт аягына чүгә төшеп, тартылырга итенә иде. Шәмсуаровның кырыена ук килеп баскан Шамкаев (гадәти бер колхоз члены булса да, һәркайда тыгылып йөргәнгә күрә, авыл халкы инде аның Шәйми, Шәймөхәммәт дигән исемен дә онытып, фамилиясе белән генә дәрәҗәләп атый иде) эткә таба ачулы бер кул хәрәкәте ясап алды.

Шәмсуаров икенче катның верандасына чыгып баскан Котлыкаевка һәм ишегалдындагыларга карап:

— Бу ихатадагы һәммә әйбер халык байлыгы булып исәпләнә. Җыелыш карарын беләсез! — диде. Айтуган байның җилдән тузгыган чәчләре учмалап маңгаена төшкән, челтәрләп эшләнгән култыксаны сындырырга теләгәндәй кысып тоткан иде ул.

— Хәзер опись ала башлыйбыз, аннары...— Шәмсуаров үз янәшәсендәгеләргә нидер әйтергә дип борылды, шул чак, киң төпле галифе чалбар, төсе уңган буденовка кигән Шамкаев, Айтуган байга карап, тамак төбе белән кычкыра башлады:

— Ә сиңа җыена башларга вакыт! Җитәр, күп көлдегез халыктан!

Калын тавышка, саллы гына әйтеп куеп, үзенә буйсындыра һәм ышаныч тудыра белгән Шәмсуаров чәпчеп чыгучыларны өнәп бетерми иде, мондагы хәлне дә ул тыныч кына башкарып чыгасына ышана иде, ахрысы, шуңа күрә, сиздерми генә беләгеннән тотып, Шамкаевны арткарак чигерде. Һәм үз тирәсендәгеләргә ни эшләргә кирәклеген аңлата башлады.

Котлыкаев әле һаман шунда басып тора, йөзе сары тимгелләнеп чыккан. Ул инде бу көннең киләсен белә, әмма нәкъ менә шушы минутта килеп керерләр дә, тамырыннан кубарырлар, дип, күзалдына да китерә алмый иде. Нәрсәдер булыр, нидер үзгәрер дигән өмет һаман сабырлык бирә иде аңа. Бакыйга бүген инде ничә тапкыр олы юл ягын карап керергә кушты. Өяздән килеп чыкмасмы дип, олы малаен көтә иде ул.

Өченче көн караңгы төшкәч, өяздән исереп кайтып керде Котлыкаев. Сафуан агай белән Бакый аны көчкә сөйрәп кертеп салдылар. Өйдә ул бераз айныган сыман булды, күзләрен калайландырып:

— Кая, мылтыкны бирегез, атам мин аны, атам! Үземне дә... Барыгызны да! — дип бәргәләнә башлады. Бакыйның әнисе, куләгә ши-

келле генә чыгып, мылтыкны чормага ыргытып керде. Инде йоклап киткәч тә, саташып:

— Бирегез мылтыкны, атам мин аны! — дип, олы малаеның исемен әйтеп кычкырды Котлыкаев.

Үзе белән тиң итеп сөйләшмәгәнгә абыйсын бик үк күрәсе килеп тормый иде Бакыйның. Килсә: «Нихәл, барчук! — дип мыскыллы эндәшер дә теләсә ни әйтеп көлә башлар.— Комсомолга керергә уйламыйсыңмы?» — дияр. «Миңа велосипед алып бир әле, үскәч акчасын түләрмен»,— дигән иде аңа бервакыт Бакый. Егылып көлде абыйсы, соныннан да гел шуны искә төшерә иде. «Беләсеңме, синә бу ихатадан чыгарга кирәк, малай,— диде ул,— арысланны читлектән чыгарсаң ни эшли? Ике адым алга, ике адым кырыйга, ике адым алга, ике адым кырыйга йөреп тора. Син дә...»

Абыйсының бүген килмәвенә Бакый эченнән генә сөенеп тә куйды. Һәр кеше үзенә аерым уй һәм эш йөрткән бу ихатага кайчан да булса үзгәреш керәсен ул тәҗрибәсез йөрәге белән дә сизенә иде. Малайның дөньясы биек коймалар артында. Ә койманың аръягында яңа тормыш куәт алып килә, шул яңа дулкынга кушыласы, аңлыйсы, үзеңне сынап карыйсы иде дә, әтисенең буйсындыручан карашы аны чарасыз калдыра, рухын ала. Үзен ул чылбырга бәйләнгән Карабай белән тиңдәш итеп күргәнгә, әтисенә эчке бер рәнҗү саклый иде.

Котлыкаев, ярсыган тавыш белән, атлар сарае янында торган Бакыйга кычкырды:

— Этне ычкындыр!

Бакый, әтисенең әмеренә аңсыз рәвештә буйсынып, ыргый-ыргый өргән эткә ташланды. Этне җибәреп кешеләргә өстерү башында да юк иде, әтисенең ачулы тавышы һаман колак төбендә чыңлап торган хәлдә, аркасында аның утлы карашын тоюдан тагын да кечерәеп, ул чылбырны муенсага беркетелгән урыннан ычкындыра алмый азапланды — куллары калтырый иде. Бакый этне гәүдәсе белән каплады һәм йомшак кына дәшеп сыйпый-сыйпый сарайга өстери башлады. Этне бикләп чыккач та, куркынып верандага күтәрелеп карады — әтисе анда юк, пыялалы ишек арасына кысылып калган пәрдә генә ак флаг сыман җилферди иде...

Капка төбендә халык: яулык читеннән карап торган хатын-кызлар, карчык-корчык, бала-чагалар, — йөзләрен җыерып, күзләрен кыса төшеп карыйлар — борчылалармы, кызганалармы — һич аңларлык түгел.

Ул арада баскычта Айтуган бай күренде. Инде ничә көннәр буе иңен баскан авыр уйдан сыгыла төшеп йөргән Айтуган бай кинәт, шул авыр уен кагып төшергәндәй, тураеп басты, сары кунган йөзенә кызыллык бәреп чыкты.

— Мине беркая да җибәрә алмасыгызны беләсезме соң сез!

Бакый моңарчы әтисен иң таза кешеләрнең берсе дип белә иде. Ә менә хәзер, әтисе баскычтан төшкәч, шуны искәрде: аякларын аерып, нык басып торган Шәмсуаров аңардан бер башка калкурак икән бит. Шәмсуаровның карашына түзеп тора алмыйча, авызыннан спирт исе аңкып торган Айтуган бай, йөзен тартыштырып, мыскыллы көлгән шикелле итте дә ишектән кереп югалды. Бакый да аның артыннан нырде. Әтисенең сәер ялтыраган күзләре куркыта, шомландыра иде аны. Елап, шешенеп беткән әнисе, юткәленә буылып, мендәргә капланган. Бакый әтисе артыннан күләгәдәй ияреп йөри, берни дә әйтә алмый, тез буыннары калтырый иде. Ютәле тукталып торган арада әнисенең инәлүле тавышы ишетелде.

— Айтуган, ташла, кирәкми берни дә, баш сау булсын.

— Әти алай итмә.— Бакыйга да әнисенең сүзләре кыюлык бирде. Әмма Айтуган бай аларны тыңларлык хәлдә түгел иде. Борынгы сте-

на сәгатен каерып кына алды да, ишек яңакларына бәреләбәреләр, баскычка чыкты. Шамкаевның: «Җәмәгать!» дип кычкыруы артыннан ук, сәгать баскыч төбендәге ташка төшеп кисәкләргә аерылды. Эчендәге пружиналары, эреле-ваклы чүкечләре буталып, ярты юлда өзелгән вакытны хәбәр итеп калырга теләгәндәй, бер зеңгелдәп алды. Арт аякларына чүгеп куйган ат, өркеп, кисәк тартылды да, кече капкага житкәч кенә, тәртә башларын коймага бәрдереп, ыргып туктады. Тагын әйберләр күтәреп чыккан Айтуган байга ыргытырга ирек бирмәделәр.

— Алыгыз үзен! Бәйләргә кирәк, җәмәгать!

Айтуган бай, ачы сүгенеп, як-якка селтәнде дә өйгә атылды. Артыннан ишек ябылырга өлгермәде, ике көпшәле мылтыгын тотып, килеп тә чыкты. Ишек алдындагылар бердәм чигенеп куйдылар. Кешеләр арасыннан түгел, ә каяндыр өстән иңгән шикелле, ухылдау авазы чыкты.

— Якын килмәгез, атам!

Бакый шушы кадәр кешеләргә каршы баруны башына да сыйдыра алмады. Әтисен дә ничек тыярга белми, ул, өзгәләнеп, бары тик «әти» дип кенә әйтә алды һәм мылтыгына барып ябышты.

— Буталма! — дип, Айтуган бай каты кулы белән малаеның иңеннән этте. Айтуган бай әллә ничек, шомлы итеп көлә-көлә, ачык капкага таба китте. Урамда кызык күрергә җыелган халык коймага елышты, бәләкәйләр олылар итәгенә постылар.

Айтуган бай каршы яктагы чирәмле сөзәк тауга, кайчандыр үзенең әтисе яшәгән, хәзер инде ялгыз өянке генә торып калган нигез урынына таба чигенә башлады.

Җыелган халык, яше-карты, ни була инде хәзер дигән тәшвишле йөз белән бер Котлыкаевка, бер Шәмсуаровка карый. Шәмсуаров та мондый борылышка әзер түгел иде ахры, хәлиткеч карарга килә алмыйча туктап калган иде. Ә бөтен өмет — аңарда.

Айтуган бай хром итекләрен салып ыргытты, мылтыгын алга сузып, атарга әзер тоткан килеш чигенә-чигенә барды да өстеннән костюмына кадәр салып ташлады. Менә ул ялан аяктан яшел чирәм өстеннән сөзәк үргә таба күтәрелә. Куе, кара чәчләре җилдә җилферди, ак күлмәк изүеннән йонлач күкрәге күренеп тора. Бакыйның әнисе: «Туктатыгыз, эчсә дуамал ул, нишләгәнен белми», дип елый-елый сыгылып төшүгә Бакый да кузгалды.

Шәмсуаров Айтуган байга таба эре-эре атлап бара. Кожан чабулары ике якка ачылып киткән, гүя ул үзеннән артта килүчеләрне калкан булып саклап бара иде.

— Ташла мылтыгыңны, Айтуган!

— Якын килмә!

Айтуган бай ике көпшәле мылтыгын күкрәк турысына күтәрде.

Шәмсуаров аның шашыну чигенә җиткән ярсулы күзләренә туры карап килә, керфеген йомып кына алса да, күз угыннан ычкынуга, үз өстенлеген тоеп алган Айтуган бай кайтарып ала алмаслык фаҗига кылып ташлар сыман иде.

— Җәл, курку юк синдә, ике дә уйламый чакмага басарыем. Җенем сөйми куркакларны!

— Җүләрләнмә, Айтуган. Без бит сине төрмәгә җибәрмибез. Эшләрсең, үзеңне күрсәтерсең, башсыз адәм түгел бит син. Властьның дөрес юлда икәнен вакыты җиткәч аңларсың...— Шәмсуаров калын тавышы белән һәр сүзне үткәзеп, шул ук вакытта аны тынычландырырга, бу кискен халәтне йомшартырга тырышып әйтә иде.— Ташла мылтыгыңны.

Тагын бер адым... Айтуган бай өчен артка, Шәмсуаров өчен алга — тагын бер адым... Айтуган бай әллә ничек, сәер гыжылдап көлә башлады.

— Якын килмә — соңгы адымың... Үзем башладым, үзем бетерәм...

Бу тамашаның хәерле соңын ышанып көткән күпме күз карашын артында тойган Шәмсуаров чыдамады, кисәк тартылып, мылтык, көбәгенә ташланды. Айтуган бай кыргый тавыш белән кычкырып куйды, мылтыгын суырып алып читкә сикерде дә, алагаем селтәнеп, түтәсен тал кәүсәсенә китереп бәрде.

Кинәт... ачы итеп гөрселдәгән мылтык тавышыннан бөтен тирә-юнь сыгылып куйды.

Бакый инде килеп җитә язган иде, әтисенең мылтык көбәген үзенә каратып, түтәсен өянке кәүсәсенә бәрүен күреп калды — җитешә алмады. Инде килеп тә җитә язган иде бит, мылтык көпшәсеннән чыккан утны күрде, ул мизгелдә әтисе тере иде әле, «коткар», дигән шикелле үкенүле инәлү белән аңа төбәлгән күз карашын да тотып алды ул — җитешә алмады. Инде килеп җитә язган иде бит югыйсә... Җитешә алмады... Аннан соң кинәт убылып төшкән гайре табигый тынлык булып алды. Бары тик таш сарай ишегеп тырнап елаган Карабай тавышы гына бу тынлыкны сызып яралый иде.

Бакый, әтисен уятырга теләгәндәй, иңеннән селкетеп карады, күз алдын томан каплады. Шул томан аша ул кемнәрнеңдер әнисен култыклап алуын күрде. Шул томан аша ул йодрыгы белән күкрәген уып торган Шәмсуаровны күрде.

...Бала чагында авыргандагы кебек Бакыйның бөтен тәне кызыша башлады. Ул әле һаман бер уй белән көрәшә: мылтыкны шартлаудан элек тотып калырга дип омтыла, әтисенең «коткар» дияргә теләгән соңгы минуттагы үкенүле карашын тоеп, утлы ядрә булган чикне аңына сыйдыра алмыйча бәргәләнә иде. Чикнең теге ягын — канлы үлемне зиһене кабул итә алмый, ә чикнең бу ягында калган тере әтисе белән ярсып бәхәсләшә, аңа әрнеп ялвара, үпкәле рәнҗи, шул чикне аерырга да бөтенесен кире кайтарырга теләп кулын суза, кычкыра, йолкына, әмма елый алмый — күңеле томаланган иде аның.

Кинәт ул айныгандай булды. «Кагылмагыз!» — дип кычкырды да, әтисенең үлем кодрәте белән кысылган кулларын көчкә каерып ачып, мылтыкны алды һәм арыш кырына таба торып йөгерде. Арттан дәһшәтле ташкын куып килә сыман иде аны.

Куаклар коймалаган таш юлны чыккач кына ул, тәмам хәлдән таеп, сугылмаган арыш көлтәсенә егылды. Салам учмасын тешләде дә, бөтен гәүдәсен калтыратып, сулкылдый башлады.

Күпме шулай яткандыр, уянып башын күтәргәндә мөлдерәп тулган кояш инде тәмам суынып күк читенә төшеп килә иде. Менә аның аскы өлеше урман сызыгына тиеп сытылып китте дә офык иненә кан йөгерде. Күзгә күренеп бата барган кояш инде күмеләм дигәндә, тагын бер калкынып куйды — Бакыйга шулай тоелды. Кояш төшеп югалуга Бакый куркынып тирә-ягына каранды, кулы мылтыкка тиеп китте — шунда гына ул аны хәтерләп кулына алды. Күккә караган чакмага баскан иде, саңгырау гына чыртлау ишетелде, икенче чакманы тартуга, мылтык түтәсе алагаем көч белән җилкәсенә китереп бәрде, гөрселдәү авазы миен томалады. Куркуыннан ул кычкырырга да өлгерә алмый өнсез калды. Күктән киек каз юлыдай тезелешеп каргалар көтүе очып бара иде, алар мылтык тавышына дәррәү сискәнешеп, бер бөгелеш ясадылар да юнәлешләрен үзгәрттеләр.

V

Моратбакый сигаретны кисеп икегә бүлде, бер яртысын мөштегенә тыгып лампаны үзенә табарак тартып китерде. Сукыр ут сузылып тәмәкегә суырылып килде дә сулап чыгарган төтен эчендә, пәрәвезгә

эләккән күбәләк сыман, җилпенергә тотынды. Тәрәзә төбеннән сыкыланган ит кисәге алды, икегә бүлеп идәнгә куюга, яшь эт үз кабымлыгына корбанына сикергән кебек ташланды, карт эт исә азык янына ашыкмыйча, вәкарь саклап кына килде.

Моратбакый тезенә аякларын мендереп куйган яшь этнең җиз төймәләр тезелгән муен каешын колагына табарак шудырып куйды һәм каеш эзе төшкән урынны кашый башлады. Каты каештан эшләнгән муенса яңа иде, ул аның кырыйларын бөккәләп йомшартты. Моны районда интернат мәктәптә торып укучы игезәк оныклары алып кайткан иде. Бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган үсмер егетләрне хәтта Моратбакыйның карчыгы да аера алмый, ә Моратбакый үзе генә чамалаган йөз чалымнары, үз-үзләрен тотышларыннан аларны һич икеләнүсез аера иде. Алар озаграк кайтмый торсалар, Моратбакый пошына башлый, кулына шөгыль таба алмый йөдәп бетә. Карчыгы аптырый: сүзгә саран, каты бәгырьгә каян әле мондый инсафлык инде, ике сүзнең берендә — оныклары, ди.

Игезәкләр үткән ялда кайтмый калгач, Моратбакый: «Капка башыннан буран сылап китте, кайтсагыз шунда бер эш булыр иде ике кулыгызга. Базда шыткан бәрәңге сабагы кебек сураеп һаман озынга үсәсез. Ир кеше беләген уйнатканда эчтә йомран йөгереп йөргән шәйле булырга тиеш...» дип хат язып салган иде, менә бүген ялга кайтып төштеләр. Капка башы дигәне бер сылтау гына инде аның, кичәге буран тагын өстәмәгән булса, алар кайтканчы көрәп тә бетерәсе иде.

Борын астыннан тузганак мамыгы кебек кыюсыз гына мыек төртеп килгән бу үсмер егетләргә карап туялмый иде ул. Бердәнбер кызына ул кадәр егылып китмәде югыйсә, ә оныкларын... Бер-берсен сүздән бүлдерә-бүлдерә, юктан да кызык табып көлешә-көлешә сөйләшүләренә, һәр кыланмышларына исе китеп, кызыгып карый иде ул. «Их, шулар урынында булып, ваемсыз, рәхәт итеп бер генә көн яшәп карыйсы иде... Ир кешенең йөз рәвеше әзрәк тупасрак булса да ярый, болар бигрәк нәзберек, бу чибәрлек белән бәхетле булырлармы икән болар... Ярабби, син боларга озын гомер бир. Берәрсе белән ул-бу була калса, икенчесе яши дә алмас, өзлегер...»

Моратбакый мондый уйларыннан арынып өчен, салынкы кашларын чөеп, елмаюга күчә.

— Йөргән кызларыгыз бармы соң әле?

Игезәкләр үзара карашып көләләр.

— Икебезгә берәү җитә безнең,— ди Азат исемлесе.

— Барыбер аермыйлар,— ди Айдары.

— Яратканы аерыр...— Яшьләргә карап сокланудан Моратбакыйның күңеле тула: «Их, бер генә көн, шулар урынында бер генә көн булып карыйсы иде...»— Йомшап китүен сиздермәс өчен ул тавышын тупасландыра:

— Нәрсә сез, бүрәнә ярыгыннан да көлгән кызлар кебек кыйланышасыз. Ир булып җиткәнсез. Унынчыда укып та...

Бабасының шулай тупас кылануын яраткан игезәкләр тыела алмыйча тагын көлешергә тотыналар. Аларга карап яшь эт тә авызын ерган, борыч кузагы сыман кызгылт теле бер якка салынып төшкән. Моратбакый да шулар кебек бер онытылып, тәгәрәп көләр иде — инәнә алтмыш еллык хәтер баскан — шул җибәрми, шул тота. Шатлык ул аркасын борырга гына тора, шатлыкның аркасы карадан.

— Заман икенче шул сез яшьләргә,— дип, Моратбакый тирән сулап куя, ачылып китеп, бары тик үзе генә белгән иң газиз серләрен беркатлы игезәкләргә сөйлисе иде дә бит — нәрсәдәндер тартына, көне килер әле дип, һаман алдагыга күчерә, бүтән вакытка калдыра.

— Синең, бабай, шул ягың әйбәт, хәзерге яшьләр тегеләй, хәзерге яшьләр болай, дип зарланмыйсың,— ди Азат.

— Моннан ике мең еллар элек Сократ та, яшьләр үзгәрде, яшьләр бозыла,— дип офтанып утырган бит,— дип аны җөпләп Айдар.

— Ике меңен белмим, күз алдында үзгәрә дөнья. Безнең генә дәвер үтеп китте...

— Кая әле. Без гадәткә кергәнгә генә бабай дибез иң сиңа.

— Илле яшьтән артыкны биреп булмый сиңа, ба... әйе.

Тыгыз тиреле булгангамы, кара тутлары шулай сакланганга мы, битен җыерчыклар бик үк кискәләмәгән Моратбакый, чыннан да, үз кордашларыннан күпкә яшь күренә иде. Оныкларының бу сүзенә күңеле булса да, яшенә, гомеренә бәйле сүзләрнең бик эчкәре яткан сагышына кагылудан аның башы әйләнеп китте. Күз кабакларын бармагы белән кысып шулай хәтсез утырды.

— Син, Азат улым, бәләкәй чагында ук: «Бабайлар таякка таянып йөри, син бабай түгел», дия идең.

Азаты хыялыйрак булыр ахры, дип уйлады Моратбакый. Сукыр утка төбәлә дә моңсуланып китә. Ә Айдары бер урында утырып тора алмый: әле чөйдәге мылтыкны тотып карый, әле көзгенең рамын бармаклары белән капшап чыга. Бабасының кесә сәгатен чылбырыннан тартып чыгара да, әйбер бәһасен чамалаган сыман, учында тирбәтеп ала, капкачын бер ачып, бер ябып әвәрә китерә.

Кайчандыр Айтуган бай да: «Синең бу балаң хыялыйрак булды, чут эшенә ярамас, байлыкны таратып кына бетерер»,— дигән Моратбакый турында. «Синең балаң» — ягъни әнисе баласы исәпләнгән Моратбакый. Айтуган байның бөтен өмете өяздә кибет тотучы олы малаенда булган.

Ә бер вакыйгадан соң ул «Күрәм, рәт чыкмас синнән, малай!» — дип, Бакыйның күзенә бәреп, мыскыллап көлгән иде. Бер чак шулай, Бакый көтүче Фәхрүшкә үз чалбарын салып биргән иде. Шуны ишеткән Айтуган бай — үзе эчкән баштан уңлы-суллы акча таратып телгә керергә яратса да — улының бу адымын егетлек дип кабул итә алмады.

Бакый бәләкәй буйлы көтүче Фәхрүшне төрле мәзәкләр чыгаруы өчен электән үк яратып калган иде. Малайлар белән көтү туплавына төшәләр дә сәгатьләр буе Фәхрүшне тыңлыйлар, аның янында әвәрә киләләр. Ни генә уйлап чыгармый иде ул.

Менә көн сүрелә төшә, чиләдән тәмам әлсерәп, исәнгерәгән сарыкларга җан керә башлый, куләгәсен ияртеп, берәм-берәм табырдан чыгу ягын каера башлыйлар. Шунда Фәхрүш тагын бер мәзәк күрсәткән иде. Такыраеп беткән сукмак читенә чүгәләде дә, юлга аркылы таяк куйды. Менә беренче килгән сарык таякны сикереп чыга, аның артыннан икенчесе... өченчесе... Шуннан соң инде Фәхрүш таягын сукмак турысыннан алып яшерә һәм читкәрәк, малайлар янынарак күчеп утыра. Ни гаҗәп, арттан килгән сарыклар да, алдагыларыннан күрмәкче, таяк бардагы шикелле, теге урыннан берәм-берәм сикереп үтә башлыйлар. Шулай итеп бөтен көтү әлеге турдан сикереп үтеп бетә. Малайлар инде сарыкларның мондый аңгыралыгыннан эчләре катып, тәгәри-тәгәри көләләр.

Үсмер егет булгач, Бакыйның Фәхрүшне күптән инде очратканы юк иде. Аръяк болында күргәч, аның шул хәтле сәләмә киеменә карап катты да калды. Катлы-катлы ямау салудан чалбарының тез башлары кәкрәеп каткан, балак очлары таланган кебек сусәреп беткән. Бакый күп уйлап тормастан, чалбарын салды да аңа сузды. Гаҗәпләнеп калган Фәхрүш:

— Кит аннан, нигә ул миңа! — дип, чалбарга кагылырга да курыккандай, артка чигенде.

— Ал инде, Фәхрулла абзый, мин бит чын күңелдән.

— Кит аннан. Кая киим ди мин аны. Бу бит... бу бит... Җиргә дә утырып булмый моның белән... Әрәм итеп...— дип Фәхрүш, чебен куган сыман кулларын селти бирде. Үзе дә уңайсызланып һәм аптырап калган Бакый чалбарын аңа көчләп диярлек тоттырды да эчке ыштаннан гына бакча артларыннан өенә таба йөгерде.

Соңыннан да ул Фәхрүшне күргәләде, әмма теге һаман да үзенең сәләмә чалбарыннан аерылмаган иде. «Айтуган байның бу малае җүләр икән, тик торганда миңа чалбарын салып бирде»,— дип сөйләнеп тә йөргән, имеш. Анысына инде Бакый ышана алмады, кеше сүзе дип кенә карады, ул бит моны бары яхшылык теләп кенә эшләгән иде...

Капылт кына моны нигә исенә төшерде соң әле... Миндәге гадәтләр бик мыскаллап кына булса да алар канына күчкәндер, алар яшәсә, мин дә яшәрмен дип, оныкларына карап, үзенә үкенечсез тынычлык, юаныч табасы килүдәндер бәлки. Картайгач та сабый чактагы кебек иркәләнәсе килеп куюлар була икән. Оныклары тарафыннан сирән гына әйтелгән җылы сүз дә, рәхәт изрәтеп, күңелендә песи кебек бөгәрләнеп ята.

— Бу сәгать белән мылтыкны сезгә нәзер итеп әйтәм инде, балалар. Үзем үлгәч, төсем итеп сакларсыз.

— Үлем турында сөйләмәле, бабай.

— Үзең турында сөйлә. Гел әйтәсең дә...

— Икенче вакыт, Азат, Айдар. Икенче кайтуыгызда онытмагыз. Минә укыган халыкны тыңлыйсы иде. Белем дигәне безгә ярты-йорты гына эләкте.

— Журналларны син бездән күбрәк укыйсың, бабай.

— Хәтта фәнниләрен дә.

— Минә сез әйтегез әле,— Моратбакый үзе дә алдан ук уйга калган сыман тынып торды.— Бу җирләрне, күк җисемнәрен ни хәрәкәткә китерә, я?!

— Бөтендөнья тартылу законы буенча...

— Бу физиканың элементар законы.

Моратбакый игезәкләрне бүлдерде:

— Закон, закон дисез. Законны бөтендөнья уйлап чыгармый, берәү уйлап таба. Җирдә дә гомер буе шулай. Күктәгесе...

— Син алла димәкче буласың инде, бабай, иеме? — Айдар сәгатьнең капкачын Азатның борын төбендә шартлатып япты да бабасының жилет кесәсенә төшереп җибәрде. Моратбакый үрелеп матчага кыстырылган таякны алды.

— Минә сез, дөньяның әүвәле дә ахыры да юк дисез. Кешене ал: туа, яши, үлә. Мисалга бу таякны алыйк — минә башы, минә азагы.

— Нинди таяк әле бу, бабай?

— Шомыртныкы.

Азат таякны өстәлгә куйды:

— Хәзер аңлатам мин сиңа: минә бу таяк үсеп утырган агачның бер ботагы булган. Ә ул агач орлыктан үсеп чыккан. Орлык каян килгән? Орлык икенче агачтан очып җиргә төшкән булган кайчандыр. Агачның үсүе өчен туфрак, тагын күпме матдәләр кирәклеген исәпли башласак, шушы юл белән бара-бара без җирнең барлыкка килүенә һәм галәмгә үк чыгып китәрбез. Аңладыңмы, бабай?

— Аңлата алдыммы, диген, улым.

Сүзгә Айдар кушылды:

— Ә инде таякның азагына килсәк, шул ук логика. Әйтик, таяк янып көлгә әйләнде ди. Җирдә ашлама булып үсемлек карынына керде һәм аны сыер ашап сөткә әверелде ди. Сөтне без тәмләп кенә эчеп

куябыз да... Саный китсәң, тагын чиксезлеккә барып чыгабыз. Материянең мәңгелек әйләнеше.

— Ярый, әйләнсен дә ди, менә шуны беренче тапкыр кем кузгатып җибәргән соң?! Тәмам башны бутадыгыз, балалар.

Игезәкләр үсмерләргә хас утырып җитмәгән тавыш белән көлешә башладылар.

— Сез бик белдекле кыланып, бөтен нәрсәгә дә кистереп җавап бирергә гадәтләнмәгез. Андыйлар бик хәтәр була.— Ялгышрак ычкындырдым ахры, дип уйлады Моратбакый, аларның бит әле бөтенесен дә беләсе, белгән атлы күренәселәре килә, хыялларына күләгә төшермим тагын...

Каравыл өендә кинәт тып-тын булып калды. Карт эт авызын шыгырдатып ачты да, ямьсез тешләрен күрсәтеп, озак кына иснәде. Малайлар этне сыйпый-сыйпый, тыела алмыйча көлешергә тотындылар. Күзләрен йомып-йомып куйган карт эт, үзеннән көлүләрен өнәп бетермәгәнлеген сиздереп, башын читкә борды.

— Син, бабай, үзең күргәннәрне сөйлә әле,— диде, көлүдән туктап, сукыр лампа янынарак елышкан Азат.

— Бер кич утырып.

— Син гел шулай дисең дә...

— Онытасың.

— Купайтып сөйләрлек берни дә майтармадым алай. Сугышны инде кинодан карап та беләсез.

Моратбакый, теше сызлаган кеше шикелле, бераз яңагын кысып утырды.

— Әллә ни күрмәдем инде... Сез әнә, аръяк тау буендагы ике кабернең тарихын өйрәнегез.

— Коммунистлар кабереме?

— Бүгенге мул тормышны тергезеп җибәргән кешеләр ята анда. Хәзер бик еш язалар бит, батырлар эзен өйрәнүче балаларны ничек дип атыйлар әле?

— Эзтабарлар.

— Менә-менә.

...Моратбакый, читтән килеп урнашып, әле ярты ел гына эшләгән председатель янына барган иде. Читтән-читтән генә күргәләп калган иде ул аны амбар тирәсендә. Якыннан, өстәл артында ничегрәк икән бу дип, кабинетына сугыласы итте. Үз авылыннан булса, кермәс тә иде бәлки.

Курач кына гәүдәле икән яшь председатель, алтын кысалы күзлек киеп җибәргән. Тавышны бөердән чыгарып, иякне күкрәккә терәп сөйләшергә гадәтләнгән председательләрне үз гомерендә күп күрде Моратбакый. Җитәкче дигәннең шундыйрак булырга тиешлеге аның инде канына сеңгән иде. Ә бу бөтенләй башка...

— Сезнең бер дә күренгәнегез юк, абзый, таныш булыйк,— дип ул өстәл артыннан чыгып, ике кулын биреп күреште.— Сезнең кебек өлкәннәр еш килә монда.

— Утын-печән сорапмы?

— Төрлесе була инде.

— Фамилиям Котлыкаев иде элек.

— Хәзер үзгәрмәгәндер бит? — дип елмайды председатель, җитдилектән арыган йөзенә яктылык сирпелде.

— Үзгәртмәдем дә... Картайгач фамилиянең кирәге калмый икән аның. Моратбакый абзый дисәң шул җитә.

Моратбакый утырган арада гына да дистәгә якын кеше, бер-бер артлы кереп, ниндидер кәгазьләргә, боерыкларга кул куйдырып чыктылар. Арадан берсе, авызын кулы белән каплап, ишек төбендә туктап калды.

— Түргәрәк үт, Сабит абзый,— диде председатель.

— Сарымсак ашаган идем шул,— дип ул уңайсызланып кына килеп боерыкны өстәлгә салды.— «Здоровье» журналын укып ятам бу арада, дөнья микроб белән тулган икән.

Ниһаять, ишек ачылып ябылудан туктагач, председатель:

— Ни йомыш иде, Моратбакый абзый, сорагыз, кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез,— диде.

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, улым.

Председатель аңа сәерсенеп карап алды һәм башын чайкап куйды.

— Әле генә дә ничә кеше гозер белән кереп чыкты үзеңә. Миндә шундый-шундый артык әйбер бар, колхозга бирәсем килә, дип кергәне бармы? Юк бит.

— Андыйларны күргәнем булмады,— диде председатель елмаеп,— пенсия яшендә дә әле эшләп йөрисез икән, сез дә кирәкне сорый аласыз, Моратбакый абзый.

— Синең катыңа, улым, зарланырга дип кермәдем. Йөзең ышанычлы күренә — сүзне суырып аласың.— Моратбакый тәрәзәгә борылды.— Сәбәбе шул керүемнең, яңа салынган фермалар артында ике кабер торамы? Язулары юк инде аларның. Кулаклар үтергән ике коммунист кабере ул. Мин аларның исән чакларын аз гына хәтерлим дә әле. Элек ул урында менә дигән чирәмлек иде, хәзер тәме киткән. Янәшәсендә төзелеш бара, силос базлары казылган. Күчерергә кирәк ул каберләрне төп зиратка.

— Мин анда үзем дә аптырап йөрдем инде. Бик әйбәт киңәш белән килгәнсез, Моратбакый абзый. Уйларга кирәк моны, уйларга... Тарихын өйрәнеп... Халыкны, мәктәп балаларын да җыеп, бер бәйрәмдә...

— Берочтан төп зиратны да төзәттерәсе иде. Председательләр килә дә китә, ә төп йорт кала. Үлгәннәргә кадер — исәннәргә дә кадер дигән сүз ул. Сугыш вакытында Европада күрдем мин каберлекләрне, мең еллар буена гөл итеп ничек тотканнар диген.

— Шәһәрдә икенче хәл.

— Шәһәрдә дә иске зират урынын тигезләп завод салганны күргән булды... Ярый, улым, сине тотмыйм,— дип Моратбакый урындыгыннан күтәрелде.

— Рәхмәт, Моратбакый, абзый, йомышыгыз төшсә, рәхим итеп...

— Миңа берни дә кирәкми бит, улым.

Председательнең күзләрендә: «Нишләп соң әле коммунист каберләре турында син килеп әйттең, башка берәү түгел — син кузгаттың» дигән сорау, шикләнү күреп калгандай булды ул. Яхшы ният белән башланган һәр сүзенә шулай караганга ул кешеләрдән читләшеп беткән иде. Бәлки алай да түгелдер, кайчандыр кылган олы гөнаһын оныта да, кичерә дә алмаганга, үз шикләнүен кешеләр күзеннән эзлидер, үз-үзен хөкем итәдер.

Игезәк малайларга күптән инде исемнәре дә онытылып барган ике коммунист кабере турында әйтүне, председатель белән шул сөйләшүдән соң хәтеренә беркетеп куйган иде ул.

— Әби, озак йөрмәгез, бабагызны да алып кайтыгыз, коймак өлгертәм, дип калган иде бит — истән чыгарганбыз! — дип Азат дәррәү урыныннан торды.

— Чәй эчкән арада келәтләрне күтәреп китмәсләр әле, әйдә, бабай,— диде Айдар.

— Әбиеңнең сүземе,— дип, Моратбакый йөзенә саран елмаю чыгарды.

Тышта эре тажлы кар ява иде. Аста, иңкүлеккә җәелгән авыл утлары карлар арасыннан җемелдәп күренә. Үрдән йөгерә-йөгерә төшкән игезәкләр бер-берсен төртешеп егалар. Башта Азат егыла. Яшь эт

Айдарга карап өрә башлый — ачуланып түгел, алай ук кирәк түгел иде, дигән сыман, кыска-кыска итеп, шелтәләп өрә. Азат карга буялып тора да Айдарны чалып ега, утырып җитмәгән карны сыдырып көрмәкләшә башлыйлар. Яшь эт үзе дә уенга кушыла, кеше дигәнең ике аягында басып торганда гына көчле күренә икән, җәнлеккә охшап, карда ятып аунаулары әнә ничек кызык, җиргә якын... Карт этнең дә җаны түзми, гарип аягын күтәреп, титаклый-титаклый яннарына бара, яшь этнең малайлар белән буталуына кызыгып карый, койрыгын бутап аңа дәрт өстәп тора.

Малайлар калкынып, бер-берсеннән читкә тайпылалар да, кар ыргытыша башлыйлар. Яшь эт, ыргытылган кар йомарламын очып барышлый эләктерергә теләгәндәй, әле Азатка, әле Айдарга таба йөгерә, куанычыннан өреп алудан да тыела алмый. Алгысынуын чак тыеп уртага баскан карт эт, койрыгын бер уңга, бер сулга селтәп, уенга кушыла. Башын кыңгыр салып, кулларын артка куеп барган Моратбакый аларны елмаеп күзәтә. Яңа яуган кар исе, яшьләрнең ваемсыз кычкыру авазлары гүя бу имин тормышның бөтенлеге турында искәртә иде. Бу уенга инде Моратбакый карт сөякләрен язып кушыла алмый, шушы кичке тынлыкта кинәнеп яуган кар аклыгына карый алмыйча ул күзләрен йомды. Күз алдыннан сызылып киткән яра эзе җуелмыйча торды. «Сөйлә дә сөйлә, диләр. Барын да сөйләсәм, ничек карарлар минем күземә бу балалар? Аларны да югалтсам, кемем кала соң...» — дигән өшеткеч уй аның иңенә кара күләгә булып баскан иде.

## VI

Зариманы бер күрергә интизар булган Бакый аның «үзем чакырырмын»ын көтеп ята алмады, инде ничә рәт килеп китте, тик Иләмән картның богау йозак салынган ишеге һаман бикле иде, эчтә җан иясе булмагангамы, сүнеп калган тәрәзәләренә хәтле йомык, моңсу.

Бүген урман ачыклыгына килеп чыгу белән ул, каеннар ышыгында утырган ызбаның ишеге ачык икәнен күреп алды һәм дәртләнеп атын куалый башлады.

Бакый хәзер әнисе белән геңә калды, торган җирләре инеш ярында, карт өянкеләр астындагы җыйнак кына өйдә иде. Төп йортларына авыл советы, колхоз идарәсе урнашкан, абзар-куралары, таш келәтләре мал-туарлары белән бергә күмәк хуҗалыкка күчкән иде. Айтуган бай кучеры Сафуан абзый да шунда ат караучы эшендә, төннәрен ихатаны каравыллый. Бакый аңа мунча түбәсе астында тасланып беткән тәмәке себеркесеннән уып тәмәке алып килеп бирә, Сафуан абзый иң бер төрерлек тәмәке өчен теләсә нәрсә эшләргә риза, шулай итеп Бакый аның белән элемтәне өзмәгән иде. Сафуан абзый Бакыйга Җирән кашканы арт капкадан гына чыгарып бирә, Бакыйны озатып кала. Бәрәңге бакчасы ызаныннан төшеп мунча янынннан үтүгә, юл тар инеш күперенә чыга, аннан инде аръяк болын аша — туры урманга.

Урман тынлыгын яңгыратып, тупырдашып ишетелгән тояк тавышына Иләмән карт күтәрелеп карады. Трубкасыннан төтен бөркелеп чыкты. Төтеннең шушы урман куенында тереклек, яшәү барын искәртеп борыла-сырыла күтәрелүендә әллә нинди моң, үзенә чакырып, әйдәп торган гадел тынычлыгы бар иде сыман. Әлеге төтенне күрүгә күңеле тулган Бакый атын тыя төште, бу халәтне нигәдер сузасы килә иде аның.

Иләмән карт бәләкәй генә агач кисмәкне алдына куеп, кыяр тозлау белән мәшгуль иде. Бакый атыннан төшәр-төшмәстән үк ул юеш

кулын күн алъяпкычына сөртә-сөртә килде, агач тамырыдай каты куллары кушырып Бакыйга сузды.

— Ә-һәй, әле дә син бар, улым, хәл белергә. Әниең ни тарафларда соң? — дип сөйләнә-сөйләнә атның тезгененнән алып аран киртәсенә илтеп бәйләде дә, алдына печән кубәсен кабартып салды һәм янә сүзгә керешә алмаган Бакыйга үзе үк ярдәмгә килде.— Әнкәңне әйтәм, чирдән арына алмады, бахыр. Үпкә чире эчтән кимерә шул кешене, эчтән...

Иләмән карт трубка көлен кага-кага баскычка килеп утырды, кул хәрәкәте белән Бакыйга да урын күрсәтте. Кара тут йөзендәге чатнап киткән җыерчыкларны тагын да тирәнәйтеп, тыңлаучыдан бигрәк үзалдына сөйләнгәндәй дәвам итте.

— Атаң мәрхүмне әйтәм, дөньяның артына тибәрдәй булып кудыкуды да... Бигрәкләр дә уйламаганча инде, ил-кавемдә булмаган үлем.

Баядан бирле, мондагы тынычлыктан, эчкерсез мөнәсәбәттән Бакыйның менә өзеләм, менә өзеләм дип калтырап торган күңелен Иләмән картның турыдан-туры, бернинди читләтүләрсез сөйләве, киресенчә, тынычландыра гына барды.

— Патша хезмәтендә чакта Тәфкилев дигән бер урыс офицеры бар иде. Мине Илюша-татарин дип йөртә иде, бахыр. Атылып үлде шул, хатыны аркасында. Илләшәп кеше иде, мәрхүм...

Бакый өйлә җиткәнче Иләмән картка булышкалап йөрде. Зарима һаман күренми — өйдә булса күптән инде чыгып керер иде. Бакый аның турында сорарга да кыймый, картны шикләндерүдән курка иде.

Иләмән карт маңгаендагы зур миңенә терәлеп торган киез эшләпәсен шудырып, маңгаен кашып куйды да, тирән сулап:

— Һәй гомерләр...— дип, исәп белән тулган күзләрен еракка текәде.— Ничек тел онытылмый диген, кырык ел бит инде шушында, каравылда... Син килгән юл өстендә имәнлек бар бит әле, шул кайчан гына туйралык иде, үзебез утырткан идек... Хәзер әнә минем белән бергә бирчәеп баралар... Атаң мәрхүмгә бер әйткән идем, ул-бу булса, гәүдәмне эзләп тормаслар, урманга кереп югалырмын, шунда булыр каберем, дигән идем, кычкырып көлде генә. Күпме игелек кылдың, күпме агач утырттың, сине алар тиз генә җибәрми әле, диде. Сукырның күзен ачарлык, бөкрене турайтып җибәрерлек бер җене бар иде шуның. Байлык сикертә аны диләр иде... Менә...

«Байлык сикертә аны... «Бу сүзләр Бакыйның хәтерен яңартып җибәрде. Бәләкәй иде әле ул чакта. Әтисе белән өяздән кайтып килә иде. Тарантас җайлы гына тирбәтеп бара. Кучер Сафуан агай өчәрләп җигелгән атларга вакыт-вакыт чөңгереп ала да, авыз эченнән нindидер моңлы бер җыр көйләргә тотына. Тик менә кызмача Айтуган бай гына тәк утыра алмый, гел борсалана. Бер-бер хикмәт чыгарыр алдыннан шулай җанын кая куярга белми ул.

Өйләдән авышкан күләгәләр урман юлына аркылы егылган. Тар күпергә җитәрәк Сафуан агай атларын туктатты. Каршыга җигүле арба чыгып килә иде. Бәкәлләренә пычрак тигәнәкләр ябышып беткән, ябык, үшән алаша Айтуган бай турысына җитүгә, өреккәндәй туктап калды. Дилбегә тоткан агай, кулын күкрәгенә кушырып, исәнләшкәндәй итте. Күз төбенә чебеннәр җыелган, ишәк кебек башын игән, ялкау сыртлы алашага күрсәтеп, Айтуган бай кинәт көлеп җибәрде:

— Җүнлерәк ат юнәтергә булмыймы, кем?!

— Әчәмәй Арсланы, Таллы Буләктән,— дип тизрәк үзен белдерергәме, сүзне икенчегә борыргамы ашыкты әлеге агай.

— Атыңны әйтәм, ишәктән туганмы әллә?

Айтуган байның шаркылдап көлүеннән рәнҗетелгән агай, йөзен читкә борып:

— Соң, ходайның бирмеше шул булгач,— диде.

— Шәп атлы буласың киләме?

— Кая инде ул безгә...

— Өч тапкыр кәҗә булып кычкырсаң, атлык акча синеке.

Агай шәлперәйгән читле киез эшләпәсен бер салып, бер киеп куйды да, астан сөзеп карап:

— Булмый, туган,— диде һәм атын кузгата башлады.

— Син нәрсә! — Айтуган бай, аяк астыннан кармалап, җәһәт кенә мылтыгын суырып алды да, сыңар кулында гына тоткан килеш атның күкрәгенә төбәп атып та җибәрде. Моны Сафуан агай да, Бакый да абайламый калдылар. Башын чөеп, тәртә баулары өзелерлек итеп кисәк тартылган ат гөрселдәп җиргә егылды. Арбага тартылуга ук чәчрәп төшкән агай йөгереп килеп атының башын кочаклады, аннары тыпырчынган атның аякларын тоткалады, аты тирәли йөгереп йөри башлады.

— Нишләттеләр актык атымны, нишләттеләр, я хода!

Бу тамашага исерек көлү аша карап торган Айтуган бай, киерелеп, эчке кесәсеннән бумажнигын чыгарды да, эре акчалар санап, тегеагайның аяк астына ыргытты.

— Мә, якшәмбе базарында иң шәп ат синеке!

Күзләре ларып чыккан агай ачы сүгенеп, йодрыкларын кыскан хәлдә аның өстенә килә башлауга, Айтуган бай кучерның аркасына төртте, тройка дәррәү урыныннан кузгалды. Күперне чыгып, борылыштан күмелгәнче Бакый артына карый-карый барды. Кызганыч иде аңа карт алаша, кызганыч иде аңа тузан эчендә басып калган юаш агай.

— Нигә, эти, акчаңны болай гына бирмәдең, ник аттың, ник аттың, эти! — дип, кабатлый-кабатлый үкси башлаган малаеның беләгеннән кысты Айтуган бай.

— Син нәрсә беләсең, малай! Болай гына, имеш. Икенче ат алырга акчаны кызганачак иде ул барыбер, шулай бит, Сафуан?

Кучер борылмый гына, авыз эченнән нидер мыгырданып, дилбегә какты, аннары кычкырып атларга дәште. Ә «бүре йөрәк» Айтуган бай, салган баштан шундый мәзәк чыгара алуына үз-үзенә сокланып һәм иртәгә үк моның халык арасында таралачагын уйлап, хозурлы җырлап җибәрде.

Атның егылган чактагы күз карашы Бакыйның хәтерендә әле дә мөлдерәп тора.

Иләмән карт күз кырыен гына Бакыйга төшереп алды, егетнең бөтенләй канаты салынганны үзенчә юрап, сүзне икенчегә борды.

— Мин бykылдармын ул, әнә, кошлар сөйләшкәнне тыңла син.— Иләмән карт, башын кыңгыр салып, мыек астыннан елмайды, кулын күтәреп, Бакыйга тын торырга ымлады.— Кара син шомырт агачындагысын, ничек өзәләнеп чакыра кызын, ә тегесе: «Ашыкма син, ашыкма син»,— ди. «Сагынырсың, сагынырсың»,— ди зирек агачындагысы. Ишет син тегесенең ничек мыскыл итеп сызгыруын. Һәй гомерләр... Шунысы гаҗәп: ничәмә ел урманда яшәп, үле сандугач гәүдәсенә бер дә тап була алмадым...

Иләмән карт сыңар тезенә таянып күтәрелде: «Чәй куеп җибәрик, синең дә авыз кипкәндер, кайтмады бу, Зарима кызымны әйтәм, чиягә дип киткән иде»,— дип сөйләнә-сөйләнә өйалдына кереп китте.

Кисәк кенә кузгалган җил агач ябалдашларын сыйпап узуга, урман эре яңгыр яугандагы кебек тоташ шауга күмелде. Бакый, өшеп киткәндәй, куырылып куйды. Башын күтәреп, колакларын шомы-

райткан ат та пошкырып җибәрде. Агачлар арасыннан йөзләрчә күзләр төбәлгән шикелле тоелды Бакыйга, һәм ул, шомланып, бусагадан эчкә атлады. Кояштан керүгә, өйдәге салкынча күләгәгә бер мәл ияләшә алмый торды. Сәкегә җәелгән кулдан тукылган паласка да, кабартып куелган мендәрләргә дә, юылган идәнгә дә хатын-кыз кулы тигәнлеге беленеп тора. Сизелер-сизелмәс кенә эрем исе килә, шушы гап-гади генә җыештырылган гадәти әйберләрдән аның җылысы үзен сиздереп, өй эченә тыенкы бер ямь бирә иде.

Чәй янында Иләмән карт сүзне тагын Айтуган байдан башлады:

— Өяздә очрашкан идек, соңгы күрү булган икән мәрхүмне. Нигә дип мине чакыргандыр инде үзләре белән утырырга. Әй бәхәсләштеләр инде абыең белән. Татарча да, урысча да сүгештеләр. Абыең бит, беләсеңдер инде, бөтен байлыгын тапшырып, совет яклы булып китте. Әйбәт кенә урында эшли икән. Соңыннан Айтуган бай: «Син атаңа хыянәт иттең, югал күземнән!» дип куып чыгарды үзен. Икәү генә калгач, җылады мәрхүм. Хәмер дә башына киткәндер инде.

Бакый, ачык тәрәзәдән очып кергән бал кортын күзәтеп, сүзсез утыра бирде. Чәйдән чагылган кояш түгәрәге түшәмдә тирбәлә, эчпошыргыч бертөрлелек белән безелдәп, бал корты табын тирәли әйләнә, тәрәзә артында урман шаулый — җаны тарыгудан ничек котылырга белмәгән Бакыйның тышка йөгереп чыгасы да, бөтен урманны яңгыратып, бар тавышына кычкырасы килде. Шул теләк аны урыныннан кузгатты.

— Зари-ма-аа!

Урманның тоташ шавы астында аның тавышы ерак китә алмады. Менә хәзер, каршыдагы борылыштан кулына кәрзин тоткан кыз килеп чыгар... Атын куды да куды. Менә хәзер, иңкүлекне генә үтәсе дә, усаклар артындагы аланнан ул күренер... Атын куды да куды. Әмма кыз күренмәде. Ниһаять, Бакый теге түгәрәк күл буена килеп чыкты. Каеннар арасында кыймылдап куйган шәүләне искәреп, ымсынып куйды:

— За-ри-маа!

Беркем юк. Урман галәме эчпошыргыч көйгә гөжелди дә гөжелди.

«Кайда йөрисең син, урман кызы?! Нигә күренергә теләмисең? Җен кызы, җен кызы! Мине бәхетсез итәргә яратылган булсаң — күренмә! Кирәгең юк, кирәгең юк, җен кызы! Мин сине барыбер эзләп табам, табам да...» — Шулай үзалдына сөйләнә-сөйләнә Бакый бер аланнан икенчесенә килеп чыкты. Ахырда инде аңа тәмам рәнҗеп, арыган, ватылган хәлдә кайтыр юлга борылды. Атын куалый башлады, бу хыянәтчел урманнан тизрәк котылырга, ачуын басарга иркенлек кирәк иде аңа. Менә сирәкләнә барган каеннар арасыннан дулкынланып торган иген кыры күренде. Ачыклыкка җитүгә, урманга керә алмый азапланган җил аның йөзенә бәрелде, кепкасын йолкып алып артка ыргытты. Бакый, атын көчкә тыеп, кире борылды. Кепкасын алып, өзәңгегә генә баскан иде, имәнеп, катып калды. Авыл турыннан (ике тау арасындагы өйләр моннан күренми) күтәрелгән кара кучкыл төтен, гарасатлы давыл булып кайный-кайный, урман ягына агыла иде. Бу тирәдәге сары кырлар әле күгелҗем күләгәләр хасил итеп уйнаган җилдән хозурланып ята, ә анда... Бакый, ярдәм эзләгәндәй, аяз күк белән чикләнгән ерак офыкларга карады — бары да тынычлыкта, ә монда... авыл турысыннан, күк зәңгәрлеген томалап, әшәке төтен күтәрелә.

Бакый итек кунычына бөтереп тыгылган озын камчысын алып баш очында әйләндерергә тотынды. Ат томырылып урыныннан купты. Тоякларга тиеп кенә киткән юл артка йөгерә, Бакыйның күңеле нидер буласын сизенгәндәй ашыга, алгысына иде. Аръяк болынга

төшеп, чаптырып кына үзләренең тар күпереннән чыкты да карт өянкеләр астындагы сукмактан мунча капкасы янына килеп туктады. Күзләре кызарган әнисе каршы чыгып килә иде.

— Безнең өйгә капса, нишлибез, улым?

— Нинди өйгә? — диде Бакый тупас итеп. Манма тиргә баткан атның тезгенен киртәгә бәйләп куйды.

— Нинди дип...

— Безнең өй түгел бит инде ул!

— Барыбер, күпме яшәгән йорт — әтиеңнең төсе.

— Җил бу якка исми, кайгырма син.

Авыл өстендә әллә нинди фаҗигале авазлар яңгырап китә, йөгерә-йөгерә бәрәңге бакчаларына әйбер ташыйлар, өй түбәләрендә дә кешеләр күренә иде. Бакый ашыгып өске урам ягына кузгалгач, әнисе:

— Улым, син кая, йөремә, әллә нәрсә булыр тагын,— дип артыннан килә башлады.

— Кайгырма, әни.

Бу очта да кешеләр кайнаша. Әнә, гел мәзәк сөйләргә яратучан Нургали абзый өй түбәсендә, йөзеннән каны качкан. Бер кул яссуы җирнең муртайган саламына чаклы актарып ташлаган, үзе киртә буенда тукталып калган карт-корыларга карап туктаусыз сөйләнә:

— Очкын килеп төшүгә, бүрек кадәр ут бәреп тә чыкты, сулы бидрә белән өй почмагыннан очып кына менеп өлгердем тәки. Кара инде, ничек менмәк кирәк диген син, баскычсыз, сулы бидрә белән җитмәсә. Бүтән чакта якын да килмәле түгел.

Җыелганнарга җитә кала.

— Чынлап та.

— Җиле дә кире якка бит, ә!

— Ут үзе җилне бора ул,— ди Нургали абзый. Аның кабат шуны ук сөйли башлавын Бакый инде ишетмәде, үзәккә ашыкты.

Авыл үзәгендә биш-алты йорт инде кара күмергә әйләнгән. Ут телләре урамның әле бу, әле теге ягына сикереп, салам түбәләрне ялмап кына ала; күзе тонган кешеләрнең әрле-бирле чабышуы, борынны әчеттереп кергән көек исе, каерылып ташланган капкалар, өй түбәсендә торучыларның ят, хәвефле тавыш белән кычкырышу-сүгенүләре — барысы да күңелгә аяныч шом сала, авыл кайный, акылны, зиһенне ала торган әллә нинди күренеш иде бу.

Бакый килеп җиткәндә Шамкаевның өе яна иде. Билдән чишенеп ташлаган янгын сүндерүчеләр алагаем көч белән пешкәкнең сиртмәсен хәрәкәткә китерәләр. Әмма барыбер шлангтан чәптергән су ут каршында «кырмыска төкереге» кебек кенә. Өй тирәсендә багор тоткан адәмнәр кайнаша. Чиләк белән су китерүчеләр, йөзләрен каплый-каплый гына, утка бик якын килә алмыйча ерактан гына селтәнеп сипкән сыман итәләр.

Кинәт, ут телләренең дәһшәтле чытырдавын бүлеп, бер-бер артлы гөрселдәү авазлары яңгырап китте. Бер кырыйда кара тиргә батып, өметсез кыяфәттә басып торган Шамкаев кычкыра башлады:

— Ятыгыз! Ят! Анда минем обоймалар!

Бакый кыймылдарга да өлгерә алмыйча калды бугай. Каядыр чылтырап тәрәзә пыялалары коелды, шомлы гөрселдәү тавышлары бетүгә, афәт килгәч шулай бер йөрәк, бер җан булып береккән халык аһ итеп куйды. Каршы йортның салам түбәсеннән ут бөркелеп, түбәне ялмап ук килә икән. «Җәмәгать!» — дип Шамкаев, кешеләрне үз артыннан ияртеп, шунда таба йөгерде.

Җил белән бергә кушылып, ыңгыраша-ыңгыраша гүләгән утның йөрәккә шом сала торган үз тавышы була. Ут телләрендә чагылып киткән гаҗәеп төсләрнең кешеләрне әсәрендерә торган бер тәэсире

бар, йончыган, йөзләренә корым сарган, афәттән сыгылган адәмнәрне дә күз чите белән генә булса да тамаша кылырга мәҗбүр итә бәла китерүче кодрәт иясе ут.

Шул вакыт, бөтен тавышларны күмеп, «балам, балам!» дип кычкыра-кычкыра, дөрләп янган өйгә таба бер хатын йөгерә башлады. Бәрәңге бакчасына әйберләрен ташып йөргән җиреннән, кинәт исенә килеп, бакча киртәсен сикереп кенә чыкты да, бу якка таба йөгерә башлады. Хатынның күзләре калайланган, тиргә манчылган күлмәге, аркасыннан умырылып, беләкләренә салынып төшкән, изүеннән таза күкрәкләре ташып чыккан иде. Инде ут эченә кереп китә дигәндә генә Бакый аны тотып өлгерде: «Балам, балам!» — дип кычкыра-кычкыра ул Бакыйны йодрыклый, йолкына башлады. Кемнәрдер баласын табып китергәч тә әле ул тынычлана алмый интекте: баласын кысып үтерерлек итеп әле кочагына кысты, әле читкә тартылып, елый-көлә, көлә-елый, үз күзләренә ышана алмагандай, туктаусыз баласының исемен кабатлады.

Сөремле кызган һаваны шушы халык белән бергә сулап, утка каршы күтәрелгән дулкынга кушылып киткән Бакый үзе дә шашынган кыяфәттә бер тегендә, бер монда килеп тотына иде. Янгынга каршы булашканнар арасында ул шуны белде: ут Шәрәфи атлы адәмнең өеннән чыккан икән. Кызган халыкның талканы коры иде.

— Утка салырга кирәк аны, утка! — дигән сүзләр ишетелде.

— Үзе төрткән ул аны, урманга таба йөгергәнен күреп калганнар!

— Страховой алыргадыр исәбе, аның беткән өенә.

— Үз кулларым белән тотып салырыем!

— Артыннан киткәннәр инде.

— Утка салырга аны, утка!

Һәммә кеше бу фаҗиганың башын эзли иде.

Бакый монда тарсына башлады, бу кычкырышның, бу афәтнең ахыры булмас, әгәр... ут төртүчене шушы кешеләр аягы астына китереп ташлаучы табылмаса... бу көннең ахыры җитмәс шикелле тоела башлады аңа. Бакый, үз-үзен белештермичә, су буена, атын бәйдә калдырган урынга ташланды.

Атын чишкән чакта, әнисенең чыгып инәлә-инәлә аңа нидер сөйләнүен дә ишетмәде ул. Колагы баягы тавышлардан шаулап тора, күз алдында ут шәүләсе төшкән зәһәр йөзләр иде.

Башта ул атын сомраука юлыннан чаптырды (бояр Сумароков җирләре). Урманга җиткәч, икенче юлга төшеп, кире борылды. Нөгеш ярына чыккач, инкүлектә куе зирекләр, усаклар белән су дымын тартып хәйран үскән куаклыклар арасында, шәүлә кыймылдап куюын шәйләгәндәй булды, туктап, тыңланып торгалады. Ләкин ныклабрак карауга ялгышканын аңлады. Ул-бу күренми иде. Бары тик җил генә һаман бер көйгә җуылдый.

Атын җай гына атлатып текә яр борылышына җиткәндә, арыш арасында кара шәүлә калкынып алганын искәргәндәй булып, текәлебрәк карый башлады. Күземә генә күренә бугай, дип уйлады Бакый. Тезгенен кагып атын кузгатты. Инде китеп барасы иде бу төбәктән, көтмәгәндә теге шәүлә тагын калкынды. Бакыйны шәйләп алды бугай, нелә-нелә йөгерә дә башлады. Бакый кычкырып җибәрде, атын сикертеп диярлек урыныннан кузгатты. Һәм тегенең эзенә дә басты. Әйләнеп карагач, туп-туры өстенә томырылып килгән атны күреп, Шәрәфи өнсез курку белән җиргә чүгәләде. Өстенә чак басмый тыелып туктаган ат, алгы аякларын кушырып, катып калды. Шәрәфи тәгәри-тәгәри читкә тайпылды, тояклар астыннан чыгып өлгер-

де. Бакый аның тирләгән, пычранып беткән йөзенә төкергән сыман итеп кычкырып җибәрде:

— Син төрттеңме утны?!

Шәрәфинең кыйшаеп калтыранган иреннәре арасыннан аңлаешсыз мыгырдау чыкты. Бакый атыннан сикереп төште дә, аның пиджак изүеннән умырып алды. Болай да изрәп беткән пиджак, тиргә манчылган тәнне ялангач калдырып, аерылып төште.

— Тимә, апаем, котырттылар мине.. Үз өемә бит... Котырттылар мине...

Бакый аны акланыр, тана башлар дип уйлаган иде, кинәт дөресен әйтеп бирүе аны киресенчә ярсытты гына. Бүген көне буена тулышып килгән ачу-ярсуы, урманда үзен беркемгә дә кирәксез санап каңгырып йөрүе, авыл өстенә килгән афәт — бөтенесе дә бер төенгә тулышып, менә хәзер, шушы кешегә ташып чыкты. Бакый үз-үзен белештермичә, күнитек кунычыннан камчысын суырып чыгарды.

Чыжылдап камчы килеп тиюгә, Шәрәфинең күкрәк турында кызыл эз уелып чыкты. Шәрәфинең кыяфәте мескен була барган саен, ярсыды Бакый. Кан күрүгә тәмам иләсләнеп, үз-үзен белештермичә, хайвани дәрт белән ярды да ярды. Камчысы Шәрәфинең муенына уралды, Бакый аны тартып-тартып караса да, ычкындыра алмады. Күзләре акайган, шәмәхәләнгән иреннәре арасыннан күбек бәреп чыккан Шәрәфи, таш кебек киселеп, йөзтүбән ауды. Бакый читкә борылып укшый башлады, күзләренә яшь тыгылды. Аңын томалаган гасабилы йөзләр, дәһшәтле гүләгән ут телләре һәм шуның сәбәпчесе булган Шәрәфи — тук башаклары йөзне сыйпап-сыйпап алган тыныч кыр уртасында барысы да кинәт кенә мәгънәсен җуеп, Бакыйны бөтенләй чарасыз калдырды. Утка ташлаучылар кулына алып кайтырга иде бит исәбе. «Нигә соң әле мин йөрим? Мин үзем дә кыерсытылган бер ятим, бичара түгелме соң? Алар барыбер мине күрәлмаячак. Барыбер...»

Шунда Бакый атының ычкынып киткәнлеген, яр кырыендагы агачлык буеннан урманга таба юыртып баруын күреп алды.

Атын ул урманга җиткәч кенә куып тота алды, тезгене аягына уралганга гына тукталган булган ахры, күзләре шомлы ялтыраган, әсәренгән ат әле анда да тоттырмый йөдәтте. Бакый атка үлән чемченергә җай калдырып, тезгенен алгы аягына бәйләде дә, яр астына төшеп, инештә озаклап юынды, йотлыгып су эчте. Шунда гына ул үзенең бөтен тәне арып ватылганын тойды, мүкәләп килеп үлән арасына ауды. Урман инде гүләми, җил тынып калган, күктә кысыр болытлар җай гына агалар иде. Шулай оеп, йокылы-уяулы хәлдә күпме яткандыр, ниһаять, җиргә берекkән шикелле, авырайган гәүдәсен көчкә кузгатып күтәрелде. Атка атлангач, малай чагындагы гадәте исенә төшепме, атының җылы муенын кочаклап, ялына башын төртте дә, күзләрен йомды. Кайсы тарафка китсә дә, барыбер иде аңа.

Бүген генә булып алган хәлләрне кабат-кабат күз алдыннан кичереп карады ул. Арыш кырында Шәрәфинең башы күренеп китмәгән булса? Нәрсә булды соң әле? Нигә дип үрсәләнде ул? Әгәр авылга алып кайткан булса, шашынган кыяфәтле адәмнәрнең кулына тапшырса, мыскал да кызганмыйча утка салалар иде бит аны...

Кисәк кенә суытып җибәрдеме, Бакыйның тәне өшеп, калтырап куйды. Ат үз көенә барды да барды. Хуҗасы тезгенне тотмавын сизеп, юлдан каерылып үләнгә борын төртеп тә алгалады, тагын кузгалды.

Үр төшеп килгәндә генә Бакый күтәрелеп карады. Каршыда, инеш ярын каплаган шомыртлык артында таныш өй күренде. Җирән кашка

аны күнегелгән эзеннән Иләмән картның өенә алып бара икән. Бакый атны борып карт каен төбенә туктатты. Бу хәлендә күренәсе килми иде аның. Җанын өметсез бушлык биләгән иде. Тынып калган урман, сүрелеп барган көн дә аның иртәнге якты уйларын томалаган иде.

Баскычта Зарима күренүгә, ул, үзе дә сизмәстән, каен ышыгынарак елышты. Зарима, аяк очларына басып үреләүреlә, өй артына сузылган бауга керләр элә башлады. Шул вакыт өй каршына чаптырып атлы җайдак килеп туктады. Ямьшәйгән эшләпәсеннән үк аның Иләмән карт икәнен Бакый танып алды. Ул нидер әйтүгә — тавышы монда кадәр ишетелми иде — Зарима кулындагы керләрен төшереп җибәрде дә, бабасының янына килеп нидер аңлаштылар, шуннан соң Зарима кисәк кузгалып авылга кайта торган олы юлга йөгерә-атлый чыгып китте. Бабасы аның артыннан кычкырып та карады, ә ул, борылып та карамыйча, агачлар арасына кереп күмелде.

Бераздан Бакый да килгән юлына атын борды. Күнитеге кунычыннан камчысын алырга дип иелде, камчының Шәрәфине кыйнаган җирдә калганлыгы исенә төшкәч, тезген очы белән уңлы-суллы сыдырып, атны куалый башлады. Бүгенге хәлләрне хәтереннән чигерә-чигерә арган миен кинәт яралап кергән «үлдеме икән әллә?!» — дигән уй аны тәмам тәшвишкә салды. Моңа кадәр нишләп соң ул аны башына китермәде?

Тагын җил кузгалды бугай, тирә-юнь тоташ шауга күмелде. Урман я бер авыр итеп сулыш алгандай итеп куя, я бер ыңгырашып ала. «Үтердең... үтердең... үтердең...». Урман ешкынлыгыннан килгән бу пышылдау Бакыйның кан тамырларына таралып сулкылдый. «Тизрәк барып җитәргә кирәк теге урынга.» Бакый атның корсагын үкчәсе белән сызып алды. «Теге урынга... Тизрәк... тизрәк... тизрәк...»,— дип, тояклар тупырдады. «Киресенчә, мин аны коткарып калдым»,— дип Бакый, ярдәм эзләгәндәй, агач ябалдашларына, күккә карады. Әле иртән генә бөтенесеннән дә иркәрәк иде бит ул. Иртән генә... Зарима өйдә туры килгән булса, мондый хәлгә тарыр идемени, урманда бер хәбәрсез югалып торыр иде, Зарима өйдә булган булса...

Әнә арыш кыры. Инешнең текә яры уелып кергән, юл бөгелеш ясаган турда Бакый атын туктатты. Менә арыш сабакларын ерып кергән эзләр. Бөтерелеп үскән куе тармаклы каен төбендә Бакый атын калдырды да эзләр буйлап арыш арасына кереп китте. Сары дулкын арасыннан тагын теге шәүлә караеп баш калкытыр сыман тоелды аңа. Шушы төш бит инде, бер кишәрлек урында арыш сабаклары егылып, кара туфрак белән буталган — беркем юк. Бакый тезләнеп, мүкәли-мүкәли карап чыкты — өзелгән сәдәфтән башка нәрсә табылмады. Бүтән тарафка киткән эзләр дә күренми, арыш сабаклары тоташ стена булып утыра, эзләр бары бер якка, инеш ярына таба юнәлгән иде.

Шикле уйлардан изелеп килгән Бакый җиңел сулап күтәрелде, камчысы да табылган булса... Шәрәфи үзе белән әлләктереп киткәндер, дип уйлады ул. Атын җитәкләп, ярның сөзәкләнгән турыннан төште дә инешне аркылы кисте. Хәзер инде Зариманың каршысына чыгу иде аның нияте. Урман өстенә сыек кына зәңгәр иңеп килә, иртәгесе көнгә куәт җыярга әзерләнгән агачлар калкынып, кабарыбрак киткән кебек.

Куе усаклыкны үтеп чаттан борылуга, Бакый ерактан ук Зариманы искәреп алды. Озын күлмәк итәге атлаган уңайга җилферди. Ашыгып килә. Каршысында атлыны күрүгә, кыз бер мәлгә туктап калды, әллә инде Бакыйны танымады, нигәдер юлдан тайпылды да куе куаклар арасына кереп күмелде.

— Зари-ма!

Бакыйның тавышы, чыбыркы шартлагандагы кебек өзек-өзек таланып, урман эченнән кире кайтты. Куаклар арасында, кызның зәңгәр

кулмәгә чагылып киткән турда, Бакый, атын туктатып та бетермәстән, җиргә сикереп төште.

— Зарима, кая йөгерәсең, туктале!

Куакларга сыдырыла-сыдырыла аның артыннан үзе дә чаба башлаган Бакый бу сәер кызның тагын ниләр кыласын башына да китерә алмый, бары тик аны отыры караңгылана барган ешкынлыкта күздән җуймаска, югалтмаска гына тели иде. «Нигә шулай син, пәри кызы... Кайчан кулга өйрәтермен сине, кыргый җан...»

Танымаган шикелле, һаман саен артына карый-карый йөгергән кызны ахыр чиктә куып җитеп биленнән кочып алгач, Бакый аңа шул сүзләрне әйтергә дип авызын ачкан гына иде, ләкин йодрыклары белән Бакыйның күкрәгенә суга, йолкына-тартыла башлаган Зариманың нәфрәтле күзләре аны тәмам аптырашта калдырды. Зарима, аңардан чирканган рәвешле, кулларын сузып читкә ыргытылды.

— Кагылма миңа!

— Ни булды, Зарима?

— Якын киләсе булма!

— Син нәрсә?

— Кулың гөнаһлы синең. Кан исе, кан исе, кан... Абыемны үтерүче!

— Абыеңны?! Мин беркемне дә үтермәдем, Зарима, акылыңа кил.— Шашынып, ни эшләргә белмичә, Бакый аның артыннан бара, күз алдына Шәрәфинең кырынмаган соргылт йөзе, куркынган чырае килә, шуның белән Зарима арасындагы уртаклыкны һич тә башына сыйдыра алмый һәм бу коточкыч сүзләргә ышана да алмый иде. Кинәт аңа бу кыз шулкадәрле дә чит-ят, бүтән дөньядан килгән салкын бәгырьле бер зат булып тоелды, янәшәдәге агачлар да ниндидер хакыйкатьны яшергәндәй шомлы, караңгы, усал күренделәр. Шушы уен басарга теләп, ул авыз эченнән гел бер сүзне кабатлап барды. «Мин үтермәдем, мин үтермәдем...»

— Минем абыем иде ул!

Зарима ләгънәтле йөз белән кырт борылып туктады һәм кискен бер хәрәкәт ясап, изүен ачып җибәргәндәй булды. Нәкъ шул мәлдә агачлар арасыннан төшкән кызгылт кояш нуры Бакыйның күзен чагылдырды, күзен йомар алдыннан ул, баеп барган кояш нуры аша, Зариманың тәнендә муен янының аркылы-торкылы сызылып төшкән камчы эзләрен күреп калгандай булды. Моңа ышанасы килмичә, бер кулы белән күзләрен каплады да, икенче кулы белән капшанып янәшәдәге агач кәүсәсенә тотынды. Агачның әкрен генә тирбәлүе бераздан аны тынычландыргандай булды. Керфекләрен күтәрсә... адашып кергән кояш нуры да урман ешкынлыгында йомылып сүнгән, Зарима да җил алган кебек юкка чыккан иде. Аның әле генә шул урында басып торганлыгын раслап, тапталып калган абагалар гына тураерга теләгәндәй кыймылдап куйдылар.

## VII

Йокылы-уяулы яткан Бакый стена артында нидер кыштырдаганга күзләрен ачты һәм тәрәзәгә капланган шәүләне искәреп сикереп торды. Шикләнә-шикләнә аяк очына басып, тәрәзәгә иелде. Тирләгән пыяла аша йөзен ачык күрмәсә дә аксыл яулыгыннан хатын-кыз икәнен шәйләп алды. «Зарима», дигән уй бөтен тәненә уттай йөгерде. Бакый, абына-сөртенә чыгып, ишекне ачты.

— Кем ул анда?

— Мин бу — Зәйтүнә.

— Сине кем җибәрде?

Бакыйның шикләнү катыш ачулы тавышыннан каушаган кыз сүзен әйтә алмыйча торды. Аннары гына, исенә килеп, кулындагы ашъяулыкка төргән әйберен сузды.

— Ашыйсың килгәндер, менә, җылы бәрәңге.

Бакый үрелеп өстәлдәге сукыр лампаны кабызды.

— Әйдә, кер,— дип, Бакый ишек төбендә таптанып торган кызның кулындагы төенчеген алды, аның капылт кына шулай килеп керүен һаман да төшенеп җитмәгән иде әле ул. Төенчектәге кулын пешереп торган ризык кайнарлыгы гына бераз тынычландырган кебек булды аны. Өй эче сары бүрәнәләренә кадәр яктырып китте. Бакый тиз генә бәләкәй тәрәзәне корып куйды.

— Әниеңнәр сине кичкә хәтле көттеләр-көттеләр дә тарантаска утырып китеп бардылар.

— Беләм.— Калдырган язулары буенча, әнисен дә, Бакыйны да алып китәргә дип абыйсы кайтканлыгын белә иде ул.— Сиңа әйтеп калдырдыларммы? — Әнисенең бу кыз белән бер дә сүзгә кермәвен, аны ерактан күрсә дә, сыртын куюын күрә-сизә иде Бакый, юри, үчекләп кенә сораган булды. Башыннан үткән бүгенге хәлләрне мең кат яңадан кичерә-кичерә тәмам гаҗиз булган, кыйналып ташланган кебек арган иде ул, кулы кайнар бәрәңгегә кагылуга, җанына тынычлык иңде, сөйләшәсе килә башлады. Азга гына булса да онытылырга иде аңа.

— Сөйләшкәннәрен ишеттем. Күреп тордым. Без бит күршеләр.

Су буенда, утыртма казыктан кызыл балчык сылап эшләнгән фәкыйрь генә йортта яшәүче бу кызның өянкеләр арасындагы сукмактан көянтә-чиләк асып суга барганын көн дә диярлек күреп кала иде Бакый. Төбенә бирчәеп беткән кычытканнар үскән киртә аша аның ишегалдында чуалганын да искәрә иде. Бакыйларның мунчасы ул өй янәшәсендә генә. Шулай да кызның: «Без бит күршеләр» дию мыскыллау булыбрак ишетелде Бакыйга. Әнисенең һаман «Китик моннан, китик» дип тукуы шулар белән янәшә яшәүдән гарьләнү аркасындадыр әле, дип юрады Бакый.

— Сине мин телсез дип йөри идем.

Зәйтүнә йөзен түбән иде, маңгаена ук төшереп, ямьсез итеп бәйләнгән иске яулыгы астыннан керфек очлары гына күренеп калды. Әллә нинди чубыргалы күлмәк кигән, җилдә җилфердәп торган җитез гәүдәле карчыкларга охшап йөргән бу кыз белән кайчан да булса сөйләшергә, болай янәшә калырга туры килер дип башына да китермәгән иде Бакый. Зәйтүнә, башын күтәрмичә генә, керфекләр арасыннан карап:

— Син дә китәсеңме? — диде. Аның куркынган кебек соравына каршы Бакый дәшмәде, каткан ипине шыкырдатып сындырды, өстәл сыман нәрсәне уртагарак күчереп куйды.

— Әйдә, синең дә ашыйсың киләдер бит?

Зәйтүнә, кыстатып тормастан, өстәл янына килеп чүгәләде.

— Мин берүзем генә. Күңелсез. Әни күрше авылдагы берәүгә кияүгә чыкты. Ныклап торып яшәп китәлсәк, кайтып алырмын, ди.

Зәйтүнәнең әнисе бөкре Сәйдәне, димче хатын буларак, бөтен тирәяк белә иде. Хәтта, Бакыйның этисе дә аның белән нигәдер төче теллләнеп сөйләшә иде. Нигәдер... Элегрәк, этисенең кибетеннән «түләрем, Айтуган, гадәтемне беләсең бит», дип кайбер әйберләрне бушка гына алып чыгып киткәләгәнен Бакыйның да күреп калганы бар.

— Берүзеңә куркыныч түгелме соң?

— Ишек төбендә балта тотам.

Әлеге фәкыйрь генә өйдә болай бер дә тартынусыз сөйләшә белгән кыз яшидер дип һич тә уйламый иде Бакый. Ирексездән ул аны Зарима белән чагыштырып карады. Сәер гадәтләре белән һәрчак сине киеренке халәткә куя торган, бер карасаң салкын, бер карасаң ут алын-

ган карашы күңелеңне үтәли күрә алган Зарима бөтенләй бүтәнчә икән шул, аның белән чагыштырганда — Зәйтүнә гади, аңлаешлы, ни әйтсәң дә тыңлар кебек. Зариманың өстенлеген тойган Бакыйда горурлык һәм әрнү хисе бергә туды. Бу кызның каршыда утыруы әлеге хисне рәнҗетә иде. Бакый, йөзенә китереп, нигәдер кулларын иснәде. Зариманың изүен ачып җибәрүе, тәнендә аркылы-торкылы сызылган камчы эзләре...аның кычкырган тавышы — барысын да хәтереннән алып ташларга, күз алдыннан куарга тырышты Бакый. Күрше кызының кырыемда утыруы, бер карасаң, әйбәттер дә әле, әгәр ул хәзер чыгып китсә, акылдан язуым бар, дип уйлады ул.

Арыган-йончыган, яшәү кызыгын җуйган Бакыйга көтмәгәндә шушылай кайнар бәрәңге күтәреп кергән кыз гүя үзе белән юату, тынычлык алып керде.

— Мин пешергән бәрәңгене ашап кара инде,— диде Зәйтүнә. Аның җылы тавышы, үзен олысымак һәм ипле тотуы Бакыйны буйсындырды, малай хәлендә калгандай, кыюсызланып ул юктан бар булган табынга үрелде.

— Мин соң кайттым, урманнан.

— Син гел каядыр китеп югаласың.

— Ниләр булып бетте авылда?

— Уналты йорт янды.

— Тагын?

Зәйтүнә кемнәрнең ихаталары януы турында тәфсилләп сөйләргә кереште. Соңыннан ипи валчыгын, бәрәңге кабыкларын бик бөртекләп җыеп коштабакка салды, өстәлне сөртергә кереште.

— Ярый, Морат, син йокла.

— Бакый дип эндәш миңа.— Көтмәгәндә шундый кадер күрсәтүенә каршы бер кәлимә җылы сүз дә әйтә алмавына Бакыйның үз-үзенә ачуы килде. Өйдә икәнлеген беркемгә дә әйтмәскә кушып, ишекне тыштан бикләттереп калды. Зәйтүнә карусыз риза булды.

Икенче көнне, кеше-кара күрмәгәндә, Зәйтүнә тагын аңа ашарга китерде. Ишек ачылып китүгә, сәкедә йөзтүбән яткан Бакый агарып, сулып калган йөзен күтәрде. Берни аңышмый торды. Эчкә уелып кергән кояш яктысын Зәйтүнә ишек белән кысып куйгач һәм тәрәзәдәге япманы ачкач кына күзләре ияләште.

— Син бүген китәсеңме, Бакый?

— Кая?

— Әниең янына.

— Мин беркая да бара алмам инде, беркая да! — Бакый йодрыкларын чытырдатып кысты.

— Шәрәфи абзыйны күмгәннәр бүген.

— Күмгәннәр?!.

— Ишетмәгән идеңмени, арыш арасында үтергәннәрен?

— Кем үтергән аны? Кем! Кайчан?! — Бакый кычкыра-кычкыра сикереп торды да, Зәйтүнәнең изүеннән алып җилтерәтергә тотынды.— Кем үтергән?!

Зәйтүнәнең карасу-зәңгәр күзләре куркынып ачылды, Бакыйның капылт ярсуыннан һушы китеп, бер сүз дә әйтергә базмыйча кулларын салындырды. Бакый аны өзгәләп ташларга да, ялварып алдына тезләнергә дә белмичә икеләнеп калган шашынулы кыяфәттә иде. Зәйтүнә изүен кысып алган кулларны ычкындырырга да кыймый ашыга-ашыга сөйләнә башлады:

— Мин каян белим. Күмәргә кеше таба алмый аптыраганнар. Бөтен авыл каргаган ие бит үзен. Аның аркасында күпме каза.

Бакый, йөзен учына чумырып, сәкегә килеп утырды. «Әтидән калгач нишләрмен дип уйлаган идем. Ә бит бәхетле булганмын икән. Кичә генә

әле, бүген иртән генә... очар кош кебек иректә идем бит. Миннән качып йөрмәгән булсаң, җен кызы. Син шуңа этәргәнсеңдер әле, җенле кыз...»
Бакый ишек катында ни эшләргә белми торган Зәйтүнәгә гүя Заримага булган ачуы аша чиркапып карады.

— Син юк идең бит әле, кичә генә... Сөйләшә белми йөргән күләгә идең! — Бакый кычкырып көләргә тотынды.— Нигә дип ашарга ташыйсың миңа?! Бар, чыгып кит моннан, күземә күренмә! Телсез күләгә идең бит...

Зәйтүнә аяк очларына басып ишеккә килде. Бакый терсәкләренә таянып сәкегә капланды.

Шул халәттә бөтен санына оеп күпме яткандыр, иңенә җиңел генә кагылудан уянып китте.

— Син чирлисең бугай, Бакый үскәнем. Ни булды? Синнән өч яшькә олырак бит мин, тыңла сүземне. Кызма. Менә, мәтрүшкә чәе китердем, эчеп җибәр әле.

Аналарча бер җылылык белән сөйләнә-сөйләнә чәчен, аркасын сыпырудан Бакыйның бөтен тәненә талгын рәхәтлек таралды. Зәйтүнәгә бая кычкыруы өчен ул инде үкенә, күтәрелеп карарга кыймый иде. Зәйтүнә, берни булмагандай, аны көйләп, торып утырырга мәҗбүр итте. Буы чыгып бетмәгән калай кружканы кулына ук тоттырды. Аның һәр хәрәкәтендә, җылы тавышында тыңлата алучан бер тылсым, тормышны татыган тәҗрибә бар иде, ахры. Әнисенең Бакыйга һәрвакыт ярарга тырышып, һәр хәрәкәтенә нәтиҗә ясап, вәгазь укып, баласытып каравы ошамый иде. Ә бу — бөтенләй башка, дип уйлады Бакый. Күзгә бәрелми торган кагылыр-кагылмас ягымлылык. Яшь-яшь кызның күндәм кайгыртучанлыгын ана назы белән чагыштыру сәбәбен Бакый соңыннан аңлады...

— Син ашыкма, утырып тор,— диде Бакый. Зәйтүнә әле чыгарга җыенмаган иде югыйсә, бу тыенкы сүзләрдә Бакыйның аңа бөтенесе өчен дә рәхмәт әйтүе сизелә иде.

Дөнья, бәләкәйләнеп, шушы дүрт стена арасына сыйды. Сүрәнәя барган кояш нурлары, кечкенә тәрәзә аша сузылып, ялангач стеналарга төшкән. Шушы ярлы тынычлыкта бер-береңне чит-ят итмичә утырырга да утырырга иде.

— Синең күзләрең кара түгел икән. Чәчең нинди?
— Синеке төсле,— диде Зәйтүнә.

Бакый үрелеп аның ияк астына ук төшереп бәйләгән яулыгын чишә башлады. Зәйтүнә каршы килмәде, үзе үк яулыкны иңенә шудырып төшерде. Яулык астыннан толымы маңгай эргәсеннән уратып алынган, һәр бөртеге пөхтәләп җыелган калын коңгырт чәч килеп чыгуга, аның йөзе, торышы бөтенләй үзгәреп китте.

— Бу чәчләреңне яшереп нигә карчыкларча йөрисең?
— Күз тимәсен дип...
— Матур икәнеңне беләсеңме соң син?

Зәйтүнә, кайсы хатын-кыз үзен чибәргә санамас икән дигән шикелле, үзалдына көлеп куйды.

— Элеккечә бәйләп йөр яулыгыңны, харап итәрләр сине.

Зәйтүнә яулыгын кулына алды да, кисәк кенә кузгалып, йөгерәатлый чыгып китте.

Берничә көннән соң Бакыйны авыл советына чакырттылар. Теге сөйләшүдән соң Зәйтүнә ишекне ача да, ашъяулыкка төргән савытын, чәйле кружкасын тупсага куеп, дәшми-тынмый китеп бара иде. Бүген ишекне ачуга:

— Бакый, сине эзлиләр,— диде.— Авыл советыннан.

Бакый барысына да әзер иде инде. Әтисеннән калган көмеш кесә сәгатен, мин кайтканчы сакларсың дип, Зәйтүнәгә бирде. Аңлатып тор-

мады көндәм кызга: кая китә, кайчан кайта. Аның сораулы карашын аркасында тойган хәлдә бакча ызанынннан өске башка менеп китте. Бәрәңге сабакларында пәрәвез җепләре яшьнәп китә. Алабута яфракларына килеп кунган тәти кашыклар күзгә каен җиләге булып күренәләр. Бакый, офык ягына карамаса да, зәңгәрсу урманны тоеп бара. Ул тарафка юл өзелгән инде аның өчен. Бөтенесенә үч итеп, еракка китеп барырга, зур кеше булып кайтырга уйлаган иде ул. Менә ни килеп чыкты — үзе дә аңламаган, үзе дә көтмәгән хәл. Хәзер инде хөкемгә бара... Атлар утарын узып, ихатага кергәндә, аны Карабай каршылады. Сагынганын белдереп, нечкә еламсырау чыгарган этне Бакый үтешли генә сөйде дә авыл советы урнашкан өйгә таба китте. Һәр тактасы, шомарып ялтыраган һәр кадагы хәтеренә сеңгән таныш баскычны менгәндә аяклары бермә-бер авырайды. Теге көннән бирле бу йортка аның беренче аяк басуы иде. Бәлки соңгысыдыр...

Өстәл артында Шамкаев утыруын күргәч, ул аптырап калды. Авыл советы рәисе белән Шәмсуаровның өязгә киткән җирдән менә өч тәүлек инде хәбәрсез югалулары, төрле имеш-мимеш хәбәрләр килгән. Калын урман юлына аларны эзләргә кешеләр җибәрелүе турында берни дә белми иде әле Бакый.

Яшел сукнолы өстәл артында Шамкаев нидер язып утыра иде. Тимер чыбыклар кискәләп ташлаган кебек эре хәрефләре кәгазьгә ярылып ята. Өй эче шып-шыр. Элекке әйберләрдән шушы өстәл дә, матчага эсылган егермеле лампа һәм кара агачтан каймаланган көзге генә. Таныш, ияләнгән әйберләр булмагач, кайчандыр монда тулы бер гаилә көн иткәнлегенә ышанмалы да түгел. Уртадагы зур мич кенә, барысын да хәтерләгән шикелле, өйнең җаны булып утыра.

— Шуннан,— диде Шамкаев, маңгай астыннан карап.

— Әни китте,— диде Бакый нәрсә әйтергә белмичә.

— Беләм, абыеңны күргән идем. Мин сине авыл советы рәисе урынына калган кеше буларак чакырттым. Авылда калырга булдыңмы?

Бакый җилкәсен сикертеп куйды. Шамкаевның болай күтәрелеп бәрелмичә сүз башлавын ул бары тик абыйсы аркасында гына дип уйлады. Шамкаев, кеше урынына вакытлыча калып торса да, хуҗа икәнен сиздереп, күн итек үкчәсе белән идәнне шакылдата башлады. Солдаттан алып кайткан гадәте.

— Башсыз кеше түгел иде, этиеңне әйтәм. Ашыкмаска кирәк иде, понимаешь... Властьның дөрес юлда икәнен әкренләп аңлар иде. Болай, авылда вак-төяк кулак элементлары белән бәйләнешкә кергәне сизелмәде дә, өяз-шәһәрдәгеләр белән кул тотышмаган булса... Абыең әнә, малаҗис, безнең якта...

Бакый, эчтән тынычлана башласа да, әлегә Шамкаевның төп сүзгә күчмәвен сизенә, һаман энәләр өстендә утыра иде.

— Бәла-каза кемгә килмәс, сыгылып төшмәскә кирәк, менә минем дә йорт-җирем уйламаганда көлгә әйләнде, пнимаешь. Хәзергә келәттә яшим,— дип, ул ишегалды ягына караган тәрәзәгә ымлады. Чак кына «сезнең келәттә» дип әйтеп җибәрмәде. Шамкаевның сары кашлары өскә күтәрелде, кызгылт туттан куныкланган сыман йөзе тартышып куйды. Үтәли күрергә теләгәндәй Бакыйга текәлеп, өстәл тартмасыннан алган камчыны куйды.

— Синекеме?

Бакыйның йөзенә кан йөгерде. Шамкаевның бармагы камчы сабындагы билгегә төртелгән иде. Кытай иероглифына охшаган билге Котлыкаевның нәсел тамгасы икәнлеге һәммә кешегә мәгълүм иде.

— Шәрәфинең үтерелгән гәүдәсе янында табылды. Дөрес, Шәрәфи үзенең аңсызлыгы аркасында күпме бәла-каза китерде. Моңа карап бит самосуд ясарга димәгән! — Сүзенең аеруча мөһим саналган уры-

нында Шамкаевның тавышы куерып, җидедән үргән камчыдай калынаеп чыкты. Ул Бакый каршына килеп басты да, бармагын наган итеп, борын төбенә селкеп төшерде.

— Пнимаешь, самосуд ясарга закон рөхсәт итми, закон!

Әле нәрсәгәдер ышанычы калган Бакыйның тәмам өмете өзелеп, күз аллары караңгыланып китте. Шатлыклары, якты көннәре белән бөтен үткәне кара бөҗралар эчендә калды. Мин үтермәдем, дип калкынырга теләде ул, булдыра алмады. «Син гаепле, син гаепле» дип тукылдады Шамкаевның каты үкчәсе. Бакыйның күз алдында — пожар вакытындагы кешеләрнең ачудан ямьшәйгән йөзләре, сүзләре: «Утка салырга кирәк аны, утка!», «Үз кулларым белән!..» Шуларга ярарга теләгән иде, үзен күрсәтәсе килгән иде бит Бакыйның. Теге вакытта, этисенең хыялый дип мыскыл итүенә үч итеп, бүре атарга чыккандагы гарьлек туган иде аңарда. Тагын булмады. Күңеле сынды.

— Дөрес, теге көнне бөтенесе дә кайнарланган иде. Бәла-каза үтә ул, яралар төзәлә, пнимаешь... Ә кеше үтерүчене — юк! Беркайчан да онытмыйлар аны!

Тынлыкны Шамкаевның итек үкчәсе өзгәли башлады. Ул тәрәзәдән тышны күзәтеп алды да, нигәдер ашыга башлады. Һәр сүзен үткәзергә тырышып әйтте:

— Әгәр... ике теләгемне үтәсәң... мин сине йолып калалам. Төп мәчетнең манарасын кисәргә кирәк безгә. Ул минем монда тора,— дип Шамкаев җилкәсен кагып куйды.

— Берүземме? — Бакый үзен алҗыткан билгесезлектән котылу өчен хәзер нәрсәгә дә риза иде.

— Ярдәмгә кешеләр табылыр,— дип, Шамкаев төлкеле карашын елтыратты.— Икенчесе шул: эшне бетерүгә, син моннан китәргә тиешсең. Мөмкин кадәр ераккарак олагып торырга кирәк сиңа. Соңыннан, теләгең булса, кайтып төпләнерсең.— Шамкаев, баскан урынында кырт барылып, бармагын наган итеп төбәде.— Бүген төнлә мәчет башсыз калырга тиеш. Көндез дә эшләп булыр иде аны. Авыл зур. Усал дигәнен да беләсең, ата улны, ана кызны белми — ни чыгармаслар.

Бакый китәргә дип кузгалгач, тагын туктатты.

— Мә, камчыңны ал. Җуй син аны, эзе калмасын. Ә теге... мылтыкны китереп тапшыр. Әллә кемнәр кулына эләгүе бар. Ау мылтыгы булса да, ярамый мондый чакта.

— Мин аны кырда ташлап калдырдым,— дип Бакый тизрәк бусагадан атлады. Мылтыкны яшергән иде ул.

...Ике яктан да сөзәк таулар белән ышыкланган авыл кичке талгынлыкка чума. Талчыккан кояш тау артына төшеп чумуга; адашып калган кызгылт нурлары мәчет манарасы буйлап өскә таба шуыша башлый. Шул мәлдә авыл өстендә кичке азан башлана. Борынгыдан килгән моңлы җыр шикелле сихерле тавыш әсирлегендә авыл, тынын кысып, бер ноктага төбәлә.

Киртә буеннан, аяк тавышын чыгарырга да куркып, сипкелле малай посып кына мәчеткә таба юнәлә. Манара башыннан яңгыраган моңлы тавыш һаман якыная, отыры көчәя бара. Манара күзгә күренеп биегәя, биегәя, тирә-юньдәге өйләр исә тагын да тәбәнәкләнә, чүгә бара. Мәйданга ук чыгарга малайның батырлыгы җитми, тыкрык буенда туктап кала. Күктән иңгән хикмәтле аваз аның бөтен барлыгын били, акылын ала. Бу аваз үзеңне онытырып каядыр чакыра, бүтән бер илаһи дөньяга димли, аякларны җирдән аера...

Азан тынгач та, малай хәтерен җуеп, онытылып бераз басып тора һәм аннан соң гына, исенә килеп, су буена, болынлыкка йөгерә. Хәзер

инде аның бу урамнарга, бу өйләргә карыйсы килми, әтисен дә, әнисен дә күрәсе килми — шушы тау буеннан сузылган чиксез болыннарга кушыласы килә. Бая яңгыраган моңлы җыр колагыннан китми, берберсенә үрелеп, чигелеп барган ягымлы сүзләрен аңламады да югыйсә, хәтта ул турыда уена да кертмәде, йомшак дулкынга эләгеп, чиксез киңлектә үзенең эреп югала баруын гына тойды.

Малай караңгылана барган тугайларга, сак өянкеләргә, утлап йөргән гамьсез атларга бүтән күз белән карый. Аны рәхәт шом биләп ала. Болар барысы да күзенә генә күренәдер, чынлыкта аларның берсе дә юктыр кебек тоела. Малайның күзләреннән яшь ага башлый. Тирәюньдәге һәммә әйберне аның сыйпап, тотып карыйсы, чынлап та барлыгына ышанасы килә, ләкин кемнендер карашыннан курка...

Шул вакыт ерак та түгел әнисенең тавышы ишетелә.

— Мо-ра-ат, улым, Бакый, кайда син?!

Малай сискәнеп китә, әнисенең тавышы малайны газаплап торган саташулы өннең ләззәтен бетерә. Һәм шуңа күрә дә аның әнисенә ачуы чыга. Шулай да, тәэсирле халәтеннән арынып, әнисенә каршы йөгерә башлый һәм, сөенеп калтыранган гәүдәсе белән әнисенең итәгенә килеп сарыла.

Икенче вакыт, кичке азан вакытында ул тагын урамга чыга, манарадан яңгыраган моң аны тагын үзенә тарта. Малайның салам түбәле фәкыйрь өйләргә карыйсы килми, күктә яшькелт-сары, кызгылт-сары, аксыл-сары төс белән өртелгән мөлдерәп тулган болыт сөрүләре. Әллә нинди җанварлар сурәтенә кергән болытлар офыкка җитеп туарылганнар. Ә теге аваз һаман саен көчлерәк яңгырый, бер ерагая, бер якыная. Малай исә, шомлы ләззәткә чыдый алмыйча, кычкырып елап җибәрә һәм тагын аръяк болынга торып йөгерә. Аның күз алдында моңа кадәр ул күрмәгән дә, ул ишетмәгән дә сурәтләр ярала — иксез-чиксез ком чүлләре, ялангач ташлардан торган таулар, кыя таулар астыннан тезелеп барган дөяләр кәрваны... Малайга рәхәт тә, куркыныч та булып китә. Ләкин аның кемгә дә булса сыенасы килми, куркуны ялгызы җиңәсе килә. Ул өянкеләрне сыйпап карый, суга таш ата, атларны өркетә — барысы да гамәлдәгечә, тере, чын икән бит! Малай күзләрен йома да чынбарлык һәм үзе генә белгән дөнья арасында изрәп онытыла...

Шулай азан әйтү сәгатен көтеп ала торган булды ул.

Әтисе аны ерак Себердә яшәүче туганнарында калдырып кайткан иде (аннан алда туган ике баласы үлгәч, әллә яңа урын килешмәде инде, бераз читтә торгызып карыйк микән әллә монысын, дип илткәннәр иде аны). Үз-үзен ныклап белә башлаган малай быелгы җәйдә генә авылга кайткан иде. Өсте-өстенә ямау салудан тез башлары кәкрәеп каткан ыштанлы такыр башлы авыл малайлары белән тиз үзләшеп китте ул. Ләкин кичке азан вакытындагы уйларын беркем белән дә бүлешергә кыймады.

Көннән-көн кыюлана барды ул һәм бер көнне... Мәчеткә якын ук килде. Шәфәкъ нурлары яктысында манарадагы ак чалмалы затка текәлеп калды. Ак чалмалы бер урыннан икенче урынга күчкәндә, тавышы әле көчәеп, әле түбәнәеп ала иде. Малай аны азан әйтер өчен генә, вакытлыча гына күк тәхетеннән төшкән сәмави дип уйлый һәм түземсезлек белән азан беткәнен көтә иде. Ак канатларын җәеп күккә ашканын күрергә тели иде ул аның. Менә азан вакыты бетте. Мәчет янына җыелганнар да кузгалыша башлады, әмма күккә ашучы һаман күренмәде. Бераздан ишектән ак чалмалы, симез йөзле кеше чыкты. Якын тирәдәге агайлар аның белән кулларын күкрәкләренә кушырып исәнләштеләр. Бакый әлеге кешене күреп белә иде. Ак чалмалы мәэзин, сынын горур тотып, югары очка китеп баруга, авыл агайларыннан берсе:

— Шәп тә соң тавышы, йөрәкләргә үтә,— диде.

Малай шунда гына азан әйтүченең шул кеше булуына төшенде. Нишләргә икәнен дә тәгаен уйламастан, әлеге чалмалы мәэзин артыннан йөгерде. Тыны-көне бетеп чабып килгән уңайга мәэзиннең чапан итәгеннән эләктереп алды.

— Синме... азан әйтүче, синме?

Мәэзин кинәт кенә болай тәкәллефсез килеп тотынган малайга ачуы чыгып борылган иде, Айтуган бай малае икәнен чамалап, кызуы сүрелде, гаҗәпләнүен тыялмыйча:

— Мин, улым, нигә алай сорыйсың? — диде.

— Әлек тә син әйтә идеңме?!

— Әйе, улым.— Мәэзин чапан итәгеннән малайның чытырдап ябышкан кулларын ычкындырырга үрелде. Малайның күз аллары караңгыланып китте.

Майдан ялтыраган борынлы мәэзиннең билендәге путасы керләнгән икәнен искәреп алды ул. Шуның азан әйтүче икәнен беләү малайны шулкадәр рәнҗәтте ки, теге саташулы рәхәтлектә йөргән көннәренең тәэсире берьюлы коелып төште. Тупас алдану мәкерен бары тик шушы кешедән күреп, ул ачыргаланып кычкыра-кычкыра, калтыранган йодрыкларын йомарлап, аңа уңлы-суллы бәргәли башлады.

— Син генә гаепле! Син генә! Ялганчы!

Шул бит инде, аның иптәшләрен, койма ярыгыннан бакчасына үрелгәндә тотып, кычыткannан чактыра-чактыра мәсхәрәләгән иде. Шул бит инде, үз ишегалдында яшь хатынын, чәченнән өстери-өстери кыйнаган иде. Ул аны койма ярыгыннан күреп торды.

— Менә сиңа! Әшәке кеше! Син генә гаепле!

Бу хәлгә шаккатып калган мәэзин, ниһаять, аңга килде.

— Нишлисең, үскәнем?! — малайны кочаклап алды да, тынычландырырга керешә.— Тьфу, тьфу, әстәгыфирулла... зәхмәт кагылгандыр сиңа, улым, чирлисең түгелме,— дип сөйләнә-сөйләнә, салкын учын малайның маңгаена куйды.

Бакый шуннан соң атна буе авырып ятты һәм... мәчет манарасын күрәлмас булды. Яныннан үткән саен хәнҗәр кебек очлы манара аның җәрәхәтле күңелен чәнчеп ала иде.

Менә Бакый шыгырдап торган баскычлардан манарага менеп бара. Ул инде бүтән Бакый, теге чакта авырып йөргән малай каядыр еракта адашып калган, эзсез югалган. Шул авырудан соң бит инде әтисе аны «хыялый» дип кимсетә башлады. Әнисе малаена әйләнде Бакый. «Синең малай» — әтисе сүзе, кул селтәде ул аңа, үзенең дәвамы, алмашчысы итеп карый алмады. Ул малай күптән юк инде, хәер... еракта калган малай вакыт-вакыт уянгалый, тавыш бирә: Бакыйга нидер искәртеп кагыла, күңеленә күз яше салып киткәли, кысылган йодрыкларын ачтыра. Бакыйның шул зәгыйфь, хыялый малайга каршы торырга көче җитми, җиңә алмый, юк итә алмый ул аны үзендә. Менә хәзер дә еракта калган малай аңа дәшә, манарага менмәскә, кире борылырга куша. Ләкин Бакыйның үҗәтлеге нык, ул аңа бирешмәс бүген. Ул — үз үзенә хуҗа.

Бакый өскә үк менеп җитте. Ышык урынга күгәрченнәр кунаклаган икән. Бакый кул фонарен өскәрәк күтәрде. Ут яктысыннан сукырайган күгәрченнәр тагын тындылар. Бакый аларны урыннарыннан кузгата башлады. Фонарен артына яшерде дә, күгәрченнәрне берәм-берәм тышка очырды. Өстенә әче тузан коелды. Эчпошыргыч көйгә җил жуылдый, манараны тирбәтә иде. Аска караган Бакыйның башы әйләнеп китте. Өстә күгәргән болытлар агыла, салкынча иде монда. Манараны кисәр алдыннан өскә үк бер менеп төшәргә уйлады ул. Әнә, күрше

авыл агайлары аркан сузып яталар.

Шушы мәчеткә йөргән картлар бит инде: «Мөселманга ят үлем — үзенә кул салу, мордар китте», дип Айтуган байның мәетен зиратка куйдырмаска тырышканнар иде. Менә хәзер алардан Бакый үч ала. Тизрәк аударырга да котылырга, дип уйлады ул. Шамкаев сүзендә торыр микән, алдамасмы? Манараны кисеп төшерүгә, кулын бәйләтеп үязгә озаттырмасмы?.. Артында баскыч шыгырдаганга ул шикләнеп борылды:

— Кем ул анда?!

— Нәрсә терәлеп каттың, тизрәк тотынырга кирәк.

Бакый фонарен өскәрәк күтәрде. Шамкаевның артында аркан тоткан тагын берәү бар иде.

— Сиңа ярдәмгә,— диде Шамкаев, җирән мыеклыга ымлап.

— Кисүен кисәбез, әгәр алдасаң!..

Сулышлар йөзгә бәрелде күзләр елтыраштьі.

— Ике сөйләшү юк, пнимаешь,— диде Шамкаев.

Киселгән манара җиргә гөрселдәп килеп төшүгә, кемдер аһ орып куйды. Бакый җиргә сыгылып төшкән шәүлә янына йөгерде. Манара очындагы ай төбеннән кубып, читкә очканда аркан тартып торучы озын буйлы җирән мыеклы әдәмгә тигән, кулбаш итен умырып алган икән. Ул арада этләр өрә башлады, каршы йортның ишеге шыгырдап ачылды. Аркан-пычкы ише кирәк-яракларны җыеп алуга, Шамкаев, ашыктырып, аларны тар тыкрыкка таба алып китте. Җирән мыеклы ыңгырашып куя, кулбашын кысып тоткан бармаклары арасыннан карасу кан агып чыккан иде. Як-ягы эре кычытканнар белән капланган тар тыкрыкка кергәч, азга гына тукталдылар. Болыт арасыннан бәреп чыккан ай яктысында җирән мыеклының ярасы, уылдыклары күренеп торган балык корсагы кебек, чиркангыч иде. Ярага туфрак сибәргә чамалавын күреп, Бакый аны туктатты, ике дә уйламыйча күлмәген салып ерта башлагач, Бакыйга гаҗәпләнделәр.

— Нишлисең, җүләр!

— Әрәм итмә.

— Тагын бер күлмәгем бар, нәрсә сез! — дип Бакый, умырып чыгарган күлмәк кисәге белән җирән мыеклының ярасын бәйләргә кереште. Барыбер, аның ай-ваена карамыйча, ярага туфрак сиптеләр.

Су буена, тегеләрнең атлары яшеренгән төшкә җиткәч, киндер капчыктан дүрт кырлы шешә, ипи, кыштырдап торган кабыклы суган чыкты. Калай кружканы киселгән өянке төбенә куйдылар. Тегеләр, менә төп эшкә җиттек дигән шикелле, тел шартлатып, үтә бер дәрт белән тотындылар. Җирән мыеклы да ярасын онытты бугай, йөзе яктырып китте. Бакыйга да өлеш чыгардылар. Аның әле тәмсез ис килеп торган аракыны беренче тапкыр авызына китерүе иде. Шушы таза ирләрнең, сулышларын тышка бәреп, үзенә бер ләззәт белән шома гына эчеп куюларын күзәтте дә, ачысын-төчесен татытачак тормыш дигәненә бу да ят, харам түгелдер дигән уй белән кружкадан бераз йотып куйды. Күзеннән яшь чыкты, тамагына утлы күмер килеп тыгылды. Шуннан соң гына әкрен-әкрен бөтен тәненә оеткыч рәхәтлек тарала башлады. Хәзер инде ирләрнең дәртле тавышка кызып-кызып сөйләшүләре дә, Шамкаевның аларга тынычрак булырга кушуы да — бөтенесе мәгънәсен җуйган иде. Өянкеләр арасындагы караңгы сукмакка кереп киткән вакытта ул артыннан Шамкаевның тавышын ишетте: «Бүгеннән калма!»

Бакый үзалдына мыгырдана-мыгырдана кайтты. Башы әйләнә, аңы талгын бушлыкта йөзә, бөтен борчулары, уй-газаплары еракка китеп чигенгән. «Барысы да синең аркада, җен кызы. Синең белән саубуллашмыйча да китәм мин. Сагынырсың әле, шундый юксынырсың... Мин дә онытa алмам шул сине, Зарима, әмма беркайчан да эзләп килмәм. Куркам мин синнән, җен кызы, куркам... Шулай да бер генә тапкыр урманга барасы иде. Ут яктысына җыелган күбәләкләр белән сөйләшеп утырасың микән? Теге күлдәге утрауга тагын бер генә чыгасы иде, икәүләп, җитәкләшеп. Тагын бер... Ул төн чынлап та булган идеме соң әле? Төшкә генә кереп калмадымы?..»

Бәләкәй капканы ачып кереп, мунча сукмагына төшүгә ул, баскычта утырган күләгәне искәреп, туктап калды. Ниндидер өметтән буыннары хәлсезләнде. Әкрен генә якынайды. Менә шәүлә кыймылдап куйды, башын беләкләренә салып йокыга киткән бу кыз Зәйтүнә иде, аяк тавышына дерт итеп уянды, каршысында куллары пычранып беткән, ялангач тәне черкиләрдән тешләнгән Бакыйны күреп сикереп торды.

— Нишләдең син?

— Төш бит ул, төш, ә син ышанган буласың,— дип Бакый шаркылдап көлә башлады.

— Нишләдең син, Бакый, әйдә, юындырам үзеңне, кайнар чәй эчерәм.

Зәйтүнә аның кулларыннан тотып үзләре ягына өстери башлады. «Нишләдең син, нишләдең?» — бу сорау Бакыйның җанын өшетә, шушы кулларны ычкындырмаска өнди, үзенә буйсындыра иде.

Утыртма казыктан эшләнгән өй эче болай катлаулыдыр дип башына китермәгән иде Бакый. Әллә нинди караңгы аралыклар аша бәрелә-сугыла керделәр. Ут алганда Бакый инде бәләкәй генә бүлмәнең агач сәкесендә утыра иде. Зәйтүнә тас, комган китереп мәш килә башлады. Тыз-быз йөргән арада, хәзер була, хәзер, дип авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә, Бакыйга кул очы белән кагылып китkәләде. Барысын да эшләр, тик ул гына урыныннан кузгалмасын, тик ул гына чыгып китә күрмәсен.

Бакый юынып алганнан соң чәйгә үрелде. Зәйтүнә ярлы гына табынны да бай итеп күрсәтә белә, бөтен хәрәкәтендә мут ягымлылык бар иде аның. Чәйдән соң Зәйтүнә икенче бүлмәнең ишеген ачты...

Беленер-беленмәс таң эңгере бүлмәгә сузылган чакта Бакый уянып китте. «Миңа китәргә кирәк» дигән уен онытып, кузгалырга да кыймыйча ята бирде. Тәненә җиңел генә кагылган йомшак юрганны, мендәр тиеп торган стенадагы келәмне, чынлыгына ышанырга теләгәндәй, тотып-тотып карады. Кайда соң әле ул? Ничек эләккән монда? Бакый әкрен генә юрганны ачты, затлы хушбуй исе аңкытып, таралган чәчләр арасында күмелеп яткан кызны кочагына алды. Калку күкрәкләр өстеннән шуып төшкән юрган астындагы кайнар дулкын аны дөньядан аерды.

Соңыннан, чыбылдыкны ачып җибәргәч, бәләкәй тәрәзәдән саркып кына кергән таң эңгерендә шушылай кадерле булып әверелгән җанның еш-еш сулу алып, куркытылган хәлсез җәнлек сыман мендәргә сеңеп ятуы Бакыйны тәмам чарасыз итте. Китәргә дигән ятим нияте мәгънәсен җуйгандай булды. Ә таң исә котылгысыз рәвештә һаман беленә бара, почмаклар яктыра, төн караңгылыгына чумып онытылган әйберләр, кешене мәшәкатьле көнгә кайтарырга, уятырга теләгән кебек, отыры ачыграк шәйләнә баралар.

Каласы килә, әмма калырга ярамый, китәргә кирәк, әмма китәсе килми — шушы икеләнү арасында калган Бакый, ниһаять, сабый сулышы шикелле генә сирпелеп торган хушбуй исен, шушы рәхәт ты-

нычлыкны, чәчләр арасыннан төбәлгән сорау катыш куркынулы карашны җинеп:

— Миңа китәргә кирәк,— дип урынынан калкынды.

— Бакый...— Зәйтүнә аны кочаклап, кысып алды, аның битен, күкрәген сыйпый башлады.— Мине дә үзеңнән калдырма, Бакый. Монда тынгы булмаячак миңа, калдырма, Бакый!

Зәйтүнә, анык карарга килә алмый торган Бакыйны калдырып, караваттан сикереп төште дә, сандыгын ачып җибәрде.

— Сиңа йөк булмам, Бакый. Курыкма. Менә, менә,— Зәйтүнә идән паласына ялтыравык кашлы алкалар, әллә нинди кыйммәтле чүпрәкләр таратып ташлады.— Кеше алдында ким-хур булмассың, киярgә күлмәкләрем дә бар, менә, менә! — ул, ашыгып, каушый-сөйләнә, әле бер, әле икенче күлмәкне җәеп гәүдәсенә үлчәп караган дай итә дә, идәнгә ташлый иде. Аның шундый чаялыгына, кыю матурлыгы белән капылт ачылып китүенә гаҗәпсенеп калган Бакый кычкырып җибәрде. Мондый затлы әйберләр бу өйгә каян килеп кергән соң әле? Зәйтүнә кулындагы зәңгәр парчалы күлмәкне кайдадыр күргән иде бит ул! Кайчан соң әле? Кайда?.. Нәкъ шушы күлмәк иде бит! Әтисе Мәскәү базарыннан кайткач... әйберләрен актарып маташканда Бакый килеп кермәсенме... Шушы зәңгәр парчалы күлмәк, хушбуй шешәләре...

Әле генә бөтен барлыгы белән иркәли һәм иркәләнә белгән кызның тән кайнарлыгын да җуймаган хәлдә, ярым ялангач гәүдәсенә соклану иләслегән чак җиңеп, салкын бер үкенечле нәфрәт белән ул кызның иңеннән кысып тотты.

— Каян алдың боларны?!

Зәйтүнә ни үле, ни тере хәлдә башын артка ташлап торды да, кулыннан ычкынып, идәнгә сыгылып төште, Бакыйның аякларын кочып үкси башлады.

— Сорама, Бакый... Кем бүләкләре икәнен беләсең бит инде. Әни мәҗбүр итте мине... кешечә яшәрбез ичмасам, диде... Әни аркасында... Ундүрт яшемнән бирле... Айтуган бай: «Чирле ул, озак яшәми» диде әнием турында, өйләнәм диде. Кешегә белгертсәң, үтерәм дип янады... Мин яшь идем әле ул чакта, берни дә аңламый идем... Тимә, Бакый, тимә... Ал мине үзең белән, киемеңне юып торырмын, ашарыңа әзерләрмен, мин барысын да эшли беләм. Шәһәрдә дә булганым бар... Бакый, калдырма мине... Бакый... үз тиңеңне тапкач, китәрсең...

Бу хакыйкатьны белүгә караганда белмәве җиңелрәк булган икән. Димәк, Бакыйның әнисе бу турыда белгән, сизенгән... Аягын кочып, үкси-үкси елаган кызның ялынычлы һәммә сүзе ни кылырга, ни әйтергә җөрьәт итәлмәгән Бакыйны чәнчеп-чәнчеп ала иде. Кинәт ул үзендә бушанып калган сабырлык, хәлсезлек, кан тамырларына сыеша алмаган бер олыгаю сизде. Яшерен рух сеңгән, мәкерле ис саклаган бу стеналар аны кыса башлады. Үткәннәрен аралап күзенә пәрдә төште.

Бакый һавага чыккач та үзенә урын таба алмыйча әле анда, әле монда сугылды. Тирә-юньдәге бөтен нәрсә тереклек асылын җуйган үле бер халәттә иде. Бакый соңгы күлмәген алып киде, пинжәген иңенә салды, кесәсен авырайтып торган сәгатен капшап карады да, су буена төшеп битен юып менде. Күк читендәге яшькелт яктылык ачылып килә. Каядыр иртә уянган таң әтәче сузып кычкырды. Өянкеләр арасында кошлар чыркылдашып алды. Бакый тагын әйләнеп килде. Үзе ашыга, көн туганчы кузгалырга ашыга, үзе һаман тоткарлана, нидер эзләгән шикелле арлы-бирле йөренә иде. Менә ул кычытканлы киртә буена кабаттан килде. Салам түбәле сипсегән

йорт, әфсен укырга җыенгандай, каш астыннан карап торган төмсә йөзле карчык шикелле тын гына күзәтә иде аны. Шылт иткән тавыш та ишетелми, бер хәрәкәт тә сизелми — авыр тынлык. Бакый, капылт бер карарга килеп, киртә аша сикерде дә ишеккә төртелде. Ишек эчтән бикләнгән иде.

— Зәйтүнә...

Һичбер җавап ишетелмәгәч, шомланып, ул ишекне кагарга тотынды. Хәзер ачтырмасам, менә хәзер өлгерә алмасам, гомер үкенечкә каласы бер-бер хәл булыр да..., дигән шөбһәле уйдан ыргып ишекне иңе белән бәреп ачты да, эчкә ташланды. Идәндә тезләнеп утырган Зәйтүнә ишек тавышына күтәрелеп бакмады, инде ул тынычланган күренә, гәүдәсен калтыратып, вакыт-вакыт сулкылдап кына куя иде.

— Җыен әйдә, китәбез!

Зәйтүнә маңгаена төшкән чәчләрен аралап, моң һәм сагыштан томаланган күзләрен күтәрде. Күпереп чыккан иреннәреннән хәлсез пышылдау чыкты:

— Булмый инде, Бакый... Үзең генә...

— Бүген китә алмасак, бүтән беркайчан да... Зәйтүнә, тиз бул.

Бакый аны газаплы хәтереннән айнытырга теләгәндәй, иңеннән тотып селкетә башлады. Әмма Зәйтүнә бая гына кабынып алган өметеннән ваз кичкән иде, битараф, җансыз иде. Аны яңадан терелтергә, җан өерергә теләүдән Бакыйның өзәләнүе тышка бәреп чыкты:

— Мин кеше үтердем, Зәйтүнә, аңлыйсыңмы, кеше... Син коткар мине, тагын мең явызлыклар эшләүдән коткар!

Зәйтүнә, тәненә бозлы су тигәндәй калтырап куйды, үз кайгысыннан айный барып, Бакыйга якын килде.

— Ни сөйлисең, Бакый?! Шушы кулларың беләнме? Ышанмыйм. Күзләрең мондый булмас иде. Ышанмыйм. Әйтмә, бүтән алай әйтмә! — Зәйтүнә кулы белән аның авызын каплады.— Әйтмә...

Яшерен төннәр хакына үзен корбан итеп, чибәрлеген кешеләр күзеннән каплап йөргән бу бәхетсез җанны ялгызын гына калдыра алмасына, үзенә шундый ышаныч белән караган бу җанны гомере буена ташлый алмаячагына әле генә төшенгән Бакый, бердәнбер коткаручысы итеп аңа сыенды.

Чыклы үлән өстендә эзләр калдырып, алар тауга күтәрелделәр. Ямьсез төштән әле дә котыла алмагандай башын иеп барган Зәйтүнә артына бер дә борылып карамады. Бакый гына йокыга талган авыл манзарасын күзеннән кичерде. Бер җепкә тезелгәндәй төрле яктан килеп үзәк мәйданга кушылган авыл урамнарын тоташтырып күтәрелгән Олы мәчет манарасы булмагач, нидер җитми, авыл таралыбрак киткән кебек иде. Соңгы йорт та күмелеп тау астында калгач, ул офык читендәге зәңгәр урманга текәлде. Соңгы тапкыр... Аның беркемгә сөйли алмаячак серен, азагы нәфрәт белән беткән иң матур чакларын урман хәтерләр микән? Еллар аша ул Моратбакый булып кире әйләнеп кайтканда урман юллары инде үзгәргән булыр. Иләмән картның каберен дә белмәсләр, картайган көнендә, актык көчен җыеп ул урман арасына кереп югалган булыр... Ә Зарима?.. Каеннар ышыгындагы өйне Моратбакый түбәсе җимерелеп, иңеп калган хәлдә күрер. Шул чакның ядкаре булган бердәнбер исән әйберне табып кулына алыр — тоткасы төшкән сукыр лампа булыр ул...

Теге, онытылмас төнгә шаһит булган күл урынында баткаклык җәйрәп ятыр. Йөзмә утрауны да әрсез куаклар каплаган тирәлектән

табып булмас, тамыр җибәреп ул җиргә кушылган булыр. Шул урында яшьлек җуләрлеген искә төшереп, ул төн чынлап та булган идеме, дип кычкырып урманнан сорыйсы килер, әмма ул теләге аның үйда гына калыр, үйда гына... Әгәр сораса, ул чакны яфракларын койган хәтерсез урман ни дип җавап бирер иде икән? Хәтерсез урман...

## VIII

— Әби, бабайны алып кайттык!

Игезәкләр шулай шау-гөр килеп ишекне ачканда, өстәлдә инде самавыр гөжләп утыра, табын әзер иде. Моратбакый оныкларыннан арткарак калып, өялдындагы утны яндырды, итегенә ярмаланып ябышкан карны чырагач белән кырып төшерде дә, ишекне каерып ачты. Карчыгы мичтән өстенә коштабак япкан коймаклы табаны алып маташа иде, үрелеп карады да:

— Нигә бик сөмсерең коелган, картым,— диде.

Моратбакый җавап урынына ютәлләгән булды, өстен чишенүгә түрге өйгә үтте. Коймакка үреләә башлаган игезәкләрне әбиләре ягымлы шелтәләп:

— Әнә, юынгычта җылы су, әшне шуннан башлагыз,— дип туктатты. Кич буе кызу мич каршында булашуданмы, Зәйтүнә әбинең бит очлары яшәреп киткән иде. Коймакның йөзе килгәнлегенә, уңганлыгына куануын ничек чыгарырга белми, өстәл янында туктаусыз йөренә, шкафтан әле бер бизәкле, әле икенче бизәкле чынаякны өстәлгә китереп куя, тагын алыштыра.

— Азат, Айдар,— дип инде утырыша башлаган игезәкләрне дә кыдырып алган булды.— Кая соң үзе?

— Бабай, коймак бетеп килә! — дип кычкырышты игезәкләр.

— Хәзер, карчык, хәзер.

Урта ишекне ачып чыга башлаган картына ул сынаулы караш ташлады. «Карчык» дигәнне әллә ничек кенә, җылынып киткән тавыш белән, ярым кадерләп әйтүеннән үк сизенеп өлгерде — димәк, шкафтагы шешә урыныннан кузгатылган.

— И-ии, тавышлары үзгәреп китә инде шуның — «Теленә ачы су тисә» дигәнен эчендә калдырды Зәйтүнә әби.

— Шаулама, карчык, баланы уятасың.— Моратбакыйның аңа гына әйтелә торган яраткан сүзе иде бу.

— Әйдә, җитешегез, клубка чыгасыгыз бардыр,— дип иң беренче нәүбәттә оныкларын кыстарга тотынды Зәйтүнә әби.

Чәй нуры төшкән түгәрәк табын стенадагы күкеле сәгать текелдәве астында гомер дигәннең кадерле минутларын берләштереп куйды.

— Азат, Айдар, коймагы белән эч, ашыкма шулкадәр.— Зәйтүнә әби игезәкләрне һич тә аера алмый, берсенә эндәшкәндә икесенең дә исемен кушып әйтә, киемнәрегезне, ичмасам, төрледән кияр идегез, дия иде. Андый чакта Моратбакый көлә генә, кайтып керүләренә үк, карчык, син берәрсенең җиңенә кызыл чүпрәк тегеп куй, дип мыскыл итә. Азатына тактым микән, Айдарына тактыммы дип, тагын бутап бетерермен, карт, дип көлә Зәйтүнә әби.

— Бигрәккенәләр дә охшаганнар шул инде, гомерләре озын булгыры! — Зәйтүнә әби, хисен тыя алмыйча калкынып, оныкларын сөеп алды. Кайткан саен ул аларның сиздермичә генә берәр чәч бөртеген кисеп ала, күз тиюдән харап курка иде.

— Унны бетергәч кая барырга соң исәбегез, балалар?
— Авылга эшкә кайтырлар,— Моратбакый карчыгына күз кысып ала.
Игезәкләр бер-берсенә мәгънәле елмаешалар.
— Хәрби училищега,— ди Азат.
— Летчик булабыз,— ди Айдар.
— Бигрәкләр дә куркыныч һөнәр сайлагансыз, балалар.
— Тавык йомыркасы кадәр генә җиргә өстән карап очулары үзе ни тора, әби.— Азат савытыннан пешкән йомырка алып бер урында әйләндерә башлады.
— Җир бәләкәйләнә барган саен, кеше урынны күктән эзли башлаячак, әби,— диде Айдар.
— Җир бәләкәйләнергә, ул бит сүрүе тузган мендәр түгел.
— Һи, әби, шуны да аңламыйсың. Кеше саны арткан саен җирдә урын кысанрак булачак. Әйтик, ике меңенче елны, Айдар, ничә миллиардка җитә әле?
— Алты.
— Дүрт диген.
— Юк, алты.
— Ярар, синеңчә булсын,— дип килеште Айдар.— Менә, әби, бабай, киләчәктә сезне ерак бер планетага күчереп куярбыз да...
— Әйтик, Марска,— дип кушылды Азат,— коймак онының оныта күрмә, әби.
— Әй, улларым, җирдә рәтле яшәсәң дә... Марска очканчы әнә абзар капкасын рәтләп бирсәгез ие. Соңгы елда бабагыз, миңа бер-ни дә кирәкми дип, түшәмгә карап ята бирә.
— Түшәмгә бик күп нәрсә язылган бит ул, карчык.
Игезәкләр өстәл артыннан кубып, калдык чәйләрен аяк өсте генә чөмерделәр дә, рәхмәт әйтеп, ашыга-ашыга киенә башладылар.
— Клубны күтәреп китмәсләр, ул кадәр каударланмасагыз да,— диде Моратбакый.
— Самалютта да гел шулай бергә очарсыз микән? — диде Зәйтүнә әби.
— Бергә очабыз. Бер фатирда яшибез.
— Еллар имин булсын инде...— Зәйтүнә әбинең тавышы кисәк өзелде, калагы идәнгә төшеп чылтырады. Игезәкләр әбисенең беркатлылыгыннан көлешә-көлешә киенделәр һәм ишекне ыргытып кына ябып, чыгып та киттеләр. Ишек алдындагы аяк тавышларына колак салыпмы, мич аралыгындагы сарык бәтие мекердәп куйды. Сәгатькә дә җан керде — күкесе оясыннан сигез мәртәбә башын чыгарып карады.
Аннан соң өйгә сыгылып кына тынлык иңде. Эчендәге уйларыңны бер-береңә ирештерә торган тынлык... Шул тынлыкка кот кундырырга теләгәндәй, каядыр бик якындамы, бик ерактамы, колакны ягымлы иркәләп, өй чикерткәсе сайрый иде. Моратбакый карчыгына якынрак килеп, кулын аның ябык биленә салды.
— Их, шул малайлар урынында бер көн генә булып карыйсы иде, карчык, ә! Картаябыз...
— Бүген генә искәрдеңме әллә.
«Беләм бит, гел миңа ярарга тырышып, бик әйтәсе килгән чакларында да эчендәгене ярып әйтәлмичә, үзеңне гаепле санап яшәгәнгә шулай картайдың син, Зәйтүнә. Хатын-кызга эчкә җыю килешми шул»,— дип уйлады Моратбакый.
Аның уйларын сизгәндәй, Зәйтүнә карчык:
— Какмадың, сукмадың, тыныч яшәдек болай... Шунысына шөкер,— диде.

Моратбакый аның белән уйнап кына яшәгәндәй яшәде. Алда һаманниндидер өмет җылытып тора иде аны. Бу тормышы әле аның чын тормыш түгел, көтмәгән бер көнне барысы да үзгәрер дә, ул бөтенләй икенче төрле яши башлар шикелле тоела иде аңа. Ерактан, билгесез тарафтан, барлыгын да сиздермәгән яшерен өметкә алданып ул тормыш көтә-көтә, инде шактый еллар үткәнен дә, инде тәмам картая барганын да сизмичә калды. Ул өметкә инде үзе түгел, ә олыгаймый сакланган хыялы гына омтылганын онытып җибәргәненә Моратбакый быелтыр төшенде. Былтыр...

Авылга белемче карчык килгән дигән хәбәр таралган иде. Чиренне белә икән, бөтен уеңны белән икән кебегрәк имеш-мимешләргә ышанып бетмәстән, Моратбакый нигәдер аның белән кызыксына башлады. Исемен сорап белешкәнче үк, багучы дигәннең кем икәнен төшенеп өлгергән иде инде ул.

Моратбакый тыкрык кырыендагы ялгыз карчык өенә туктаган белемченең кем икәнен тәгаен белеп килсә дә, баскыч төбенә җиткәч, ишекне ачарга кыймыйча байтак басып торды. Кайчандыр аны урманда адаштырып калдырган кыз әле һаман да исәндер, нәкъ шул кыяфәтледер дигән ялган ышаныч яшәтте бит аны. Төш икәнен белеп тә, уянасы килмичә, дәвамын күрергә теләгән кеше халәтендә иде ул. Ниһаять, ишекне ачты. Мендәр өстендә утырган, эре бөртекле чәчләренә чал кергән карчыкны күрүгә үк таныды. Таныды. Зарима дип эндәшсә рәнҗетер шикелле тоелды. Юк, аны түгел, үзенең хатерен рәнҗетер шикелле тоелды. Шундый үзгәрешне кабул итә алмаганга аны да, үзен дә кызганып куйды.

— Никадәр әйләнгеч юллар белән килдең син, Моратбакый.

— Язмыштан узмыш юк инде. Син кайтып төшәрсең дип кем уйлаган.

— Мәнә күңел суы кипкән гәүдәмне туган туфракка алып кайттым әле.

— Гел картаймас кебек идең.

— Сырхаулап килгәннәрнең авыруын үземә алып, менә шулай бетерендем инде.

— Ничек яшәдең соң, Зарима, балаларың бармы? Ташкентта яшәп ятканыңны ишетеп белә идем.

— Аягыңны нишләттең, Моратбакый?

Моратбакый башта аптырап калды. Аннары, Зариманың күз карашыннан аңлап, сул аягындагы яра җөенә чалбар аша кулын салды.

— Ә-әә! Бөтенләй онытылган. Сугышта пуля тигән иде.

— Шулайдыр шул...

Моратбакыйның зиһене таралды, тотынып нәрсә эзләп, урындыгын этәреп өстәл кырыенарак чүмәште.

— Һаман шул... сәерлегең бетмәгән икән.

Зариманың кара тут йөзендә әчке бер елмаю чагыла иде. Ул үзе генә белгән мәгънәне төшендерергә теләмәгәндәй, тын гына оеп утыра бирде.

Икесе дә алар картаюны күз алдына да китермәгән шат, ваемсыз яшьлекләренең гүя уртак кабере өстендә утыралар, сүзләргә урын юк, бары тик эчкәре яшерелгән кисәтү, дәшә күрмә, ул турыда күз гатмыйк, тынычлыгын бозмыйк үткәннең, дигән теләк һәм бер-беренә рәхмәтле хис кенә калган иде.

Ул арада хуҗабикә өйалдыннан самавырын алып кереп, өстәлгә утыртты, ашъяулык астыннан нигъмәтләрен чыгарып тезде дә, әчә торыгыз дигән ым кагып, чыгып та китте. Зарима мендәре белән бергә өстәл янынарак шуышты. Үрелеп, ике касәгә чәй агыза башлады. Моратбакый да, җиңел сулап, гел киеренке утырудан талган буыннарын язып җибәрде.

— Сине белемче диләр бит, күпме гомер калган икән соң, миңа да күрәзәлек кыл инде,— дигән булды Моратбакый.— Фин сугышы вакытында — ул якта атлаган саен күлләр бит — бер чегән кызы учыма карап әйткән иде: әҗәлең судан дип, тәки коткы салды бит шул, гел судан курка торган булдым шуннан соң, җүләр түгел диген.

Зарима үрелеп аның кулына, иңнәренә кагылып алды һәм көлеп:
— Яшисең әле, Моратбакый, вакытың бар синең,— диде.

— Теге вакытта... Пожар көнне...— Моратбакый төртелеп калды, ачык кына әйтеп бирергә кодрәте җитмәде.— Абыең өчен гомерлек рәнҗү саклагансыңдыр инде... Синең катыңа килдем менә, кара йөземне ак итеп...

— Үткәнгә кагылмыйк, Моратбакый. Ул чагында кем ялгышмаган... Мине кичер син. Кызулык белән... Мин дә ялгышканмын бит...

Моратбакый авыр кашларын күтәрде, нидер сорарга, ачыкларга иде исәбе, әмма дәшми калды. Зариманың тәрәзәдән урман ягына текәлгән карашында әллә нинди тын агышлы моң, ләззәтле онытылу сизелә иде. Аны бу халәтеннән уяту, сискәндерү утә бер гаделсезлек булыр иде. Зарима шулай бер тын утырганнан соң капылт исенә килде, тәүге тапкыр күргәндәй, ят караш белән Моратбакыйга карады, өй эченә күз йөгертеп чыкты һәм нәрсәдәндер нәүмиз калган бер сүлпәнлек белән, тирән сулап:

— Урманнарны, кырларны әйләнеп кайттым әле машинада,— диде Зарима.— Ничә еллар күрмәгән җирләр... Үзгәргән, танымаслык булып үзгәргән. Әллә ул җирләр бөтенләй мин белгәнчә булмаган, әллә мин булмаганмын, аңламассың.

Моратбакыйның күңеле тулды. Уйлап баксаң, барысы да кичә генә кебек, кул сузымы гына ара, ә берсен дә кире кайтарып булмый. Тулышкан хәтер — баеп барган кояш кебек. Көн инде кабатланмый, соңгы ноктасында...

Зарима мендәр өстендә кымшанып алды, ирен сызыгыннан елмаю күләгәсе чагылып үтте.

— Карчыгың янына кайт, Моратбакый, йөрәгемне чәнчи, ерактан ук сизеп торам.

— Тәки аңлап булмады сине, ни яшьлегеңдә, ни картлыгыңда... Һаман шулай.— Моратбакый кесәсенә тыгылып тәмәке чыгарды, бармаклары арасында угалап әвәләде дә кире тыгып куйды.

— Аңлатыр өчен бер гомер генә әз бит...

Шунысына гаҗәпләнде Моратбакый: элек, кыз чагында, Зариманың күзләре олыгайган кешенеке сыман, моңсу, җитди карый иде, ә хәзер, киресенчә, аның күзләре яшь иде, җыерчыклы йөзгә бөтенләй ярашмаганча аерым балкып торалар.

Моратбакый Заримадан чыгып өенә кайтып барышлый урамда очраган яшьләргә туры карамыйча гына, баш кагып кына исәнләшеп узды. Туры караса, күзеннән эчке уйларын белерләр дә оят булып китәр сыман тоелды. Алар бит картларның эчендә бернинди дә уй юк, кайнар чәй эчү дә йомшак түшәк кайгысы гына дип беләләр. Үзем дә яшьлектә шулай уйлап, картларга кызганып карый идем, дип уйлады Моратбакый.

Юл буе ул үз-үзен битәрләп кайтты.

«Киләсе калмаган, күрәсе калмаган...» Гүя ул ничә еллар буена ерактан, бик ерактан үзен алгысытып, чакырып, җылытып торган урман кызына хыянәт итте. Нидер сүнде, сызлану авазы чыгармыйча гына нидер тын гына үлде. Хәзер инде аны берничек тә кире кайтарып булмый. Аңа килеп, аны күреп хәтеренә хыянәт итте бугай ул. Бу карчык белән ул урман кызы арасында бернинди дә уртаклык юк

бит инде. «Киләсе калмаган, күрәсе калмаган...» — дип кабатлады Моратбакый. Ә бәлки Зарима да миңа карап шулай уйлагандыр. Әнә бит ничек, сөйләшү дә ялганмады, коры гына килеп чыкты. Ул да мине күреп хәтеренә хыянәт иткәндер. Без бит бер-беребезне төсмерләдек кенә, ә танымадык...

Зәйтүнә карчык теге вакытта ук инде Моратбакыйның урман юлын нигә таптаганын белә иде. Урман җене дип Зариманы күрәлмый иде. Инде хәзер, аның авылга кайтып төшкәнен ишеткәч, тынычлыгы бетте, әмма иренә берни сиздермәде.

Зәйтүнә теге вакытта Моратбакыйга: «Үз теләгәнеңне тапкач, китәрсең»— дигән иде, әллә менә хәзер шул көн җиттеме, дип пошынса да, тышка чыгармады, эченә йотты. Үземне җирдән күтәреп алган иремнән көнләшергә ни хакым бар соң, дип уйлады ул.

Зарима туган җиргә әҗәлен сизенеп кайткан булган икән...

Гомер буе үзен җылытып килгән өмете сүнгәч, Моратбакый эчтән сүрелеп, боегып калды. Нидер өзелде. «Миңа хәзер берни дә кирәкми инде» дигән сүзе шул өмете сүнгән көннән башланды бугай. Ялгыз калырга куркуданмы, карчыгына елышарак төшеп яши башлады ул. Каты бәрелергә тырышмады.

Ә бит Зәйтүнә, җае туры килү белән мендәргә кырынаеп, черем итеп алырга яраткан карчыкларга охшамаган, җил белән узышып йөргән шикелле — гел хәрәкәттә; ике кулына берәр шөгыль табып мәш килә, эшнең тизрәк ахырын күрергә теләгәндәй житез кыйлана иде.

— Әзрәк ял итеп алыр идең, карчык,— ди ана Моратбакый.

— Һи-ии, фәлән төшем, төгән җирем авырта дип ятсам, күптән инде гүр иясе булыр идем, картым,— ди Зәйтүнә.

...Баядан бирле Моратбакыйның аска карап, кулларын тезенә кушырып утыруын күзәткән Зәйтүнә ярым пышылдап:

— Нигә әле болай оедың. Кәефеңә көя төштеме? — диде.

Моратбакый башын күтәреп сагышлы елмайды, Зәйтүнәне кочаклап алды:

— Әле дә син бар, карчык. Берүк мине калдырып алдан китә күрмә инде...

— Синнән, миннән генә сорап килсә икән.

— Нишләп болай утырабыз соң, җырлале бер, карчык, ә! Теге җырыңны.

— Әй, әзерәк кабып алсаң, гел шулай тинтерәтәсең инде.

— Синең кебек җырлаучы юк бит аны.

— Тиктомалдан.

Елның үзе генә белгән бер вакытында Моратбакый аңардан Сак-Сок бәетен укытып ала. Зәйтүнә карчык таушалып беткән күн тышлы дәфтәрен сандыгыннан чыгара, колаксалары җеп бәйләп ныгытылган күзлеген киеп куя да, бармагын төкреклэп, дәфтәрне актара башлый. Кирәкле битен табып алгач, «И-ни, чәйнегем кайнап түгелмәсен тагын»,— дип җәһәт кенә кузгалып алгы бүлмәгә чыгып китә. Андый чакта Моратбакый сукранмый, сабырлык белән көтә бирә, чөнки белә ул: карчыгы теге якта, тамак кыргалап, тавышын көйләп йөри. Ә Зәйтүнә карчык һаман суза әле. «Лампочканың икенчесен куясыңмы, карт, бусы караңгы сыман»,— дигән була. Моратбакый карусыз буйсына. Бу минутта алыштыргысыз өстенлеген сизеп, картын үз кубызына биетүе инде, янәсе. Моратбакый үзе генә алып укыр иде дә бит, тәэсире башка шул, көйләп, моңлы итеп аны бары Зәйтүнә генә укый белә.

Менә ул дәфтәргә карамый гына көйләп җибәрә. Моратбакый аяк очына басып кына тәрәзә катына килә. Яфракларын койган агачлардан көзге авыр тамчылар тама. Юештән каралган, монсу ихата-кураларны кысрыклап болытлы төн иңеп килә. Моратбакый яшен чыгармыйча, эчтән, фаҗигалы моңга кушылып бәгыреннән җылый. Шушы каралты-куралар аша, көзге калын төн аша ул моң агышына бирелеп, үткәненә юл эзли. Кайтарып алып булмагангамы, узган еллар — кайгылысы да, шатлыклысы да бердәй якын, кадерле тоела. Үткән хатирәләр төенләнеп учка сыярлык кына калган. Кыссаң аннан сагыш тама, сагыш... Хәтта гомер буена, бер иркенләп сөйләшә дә алмаган, очрашкан чакларында мыскыллап: «Нихәл, барчук!» дип эндәшә торган абыйсы да якын кебек хәзер. Сугышта хәбәрсез югалгангамы, бүгенге көндә янда булмагангамы шулай?.. Үзе окопларда яткан чагында монда үпкә чиреннән үлгән әнисе белән дә яуга китәр алдыннан бер тапкыр гына очраша алды бит ул. Улының Зәйтүнә белән кушылуын кичермәде хәсрәтле ана. Бәхилләмичә киткәндер, мөгаен.

Моратбакый сугышта ятып калган иптәшләрен хәтерләде. Тавышлары колакта. Сүзләре истә, йөзләре күз алдында. Шундый хәлләргә тарый иде кайчагында: вокзаллардамы, кая да булса, бергә хезмәт иткән полкташын күреп ала, сугышта үлеп калганын да белә югыйсә, әмма ни гаҗәп — йөзе аныкы, йөреше аныкы — коеп куйган ул. Моратбакый әлеге кеше артыннан ияреп бара, күзәтә-күзәтә бара да... кирәк бит, теге сөйләшә башлау белән катып кала. Тавышы бөтенләй ят икән, ә йөзе нинди охшаган. Әллә кешеләр кабатлана микән, дип уйлый иде Моратбакый.

Бәетнең моңлы көе һаман агыла, рәхимсез дә ул, шәфкатьле дә... Бик тирәндә, караңгы вакыт төпкелендә, кайчандыр син якыннан белгән тансык йөзләр бер-бер артлы пәйда була. Алар, синең турыда үзләре белән алып киткән җылы сүзне әйтеп, күңелеңдә калган бушлыкны тутырырга телиләрме, әллә инде, үзләренә бәйле хатирәне исләренә төшерергә теләп тартылаларммы?.. Сак белән Сок кушыла алмаган кебек, аларга кул суза алмыйсың инде, арада — мәңгелек чоңгыл. Рәхимсез вакыт агымын кичеп, аргы ярга чыгып буламыни... Шушы киеренкелектә акыл җебе өзелер иде, әгәр моң булмаса. Моң барысын да сыйпап юата һәм син, яңадан тугандай җиңеләеп, элеккеге урыныңда, тәрәзә катында торасың. Агачлардан тамган тамчылар да авыр булып йөрәккә таммый инде. Көзге төннән сыгылган каралты-куралар да баягыча өметсез моңсулыкта түгел. Болытлар артында инде юка элпә булып яктыра барган айны шәйлисең...

Бәетнең азагын да көтмичә Моратбакый маллар карарга дип ишегалдына чыгып китә торган иде. Сак-Сок бәетен ул нәкъ менә шундый җан тарыктыргыч көзге кичләрнең берсендә тыңлый иде. Ел да шулай...

Ә бүген — җыр. Зәйтүнәсе кебек итеп бүтән беркем дә җырлый алмаган бу җырны ул хозурланып, дөньясын онытып тыңлый.

Җитәсе лә җиргә, ай, җитәлмим,
Ниләр булды икән туры атка?..

Хәзер инде карчыгы бу җырны элеккечә итеп суза алмый, озын бөгелешләрендә тавышы өзелеп тә калгалый, ә барыбер аны Моратбакый изелеп тыңлый, килеп җитмәгән җирләренә хәтерендә уелып калган моңны ялгап җибәрә иде. Кеше хәтерен моң яшәтә, ахры. Менә, сиздермичә генә моң да картайды...

— Җырлале, карчык.

Сайрар алдыннан каурыйларын, канатларын төзәтеп куйган кош кебек, Зәйтүнә карчык та аркасына төшереп бәйләгән шәл яулыгын ике кулы белән төзәтеп куйды, чәч-кашларын сыпырып алды.

Шул вакыт, бөтен өйне дер селкетеп, ишекләрне ача-ябa игезәкләр кайтып керделәр. Икесе бер авыздан:

— Кино икән анда, караган кино,— диештеләр.

Карт белән карчык, хисләнеп утыруларыннан оялгандай, җәһәт кенә урыннарыннан куптылар.

Тыңлый алмый калды Моратбакый яраткан җырын. Каравылга китәргә дип кузгалды. Тышта шундый матур кар ява дип, игезәкләр аны озатырга булдылар.

— Минем сукмакны кар күмгәндер инде,— диде Моратбакый.

Бер җыенып чыккач, ул өенә кабат әйләнеп керде. Карчыгы чыныяклар җыештырып йөргән уңайдан ишек тавышына борылып карады да, кулын иңенә салынган сөлгегә сөртә-сөртә морҗага сөялде. Аның аптыраулы йөзенә карап Моратбакый:

— Миңа хәтер... әллә нәрсә әйтергә дип кергән идем, карчык, исемнән чыкты,— диде.

— Ашарыңа тыктым. Пилтуанны беркөн үк алып киткән иең. Кем инде каравыл йортында кырына.

Моратбакый, кулларын салындырып, ишек катында бер мәл чарасыз торды. Ни әйтергә теләгән иде соң әле ул? Нигә дип кередән кергән иде? Бая бик әзерләнеп тә, җыр йогынтысына бирелә алмый калган тәэсире аны шулай йомшартып җибәрде ахры, ул, беренче кат күргәндәй һәм хәтерендә калдырырга тырышкандай, әй эчен дулкать белән күздән кичерде. Ерак юлга китәргә җыенгандагы кебек, хәтерзиһене таркау иде аның. Һаман шул рәвештә морҗага сөялеп торган карчыгыннан кыенсынып, аралыктагы бәрәнне иелеп кулына алды. Сабый җылысы килеп торган йомшак бөдрә йонлы бәкәйне иркәләп сөйде-сөйде дә, капылт кузгалып, ишекне ачты. Азат белән Айдар аны капка төбендә көтәләр, этләр дә шул тирәдә чуала иде.

Яфрак-яфрак кар төн йөзен агартып, чуарлап ява. Күкнең сөрүе җөйннән сүтелеп киткән дә аннан каз мамыгы сибелә диярсең. Урамга чыгуга кар кисәк кенә тукталды, каралты-өйләр, кагынып чистарынган шикелле, калкынып киттеләр. Бер яктан җемелдәгән йолдызлары белән күк чите ачылып килә иде.

Моратбакый малайларны бөкрәеп утырган карт өянке яныннан алып китте. Мылтык түтәсендә шушы өянке кәүсәсенә бәрелгән эз бит инде... Өянке әле дә исән... Өч тармагының берсе күптән инде сынып төшкән, икенче тармагы да чак эләгеп тора, аерылып китмәсен дип, Моратбакый аңа терәү куйган иде. Өянкенең төп кәүсәсе эчтән тәмам череп, куышка әйләнгән, кабыгы гына тотып тора. Элек, Моратбакыйның тәрәзәсеннән караганда, иртәнге кояш гел шушы өянке турысыннан күтәрелә иде. Нурлары куе яфраклар аша энә күзеннән чыккан кебек күренә иде. Хәзер инде ботаклары да сирәк, яфраклары да. Үз яшендә күпме үзгәрешләр, югалтулар кичергән Моратбакый өчен бу өянке гүя вакытның үзе, өянке ауса, вакыт та тукталыр шикелле иде. Агачның да хәтере бардыр ул, югыйсә болай ук картаймас иде, дип уйлады Моратбакый. Кычкырып көлешә-көлешә кар атышкан игезәкләргә сокланып атлады. «Кичәгесе юк бит әле боларның, бөтен уйлары — иртәгедә...»

— Бабай, коткар, бабай! — дип кычкырды карга күмелгән Азат. Айдары аның өстенә менеп утырган да ат куган шикелле кыйлана иде.

Шушы өянке янында булган вакыйгаларны сөйләргә ниятләгән иде Моратбакый оныкларына, ләкин аларның шатлыгына кагыласы килмәде.

# IX

Моратбакый амбар тирәсен урап чыгарга дип этләрен дә иртте. Кышын да, җәен дә гел бер эздән йөргәнгә, сукмагы такыр булыр аның. Электр уты эленгән баганаларны да шушы сукмак буена тезеп утырттылар. Каравылчы сукмагыннан тәүлегенә ничә рәт үтәдер ул. Үткән гомерен буйлаган кебек, кайчакта адымнарын санап бара. Кәефле көннәрендә эрерәк, саллырак атлыйммы — мең ике йөз дә бер адым була. Билен сызлатырлык тымызык көннәрдә, кулын артка куеп, өшәнебрәк узамы бу араны — адымнары мең ике йөз унга җитә. Салкынга, җылыга карап тимер чыбыклар, чуен юллар да бер кыскара, бер сузыла икән бит, әллә җир дә шулай микән, дип уйлап куя ул андый чакта. Исәпләп карасаң, җирне уратып кайтырлык ара үтелгәндер инде шушы сукмаклардан?

Сугыштан соңгы елларда симәнә бодае урларга килеп, келәтнең нигез ташын сүтүчеләр дә булмады түгел, булды. Моратбакыйның маңгаендагы яра шулар истәлеге. Хәзер инде андый төнге караклар күренми.

Шуннан соң Моратбакый этләр тота башлады. Яфрак өзелгәнне дә, чакрым ярымдагы аяк тавышын да ишетә алган эт белән ышанычлырак. Каравылчының да исеме генә инде, кирәге шулкадәр, диючеләр дә бар. Әмма Моратбакый андыйлар белән килешми. Каравылчының бар икәненә күнеккәннәрдер, ә менә юк икәнен белсәләр ничек булыр?.. Кара син төн караңгылыгына сузылып киткән бу амбарларны — күпме байлык бит монда, күз-колак булмасаң, ни чыгып куймас хикмәтле заманда. Юк-юкта да үзен белдереп куя бит үчле бәндәләр.

Каравылчы сукмагы... Йомшак аяз төн. Кар өстенә йолдыз тузаны коелганмыни — тоташ җемелдәү. Сукмактан өчәү бара. Алда яшь эт, уртада Моратбакый, кулларын артка куеп үз биләмәләрен күзәтеп килә. Яшь эт артына борылып-борылып карый. Аларның кешегә мәгълүм булмаган үз телләре бар, койрыклары белән сөйләшәләр. «Бик кызулама, миңа авыр бит житешүе»,— ди карт эт. Яшь эт койрыгын кискен уйнатып ала: «Синең шул инде, зарланудан туймыйсың»,— дип ризасызлыгын белдерә. Кинәт ул әсәренеп туктала, шиңгән яфрак сыман шәлперәйгән колаклары үрә баса, әллә кай ераклыклардан саркып кына ишетелгән авазларны да тотып ала, куркыныч янамаганын белгәч кенә, тынычланып, иснәнә-иснәнә алга омтыла. Эт — кешенең ярдәмче колагы, ул тавышлар чолганышында яши...

Каравыл өенә кайткач, Моратбакый арыган гәүдәсен сәкегә таратып ташлады. Кулларын баш астына куеп, күзләрен йомды. Этләр дә идәнгә сузылдылар. Моратбакыйның изрәп болай тиз йокыга киткәне юк иде әле. Сукыр ут яктысында вакыт әкрен үтә. Кайнар сулышыннан күренер-күренмәс сөрем чыгарып күпме янгандыр ул — кинәт, йокы аралаш, Моратбакыйның колагына таныш та, таныш түгел дә тавыш ишетелде.

— Моратбакы-ый!

Әллә бик ерактан, әллә бик якыннан аермачык ишетелгән бу тавыш гүя аны өзәләнеп үзенә дәшә, чакыра иде. Сискәнеп уянгач та ул колак салып бер тын кузгалмыйча ятты. Кабатланмады тавыш. Саташам бугай, дип ул эченнән сүгенеп куйды. Этләренә карады, гамьнәрендә дә юк, таралып йоклыйлар. Әгәр тавыш чынлап та ишетелгән булса, баш калкытырлар иде.

«Ярый әле, теге төш түгел...» — дип уйлады Моратбакый. Шул кермәсә генә ярар иде дип алдан ук уйлап яткангамы, аның йокысын бүлеп гел бер төш бимазалый торган иде. Сугыш вакыты имеш. Моратбакый ярым җимерек бина эченнән кара шәүләләр булып килгән не-

мецларга атып ята. Кинәт ул, нидер сизенепме, артына борылып карый. Ә артта — тәрәзә тупсасына аякларын аерып баскан немец солдаты, киерелгән кулында инде ычкынырга торган граната. Аңа борылып атарга яисә кая да булса яшеренергә Моратбакыйга җай да, ара да юк. Нәкъ менә шул вакытта Моратбакый уянып китә һәм, төш тәэсиреннән айнып бетмәгән хәлдә, жиргә сыенган кебек, салкын тир бәреп чыккан маңгае белән мендәргә сыена. Ярый әле жылы түшәк бар, ярый әле, тиз генә уянып, өндә котылып калырга була. Ә бер вакыт, уянырга житешә алмасаң... немец солдаты гранатасын ыргытырга өлгерәчәк бит!

«Ярый әле, бүген читләтеп үтте» — дип уйлады Моратбакый. Хәер, бу төш аңа өендә, йомшак түшәктә йоклаган чагында гына керә иде бугай. Ә бу минутта ул черем итү түгел, баш төртеп алырга гына өлгергән иде.

Карт этнең һаман шулай күз кабаклары йомылып бетмәгән, кара сызык булып, мәкерле күләгәләнеп тора. Моратбакый аягын идәнгә шапылдатып төшерде дә урыныннан күтәрелде. Этләр дә калыктылар. Яшь эт, юмакайланып, хуҗасының аягына килеп сыенды. Карт эт исә иренеп кенә торды, йоны коела башлаган тупас койрыгын ялкау гына сөйрәп, хуҗасына таба якынлашты. Моратбакый аның сау аягыннан күтәреп тезенә таяндырды. Тупыйк колаклы карт эт бүрене хәтерләтә иде. Күзләре дә бит әнә, яшь этнеке сыман мөлдерәп, ярарга тырышып карамый, ә буйсынуын кичерә алмаган бер зәһәрлек белән яна, Карабай атлы, бүре нәселеннән килгән бу эттә чынлап та үз токымының эзләре сакланган иде. Моратбакый аның башыннан сыйпап сөя башлауга яшь эт, көнләшүдән шыңшый-шыңшый, борынын төртеп арага керде. Карт эт күзләрен йомгалап башын читкә борды.

— Бергә картаябыз. Бер чүгә башлагач, эт түгел, кеше дә юашлана икән шул...

Кинәт яшь эт дәррәү кузгалды да, ишекне күкрәге белән генә бәреп ачып, өрә-өрә тышка атылды. Ишек ябылу җиленнән ут сүнде. Моратбакый сырган чалбарының тирән кесәсеннән шырпы алып, сукрана-сукрана ут алганчы карт эт тә чыгып киткән иде инде. Кесә сәгатен алып карады — төнге беренче ярты икән. Кыдрачланып Шамкаев йөри дисәң, бүген аның каравыл көне түгел. Нинди төн убыры икән?

...Шамкаев теге чакларда тәки председатель урынына кала алмады. Нинди генә эшләрдә үзен күрсәтмәде ул: завхоз, ферма мөдире дисеңме, аннары бригадир эше. Соңрак кибеттә сату итте. Пенсиягә чыгар алдыннан инде шул кибеттә каравылчы булып торды. Кайда гына эшләсә дә, гел идарә тирәсендә чуалды. Шунда туып, шунда үсеп, шунда картаясы кеше кебек идарәсез яши алмады. Юк кына эшне дә ярып салып, олыдан күрсәтә белә, аңа караган шөгыльмеюкмы, иң әүвәл ул барып тотына, ул житешә иде. Каравылчы булгач та ул барыбер Шамкаев булып калды. Инде картайса да, тынычсыз җаны өйдә ятуны өнәми. Килгән саен берәр төрле зарын чыгармый калмас, протезлы аягын туры катырып, тып басып керер дә:

— Өченче көн, каравылга килсәм, ни күрәм диген, завхоз бар бит әле, минем күрше... теге... «Кайнар», пнимаешь, шул олы трактор алып килгән дә,— төзелештән калган бетон балкалар ята анда,— шуларны кар астыннан чыгарган, өстерәп маташа. Нигә кагыласың аларга, хөкүмәтнеке бит ул, мәйтәм. Баз өрлегенә, ди. Кирәк әйберне ике ел буена черетеп яткырмыйлар аны, ди. Бетон чери димени инде, әй! Тәки бирмәдем тегеңә. Яңадан килүемә, жилләр искән балкалардан. Кайтарып аударган ихатасына Кайнар. Күр инде син Кайнарның

ишегалдын — хөкүмәт аңа, пычракларда җайсыз булмасын, тигезлә, дип әсфәлт китереп сатканмы! Күр инде син аның өен — клуб чаклы бит. Ихатасын кара — сарай өстендә сарай. Капка баганаларын әйт — алып ташла имән баганаларыңны, дип хөкүмәт аңа тимер торбалар китереп сатканмы! Пнимаешь, җепсәләре дә тимердән бит. Алагаем зур сварка машинасы китерттеләр, такта кадакларын да икенче ягыннан эретеп кенә ябыштырдылар тимергә. Үзең әйткәндәй, хатыны да бит аның... Чәйне аягүрә генә эчә, ашауга вакыты әрәм китә, янәсе. Әсфәлтне чык-чык ватып, капка баганасына чокыр казып ята бу бервакыт. Пнимаешь, иртән үтәм яныннан — исәнләшеп кала башын күтәреп, төш алдыннан үтәм — ломына тотынып ял иткән җиреннән тагын исәнләшә, төштән соң үтәм турларыннан — тагын исәнләшә бу. Орынып торган күршесе белән кем инде көненә өч тапкыр исәнләшә! Кешене күрми — менә хикмәт кайда! Пнимаешь... Үз ихатасына ташучылар бер ул гынамы. Председательгә барганыем, ни карыйсың, мәйтәм, син хуҗа бит, дим. Хуҗа әллә каян төшми ул, менә без барыбыз да хуҗа, ди бу. Син дөрес әйтәсең, комагайлар бар арада, ди. Кулыннан эш килгәннәрнең барысын да бер буразнага салмыйк без, ди. Менә дигән хуҗалык тотучыларның күбесе колхозда да батырып эшли, үзенә барның, кешегә дә бар аның, ди. Без малай чакта мотоциклга атланып урам чаба идек, өлкәннәр: бу яшьләр ничек бозылмасын, безгә велосипеды да әләкмәде, дип кала торган иде. Хәзер әнә, унбиш-уналты яшьлек малайлар, этисенең машинасын йөртә. Үзгәрә бара тормыш. Әйбергә карап кына хөкем чыгармыйк, бабай, хикмәт җан матурлыгында, шуны саклыйк, шуны югалтмыйк, югыйсә, затлы әйберләр безне буып ташлар, дип әйтә. Яшь кенә, үзең әйткәндәй, башлы, чукынчык, күзлек кигән шул...

— Хәзер миллионнар белән эш итә хуҗалык, элекке кебек, тиеннәр санап...

Шамкаев Моратбакыйны кырт кисә:

— Шуңа күрә урлауны исәпләп тә тормыйлар дисеңме!

Шамкаев авыр сулап кесәсеннән тәмәке чыгара, мөштегенә тыгып кабыза. Шулай бәхәсләшә-сөйләшә төнне үткәрәләр. Элек, пенсиягә чыкканчы, Шамкаев янына якын да килеп булмый иде. Ул гел хәрәкәттә иде. Хәзер менә үзе килә. Тынмас җаны әле дә сүрелә алмый. Инде зарсыз гына, картлыгына таяныч эзләп кенә йөрүедер дисең — юк, вакыт-вакыт кайнап ала, битараф кына читтән күзәтеп йөри алмый. Моратбакый янына гел сугылып чыга ул. Һәр әйткәнен җөпләп, «әйе» дип кенә йокымсырап тыңламаган, сүзгә аркылы төшеп утырганы өчен килә ул аның янына. «Әйе» дип торганнарга да сөйләү кызык, үзеңне генә акыллы итеп тоя башлыйсың. Тик, бер-ике тапкырга гына җитә түземең. Аннары, тәмам туеп, пеше имән төбен тимер чөй белән дә яралмаган кебек арып, андыйларга кул селтисең.

Шамкаевны тыңлау кызык: каян белеп, каяннар күреп бетерә диген, сүзе белән йокымсыраган тәнеңне уята, яшәү коткысы салып китә.

— Теге, югары оч Сабитны беләсең бит. Әтисе дә авызыннан өзми-куймый тәмәке тарта торган бер мәзәк кеше иде. Үлгәч, өч көн күмми көткәннәр, авыз-борыныннан төтен чыгып яткан, дип көлеп сөйләгәннәре хәтеремдә... Менә, Сабитны әйтәм, намаз укый башлаган!

— Булмаганны.

Шамкаев урыныннан ук сикереп тора.

— Булмаганны дип, үзем күреп сөйләштем. Аңлап укыйсыңмы аны, дип сорыйм. Аңлау нигә, ятлаган сүрә инде ул, ди. «Здоровье» журналын укы син әнә, йөрәктән үлүчеләр күбәя, ди. Мин заманында эчеп карадым, анысы, бөтен кеше белә, ди.

— Гомер-гомергә җилкуар булды инде ул,— дип, Моратбакый аның сүзен бүлдерде.

— Ялкау диген! Шуны аклый бит. Намаз укыгач, утын әзерлисе дә, печән алып кайтасы да онытылып тора, ди. Монда диннең катнашы юк, нервыны саклау өчен укыйм мин аны, ә нерв — бик нечкә нәрсә, пәрәвез җебе шикелле генә, күбәләк канатыннан да тизрәк ертылырга тора, ди. Вәт син аны, ә! Аңлап уку кирәкми аны, ди, йоклый алмый ятканда йөзгә кадәр санарга кушалармы, шул ук әйбер ул намаз да, онытылыр өчен, ә кешенең башы корт шәйле вак-төяк белән тулган, аны түкмәсәң, менә монда суга, дип йөрәк турын кагып күрсәтә. Вәт син аны, рәтсезне!

— Хикмәтләр бар инде безнең авылда, Шамкаев абзый, ә!

— Хет син әйтмә сана шулай дип, Шамкаев та Шамкаев. Исемне гел оныттылар.

— Өйрәнелгән бит инде, Шәймөхәммәт абзый.

Шамкаевның һәммә эшкә йөрәксенеп тотынуына, һәммә вакыйгага кушылып китеп, шаукым тудыра белүенә кызыга иде Моратбакый. Үзенең кешеләр күзеннән читтәрәк яшәвенә бер үкенә, көчем, акылым сау чакта файдалана белмәдегез дип, кемнәргәдер үпкәләгәндәй бер юаныч та таба иде. Барысы да үтте инде...

Чишмә суын торбалар аша якындагы поселокка кудыру өчен насослар, ниндидер биналар кордылар. Шамкаев шунда өч тәүлеккә бер каравылда тора, төнге уникедә алышынгач, кайтышлый Моратбакыйда кич утырып китә иде. Иртәгә иде бугай аның көне. Числоны бутаганмын инде алай булгач, дип уйлады Моратбакый. Менә хәзер Шамкаев килеп керер дә, авылны уч төбенә алып, тагын берәр хикмәт сөйли башлар...

Яшь эт, камалый-камалый өреп, сырындылар арасыннан сузылган сукмактан тимер капкага ташланды. Карт эт исә кар шыгырдатып килүчене аяк тавышыннан ук күптән инде танып алган иде. Шулай да, яшь этнең ихлас өрүенә кызыгып, бары тик этлеген итеп кенә өнсез тавыш бирде. Кайчандыр, ерак чакрымнардан ук танылa торган, йөрәккә килеп бәрелмәле гаярь тавышлы эт, хәзерге өнсез тавышыннан уңайсызланыпмы, онытканда бер генә өргән сыман итә иде.

Капкадан кереп килүчене танып алуга, яшь этнең койрыгы бот арасына посты, елар дәрәҗәгә житеп шыңшырга кереште, аннары койрыгын дәртле бутый-бутый, түшендә шуышып килә-килә, ялгыш кына өргәнлеген, аяк астында кар булырга әзер икәнлеген аңлатырга кереште. Шамкаев аны иелеп сөйде, кесәсеннән ипи кисәге алып этләргә бирде дә каравыл өенә таба китте.

Бүген ул бик йончыган кыяфәттә иде. Протезлы аягын ишек тупсасыннан көчкә күтәреп салды. Кызарган күзләре өстендәге ап-ак кашлары түбә кары шикелле салынып тора.

— **Нихәлләр бар, яшьти.**

— Менә, үткәнне уйлап ятам әле.

— Картлыгыңа җиңел булсын дисәң, үткәнне күм икән аны.

— Эт картайса, койрыгын сөйрәр, кеше картайса, үткәнен сөйләр диме?

— Сөйләр идең дә, тыңлаучы булса, хәзерге яшьләрнең пнимаешь, талканы бүтән шул. Алай да... Баягынак синең теге, игезәкләрең килеп керделәр өйгә. Әллә нәмәләр сөйләтеп бетерделәр. Бик инсафлыга охшаганнар, үзең әйткәндәй.— Шамкаев эскәмиягә килеп утырды, бүреген салып тәрәзә төбенә чәпәде, пар күтәрелгән такыр башын сыпырып:— Бетте... беркая чыкмыйм да, йөрмим дә... Бу аяк белән,— диде.

— Бәйләп куймасаң, тотырсың сине өйдә.

— Игезәкләрне әйтәм, үткәннәрне сораштырып, күңелне кузгатып киттеләр. Авылның беренче коммунистлары — кулаклар кулыннан үтерелгән Яркаев белән Шәмсуаров турында беләселәре килә. Аерым күмгән идек, матур җиргә... Моннан унбиш еллар элек, ул тирәдә ферма төзи башлагач, элеккеге председательгә әйттем мин, урыны әйбәт, дигән булды. Хәзер әнә андагы төзелешләрне туктатып кара син! Каберләре бөтенләй кысылып калды бит, ташландык хәлдә... Төп зиратка күчерергә кирәк аларны.

— Әйе шул,— дип саран гына җөпләп куйды аны Моратбакый.

Аның кыска гына сүзендә шул коммунистларга кушыла алмый калган үткәне, яшьлеге өчен битараф булмау тойгысы ята һәм аларга кадерсез карау — үзенең дә үткәне, яшьлеген оныту дип кабул итә иде ул.

Һәр икесе дә беразга үз уйларына йотылдылар.

Шамкаев үзалдына сөйләнеп куйды:

— Бетте... бетте... Гәүдәне йөртү авырлашты... Яндыр син электр утын, кем инде...

— Өзделәр бит утны, яңа йортка күчергә диләр.

— Әйдә, чыгып тәтәтик, булмаса. Тир катты. Һавасы бик шәп. Май яккан ипи кебек, пнимаешь.

Аның «пнимаешь»ы элек җыелышларда чәчрәп чыгып сөйләгәндә мәгънә куәсенә көч бирүче сүз буларак китерелсә, «Үзең әйткәндәй»е янәшә торып сөйләшкәндә кулланыла иде. Хәзер инде һәр икесенең дә урыннары буталды.

Көмешсу ай нурыннан изрәгән авыл кар көртләренә сыенган. Төн куелыгы ай нуры йөгертелгән карлы киңлекләрдән чигенеп, ике тау арасына урнашкан авыл иңкүлегенә төшеп җәелгән, борынгы өянкеләр ышыгына куе күләгәләр булып поскан. Әнә, авыл читендә, озын-озын каралтылар сузылган төбәктә, тереклек барын искәртеп, салкыннан күшеккән утлар җемелди. Бер катлы авылның күз карашын җәлеп итәрдәй иң биек ноктасы булып ике силос башнясы янәшә күтәрелгән. Кабарынкы гөмбәзләре яктырып, йокыга талган тирәюньне үчекләгән шикелле, төнге сүрәнлектә балкып торалар.

Каравыл өе кырыена чыгып баскан ике карт аста, күз күреме җирләрдә җәелеп яткан авыл манзарасын тамаша кылып тордылар. Авыл өстендә карлы киңлекләрдән йотылып килгән тынлык иде. Кышкы төннәрдә генә була торган моңсу тынлык.

— Картаябыз, җанны гамь баса,— диде Моратбакый.

— Тәндә көч барда бик уйлатмый икән шул.

— Эш атыдай, күзең гел җирдә була. Башыңны күтәреп өскә карасаң, мескен бүрегең төшеп китә. Әнә, тау халыкларының бүрекләре дә кыя тау шикелле, батырып кимәле. Биеккә күтәрелеп карасаң да башыңнан төшми.

— Һы, әйтеп куясың инде син, үзең әйткәндәй.

— Тегендә барасы бар бит, Шәймөхәммәт абзый, тегендә... Алла каршына. Тәндә көч беткәч кенә искә төшергәнне кичермәс бит ул.

— Һы, пнимаешь... Бер көч бардыр инде анысы. Бер кулга җыймасаң колхоз да тарала. Бөтендөнья тартылу көче диләрме әле малайларның физикасында.

— Таеп кына киткәндә дә егылмас өчен алла дип куясың. Бөтендөнья тартылу законы дияргә өлгерә алмыйсың шул,— диде Моратбакый.

Шамкаевның ак кашлары җыерылып бергә кушылды.

— Туңдыра башлады, кузгалыйм булмаса.

— Чәй эчик соң...

Шамкаев бераз икеләнеп торды да, кулын селтәп, Моратбакыйга иярде. Кергәч, кысып кына куелган сукыр утны көчәйтеп җибәрделәр. Шамкаев мич каршына тезләнеп, җылысы әле сүрелмәгән күмерләр өстенә кулын куйды. Моратбакый термостан чәй агыза-агыза
— Соңгы арада йокы качты,— диде.
— Теге... клуб мөдире тора бит бездә фатирда, беләсең инде. Ядәч сөяге кебек ябык кына бер нәрсә. Егетләрен әйтерием, ихлары корый инде шул чалбарлы кыз дигәндә. Капка төбенә чаклы өерләре белән кайталар. Ул кызый кереп ятмыйча күзгә йокы эленми, карчык та, мин дә тик борсаланып ятабыз.
— Ятканда ул кызың чалбарын саладыр бит.
— Салмыйча.
— Нигә йоклый алмавың билгеле, болай булгач.
— Что син! Үз кызым кебек лә ул.
Моратбакый чәй ясаган арада Шамкаев йөзен чытып ишек катына килде.
— Аяк сызлап тора әле, бурангадыр.
Сугыштан яраланып кайткач та сау аяклы кешеләрдән күбрәк йөрде, арттырыбрак эшләде, үз-үзен онытып, булсынга дип чапты бит ул. Әмма бүген әллә нишләгән иде, инде генә ачылып китә дисәң, тагын пошаманга кала, йөзе чытыла. Менә тагын ишек тоткасына барып тотынды.
— Кайтырга кирәктер инде... пнимаешь...
— Ни булды сиңа, гомер кыйланмаганны?! Теге кызың кереп яткандыр инде. Утыр, әйдә,— дип шелтәле-көлә Моратбакый аның бүреген салдырды.— Әллә бер тотып куябызмы соң? Минем бар монда, калганы,— Моратбакый, үрелеп, сәке астыннан кәгазь бөке тыгылган шешә тартып чыгарды.
— Йөрәк шаяра, йөрәк,— дип Шамкаев өстәл янынарак шуышты. Моратбакый кружкаларга бүлде, тәрәзә төбеннән каты кәгазьгә төрелгән ат ите алды, ишек артында тавыш биргән этләрен кертеп, аларга да өлеш чыгарды.
— Ат итенең файдасы турында күп язалар хәзер,— диде Моратбакый.
— Хәзер генә аңладылармыни... Бу галимнәр элек ни караган?!
— Алар бит әле күкәй алдан барлыкка килгәнме, тавыкмы икәнен дә кистереп әйтә алмыйлар. Күкәй дияр идең, аны тавык салырга тиеш, тавык дияр идең — анысы күкәйдән чыга.
Шамкаев, электән калган гадәте буенча, бармагын наган итеп күтәрде.
— Тукта, тукта! Күкәйдән тавык чыкмый бит, үзең әйткәндәй, чеби чыга, ә ул чебинең әтәч булуы да мөмкин. Әтәч инде тавыкны таба да таба.
Ит кисәкләрен ялмап куйган талымсыз этләр ике картның җыр-җыр көлешеп тә, авыз чәпелдәтә-чәпелдәтә ашап та алуларына кызыгып, гамьнәрен онытып карап яттылар. Катмый калган тәрәзә өлгесеннән ае инде тәбәнәкләнә барган күк чите күренә, бик авырлык белән туасы кышкы таңга ерак иде әле.
Моратбакый торып этләрен тышка чыгарып җибәрде. Каравыл өе бер мәлгә бушап калгандай булды. Тынлыкны бозарга җөрьәт итмичә хәтсез утырдылар. Моратбакыйның сагыш белән куерган тавышы тынлыкны тагын да сагайта иде.
— Яшибез, яшибез дә...
— Кайтырга иде бит...— Шамкаевның авыз эченнән мыгырданып борсалануын Моратбакый үзенчә аңлады, «шунда гына тарт», дип сүзен дәвам итте:

— Жирдән күпме алып, нинди расходлар чыгарып яшә-яшә дә... Эзсез югал, имеш. Алай гына булмас ул. Булмас...

— Өйдән беркая чыгып йөрмим,— дип мыгырданды Шамкаев. Нин дидер уен әйтергә дә, әйтмәскә дә курыккан шикелле кыбырсып утыра иде ул.

— Йөрәк шаяра, андый чакта алдын да, артын да исәплисең икән. Минем күңелдә йөргәнне әллә ничек, җайлы гына әйтеп салдың. Дөнья куып, күп нәрсә күз угыннан читтә калган. Хәзер инде... Минем яшьтә. Төнгә керсәң, иртәгә уянырмын микән дип... пнимаешь... Теге вакытлар өчен кинә сакламадың син, Моратбакый. Үч саклаган кеше дымлы урында үскән усак кебек эчтән бозыла дигәнең дә хәтердә.— Шамкаев кружканы алып иренәнә тигезеп куйды.— Бер тотынгач, бетерик инде. Синең ничек соң йөрәк?

Моратбакый ипи капкан авызындагы сүзләрне әумәкәйләндереп:

— «Бүре йөрәк» Айтуган малае бит мин,— дигән булды.

Шамкаев, җыерчыкларын тигезләргә теләгәндәй, маңгаен авырттырып-авырттырып ышкый башлады.

— Гел әйтергә йөрдем, гел әйтергә дип... Өстәлең артында минә ризыгыңны ашап утырам... Ничә тапкырлар калкынып карадым — булмады. Бүген бит минем каравыл көне түгел. Игезәкләрең килде дә күңелне айкап киттеләр. Күзләре чиста, пнимаешь, туры карасаң, үзеңдәге тапларны күрерлек. Без дә шулай булдык микән? — Шамкаев йомарланган йодрыгын икенче учына алып кыса, әвәли башлады.— Беләсең бит, гомер кызыктым мин председатель урынында калырга. Нигә кирәк булгандыр, үз эшем дә минә дигән югыйсә, ә кызыктым — чукындырасыңмыни аны! Мәчетне кистерү дә... Ашыгып. Төнлә белән. Эш күрсәтеп калам, имеш. Эләкте дә соң үземә актыктан... Халыктан яшерен эшли башласак, безгә моннан соң ничек ышанырлар соң, диделәр. Аны бит халыкка яхшылап аңлатып эшләп була иде, диделәр... Чак эләгеп калдым шул чакта... Яркәев урынын алырга кызыга идем бит. Эш күрсәтәм дип... Хәзер дә бар ул андыйлар: ике кулын чумырып эшләрлек эше бар, ә үзе булдыра алмастаена кызыга, аяк чала башлый, бар андыйлар... Теге чакта кулга алдырмый калды дип рәхмәтле булып йөрисең инде син. Дөресен әйткәндә... курыктым мин синнән, бер-бер нәрсә эшләп ташларсың дип курыктым. Авылдан китүең кирәк иде миңа. Сәбәбе соңыннан, үзеннән-үзе килеп чыкты.— Шамкаев кызыл тамырлы күзләрен күтәреп карады, тирән сулыш алды, авыз читләре сәер елмаюга охшап тартышып куйды.— Шәрәфине үтерүдә гаебең юк бит синең, Моратбакый!

— Син нәрсә!

— Үтерүче син түгел.

— Акылыңдамы, картлач! — йодрыкларын йомарлаган Моратбакый, кычкырып, сикереп торырга итенде, ләкин кул-аяклары богаулагандай, урынында катып калды. Тәнен хәлсезләндереп, кайнар дулкын йөгереп үтте. Шамкаевның элеккеге көр тавышы үзенә кайткан иде инде.

— Син тыңлап бетер. Утка салырга дип Шәрәфине эзләп китүләрен белдем дә,— үземнең инде өй янып бетеп бара, коткарырлыгы калмаган иде,— аны табып алып, самосуд ясамасыннар дип, ат белән урманга чаптым. Урманга кергәндә, инешнең текә ярында тамырлары белән генә эләгеп торган каен барые бит, шуның төбендә күреп алдым мин аны. Хәл җыеп утырамы-болаймы, мине искәреп алды да мүкәләп чигенә башлады. Туктата алмый калдым... Яр астына бәрелә-сугыла очты. Әйләнгеч юлдан янына төшкәндә инде җан биргән иде. Сынып беткән гәүдәсен, сөзәк җир сайлап, көчкә күтәреп мендем... Ул арада аны эзли чыккан авылдашлар килеп чыкты. Иләмән картның өен тентеп кайтышлары икән, Шәрәфи аңа туган тиешле иде бит. Иләмән картны да иярткәннәр... Шул. Мин ничек аңлатырга белми торганда,

кемдер синең камчыны табып алды. «Айтуган бай малае эшләгән моны!» — дип кычкырып җибәрделәр. Ә мин дәшмәдем. Шул чакта дөресен әйтсәм, миннән шикләнерләр, мине гаепләрләр дип курыктым. Шәрафине син үтермәдең, Моратбакый.

Бу хикәятнең соңы җиткәнне хәлсез бер сабырлык белән тыңлап утырган Моратбакый күзгә күренеп иелә, бөкерәя барды. Бөтен язмышын үзгәртеп җибәргән ул фаҗигалы көнне кайта-кайта башыннан үткәреп, мең мәртәбәләр ачыну, әрнү кичергән иде бит ул. Шул үкенечне авыр таш итеп, гомер буе күтәреп йөрергә күнеккән, аңа инде тәмам ияләшкән иде. Һич көтмәгәндә ул ташны менә кубарып алдылар. Котычкыч бушлык урынына хәзер яңа үкенеч, элеккесеннән дә авыррак... «Зарима дөресен белмичә китеп барды...»

Күңеленнән кычкырса да, Моратбакыйның тавышы пышылдап кына чыкты:

— Нигә сөйләдең син моны... Эчеңдә калсын иде... Соң бит инде, соң...

— Минем дә бит... китәсе бар... туфрагым авыр булмасын дип...

— Кирәкми иде.— Моратбакый утны калкытыбрак куйды, моржага кулын куеп карады, ишекне дә тартыбрак япты. Шул вакыт тышта, бик якында гына сузып улаган тавыш ишетелде. Бүре булып улаган карт эт тавышын таныды Моратбакый. Кызганыч та, афәтле дә иде бәгырьне телеп ала торган бу тавыш. Карт этнең йоклаган чагында да күзләрен йомып бетермичә, нидер көтеп, сизенеп яткан мәкерен яңа аңлады Моратбакый. Үрелеп стенадагы мылтыкны алды, изелеп, тораташ калып утырган Шамкаевның күзләрендә: «Нишләргә уйлыйсың тагын, картлык көнеңдә?..» дигән сискәнүле сорауга җавап итеп:

— Үлем чакыра ул бүре булып улаган эт,— дип, ишекне тибеп ачты, арт аякларына утырып, күккә карап улаган эткә төбәп тә тормыйча атып җибәрде. Берни аңышмый калган яшь эт, үз тавышыннан буылып, тынсыз ауган карт эт янына килеп, чиный-чиный тирәсендә әйләнергә, иснәнергә тотынды. Хуҗасы килә башлагач, куркып, әллә кая гына юкка да чыкты. Моратбакый этнең үле гәүдәсен койма кырыенарак сөйрәп китерде дә кар белән күмә башлады. Суынып та җитмәгән гәүдәсен сыйпый-сыйпый күмде.

— Менә бит, уйламаганда, кайнарлык белән, ничек килеп чыкты... Рәнҗеп китмә инде... Ничә еллар бергә... Картайган идең, интегеп яши идең — рәнҗемә... Көчле идең заманында, ә көчлеләр картаюны авыр кичерә... Кеше дә шулай... Рәнҗеп китмә...

Бәләкәй генә кар тавы үсеп чыкты. Моратбакый аның каршында башын иеп бераз торды да, исенә килеп, артына борылды. Шамкаев кай арада китеп өлгергән соң әле, еракта тимер капканың шалтырап ябылганы ишетелде. Моратбакыйның аны куып җитеп:

— Син моны беркемгә дә сөйләмә, Шәймөхәммәт абзый, эчеңдә калсын,— дип әйтәсе килде. Җитешә алмам дип ул уеннан кире кайтты. Нигә җитешә алмый — тәгаен генә үзе дә ачыклап тормады. «Зарима дөресен белми китеп барды... ашыгырга кирәк» — дип уйлады ул. Кая ашыгырга икәнен үзе дә уйлап бетермәде. Кырт борылып, ул көрт баскан койма аша салынган сукмагына таба китте. Җаны каядыр ашыга, алгысыта иде аны. Тиз генә өйгә кайтып килергә, игезәк оныклары Азат белән Айдарны уятырга кирәк. Аларга бик күптән инде өнендә күргән төшен сөйлисе бар аның. Үзең өчен тормышта иң газиз, иң бәхетле көнең булырга тиеш. Кешене шул яшәтә, кайгылардан, шатлыклардан шул аралап ала икән. Әйтәсе сүзе бар аның оныкларына. Тизрәк кайтып җитәсе дә... Карчыгын да уятыр. «Ни булды, әллә ут чыкканмы!» — дип, сискәнеп тора ул төн уртасында уятсаң, уттан курка... Шуның өчен йомшак кына дәшеп уятыр ул аны. Җырла әле,

карчык, теге җырыңны дияр. Балалар да тыңласын, моңын сеңдереп калсалар, туган җирне онытмаслар, бездән бәхетлерәк булып, кешеләр күзенә туры карап яшәрләр, дияр.

Кем инде төн уртасында торып җырлап утырсын, ди. Кичә иде аның вакыты, кичә... Кайтарып булса икән үткән вакытларны. Үкенер өчен генә яшәләме соң әллә бу җирдә? Ашыгылган, шатлык килгәндә иркенләп шатланылмаган, кайгы килгәндә бушаганчы кайгырылмаган — ашыгылган. Соңга калганыңны белер өчен шулай кирәктер дә ул. Барысына да син өлгерсәң, артыңнан килгәннәргә ни калыр иде?..

Менә бит, менә, кичә генә игезәкләр белән өчәүләп төшкән эзләре суынырга да өлгермәгән әле. Их, шуларга кушылып, кар атыша-атыша бер уйныйсы калган икән. Әнә, кул сузымы гына арада — авыл. Әнә таулар. Еракта караллҗым урман. Юллар бара микән анда хәзер... Бу таулар, бу урманнар мин булмасам да гел шулай калыр микән?..

Кар шыгырдавын ишетеп, ул артына борылды. Юк, беркем дә юк иде. Күзенә сүрән яктылык төште. Каравыл өенең ишеге төбенә кадәр ачык калган икән. Эчтә сукыр ут яна. Моратбакый килгән эзеннән кире китте. Сүндерергә онытткан. Сүндерергә. Тизрәк, тизрәк, тизрәк, дип ашыктырды аны кар шыгырдавы.

Кинәт... күкрәк турысыннан күкрәү үтте. Карлы кырлар, ерак урман, йолдызлы күк тетрәп бер убылып алды. Күкрәк читлегендә гомер буена үзен сиздерми яткан кош уянып, хәтәр көч белән бәргәләнә иде.

Якынлашкан саен, каравыл өе бәләкәйләнә бара, бәләкәйләнә бара — Моратбакый якты төшкән ишектән сыеп керә алмасын аңлады да, утны сүндерергә теләп, кулларын алга сузды.

Күкрәк читлегендәге кош канатларын турайтып киерелә башлады.

Җирдә бер генә кат яшәүнең кадерен, бүтән инде мәңге кабатланмасын әле генә аңлаган Моратбакый, үзенә соңгы юаныч итеп бирелгән, бөтен гомере сыйган актык минутында әле бүген генә төшендә чакырган таныш тавышны янәдән ишетте:

— Моратбакый!

Инде тавышның иясе дә күренә дигән мизгелдә дулкын булып өскә ябырылып килгән урман ике араны бүлде...

Тарсынып, күкрәк читлеген аерып чыккан кошны күк иләп үзенә алды.

# ТӨНЬЯК ОСЕТИЯ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

## Коста Хетагуров

(1859—1906)

### Хуш!..

Аяк-чуны кидем һәм биштәрне,
Пеше чыбык булды билбавым,
Ямаулы тун өстә, кулда таяк —
Бу көнне дә күрдек... Хуш, җаным!

Карашларым күптән шом салгандыр —
«Олак!»— диеп әйтте күзләрең.
Җан тылсымы белән тойдым бугай
Күңелеңнең яшерен сүзләрен.

И күз нурым! Сау бул! Көтмә бүтән!
Сукбайдан ни рәхәт көтәргә?!
Карашымны онытырсың бүген,
Исемемне исә — иртәгә...

Хыялый һәм ялгыз иде диеп,
Уйлап куярсың син бер мәлдә...
Бәлкем, күргән төшләреңдә үлем
Бусагасын атлар бу бәндәң.

Газапланма ләкин! Бу төштән соң
Рәхәт тормыш килер сиңа да:
Кайгыларың кемдер уртаклашыр,
«Тик син!»— диеп яшәр дөньяда.

Юлдаш булсын рәхимсез бу язмыш
Сиңа түгел — миңа! Сайладым...
Шушы язмыш җитәр минем башка —
Газапланма ләкин... Хуш, җаным!

### Яңа ел төнендә

Көтмәгәндә тупсагызны
Атлап әгәр мин керсәм:
«Саумы, хуҗалар! Гомремне
Сезгә багышлыйм!» дисәм,

Каршылау өчен кунакны
Ишек янына килсәң,
Үзеңә бер күз салырга
Әгәр мөмкинлек бирсәң,

Син тыйнак кына елмаеп
Күземә карар идең,
Сабыйлар сыман ышанып:
«Кем син?»— дип сорар идең.

Кулларыңнан тотып шулчак,
Карап якты күзеңә:
«Сине сөйгән кеше бу!»— дип
Әйтер идем үзеңә...

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәләре.

# Даут Дарчиев

## Арба җыры

Җирдә безнең үз юлыбыз,
Юлыбызда — үз җырыбыз.
Җырларыңны, әйдә, барла,
Җырла, арба, әйдә, арба!

Иплә кенә бармалы юл —
Сикәлтәле, бормалы ул.
Әйдә, алга, әйдә, арба,
Бормалардан куркып барма!

Киң булса да, тәр булса да,
Юлда яңгыр, кар булса да,
Әйдә, арба, әйдә, алга,
Бар ышаныч синдә, арба!

Давыллар да очрар алда,
Салкын җилләр кочар анда.
Ә шулай да, әйдә, арба —
Тыныч барам мин син барда.

Алга бару — синең эшең,
Әйдә, алла хакы өчен.
Әйдә, алга, әйдә, арба,
Кояшыңнан берүк калма!

Без кояшка юлыгырбыз,
Нурларында җылынырбыз.
Җырлый-җырлый, әйдә, арба,
Әйдә, арба, әйдә, арба!

Роберт **МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәсе.

# Борис Муртазов

## Бөркет

Яр буенда... ташлар арасында
Бер ялгызы калган.
Аның әле беренче кат шулай
Канатлары талган.

Тик күзләре генә: «Күрегез, ди,
Мин бит сизәм, беләм —
Канатларым минем түбән төште
Кыяларым белән.

Өч йөз ел очтым мин... зәңгәр күктә
Гел кояшка карап.
Өч йөз ел мин очтым... ә бер көндә
Юкка чыкты канат

Очтым, очтым боз таулары аша,
Давылларны уздым,—
Алар сулышыннан яшәрдем дә
Канатларым суздым.

Тагын шулай биек кыяларга
Очып менсәм иде,
Бөтен дусларымны биеклектә —
Күктә күрсәм иде».

Әй, бөркетем! Саубуллашмыйк әле,—
Йомма син күзеңне.
Синең күзләреңдә күрдем ләса...
Күрдем... мин үземне.

Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ тәрҗемәсе.

## Максим Цагараев

### Кояш

һәрбер күзәнәктә яши кояш.
Яктырта ул һәрбер күңелдән.
Тукылганбыз кояш нурларыннан,
Безнең гомер нурга күмелгән.

Карый кояш безнең тәрәзәдән,
Ут янамы диеп учакта.
Ул осетин бишегендә яткан
Сабый булып көлә кочакта.

Әй җилферди күктә кайнар кояш,
Әй кыздыра — түгел түзәрлек.
Безгә эссе дә бит, бәхетеннән
Җәйрәп ята әнә үзәнлек.

Җәй җитүгә, ул шарлавык булып,
Үзәннәргә таба ургыла.
Я әйләнә утлы бураннарга —
Булдырала шулай ул гына.

Безнең белән ул хакимлек итә,
Кайда кирәк, кояш ул шунда —
Картларның ул кабере тирәсендә,
Сабыйларның ул баш очында.

## Александр Царукаев

### Көзге урман

Күземә тау түбәсеннән
Ап-ак кар карап тора.
Җил ятим калган чинарның
Яфрагын тараттыра.

Соңгы тургай очып үтте
Тавышсыз-нисез генә.
Ялангач урманда ул да
Бер моңсыз-көйсез менә.

Бушап калган агачларда
Тирбәлүче оялар.
Сандугач ояларына
Инде карга оялар.

Йокыга талды буш урман.
Соңгы яфрак — түшендә.
Ахры, шул ялгыз яфракны
Күрәдер ул төшендә.

Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәләре

## Михаил Цирихов

### Умырзая

Умырзая карны ярып чыкты.
Никтер кылыч төште хәтергә.
Яшәү — көрәш!— диеп, бу гөлләргә
Кем өлгергән әле әйтергә?

Гомереңне безгә бир дигәндәй,
Карлы җилләр юкка котыра:
Зәңгәр күзле сеңелләрен көтеп,
Умырзая балкып утыра.

Рәшит **ӘХМӘТҖАНОВ** тәрҗемәсе.

## Ахсар Кодзати

### Терек

(СОНЕТ)

Башлангычың таутүбәме, изге күкме?
Иҗатыңмы — төпсез чоңгыл, күк капугы?
Кемнең хыял кодрәтендә соң син тудың?—
Җир җаны бит сине шулай тере итте.

Кыш йоклаган аю чыгар өнең ишетеп —
Тау һәм дала халкыннан дус-кардәшләрең.
Ярыңда гел — картлары һәм яшь-яшьләре —
Һәр килгәнне кабул кылдың син үз итеп.

Суың синең шифа миңа — хәлдән тайсам,
Каркылдасын утрауларда кара каргаң!
Җанга рәхәт, елгам, ярсып ырылдасаң.

Балкыт миңа иң-иң биек йолдыз нурын,
Күрсәт җирнең мең яшәтер нык тамырын.
Җырла Терек, мин дә җырлыйм син җырласаң!

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәсе.

## Васо Малиев

### Назыйм

Богаулар калдырган җәрәхәт, гүяки —
Талаган авырту синең саф йөрәкне.

Мин дә бит авырыйм нәкъ синең газаптан:
Әрнетә — тирәкне балкыткан яңа таң,
Әрнетә чыклардан яктырган үләннәр,
Шат сабый авазы... Таңнарда үлгәннәр.
Зур кайгы — тынлык та һәм дәһшәт тә кебек —
Әрнетә бу җирдә явызлык, игелек.
Җавап бир син, Назыйм, соравым бар сиңа:
Ялгызың калганда упкыннар каршында,
Кара төн мәлендә, кайгыңны кочаклап,
Әрнүләр йөрәкне терәгәч пычакка
Син нишли идең соң? Акыл бир, шагыйрем!
Сәныйгъ җан һәрвакыт үзенең гомерен
Һәлакәт белән гел бетерсен мени соң?
Нәкъ синең йөрәкне Истамбул кылычы
Урталай телде бит... Бу гасыр дөньясы!
Икегә бүленде, икегә бу гасыр!
Икенең бербөтен берлеге булып син
Тулгандың кешенең җанына тулып син.
И заман, бу кешең — таңредән һәм җирдән...
Ял ит бер син, Назыйм, коточкыч әрнүдән!—
Минем ил куйнында тынып ял ит инде —
Керфеккә кунган тын күз яше шикелле...

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәсе.

## Шамил Джикаев

●

Иксез-чиксез байлыгымны барлыйм,
Җитә миңа... кемнекен дә алмыйм.
Энҗе-мәрҗәнем бар — һич югалмас,
Утка салсаң — янмас, суда — батмас!
Дошманлыкка, үчкә буйсынмыйлар,
Комсызлар учына, юк, сыймыйлар.
Ул хәзинәм минем — Туган җирем!
Ул — нәфрәтем, мәхәббәтем минем.
Ул — Байрагым!— мәңге төсен җуймас,
Упкын йотмас аны, кылыч ярмас!
Алдан белгән җирем, алдан күргән:
Туган телне бүләк итеп биргән.
Һәрбер сүзе аның — бәхет кошы,
Һәр авазы — алсу таң балкышы.
Сөйлим... иренемә баллар куна,
Тауларымның ташы — ефәк була.
Хәзинәмнең энҗе-мәрҗәннәре —
Дөреслегем, җирем, ил гамьнәре.

Рәшит **ӘХМӘТҖАНОВ** тәрҗемәсе.

# Камал Ходов

## Әткәмне уйлап

Күпме каза килде дусларыма,
Мин юаттым: «Бетәр... Үтәр...»— дип,
Ул мәлдә син салкын окопларда
Һәммәбезне иңгә күтәрдең!

«Һәлак булды...» — дигән өчпочмакны
Укыганда ялгыз әнкәем,
Мин бишектә идем... Тойганмындыр
Сугыш җиле дулап үткәнен.

Яшь тә тулмаган чак... Тәпи бастым.
Азатлыкны саклап шул көнне
Канга батып аугансың син, әткәм,
Балта чапкан тирәк шикелле.

Йоткан сугыш... Тик улыңа сүзең
Әйтми үләр кеше түгел син!—
Кайсы сүзең әйтелмичә калды?
Ниләр миңа әйтер идең син?..

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәсе.

# Зинаида Хостикоева

●

Еллар, юллар... шундый талчыктырды.
Кош булып син очып кил монда,—
Маңгаема кулың тигер, әнкәй,
Йоклап китим әле кулыңда.

Унбиш яшьлек чагымдагы кебек
Күзләремне йомдыр иркәләп.
Таң беленгәч уят,
Таулга кунган
Таң нурларын күзлик бергәләп.

Төшләремә кергән карлыгачлар
Очып йөрсен әле күгемдә.
Мине тагын еллар, юллар көтә...
Бергә булыйк, әнкәй, бүгенгә.

Рәшит **ӘХМӘТҖАНОВ** тәрҗемәсе.

## Георгий Кайтуков

# ЭПИГРАММАЛАР

### Бер лекторга

Ачуланма, тәңре, һәм каргама мине,
Сине тиргәп сиңа акча тотам бит:
Сәдакага китә ярты эш хакым —
Бер эш белән икеләтә отам бит.

### Редакторга хат

Мөхәррир дус, мә, боларын укый башла...
Ә иртәгә бүтәннәрен китерермен.
Шигырьләрем бүген чыксын... иртәгәгә
Искерәсен беләм чөнки фикеремнең.

### «Булышчыга»

Үтенечем шундый сиңа, дустым:
Мин бит әле үзем сау-исән...
Комачавым була күрмә зинһар,
Әгәр миңа булышыйм дисәң.

### Тәнкыйтькә тәнкыйть

— Тәнкыйтьчебез каты чирләгән ди...
Больницка ук алып киткәннәр.
— Ни булган соң?
— Кемдер каршы чыккан,
Аның үзен тәнкыйть иткәннәр!

### Куркак Камбол

Хетагуров Коста таудан төшкән
Дошманнарны кыйнар-кырыр өчен.
Камбол исә шул тауларга менгән
Мәгарәдә качып торыр өчен.

## Грис Плиев

### Батыр куян

Кылый Куян озын-озак итеп
Нидер яза-сыза икән.
Кичке ауга барган чакта шуны
Төлке күреп уза икән.
Һәм сорый ул:— Ни сырлавың, җанаш?
Эчеңнән нәрсә мыгырдап?
— Жалу язам Арслан өстеннән мин!
Күп йөрдек бушка лыгырдап..
— Син? Куян? Жалу? Шикаять?
— Әйе! Җитте! Туйдым, ниһаять!
Ул — тиран, бирән палач бит,
Кем җитте шуны ботарлый...
Ә күзләре һаман ач бит!
Төлке аңа әйтә ачы көлеп:
— Сүзең хактыр! Мәгънә бар монда!
Ләкин... Ник соң эшләмәдең моны
Ерткыч әле үзе барында?..

Күпләр әле, күпләр шулай батыраеп
Берәзлексез әләк яза-сызалар.
Әйе, күпләр... Көчлеләрне бары алар
Үлгәч кенә тибеп-таптап узалар.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре


## МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

*«...хәзерге шартларда терлекчелектә дә иң мөһиме — һәр сыердан сөт алуны һәм дәүләткә тапшырыла торган терлекнең уртача авырлыгын арттыру».*

**Л. И. Брежнев.**

## Марсель Зарипов

# СЫЕРЫ БАРНЫҢ СЫЕ БАР



Тормышта шундый хәлләр дә була: әйтик, терлекнең буыннан-буынга сакланып килә торган сыйфатлары тора-бара аның өчен бер кимчелеккә әйләнеп китә. Мәсәлән, холмогор сыерының суыкка чыдам булуы, азык талымламавы, төрле авыруларга бирешмәве аңа еш кына бәхетсезлек китерә: бу токымның таза, талымсыз булуына исәп тотып, аңа җүнле тәрбия күрсәтми башлыйлар. Шул сәбәпле бу сыерлар нәселдәге яхшы сыйфатларын күрсәтә алмыйлар, сөтләре кими, сыеклана.

Әмма, шуңа да карамастан, холмогор сыерының дәрәҗәсе төшми, ил буенча ул сан ягыннан бары тик симменталь, аклы-каралы һәм кызыл дала токымнарыннан гына калышса калышыр. Бу токымның кайларга хәтле таралуын гына күз алдына китерсәк тә, Архангельск өлкәсенең Холмогоры дигән авылында халык селекциясе тарафыннан чыгарылган бу атаклы ала сыерлардан башка эш барып чыкмавын яхшы аңларбыз. Холмогор сыерын салкын Мурманск һәм Норильск төбәкләрендә дә, күлле Карелиядә, ерак Камчаткада да, элек-электән сөтле Вологда якларында да асрыйлар. Татарстанда исә 413 мең баш сыерның 159 меңе холмогор сыерлары, калганнары — аклы-каралы, швиц һәм бестужев токымнары. Әнә шул холмогор сыерлары бирә торган искиткеч тәмле май, чит ил базарларында Дания, Швеция, Финляндия фермерларыныкы белән ярышып, Вологда ягына дан-шөһрәт китермәде микән әле? Илнең урта җирендәге өлкәләрен, Идел буе республикаларын инде әйтеп тә торасы юк. Монда җәен дә, кышын да уртача һава: теләгән малыңны рәхәтләнеп асра, үрчет, гөбердәтеп сөтен сау, базарына, кибетенә, заводына илт. Әнә шуңа күрәдер, холмогор сыерын Рәсәйнең егерме алты өлкәсендә һәм республикаларында асрыйлар.

Паспортындагы сыйфатламасы буенча холмогор сыеры елына өч мең ике йөз — дүрт мең ике йөз килограмм чамасы сөт бирергә, майлылыгы өч бөтен уннан сигез — уннан тугыз процент булырга тиеш. Чынлыкта исә, бонитировка мәгълүматлары буенча, җитмеш тугызынчы елда аннан ике мең алты йөз кырык биш килограмм гына сөт савып алганнар, майлылыгы 3,5 процент булган.

---

Кыскартылган варианты «Советская Россия» газетасының 1981 елгы 15 январь санында басылды.

Холмогор сыерының әнә шулай паспорттагы сыйфатламасын расламавы, әлбәттә, бу токымның дәрәҗәсен төшерә, аны асрарга элеккеге кебек үк атлыгып тормыйлар. Хәзер Россия фермаларында ике миллион ярым холмогор терлеге бар, шуның бер миллион да йөз кырык меңе — сыерлар. Моннан ун ел элек холмогор терлеге барлык көтүнең унбиш процентын тәшкил иткән булса, хәзер җиде ярым процент кына калган.

Җаны теләгән — елан ите ашаган, ди. Тик шунысы гына начар: теге яки бу токымны сайлаган чакта күп кешеләр гади бер хакыйкатьне оныталар: гомумән начар терлек юк ул, терлек хуҗасының үзенең генә тырыш яки ялкау булуы мөмкин. Малны үзең өчен файдага да, зыянга да асрап була.

Бу уңайдан Мәскәү терлекчеләренең эше шактый гыйбрәтле. Соңгы унбиш ел эчендә Мәскәү өлкәсенең колхоз һәм совхозлары үрчетү өчен голланд, айршир, голштинофриз һәм джерси токымнарыннан тугыз меңләп тана кайтарталар. Чыгымнары белән дә исәпләшеп тормыйлар, нәселле терлек өчен алтын түлиләр, ә менә көткән нәтиҗәгә ирешә алмыйлар. Дөрес аныcы, унынчы бишьеллык урталарында өлкә авыл хуҗалыгы идарәсенә караган колхоз һәм совхозлар бер миллион да дүрт йөз унбер мең тонна сөт савып алалар (1971 елда бер миллион да туксан алты мең тонна гына була). Ләкин сөт сыерларны ишәйтү исәбенә генә арта, сыер башына исә нибары дүрт килограмм гына арта. Әгәр үзебезнең холмогор сыеры өчен шулкадәр көч куеп, мал түгеп, аның сөтен нәселендәге чамасына якынайтырга тырышсак, ничек булыр иде икән? Гадәттә галимнәр мондый вакытта төрле чарасын эзләп карый торган булалар иде, биредә исә башка, яңарак токымлы терлекләр белән генә кызыксыналар. Соңгы ун ел эчендә алар аклыкаралы токым турында ике йөз сиксән җиде китап бастырып чыгарганнар, журнал һәм җыентыкларда бер мең дә туксан ике мәкалә бастырганнар. Ә холмогор сыерын онытканнар, һәрхәлдә аның турында нибары кырык сигез китап, йөз туксан өч кенә мәкалә басылып чыккан.

Шулай итеп, атаклы холмогор сыерының инде асрарлык кыйммәте калмаган, аны башка токымлы терлекләр белән алмаштырырга вакыт микәнни? Холмогор токымын моннан ике йөз еллар элек салкын Архангельск якларында, крестьян хуҗалыгында бер-ике генә баш сыер асраган заманда китереп чыгарганнар. Ул якларда азык бик мул булмаса да, мал-туарны кадерләп караганнар. Безнең колхоз-совхоз фермаларында исә хәл бөтенләй башка. Сыерларны машина белән, «елочка», «карусель»ләр белән генә савалар, куәтле сөт фабрикалары эшләп тора, бөтен эш кнопка-автоматларга гына корылган, сыерны инде элеккечә сөеп-сыйпап азапланмыйлар. Колхоз һәм совхозлар тормышына специальләшү, хезмәт бүленеше дигән нәрсәләр килеп керде. Бозауларны берәү, таналарны икенче, кысыр сыерларны өченчеләр карый, савымчылар, эшкә ак халаттан гына килеп, сыерларның имчәкләренә саугыч машиналарны тоташтыралар. Кем белгән бит: хәзерге фән казанышлары заманында, бәлки, чыннан да, холмогор сыеры инде мондый яңа шартларга ярап бетми торгандыр, аннан әкренләп котыла башларга кирәктер?

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының терлекчелек главкы башлыгының урынбасары Анатолий Ильич Кузнецов минем әнә шундый соравыма болай дип җавап бирде:

— Сыерның сөте — телендә. Ашатырга кирәк аны. Бөтен бәла — азык җитмәүдә,— диде.

Чыннан да, фермаларда азык бик үк мул түгел. Хәзер илдә басуларның өчтән бер өлешендә мал азыгы үстерелә. Моннан тыш, күлсу туфраклы зонадагы өлкә һәм республикаларда унбиш миллион гектарлап табигый болын һәм көтүлек бар. Кызганычка каршы, ул болын-

нарның 3,7 миллион гектарын куак, әрәмәлекләр басып киткән. Чәчеп үстерелә торган җирләрдән дә терлек азыгы күп чыкмый, азык берәмлеге гектарына уртача егерме центнердан артмый. Аннан да бигрәк, булган азыкта да аксым аз. Фермаларда печән дә аз, тамыразыклар җитешми...

Шулай да игенчеләр тырышмыйлар дигән сылтау астында зоотехника культурасының түбәнлеге, селекция мәсьәләләренә салкын карау, терлекчелектә эшләүче меңләгән кеше — савымчылар, терлек караучылар, көтүчеләр, селекционер галимнәрнең эшенә җитәкчелек итүдәге кимчелекләр яшеренеп ятмый микән? Терлекнең алдында азык өелеп ятканда алдынгы булу әлләни кыен эш түгелдер. Бездә терлек азыгы шулай гел зарланырлык дәрәҗәдә аз микән соң? ВАСХНИЛның Вице-президенты академик Л. К. Эрнстның исәпләвен китерик: «Оптималь структуралы рацион белән терлеккә елына утыз дүрт центнер азык ашатканда бер сыердан ике мең сигез йөз килограмм чамасы сөт савып алырга мөмкин, ләкин унынчы бишьеллыкның дүрт елында савым ике мең дүрт йөз илле җиде килограмм гына булды».

Һәр сыер башына өч центнер ярымшар сөт кайда югалып кала икән соң? Миллионлаган баш исәбеннән кушып караганда дәрья кадәр булыр иде бит бу!

Бер караганда бик аңлаешлы, гади кебек тоелса да, бу сорауга ансат кына җавап биреп булмый — биредә хуҗалык мәсьәләләре, оештыру, техник, зоотехник һәм фәнни мәсьәләләр барысы бер төенгә килеп төйнәлгәннәр, шуларны дөрес хәл иткәндә генә эш алга китәчәк.

Көлсу туфраклы зона буенча ВАСХНИЛның фәнни һәм производство бүлекчәләренең эше турындагы калын бер гыйльми китапта кызыклы гына, беркадәр өмет уята торган бер бит күземә чалынды. Бактың исә, «ВАСХНИЛ галимнәре җитәкчелегендә специальләшкән ферма һәм комплекслар өчен сөт җитештерүнең перспективалы технологиясе эшкәртелә» икән. Конкрет адресы да әйтелгән: тәмле майлары белән атаклы Вологда ягы, Сөтчелек һәм болын-көтүлек хуҗалыгының төньяк-көнбатыш фәнни тикшерену институты. Биредә «тәҗрибә хуҗалыгы комплексларында, дымлы азык кушылмалары кулланып, сыерларны тукландыру технологиясе эшкәртелә... Моның нәтиҗәсендә һәр сыердан дүрт мең сигез йөз килограмм сөт савып алынырга тиеш».

Хәзер — ике мең ярым килограмм, киләчәктә — биш мең чамасы. Әйтәсе дә юк, өмет бик зурдан! Шулай булгач, кызыксынып, карыйсы күрәсе иде аны! Институт Вологда шәһәреннән әллә ни ерак түгел, утыз минутлык юл. Шулай итеп, мин галимнәр янына киттем.

Борын-борыннан авыл халкы әйтә килә: терлек токымының начары юк, хуҗаларның гына уңганы яки уңмаганы була, ди. Вологда галимнәре янына баргач, мин халык әйткән мондый сүзләрне дә беразтөзәтергә кирәк икәнлегенә ышандым: бер үк хуҗада сыерның сөтне потлап саудыра торганы да, литрлап кына бирә торганы да була икән.

Махсус бүлек, лаборатория һәм секторларыннан тыш, институтның Куркино, Остахово, «Знамя коммунизма» дигән өч тәҗрибә хуҗалыгы бар. Бу хуҗалыкларда галимнәр үзләренең фикер һәм гипотезаларын тикшереп сыныйлар, терлекчелекне интенсивлаштыруның отышлы, күп файда китерешле юлларын эзлиләр, мал-туарны ашату, механизация һәм селекция белән дә шөгыльләнәләр. Илдә холмогор токымын үрчетә торган ике селекция үзәгенең берсе — әнә шул институтта.

Куркино фермасына баргач, институтның директоры авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Виктор Николаевич Никитин миңа искиткеч бер сыер көтүе күрсәтте. Күргәзмәгә хәзерләгән кебек, экстерьерлары, күпме сөт бирүләре, машина белән савуга җайлашулары буенча сайлап алынган аклы-каралы токым сыерлары бу. Кыскасы, бөтен ягы уйлап, тиешенчә эшләнгән, карап торырга сокланырлык маллар. Терлекләрнең

азык базасы нык, гектарыннан утыз бишәр центнер азык бирәмлеге алалар, сыерларны кыш көне абзарда асрыйлар, бәйләп тотмыйлар, ишек алдына иркенгә чыгарып йөртәләр. Шунда ук утлыкларга печән, салам салынган, өстәвенә саламга төрле микро-тәм-том кушылган. Җәй көне көтүне сөт сауган урын тирәсендә утлауда йөртәләр, утлаулары да акыл-хәйлә белән уйлап эшләнгән — минем андый нәрсәне күргәнем юк иде әле — әйләнә-тирәле егерме ике радиаль загон ясалган. Һәр загонда хайваннарны ике тәүлек кенә тоталар да күршедәгесенә күчерәләр, тегесен тап-такыр чабып, ашлама сибеп чыгалар, «яңгыр яудыралар». Көтү башка загоннарда утлап йөргән арада биредә яңадан үлән үсеп җитә. Көтүдәге һәр сыердан дүрт мең дә өч йөзәр килограмм сөт савып алалар! Шулкадәр азык тоту, хезмәт куе һәм чыгымнар булуга карамастан, хуҗалыкка сөт артык кыйммәткә төшми. Табыш та китерә. Һәр йөз гектар җиргә сиксән дүрт баш терлек асрыйлар, шул исәптән утыз дүрт башы — сыер, унтугызы — дуңгыз. Табышны ун меңләп саныйлар, азык аз тотыла, бер центнер сөткә 2,9 кеше-сәгать китә. Бу саннар белән мактансаң да ярый.

Күрше «Знамя коммунизма» хуҗалыгындагы икенче сыер көтүен киләчәктә бик өметле дип саныйлар. Бу хуҗалыкта мең сыерга исәпләп, хәзерге заманча промышленность комплексы салынган, эче цех структурасынча бүленгән: савым сыерлар, бозаулату бүлеме, сөт ташлаган сыерлар бүлеме — мал-туарны аерым-аерым асрыйлар. Куркинодагы кебек үк зур фәнни ярдәм күрсәтелә. Ә сыерлары нинди? Галимнәргә генә түгел, гади зоотехникларга да мондый көтү тоту оят! 1979 елда һәр сыердан ике мең дүрт йөз егерме икешәр килограмм сөт савып алганнар. Ничек, азмы бу, әллә күпме? Кызганычка каршы, бик аз. Чагыштырып карау өчен мондый саннар китерик. 1968 елда бөтен Вологда өлкәсе һәр сыердан ике мең биш йөз егермешәр килограмм сөт сауган, узган бишьеллыкның дүрт елында Россия Федерациясе колхоз һәм совхозларының уртача күрсәткечләре — ике мең дүрт йөз илле җиде килограмм. Башка өлкә һәм республикаларда бармак белән генә санарлык әлеге көчле комплекс ни сәбәпле шулай да продукция бирә соң? Турысын гына әйткәндә, эшкә тиешле башыннан керешмәгәннәр. Иң элек башка эшләпә, аннары гына өскә күлмәк кия башлаганнар. Ике миллион ярым акча тотып, зур комплекс төзегәннәр, сыерлар кайтарткannar, яхшы, саф токымлыларын сайлап алганнар, тик әнә шуннан соң гына аларны ничек тукландыру, кешеләр өчен торыр урын турында уйлый башлаганнар. Сөт фабрикасын җитмеш алтынчы елда ук эшләтә башласалар да, көтүлеге әле сиксәненче елда да әзер түгел. Хуҗалыкның җирләре Куркинодагы белән чагыштырганда азыкны бер ярым тапкыр кимрәк бирә — егерме дүрт центнер гына.

Вологдага барыр алдыннан мин китапханәгә кереп, Төньяк-Көнбатыш фәнни тикшеренү институтының гыйльми хезмәтләрен караштырдым, галимнәрнең эшләре һәм уй-фикерләре белән кызыксындым. «Знамя коммунизма» комплексын өлгерткән елны басылган тугызынчы чыгарманың илле җиденче битендә мондый юллар күземә чалынды: «Терлекче мал-туарның файдалы сыйфатын үстереп, яхшырак токым тудыра ала, әмма хайваннарны тиешенчә тукландырмаганда... бу максат бөтенләй чынга ашарлык түгел». Тагын: «Терлекләрне тукландыру һәм асрау шартларын яхшыртмаганда... азрак сөтле токымны күбрәк сөтле токым белән алыштырганда да яхшы нәтиҗәгә ирешеп булмый».

Институт директоры В. Н. Никитин белән сөйләшкәндә, әлбәттә, гыйльми китапларны актарып утырмадык,— мин әлеге фикерләрне күңелемә салып куйдым, директор инде аларны биш бармагы кебек белә,— шулай да әңгәмә вакытында сүз уңаеннан мондый шигырь сыман юлларны телгә алгалап киттек: «Юк икән сөтең, җиленең — мәгънәсе бармы сине сыер диюнең!»

Мин түзмәдем: ни өчен Вологда галимнәре «сөтсез, җиленсез» сыерлар үрчетәләр? Үз-үзләренә каршы килеп, тиешенчә ашатмыйча, 4500 әр килограмм сөт бирә торган сыер көтүе булдырмакчылармы алар? — дип сорадым.

— Үрчетү, баш исәбе мәсьәләсен без хәл итмибез шул. Комплекска исәпләнгән кадәр сыер асрарга кирәк. Ә ул мәсьәләне районның авыл хуҗалыгы идарәсе хәл итә,— диде директор.

«Знамя коммунизма»да терлекләрнең баш исәбен пландагы чамасында саклыйлар, ә менә башка күрсәткечләре алдан исәпләнгәнгә якын да килми. Дүрт ел инде — аз вакыт түгел, бу комплекска проект графигы белән эшләргә вакыт. План буенча һәр сыер дүрт меңәр килограмм сөт бирергә тиеш булса да, нибары ике мең дүрт йөз килограмм гына савып алалар. Аз продукция хуҗалыкны бөлдерә генә, күп азык тотыла, хезмәт җитештерүчәнлеге исә нормадан ике-өч тапкыр кимрәк.

— Пландагы күрсәткечләргә ирешеп булмагач, ниндидер чарасына керешергә кирәк. Баш исәбен киметә төшкәндә, һәр сыердан савымны дүрт мең килограммга җиткереп, пландагыга ирешеп булмыймы? — дип сорадым мин директордан.

— Алай ярамый, җаваплылык мәсьәләсе башка,— диде Никитин.— Сөтне арттыруга караганда баш исәбен арттыру җиңелрәк. Баш санын киметү — югарыдагылардан узып, үзеңчә эш итү, гаеп дигән сүз, савымны үтәп җиткермәү — җитешсезлек кенә. Тырышуын бик тырышкан идек тә, булдыра алмадык, дисең. Монысын кичерәләр, ә менә гаепне гафу итмиләр. Шуңа күрә, сөте булмаса да, баш исәбе бар.

Хуҗалыкка моның күпме зыянга төшүен акчага әйләндереп яки башка экономик күрсәткечләр белән исәпләп күрсәтергә дә мөмкин. Ә менә бу сөт фабрикасының яхшы нәрсә икәнлеген эш белән раслап күрсәтәсе урында, бу рәвешле хурлыкка калуын ничек аңларга? Өстәвенә, селекционер-галимнәр күпме югалта! Терлекләрнең токымын яхшырту эше белән шөгыльләнүче галимнәрнең ваемы баш исәбендә түгел, хәтта бүгенге савымда да түгел, бәлки бик яхшы көтү булдыру, терлекнең генофондын арттыру, аны камилләштерүдә.

Төньяк-көнбатыш фәнни тикшеренү институтына барган чакта мин болай дип тә уйлаган идем: галимнәр, бәлки, кыюлыклары җитеп, үзләренең тәҗрибә хуҗалыкларының һәрберсендә аерым токымлы сыерлар асрый башларлар. Мәсәлән, Куркинода аклы-каралы дигән токым, «Знамя коммунизма»да холмогор сыерлары, Остаховода ярославка токымын гына асрарлар, һәм шуннан инде бу көтүләр нәселдән килә торган иң яхшы сыйфатларын күрсәтерләр. Әмма галимнәрнең кыюлыклары җитмәгән. «Знамя коммунизма» комплексында, кайсы токымның күбрәк сөт бирүен белү өчен, айршир, аклы-каралы, ярославка, кострома, холмогор сыерларын барысын бергә асрыйлар. Хәзер инде аклы-каралы токымны гына калдырырга уйлыйлар. Селекция үзәге хезмәткәрләре холмогор токымын яхшырту эше белән калган тугыз хуҗалыкта шөгыльләнергә тиешләр,— ул хуҗалыкларның иң якыны исә институттан алты йөз километр ераклыкта.

Институтка якынрак фермаларда яхшырак, яңарак нәселле холмогор көтүләрен күреп булмагач, мин Вологда өлкәсенең икенче ягына, Великий Устюг шәһәренә юл тоттым. Биредә алты районда бик күптәннән холмогор сыерлары асрыйлар икән. Кайсына барырга? Сыер башына мең ярым килограмм сөт савып ала торган начар хуҗалыккамы, әллә яхшырак тәҗрибә белән танышып булырдай алдынгыларынамы? Партиянең Великий Устюг шәһәр комитетында беренче секретарь Николай Николаевич Трудов алдынгырак хуҗалыкны күрергә киңәш итте, шуннан инде мин «Строитель коммунизма» дигән совхозны сайладым. Төньяк-көнбатыш фәнни тикшеренү институтының бер хуҗалыгы икән ул.

Биредә бик җентекле, нечкә бер эш белән шөгыльләнәләр: елына биш, җиде мең килограмм сөт бирә торган яхшы сыерлар булдырырга тырышалар икән.

Биредәге көтүне районда иң яхшы дип булмый — елгачыларның «Северодвинец» дигән совхозларында һәр сыердан дүрт мең килограммнан артыграк сөт савалар икән. Әмма яхшы нәселле сыерлар үрчетү эшендә бүгенге нәтиҗәдән бигрәк алдагысы әһәмиятлерәк. «Строитель коммунизма» совхозы иген игә, яшелчә, бәрәңге үстерә, сөт җитештерә, ләкин нәсел эше белән иң соңгы чиратта шөгыльләнә. Һәрхәлдә миндә шундыйрак фикер калды. Дөрес анысы, хуҗалыкта көтүдә селекция эше башкару планы бар. Әмма план ничек тә соң, фермаларда хәл ничек? Җитмеш алтынчы елда, Төньяк-көнбатыш фәнни тикшеренү институты хезмәткәрләре хуҗалык өчен көтүне яхшырту программасы эшләп биргәч, совхоз институтка биш мең сумлап акча түләгән, өч йөз илле өч сыер өч мең килограммнан күбрәк, илле җиде сыер — кимрәк сөт биргән. 1979 елда сыерлар саны алты йөзгә арткан, өч мең килограмм сөт саудыра торганы — ике йөз туксан дүрт, калганнары кимрәк саудырган. Совхоз өч мең килограмм савымлы сыерларның бозаулары белән үзенең көтүен яңарта тора, калганнарын нәселле терлек буларак читкә сата. Шулай да, дөресен әйтеп сөйләшкәндә, аналары бер тапкыр да өч мең килограмм сөт бирмәгән бозаулар асыл товар була ала микән? Яхшы хуҗа андый бозауларны симертеп иткә тапшырса, биредә аларны савым сыерлар көтүенә озаталар. Бәһәсен, нәселле терлек исәбеннән, кыйммәтрәк түләтәләр.

Совхоз директоры Николай Кириллович Алексеевның кабинетында өч күчмә Кызыл байрак бар. Бәхәсләшмибез,— ирешкән уңышлары өчен тапшырганнардыр, ләкин шундый бер сорау туа: совхозны нинди-дер эш нәтиҗәләре өчен мактыйлар икән, нигә төп күрсәткечләрнең берсе булган нәселле терлекнең сыйфатын таләп итмиләр. Мин гафу үтенгән булып, шул хакта Алексеевтан сорадым:

— Нигә яхшы сыерлар асрарга мәҗбүр итмиләр? — дидем.

— Бездән аның башкасын мәҗбүр иттерәләр,— диде директор һәм диспетчерлыктан агымдагы боерыклар китабын китерергә кушты. Анда иң күренекле урынга Великий Устюг район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы А. Казариновның мондый усал гына телефонограммасы теркәлгән иде: «Былтыргы һәм 1 августка ясалган отчетларны чагыштырганда сыерларның баш исәбе киму сәбәпле, һәртөрле чыгымны, шул исәптән мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшыруны һәм хуҗалыкта мал суюны тыям. Һәр сыер өчен персональ җавапка тартылачаксыз. Белгечләрне телеграмма белән таныштырып, кул куйдырырга».

Мондый усал боерыкны үтәми хәлең юк. Совхоз фермаларында отчет өчен иллеләп сыер тоталар. Алар ашаган азыкны игенгә әйләндерсәң, көн саен ярты тонна концентрат китә дигән сүз. Ә хуҗалыкта азык ягы мул түгел, тиешенчә ашатмау аркасында мал-туар үзенең токымына хас генофондын югалта. Селекционер галимнәр совхозга 1980 елда фермаларда биш мең килограммнан артык сөт бирә торган сыерларны егерме проценттан иллегә хәтле арттырырга тәкъдим иткәннәр, асылда исә андый терлек өч процент кына калган.

Яхшы нәселле дип начар тана сыерлар сату ул сөтле көтүне бетерү дигән сүз. Совхоз яхшы бозауларны үзенә алып калып, көтүне ничек тә сакларга тырыша әле, ә башка хуҗалыклар хәтта нәселле яхшы үгез дә юнәтә алмыйлар.

Великий Устюг төбәгендә йөздән артык нәсел үгезенең, уртача характеристикалары буенча, аналары дүрт мең дә бер йөз бер килограмм сөт биргән, майлылыгы 3,85 процент. Нәселле терлек үрчетү, аны сайлап алу кебек махсус мәсьәләләрдә кәгазь һәм каләм осталарының фикере зур авторитет түгел. Шуңа күрә, зур хезмәт, тырышлык куеп,

Куркинодагы бер дигән савым сыер кәтүен булдырган, Төньяк-көнбатыш фәнни тикшеренү институты директоры мәрхүм Алексей Степанович Емельянов сүзләрен китереп китәм. «Биш мең килограмм сөт бирә торган сыерлар үрчетү өчен җиде-тугыз мең килограмм савымлы сыерлардан туган нәсел үгезләре булдырырга кирәк»,— ди ул соңгы гыйльми хезмәтләренең берсендә.

Великий Устюг нәселле терлек берләшмәсенең баш зоотехнигы Таисия Петровна Дмитриева белән шушы күңелсез хәл турында сөйләшкәндә мин:

— Нигә шундый начар үгезләр тотасыз соң? Алардан ни өмет? — дип сорагач, Дмитриева авыр гына сулап:

— Ә яхшыларын каян аласың? Әйтегез, дөнья читенә хәтле булса да барып алабыз. Андый мал юнәтү елдан-ел кыенлаша бара,— дип җавап бирде.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик: Великий Устюг районы соңгы вакытта сөт буенча 1970 елгы дәрәҗәне уза алмый, бөтен Вологда өлкәсе исә савым сыер көтүләренең продуктлыгы буенча... 1968 елгы дәрәҗәгә җитәргә тырыша.

Минем Вологда якларына беренче генә килүем түгел. Бу килүемдә өлкәдәге сыер фермалары белән танышып чыккач, шундый тәэсир калды: әйтерсең, мал-туарны атаклы оста терлекчеләр карамый, бәлки үз һөнәрен оныткан, начар эшләве өчен уңайсызлана белми торган ваемсыз, ялкау кешеләр шөгыльләнә. Эшләр тагын да шулай барса, дүртбиш мең килограмм сөт бирә торган холмогор көтүләре турында хыялланy түгел, суыкка чыдамлы бу токымны «Кызыл китап»ка теркәргә туры килмәгәе!

Зоотехник культура түбән, фәнни ярдәм аз булганда, хуҗалык мәсьәләләрендә ялгыш күрсәтмәләр биреп торганда бернинди ферманың да эше алга бармый. Бигрәк тә терлекчелекне промышленность нигезенә күчергәндә, терлекләрне эре комплексларда асраганда югалтулар аеруча зур. Комплекс эрерәк булган саен эштәге пөхтәлек, төгәллек тә зуррак булырга тиеш. Хәзерге сөт фабрикалары барыбер сыерларны элеккечә, крестьян йортындагы кебек үк яхшы итеп карарга кирәклегеннән коткармый. Кызганычка каршы, җәмәгать терлекчелеген промышленность нигезенә күчерү практикасы моның киресен күрсәтә — күп хуҗалар, белгечләр комплексны мал карау мәшәкатеннән котылу чарасы итеп күрәләр.

Великий Устюгтан туп-туры Архангельск өлкәсенә дә сугылып китәргә җай чыкты. Холмогор сыерлары үзләренең туган якларында ничек яшиләр икән? Машина белән тар гына тайга урманын һәм кечерәк бер ямь-яшел уйсулыкны узгач, Котлас районының Карл Маркс исемендәге колхозына килеп җиттек. Күрешеп-исәнләшкәч, юл хәлләре, гөмбә, ау һәм башка шундый вак-төяк турында сөйләшеп утырганда кызыклы гына бер кәгазь — колхоз идарәсе беркетмәсеннән бер күчермә белән таныштык.

«Колхозның дәүләткә өч миллион сумнан артык бурычы барлыгын искә алып, Котлас авыл хуҗалыгы идарәсенең техник советыннан Карл Маркс исемендәге колхозда сигез йөз баш сыер асрарлык комплекс төземәү мәсьәләсен каравын үтенәбез»,— диелгән документта. Идарә утырышында бригадир В. А. Щекин, баш агроном Г. Н. Оверчук, баш экономист А. С. Кучина, тракторчы В. Д. Поповлар сүз алып сөйләгәннәр һәм барысы бер тавыштан «кыйммәтле сөт фабрикалары кирәк түгел» дигән нәтиҗәгә килгәннәр.

Архангельск өлкәсенең Карл Маркс исемендәге колхозында әнә нинди принципиаль кешеләр бар икән! Бу төзелеш инде байтак баскычларны: район, өлкә, башкала инстанцияләрен узган, проект, карар һәм башка күрсәтмәләргә кертелгән, ә болар «кирәк түгел» диләр. Заман

таләпләренә җавап бирерлек сөт фабрикасы төзү мәсьәләсе инде моннан ун ел элек үк кузгатылган, «Росгипросельстрой»ның баш институтында ул комплексларны урнаштыру буенча махсус схемада каралган, РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгы «эшкә ашыруга» кабул иткән. Исәп-хисап яклары экспертлар кулы аша узган, тиешле җитәкчеләр аны хуплаганнар, колхозга бурычка ике миллион ярым акча биргәннәр.

Карл Маркс исемендәге колхозның идарә членнары сөт хуҗалыгын индустрияләштерү, сыерларны машиналар белән җиһазланган якты, яхшы биналарда асрау кебек кызыктыргыч адымнан ни сәбәпле баш тарталар соң? Иң элек — азык кытлыгы. Хуҗалык үзе төньяк җирдә саналып, дәүләткә ашлык сатмаса да һәм сыер башына биш гектардан артык басу һәм болын-көтүлек җире туры килсә дә, терлекләр ачлы-туклы яши. Сөт мәсьәләсен инде әйтәсе дә юк. Узган бишьеллык азагында һәр сыердан ике мең сигез йөз егермешәр килограмм сөт сауган булсалар, хәзерге көндә ике мең дә илле килограмм чамасы көтәләр. Алдагы көндә хәлләрнең яхшырасына өмет күренми. Колхозның көтүе начар, бер мең бер йөз илле баш сыерның дүрт йөз илледән артыгы иң күп савымлы сигезенче бозау чиген узган инде. Ә утыз сыерны бөтенләй саумыйлар, аларны изге терлек урынына гына асрыйлар. Проектта көтүлек булдыру мәсьәләсе каралган, бик күп мелиорация эшләре башкарасы бар, ә азык базасын икенче чиратта гына булдырырга планлаштырганнар. Колхозчылар комплексның чиратлап, ике йөз башлап төзелүен телиләр, әмма проектта алай каралмаган, эшне бөтенләетоташы белән башлаганнар, күрәсең. Объектта нибары ике-өч кенә кеше эшләгәч, комплексны кайчан төзеп бетererләрдер? Мондый хәлдә колхозга шундый зур комплекс, чыннан да, нигә кирәк, соңыннан оятын кая куеп бетерерсең?!

Әле Сөтчелек һәм болын-көтүлек хуҗалыгы буенча төньяк-көнбатыш фәнни тикшеренү институтында һәм селекционерлар, отчетта әйтелгәнчә, елына дүрт мең сигез йөз килограмм савымлы сыер көтүе булдыра торган «Строитель коммунизма» совхозында чагында ук фермаларның хәлләре турында уйлаганда берәр саксыз сүз ычкындырып галимнәрнең хәтерен калдырудан курыккан идем. Заманында инглиз язучысы Джонатан Свифт галимнәрнең кояш нуры аерып алуларыннан көлеп язган булган. Ә хәзер һәрбер мәктәп баласы да кояш энергиясенең кадерле икәнен белә, шуңа нигезләнеп, үсемлекләр фотосинтезы дигән махсус бер фән тармагы барлыкка килде. Фән өчен ирешеп булмастай нәрсә юк. Бәлки, галимнәр генетиканың бөтен серләренә төшенгәннәрдер, начар терлектән яхшы сыер үрчетү хикмәтләрен беләләрдер?

Архангельск өлкәсендәге Карл Маркс колхозы — гадәттәге гади бер хуҗалык, ул дәүләткә ит, сөт тапшырып торырга тиешле. Нигә бу колхозның фермаларында сөтсез сыерлар асрыйлар икән соң? Крестьян халкы борын-борыннан әйтә килгән бит: «Сигез сыер асраганчы симез сыер асра»,— дигән. Кайбер урыннарда сыерны җир ашлый торган тиресе өчен генә асраганнар, имеш. Төньякта терлек азыгы мул түгел, крестьян кырдагы уңыштан бигрәк, абзардагы сыерына өмет баглаган. Изге бер нәрсәгә табынган кебек, аны бик кадерләп караган. Отчеттагы сан өчен генә күп терлек асрауны бернинди акыллы фикер белән дә аклап булмый. Халык мәкальләрен җыючы Владимир Иванович Даль «Корова на дворе, харч на столе», дигән мәкальне әнә шул төньяк җирләрендә язып алмаган микән? Безнең татар халкы да гомер-гомергә мал асраган һәм сыерны мактап: «сыеры барның сые бар»,— дигән.

Шушы күңелсез хәл турында сөйләшеп утырганда колхоз председателе Геннадий Николаевич Петров:

— Миңа нишләргә кала соң инде? — дип киңәш сорады.— Сыер көтүгә бер эләккәч, котылып кара син аннан! Тешсез булса да, бер генә

имчәгеннән сөт бирсә дә, рөхсәтсез бракка чыгарып булмый аны. Колхоз яраксыз сыерларны базарга чыгарып сатмый, закон рөхсәт итсә дә, кагыйдә буенча — юк, иткә тапшырыйм дисәң, өлкәдән рөхсәтең булмаса, бойняга якын да китермиләр. Өлкәдәге башлыклар синең көтүеңдәге сыерларыңның ниндилегенә әһәмият итми, бары тик баш исәбен генә belә. Сан өчен манекен ясатып куйдырсаң да була.

Азык базасы, яхшы көтү булдырмыйча сөт фабрикасы төзеп, күпме колхоз, совхозның авызы пеште, ә шулай да бу хатаны һаман әле кабатлыйлар. Ил буенча промышленность комплексларының кырык процентында өч мең килограммнан артык сөт савып алалар. «Ленсовет» комплексында 1975 елда эшли башлаганнан бирле өч мең тугыз йөз килограммнан ким сөт саумыйлар. Владимир Ильич исемендәге сөт фабрикасында савымны биш мең дүрт йөз утыз алты килограммга җиткергәннәр. Катлаулы, кыйммәтле комплексларның калган алтмыш процентында савым өч мең килограммнан да ким.

Россия Федерациясенең колхоз, совхозларында һәм башка предприятиеләрендә промышленностька нигезләнгән 985 сөт фабрикасы эшли. Аларда алты йөз сиксән өч мең баш сыер, ягъни савым көтүенең 4,16 проценты асрала. Исәпләп карыйк: бер сыерлык урынның бәясе мең ярымнан ике мең сумга кадәр төшә. Димәк, сөт комплексларын булдыруга әллә ничә миллиард акча тотылган дигән сүз. Ә килере әле аз, бу куәтле фабрикалар продуктлылык ягыннан гади фермалардан чак-чак кына алда баралар.

Россиянең колхоз һәм совхозларындагы промышленность комплексларындагы сыерларның баш исәбе унберенче бишьеллыкта бермә-бер артырга тиеш. Хуҗалыкларда иң беренче, иң кирәкле шартлар тудырмыйча — яхшы азык базасы, сөтле сыерлар, тәҗрибәле оста терлекчеләр булдырмыйча, болай баш исәбен арттырудан гына зур файда өмет итеп булыр микән?

Тик бәла бүгенге көндә савымның кимлегендә, гади фермалар һәм промышленность комплексларының продуктивлылыгы түбән булуында гына да түгел. Малның нәсел сыйфатына әһәмият җитмәү, баш исәбен генә арттырырга тырышу һәм көтүләрнең сыйфаты турында аз кайгырту терлекләрнең нәселен яхшырту эшенә зур зарар китерә. Кызганычка каршы, хәтта нәселле терлек хуҗалыкларының күбесендә дә эшкә алдан күреп эш итә белә торган акыллы селекционер-галим түгел, бәлки «бүгенгесе кадерле» дип, иртәгә булачакны күрми торган практик-рационалистлар юнәлеш бирә. Дөрес анысы, терлекчелектәге нәсел эше буенча Бөтен Россия фәнни-производство берләшмәсенең генеральный директоры Владимир Викторович Чистяков минем белән сөйләшкән чакта, эшләр яхшыга таба бара, диде. Яңа селекция үзәкләре барлыкка килгән, Мәскәү янындагы Лесные Поляны дигән совхозда Бөтен Россия күләмендәге нәселле терлек институты эшли башлаган, көтүләрдә саф токымлы сыерлар артканнан-арта бара икән.

Чыннан да, уйлап карасаң, моңарчы булмаган һәм булдырып булмастай эшләр эшләнгән. Совет илендә дөньяда беренче тапкыр нәсел орлыгы саклый торган махсус генетик банкалар ясалган. Ул банкаларда сыек азот эчендә йөз сиксән өч градус салкында иң яхшы үгезләрдән алынган йөз илле миллион доза орлык саклана. Аерым галимнәр генә түгел, бәлки колхоз, совхозларда сыер көтүләре белән эш итүче зоотехник-практиклар киң масштабта селекциянең «иң яхшыга — иң яхшысы» дигән төп кагыйдәсен гамәлгә ашыра алалар.

Бер кеше гомере эчендә әнә ничаклы юл үтелгән. Талантлы совет биологы Илья Иванович Иванов утызынчы елларда терлекләрне ясалма

рәвештә буазландыру ысулын таба (хәзер инде бу ысул бөтен дөнья күләмендә гамәлгә кергән). 1947 елда И. И. Иванов шәкерте һәм фикердәше академик Виктор Константинович Милованов лабораториясендә галимнәр мондый бер хикмәтле нәрсә ачалар: әгәр нәсел орлыгын туңдырып, сыек азотта сакласаң, иң яхшы нәсел үгезләренең орлыгын запаска әзерләп, аны берничә ел үткәч, әлеге үгез һәм сыерларның бозаулары ата-аналарының яхшы сыйфатларын тагын бер тапкыр раслап күрсәткәч кенә файдаланырга мөмкин. Моның белән зоотехник-практиклар алдында моңарчы булмаган зур бер мөмкинлек — сөт буенча гына түгел, бәлки гәүдә-сан төзелеше, машина белән савуга җайлашканлыгы буенча, хәзерге промышленность комплексларындагы шартларга чыдамлыгы буенча да ниндилеген алдан ук күз алдына китереп, яхшы сыерлар үрчетү мөмкинлеге туа.

Инде утыз еллап вакыт узды, ә ферма һәм сөт фабрикаларында нинди сыерлар бар соң хәзер? Сөте белән сөендерерлекләре күп түгел. Хәтта нәселле терлек үрчетүче хуҗалыклар да, мал-туарның сыйфатын яхшыртасы урында, баш исәбен генә кайгырталар. Хак эш һәркайда үзенә юл ярып чыга, диләр диюен. Ярса, тизрәк ярсын иде инде. Эшләнгән кадәресен, эшләнергә тиешлесе белән чагыштырып караганда, хәтта нәселле терлек хуҗалыкларында да селекция эшен яхшырту, промышленность нигезендәге комплексларда, гади фермаларда асрарлык яхшы савым көтүләре булдыру өчен җитәрлек чаралар күрелми. Бу кимчелекләрне азык кытлыгы белән генә акларга тырышу дөрес булмас. Мул азыкта начар сыерлар асраганчы җитәр-җитмәс азыкта яхшы сыер тоту хәерлерәктер!

Россия Федерациясендә дәүләт һәм колхозлар карамагында йөз дә унике нәселле терлек заводы, йөз дә сиксән алты нәселле терлек совхозы бар. Моның өстенә, ике мең өч йөз кырык дүрт колхоз, совхоз һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиесенең үзләрендә нәселле терлек фермалары бар. Шулай да Вологда өлкәсендәге, план төзеп, терлекләргә агымдагы контроль бонитировка ясап кына селекция эшен төгәлләгән «Строитель коммунизма» совхозы бу яктан бердәнбер түгел. Нәселле терлек совхозларының кырык процентында савым сыерлары машина белән савар өчен сайланмаганнар. Нәселле терлек фермаларындагы үгезләрнең дүрттән бере генә токым сыйфатын яхшырта. Савым сыерларын яхшырту мөмкинлеге теоретик яктан күп тапкыр артса да, практик нәтиҗәләрдә үзгәреш бик аз әле.

Сөт бөтен кешегә кирәк. Бигрәк тә яңа промышленность үзәкләре, калалар, поселоклар үсеп чыккан төшләрдә сөт-майга ихтыяҗ зур. Безнең Татарстан — шундый олы эшләр кайнаган төбәкләрнең берсе. Бөгелмә, Алабуга шәһәрләре белән беррәттән, Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Актүбә, Шөгерләр илгә нефть бирүче яшь калалар булып үсеп киттеләр. Шөгер, Баулы, Ромашкиноларда беренче нефть фонтаннары бәреп чыкканнан соң узган кырык еллап вакыт — әллә ни зур ара түгел. Промыселлар җир астыннан ел саен йөз миллион тонналап байлык алалар, Татарстан нефтьчеләре бу төбәктә беренче буларак ике миллиард тонна «кара алтын» чыгардылар. Нефтьне җир асты катламнарыннан эшчеләр, инженерлар, галимнәр чыгара, аларның гаиләләре бар. Элек иген игеп, мал-туар асрап, үз тамагын үзе туйдырган авыл халкы яшәгән төбәктә хәзер ярты миллионлап кеше арткан, хәзер шул кадәр халыкны ашату бурычы дәүләт өстенә төшкән дигән сүз.

1960 елда Түбән Кама нефть-химия комплексы салыначак урынга беренче казык кагыла. Хәзер анда 140 мең кеше яши. 1969 елда КамАЗ автогиганты, яңа Чаллы төзелә башлый, һәм ун ел эчендә ул 350 мең кешеле шәһәргә әйләнә. Шулай итеп, Кама аръягы төбәгендә тагын күпме халык арта.

Яңа калалар башка төзелешләрдән яки промыселлардан күчеп килүчеләр исәбенә генә артмый. Мондый очракта авылның күп кенә эшчәннәре шәһәр кешесе булып китә. Аларны кем туйдырыр соң?..

Конкрет экономик һәм социаль шартлар, киң күләмдә һәм кызу темплар барган төзелешләр, промышленностьның яңа тармаклары авыл хуҗалыгын бик яхшы итеп җиһазланган промышленность җирлегенә күчерергә кирәклеген күрсәтте. Соңгы елларда колхоз, совхозларда, бигрәк тә шәһәр һәм эшче поселокларына якын җирләрдә утыз зур комплекс төзелде. Аларда егерме биш мең баш сыер савалар. Зур эш башкарылган. Әмма комплекс җитештерү — мәсьәләнең бер ягы гына әле ул. Хезмәтнең бөтен хикмәтен белеп эшләргә өйрәнү — икенче нәрсә. Монда мал-туар караудагы буын-буыннан килгән байтак кына иске гадәтләрдән ваз кичәргә туры килә. Сөт күп булсын өчен, терлекчелекне интенсивлаштыруга бәйле бик күп яңа кагыйдәләрне өйрәнергә кирәк иде.

Кызганычка каршы, сөт комплексларының беренче еллардагы эше моның киресен күрсәтә. Унынчы бишьеллыкның соңгы елында, республика буенча уртача күрсәткечләр белән чагыштырганда, бер сыердан савып алган сөт колхоз фермаларында өч килограммга, совхозларда унбиш килограммга кими. Иң күп сөтне Чаллы янындагы «Гигант» совхозы бирә, ләкин анда да һәр сыердан елга нибары 3062 килограмм гына савалар. Терлекчелекнең рәтен белүче зоотехник-белгечләр, әлбәттә, мондый «уңыш» өчен мактамыйлар. Совхозның ике мең баш сыеры булып, автомобиль төзүчеләр өчен ел саен алтмыш мең центнер сөт биреп барса да, савым шул чама гына булганда, хуҗалык сөтчелектән табыш күрми. Хәер, шулай булмый хәле дә юк, комплекста бер сыер урынының бәясе ике мең сум тора. Бу чыгым, һәр сыер дүрт мең ярым килограмм сөт биргәндә генә үзен аклый.

Йомгак ясап, тагын берничә санга тукталып китик. Статистика күрсәткәнчә, соңгы елларда безнең республиканың колхоз-совхозларында сыер көтүләрен арттыру буенча байтак эш башкарылган. 1976 елда республиканың колхоз һәм совхозларында 377,6 мең баш сыер булган, хәзер — 413 мең баш. Бу көтүләрдә иң күбе — холмогор токымы, калганнары — бестужев һәм башка токымнар. Азыкның җитәрлек булмавы, көтүлек җир сайлаудагы җитешсезлекләр, гомумән, эшнең бөтен нечкәлекләрен белеп җиткермәү аркасында иң яхшы нәселле сыерлар да сөтне елдан-ел кимәтә баралар. 1970 елда һәр сыердан 2748 килограмм савым алынган, ун елдан соң, савым 2388 килограммга төшкән. Хуҗалыклар сөт җитештерүдән ел саен зарар гына күрәләр. Нәтиҗәдә, сөт җитештерүнең сөенеченнән бигрәк көенече күбрәк килеп чыга. Нишләргә соң, бу зыяннан ничек котылырга?

Дөрес, республикада сөт җитештерү арта бара, әмма бу — сыерларның баш саны ишәюе хисабына гына ирешелгән уңыш. Эшнең бөтен ягын төптән уйлап, осталык бәрабәренә ирешелгән җиңүнең борынборыннан макталып килгәнен онытырга ярамый.

— Яхшы савым сыер көтүе булдырырга, мал-туарны яхшырта төшәргә яки яңа токым китереп чыгарырга теләүче селекционер галим идеаль эш шартларын ничек итеп күз алдына китерә?

Мәскәү янындагы Лесные Поляныда нәселле терлек эше буенча фәнни тикшерену институтында эшләүче, холмогор токымы буенча селекция үзегенең җитәкчесе, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Мария Макаровна Сенаторова белән минем әңгәмәм әнә шундый, бер караганда бүгенге хәлләрдә эшкә ашырып булмастай табигый бер сораудан башланып китте.

— Иң элек профессиональ фәнни хезмәт күрсәтелсен иде — селекционер үз алдына иң зур максатлар куеп эшли алсын иде: әйтик, ун мең килограмм сөт савып алу, сөтнең куелыгы дүрт бөтен дә уннан

биш процент; терлекләрнең баш исәбен, рацион һәм азык житештерүне дә үзе хәл итсен иде.

— Дүрт ярым процент куелык күбрәк булмасмы соң?

— Күп түгел. Шулай булганда гына очраклылыктан котылырга мөмкин. Мәсәлән, химиклар төп компонентларны, технологик регламент, һәртөрле катализатор, эреткечләрне үзләре билгеләләр. Ә нигә селекционер-зоотехниклар шулай эшләмәскә тиеш?

— Хәзер шулай түгелмени? — дип сорадым мин.

— Алай түгел шул,— диде Мария Макаровна.— Башта ит, сөт, аннары гына нәселле терлекне планлаштыралар. Безнең төп нигез «Лесные Поляны»дагы нәселле терлек заводы. Бик яхшы хуҗалык ул, алтын куллы кешеләр эшли анда, сигез Хезмәт Герое гына бар. Уртача савым — дүрт мең дә дүрт йөз килограмм. Ул заводта дүрт йөз утыз җиде сыер биш мең килограмм сөт бирә. Иң әһәмиятлесе — яхшы үгезләр үстерү; аларны бала караган кебек карарга кирәк. Беләсезме, бозауга алты йөз килограмм сөт эчерергә кирәк, ярты кружка да ким булмасын. Ә район сөт сорый, иртүк директорга шалтыраталар: «Сөтне кая куясың, нишләтәсең?» — диләр. Директор да җансыз кеше түгел бит, бирешергә мәҗбүр була, бозаулар өлешенә керә. Әнә шулай, бүген берничә литр сөтне кысып, иртәгә үсеп җитәчәк көтүне харап итәбез, нәселле сыерлар төркеме елына ике йөзләп үгез бозау бирә, тик шуның яртысын гына колхозларга сатарлык итеп үстерә алабыз.

Шул минутта Великий Устюгтагы Таисия Петровна Дмитриеваның уфтанып: «Эх, яхшы үгез бирсәләр, җир читенә хәтле дә барып алыр идек!» — дигәне искә төште.

Институт конторалары белән нәселле терлек заводы янәшә генә, тәрәзәләре яшел аллея аша бер-берсенә күренеп тора. Селекциянең бик күп сер-хикмәтләрен белүче оста терлекчеләр эшләгән шул заводка иң элек ит, сөт планлаштыралар, аннары асыл затлы терлек үстерү программасы китереп куялар!

Галимнәр — бик талымлы, нәзберек халык, теге хәл, бу хәл белән исәпләшмәстән, таләпне иң зурдан куялар.

Дөресен генә әйткәндә, мин Мария Макаровна Сенаторова сөйләгәннәр чын түгелдер дип, ышанып та бетмәгән идем. Мәгәр бөтенесе дә рас булып чыкты. Әлеге завод бик атаклылардан саналса да,— ул безнең илдәге иң беренче совхозлардан, анда Владимир Дмитриевич Бонч-Бруевич директор булып эшләгән,— селекционерларның бердәнбер таләбен дә үтәми — терлекләрне тиешенчә тукландыра алмый, азык җитми. Унберенче бишьеллыкта савым сыерларны тагын өч йөз башка арттырырга планлаштырганнар, ә азык табу мәсьәләсен зирәк экономистларның берсе дә күз алдына китереп карамаган. 1985 елда бер мең дә сигез йөз тонна печән кирәк булачак, план буенча исә мең ике йөз тонна гына күздә тотыла. Силос тугыз мең дүрт йөз илле тонна кирәк булса, планда ике мең тонна кимрәк куелган. Эшнең башында ук ярым буш утлыкларга исәп тотканда генофонд, көтүнең генетик куәте дигән нәрсәне ничек яхшыртмак кирәк?!

Мин, заводны яклап:

— Аларның баш исәбен арттыру буенча программалары зур. Таләпчәнлекне бераз киметә төшегез! — дигән идем, Мария Макаровна үз сүзен куәтләп:

— Күпме киметергә мөмкин, киметүнең дә чамасы-чиге бар бит,— диде.— Һәммәсе дә баш исәбен генә кайгырта. Россия Федерациясенең колхоз һәм совхозларында уналты миллион алты йөз кырык мең баш сыер елына утыз дүрт миллион тонна сөт бирә. Моны башкачарак та эшләп була бит: сөтлерәк сыерларны азрак асрарга мөмкин. Миллионлаган сөтсез сыерларга күпме азык тотыла! Шулар өчен миллионнарча гектар җиргә азык чәчәргә, ферма, комплекслар төзергә, меңләгән

савымчы, терлекче тотарга кирәк. Сөтнең куелыгын да онытмыйк. Моннан ун-унбиш ел элек өч бөтен уннан сигез, уннан тугыз процент куелык норма булып санала иде, хәзер стандарт — өч бөтен уннан алты процент.

— Болай итеп галимнәр генә исәпли, практиклар башкача исәп йөртәләр. Алар көтүне ишәйтәләр,— дип каршы төшкән булдым мин.

— Нигә теоретиклар гына? Ленинның аграр мәсьәләләр буенча хезмәтләрен укып карагыз...

Мәскәү янындагы Лесные Поляныдан кайткач, мин Ленин томнарын актарып, менә мондый сүзләр укыдым: «...средстволар җитешмәгәндә, терлек азыгы җитешмәгәндә, терлекнең сыйфаты начар, биналар һ. б. начар булганда терлекне бик тырышып карау-тәрбияләү дә хезмәтне файдасызга әрәм итү белән бер» [1].

Бу фикерләр, безнең гасырның башында ук язылган булсалар да, бүгенге көндә дә актуаль яңгырый.

Шулай да өметсезлеккә бирелмик. Климент Аркадьевич Тимирязев, студентларга үсемлекләрдәге фотосинтез турында лекция сөйләргә килгәч, Свифт көлке итеп язган эш белән шөгыльләнәм, дигән. «Бар ашаган азыгыбыз ул... кояш нурлары консервысы» дип әйткән сүзләре дә бар. Ленинградлылар аклы-каралы токымны чит илдән кайтарткан голштинофризлар белән кушып яхшыртырга тырышалар. Горький өлкәсендә чыдамлы ярославль токымын аклы-каралы токым белән кушалар. Эссе Молдавия, Казагыстанга һәм Идел буе зоналарына төньяктан холмогор сыерлары кайтартканнар, көтүләрдә инде Даниядән кайтарткан токым белән кушканнан туган таналар утлап йөри...

Өметне өзмик, килер бер көн — тырыш селекционерлар шундый асыл токымлы сыерлар китереп чыгарырлар — шулар тәннәренә кояш энергиясен сеңдереп, аннан сөт, каймак, май ясарлар. Ул көн килер. Ә хәзергә савым сыер көтүләре белән ныгытып эшләргә, тере җан ияләрен үзебезнең мөмкинлекләргә җайлаштырып азапланмаска, бәлки үзләрен вакытында туйганчы ашатырга, эчертергә, яхшыларын сайлап савым көтүләренә җыярга кирәк. Ул чагында инде холмогор сыерларын да теге дип, бу дип яманларга туры килмәс. Салкынга чыдам, азыкка талымсыз булса да, авыруларга бирешмәсә дә, тиешенчә тәрбияләмәсәң-карамасаң, нинди генә токым да сөенеч урынына көенеч кенә китерер.

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 13 том, 183 бит.

Флүн Мусин

# ДУСЛЫК, ТУГАНЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

Олы елгаларның тарихы да зур. Әгәр алар телгә килсәләр, безгә бик күп нәрсәләр хакында сөйли алырлар иде. Чөнки гасырлар дәвамында күп вакыйгаларның шаһиты булганнар алар...

Шундый бай тарихлы елгаларның берсе — чал Идел. Әйе, аңа үз гомерендә күпне күрергә, күпне кичерергә туры килгән. Ул җирле халыкларның үз изүчеләренә һәм чит ил басып алучыларына каршы канлы көрәшләре шаһиты булган. Гасырлар дәвамында бик күп кан һәм күз яше түгелгән Идел буйларында. Шул ук вакытта ул үз ярларында яшәгән халыкларның дуслыгы тууын һәм ныгуын да күргән... Биредә әнә шул дуслыкның кайбер сәхифәләренә күз ташлыйсы, аның «җепләрен» күзаллыйсы килә.

Идел буенда яшәүче халыклар дуслыгының тамырлары ерак үткәнгә китә. Идел буе Болгар дәүләте (X—XIV гасырлар) җирлеге дә моңа якты мисал була ала. Тормыш шартларының уртаклыгы һәм үзара тыгыз аралашып яшәү бабаларыбызның тормыш-көнкүрешенә һәм рухи дөньясына, дөньяга карашларына һәм гореф-гадәтләренә тирән эз салган. Болар барысы да иң әүвәл Идел һәм Урал буенда яшәүче халыкларның телендә чагылыш тапкан. Мәсәлән, аларның тел тарихын өйрәнү нигезендә борынгы Болгар заманында хәзерге татар, чуваш, мари, мордва, удмурт һәм беркадәр башкорт халыкларының бабаларында бер төрле дини-мифологик карашлар комплексы булуы ачыкланган[1].

Үзара бәйләнешне һәм йогынтыны ачу ягыннан тагын Идел буе һәм Урал буе халыкларының күпгасырлык материаль культурасы, бигрәк тә декоратив сәнгате зур әһәмияткә ия. Дөрес, бу сәнгатьне чагыштырма-тарихи планда өйрәнү эше әле башлана гына. Әмма бу юнәлештәге беренче тәҗрибәләр[2] үк халыкларыбызның күпгасырлык сәнгать тарихында (аларның чигүләрендә, тукыма бизәкләрендә, баш киемнәре һәм милли аяк киемнәре мозаикасында, торак орнаментында) бик борынгыдан килә торган уртак сыйфатлар булуын күрсәтә.

Халыкларыбызның тарихи язмышлары һәм яшәү шартлары уртак булу аларның эш-хәрәкәтләрендә дә якынлыкны, бердәмлекне тудырган. Бөек Әтил (борынгы Кенчыгышта Иделне шулай дип атаганнар) бу халыкларның эчке һәм тышкы дошманнарга каршы бергәләп көрәшүләрен күп тапкырлар күргән. Хәзерге Калинин өлкәсендәге Волговерховье авылы янындагы кечкенә чишмәдән башланып, тора-бара күпсанлы кушылдыклары исәбенә мәһабәт су юлына әверелгән Идел кебек, аның ярларында яшәүче халыкларның да дуслыгы гасырдан-гасырга үсә, көчәя килгән. Бу дуслык еш кына авыр сынауларга да очраган, әмма алардан тагын да чыныгыбрак кына чыккан.

Идел һәм Урал буйларында яшәүче милләтләр дуслыгының һәм аларның азатлык өчен кулга-кул тотынып көрәшүләренең иң күркәм мисалларыннан берсе, әлбәттә, Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе. Ул бу регионда

---

[1] Тезисы докладов итоговой научной сессии ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН СССР за 1972 год. Казан, 1973. 47 бит.

[2] Авижанская С. А., Бикбулатов Н. И., Кузеев Р. Г. Декоративное-прикладное искусство башкир. Уфа, 1964; Ф. Х. Валеев. Орнамент казанских татар. Казань, 1969; Т. А. Крюкова. Удмуртское народное изобразительное искусство. Л., 1973.

яшәүче халыкларның хаким сыйныфларга каршы иң куәтле чыгышларыннан берсе булды. Пугачев армиясендә иңгә иң торып руслар, татарлар, башкортлар, чувашлар, марилар, мордвалылар, удмуртлар керәште. Баш күтәрүчеләрнең массовый батырлыгыннан тыш, бу сугыш Пугачев хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләренә әверелгән күп кенә милли геройларны да тудырды. Башкорт Салават Юлаев, татарлар Бәхтияр Канкаев, Мәсгут Гомәров һәм башкаларның исемнәре халык хәтерендә буыннан-буынга күчеп яши.

Шулай итеп күп сынауларны үтә-үтә, ленинчыл идеяләр белән сугарылып, бу дуслык халыкларыбызны Бөек Октябрьга алып килде, Совет власте елларында исә ул сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелде.

Идел һәм Урал буенда яшәүче халыкларның тарихи язмышларындагы уртаклык аларның поэтик иҗатында да ачык чагылды. Чынлап та, безнең әкиятләрдә, риваятьләрдә, җырларда аваздаш моментлар шактый. Алардагы куаныч һәм кайгы хисләре уртак, идеаллар һәм теләкләр бердәй. Мәсәлән, Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе бу халыклар фольклорында шактый киң гәүдәләнгән. Аның турында төрле телләрдә җырлар, легендалар, әкиятләр туган. Аларда изелгән һәм кимсетелгәннәргә азатлык китерүче Пугачевка дан җырлана. Төрле милләт крестьяннарының бу юлбашчысы җәзалап үтерелгәннән соң туган тирән кайгы татар бәетләрендә, мордвалыларның «Пугачев турында җыр»ында, удмурт әкияте «Ул Пугачев иде» дә, «Пугачевның үлеме» диган чуваш җырында һ. б. ачык чагыла. Салават Юлаев турындагы башкорт җырлары да шундый ук хисләр белән сугарылганнар. Пугачевны халык патшасы дип данлаудан тыш, фольклор әсәрләрендә аны төрле милләт кешеләренең юлбашчысы итеп күрсәтүгә дә басым ясала. Мордва җырында, мәсәлән, Пугачев «казакларны да, русларны да, мукшыларны да җитәкли, эрзяннарны һәм татарларны да үзе артыннан чакыра» диелә.

Мәгълүм ки, крестьяннар восстаниесен бастырганнан соң патша хөкүмәте халык хәтереннән Пугачев исемен тулысынча сызып ташларга тырышты. Әмма ул үз теләгенә ирешә алмады. Инде бер тапкыр азатлык тәмен татып караган халык массалары элеккечә коллыкта яшәргә теләмәделәр. Алар Пугачев заманын яңадан кайтару, аның кебек яңа юлбашчы табу турында хыялландылар, үз теләкләрен яңа җырларда һәм легендаларда чагылдырдылар. Бер татар җырында болай җырлана:

> **Пугачев патшаны күрсә идең,**
> **Алларыннан буй бөгеп үзса идең.**
> **Аргамак менеп, дан тотып,**
> **Җаек яуларында йөрсә идең.**

Идел һәм Урал буйларында яшәгән халыкларның мондый уй-хыяллары аларны алга табан да изүчеләргә каршы ачыктан-ачык көрәшкә рухландырды. Чуваш һәм мари крестьяннарының 1842 елгы Әкрам восстаниесе, рус һәм татар крестьяннарының 1861 елгы Бездна восстаниесе, шул ук елда Мордовиядә булган Кәнде восстаниесе шундый мисалларга керә.

Бу чыгышларның башында торучыларның образлары халык хәтеренә нык кереп кала һәм яңадан-яңа җырлар, хикәятләр, риваятьләр тууга сәбәпче була. Мәсәлән, чуваш фольклорында Әкрам восстаниесендә катнашучылар, аның җитәкчеләре, аерым алганда, Степан Палатей һәм Василий Григорьев турында күп кенә риваятьләр һәм хикәятләр сакланган. Ә Бездна восстаниесе бер төркем рус һәм татар фольклоры әсәрләрендә чагылыш таба. Аларда бу чыгышның күпмилләтле характерына басым ясала. Бер рус халык хикәятендә Антон Петров янына «30—40 яшьләрдәге мужиклар, руслар, татарлар һәм чувашлар да киделәр. Аларның телләре төрле булса да, моңнары бер иде», диелә. Төрле милләтнең изелгән кешеләре Антон Петровта үз мәнфәгатьләре турында кайгыртучыны күрделәр. Шунлыктан Петровның җәзалап үтерелүе алар өчен уртак югалтуга, уртак кайгыга әверелде. Татар халкының бер хикәятендә хатын-кыз исеменнән болай сөйләнелә: «Антонны атып үтергәч, без ирем белән Бездна барып килергә җыендык. Мин үземнең иң әйбәт күлмәгемне кидем. Ирем, моны күргәч, ачуланып болай диде: «Кая син болай җыендың? Бәйрәмгә барабыз дип уйлыйсыңмы әллә? Анда бит халык елаучысы Антонны үтерделәр! Нинди кайгы! Алыштыр күлмәгеңне тизрәк!»

*
* *

Егерменче гасыр Идел һәм Урал буе халыкларының тарихи үсешендә һәм үзара мөнәсәбәтләрендә яңа этапны башлап җибәрә. 1905—1907 еллар революциясе йогынтысында аларның күпчелегендә милли интеллигенция формалаша, милли матбугат һәм китап хасил була, профессиональ әдәбият туа. Идел һәм Урал буе халыкларының культура тарихын тикшерүчеләр (мәсәлән, К. Васин, Е. Владимиров) боларның барысында Казан шәһәренең хәлиткеч роль уйнавын күрсәтәләр. Чөнки ул вакытта Казан Россия империясе Көнчыгышындагы иң зур иҗтимагый-политик һәм культура үзәге була. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «тауда зур шәмдәл кеби» утырган бу шәһәр үзен «чорнаган һәрбер өязгә нур чәчеп», «барчага юл күрсәтеп» тора һәм аннан «нур ала... бөтен як».

Күрше халыкларның иң алдынгы уллары да мәгърифәт эзләп Казанга юнәләләр. 1872 елда шәһәрдә ачылган учительская семинариядә төрле-төрле милләт вәкилләре укый. Мәсәлән, 1904 елда семинариядә барлыгы 198 кеше укыса, шулардан алтмыш сигезе рус, егерме икесе татар, егерме өче чуваш, егерме алтысы мордва, унбише удмурт, унҗидесе мари, алтысы казакъ, өчесе башкорт, өчесе коми, җидесе корея-лы, дүртесе гарәп, икесе якут, бер манси һәм бер калмык була[1].

Билгеле, шул замандагы башка күп кенә миссионерлык оешмалары кебек, бу семинария дә царизмның вак милләтләрне руслаштыру политикасын тормышка ашыру юнәлешендә эшли. Рус булмаган халыкларга мәгърифәт бирүнең мондый яңа системасын тудырган Н. И. Ильминский сүзләре белән әйткәндә, әлеге политиканың төп максаты «инородецларны руслаштыру, аларны дин һәм тел буенча тулысынча рус халкына китереп кушу» тәшкил итә[2]. Әмма, семинариядәге уку-укыту системасының реакцион һәм шовинистик характерда булуына карамастан, алдынгы карашлы укучылар анда зур тырышлык белән дөньяви белем алалар, прогрессив рус культурасын өйрәнәләр. Бу семинариядән Идел һәм Урал буе халыклары интеллигенциясенең күп кенә күренекле вәкилләре белем алып чыгалар. Алар арасында, мәсәлән, үзләрен «Казанда яшәүче марилар» дип атаган В. Васильев, С. Чавайн, В. Мухин, А. Эшкинин, мордвалылар З. Дорофеев, П. Глухов, И. Кривошеев, удмуртлар Максим, Гавриил һәм Михаил Прокопьевлар, Д. Корепанов һәм башкалар була. Моннан тыш, семинарияне тәмамлаучыларның байтагы, укытучы булып, туган халыкларына мәгърифәт бирү өчен күп көч куя. Алар Казанда укып һәм үзара аралашып халыкларыбызның рухи яктан бер-берсенә якынаюына булышалар.

Казан шәһәре күрше халыкларның милли матбугаты һәм китабы формалашуда да зур роль уйнады. 1906 елда биредә беренче чуваш газетасы «Хыпар» («Хәбәр») чыга башлый. Чуваш әдәбиятының күп кенә күренекле вәкилләре аның битләрендә үзләренең беренче адымнарын ясыйлар, иҗади чыныгу алалар. Казанда мари һәм удмурт телләрендәге беренче матбугат басмалары — «Мари календаре» (1907—1913) һәм «Удмурт календаре» (1906—1910) дөнья күрә. Бу басмаларда марилардан В. Васильев, С. Чавайн, Г. Кармазин, удмуртлардан М. Прокопьев, Г. Можгин һәм башкалар актив катнаша. Мәгълүм ки, бу эшлекләләр үзләренең милли әдәбиятлары һәм культуралары формалашуда, үсеп китүдә мөһим роль уйнадылар. Мари әдәбиятчысы К. Васин «Мари календаре»н чыгару идеясе аның нәшире һәм редакторы В. Васильевта күренекле татар мәгърифәтчесе К. Насыйри эшчәнлеге белән якыннан таныш булу тәэсирендә туын белдерә[3].

Бу — Идел буе халыклары арасында Бөек Октябрьга кадәр үк башланган культура бәйләнешләренең ачык мисалы. Әйтергә кирәк, татар демократик интеллигенциясе, зур гына үсешкә ирешкән актив иҗтимагый-политик һәм мәдәни көч буларак, күрше халыкларның яшь интеллигенциясе өчен үрнәк тә булып торды. Күренекле мари шагыйре һәм галиме В. Мухин үзенең истәлекләрендә шундый бер вакыйганы тасвирлый. Бервакыт алар С. Чавайн белән икесе «Кәрван-сарай» гостиницасында бер тәр-

---

[1] Материалы по истории Чувашской АССР. Выпуск 2. Чебоксары, 1956. 263 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Габдулла Тукай. Сборник статей. Казань, 1968. 145 бит.

кем татар интеллигентларының бик җанлы әңгәмәсенә тап булалар. «Татарлар,— дип искә төшерә соңрак В. Мухин,— бик кызып актуаль политик мәсьәләләрне тикшерәләр иде. Алар дөньякүләм әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрәләр иде. Шунда мин Сергейга әйттем: «Күрәсеңме, татарлар ничек зурдан кубып фикер йөртәләр. Безгә дә алардан калышырга ярамый».

XX йөз башында Идел буе халыклары тормышының социаль-политик шартларындагы уртаклык аларның әдәбиятларының да идея-эстетик якынлыгына китерде. Бу әдәбиятлар тарихын тикшерүчеләр, мәсәлән, Г. Тукай, К. Иванов һәм С. Чавайн кебек әдипләр иҗатында күп кенә уртак моментлар табалар. Дөрестән дә, бередә аларның чынлыкка карашлары, идея-эстетик омтылышлары һәм гомумән, поэзияләре арасындагы якынлыкны раслый торган байтак мисаллар китерергә булыр иде. Бу хәл алар иҗатының проблематикасында ук ачык күренә. Сүз, барыннан да элек, бу проблематиканың халык тормышының аеруча актуаль һәм өлгергән мәсьәләләренә нигезләнгән булуы турында бара. Тукай да, Иванов һәм Чавайн да буржуаз җәмгыятьтә хатын-кызның авыр язмышы турында бик ачынып язалар, аңа ирек һәм тигезлек бирү идеясен чын күңелдән яклыйлар. Г. Тукайның «Татар кызларына», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Хатыннар хөррияте», К. Ивановның «Нарспи», С. Чавайнның «Ярлы хатыны» кебек шигырь-поэмалары шуның ачык мисалы. Бу шагыйрьләр социаль һәм милли изүне кискен гаепләделәр, туган халыкларының ирекле киләчәге турында хыялландылар.

Тукай, Иванов, Чавайн кебек әдипләр иҗатының тормышчан һәм сәнгатьчә көче алар поэзиясенең тирән халыкчанлыгында иде. Халыкның рухи оптимизмын шигъри гәүдәләндерү өчен алар, беренче чиратта, фольклор образларына һәм мотивларына мөрәҗәгать итәләр. Бу образларны һәм мотивларны сайлауда да шагыйрьләр бербереннә бик якын торалар. Мәсәлән, Тукай да, Чавайн да 1907 елда халык әкияте материалларына нигезләнеп «Шүрәле» һәм «Вувер» дигән поэмаларын язалар. Әсәрләрнең беренчесендә тапкыр егет Былтыр Шүрәлене җиңсә, икенчесендә мари крестьяны шулай ук үзенең кыюлыгы һәм тапкырлыгы белән әкияттәге кара көч Вуверңан өстенрәк чыга. Икенче төрле әйткәндә, шагыйрьләр тормышның кара көчләре белән көрәштә җиңеп чыккан кеше акылына дан җырлыйлар.

Халык рухына тирәнтен үтеп керү, иҗтимагый үсешнең өлгергән мәсьәләләрен кыю рәвештә сурәтләү — Тукай, Иванов һәм Чавайнның популярлыгы үз чорында әнә шулар белән билгеләнә иде. Шушы ук сыйфатлар безнең заманда алар поэзиясенең милли һәм интернациональ әһәмиятен ачыкларга да булыша. Шундый сыйфатларга ия булганлыктан Тукай поэзиясе шагыйрь исән чакта ук милли рамкалар белән генә чикләнеп калмады, ә күп кенә бүтән халыкларда да зур популярлык казанды. Бөек татар классигының бу әдәбиятлар үсешендәге роле аларның күренекле вәкилләре тарафыннан күп тапкырлар зур хөрмәт белән билгеләп үтелде. Бередә бары бер генә мисал китерәсе килә. Казакъ әдәбияты аксакалы С. Муканов болай ди: «Октябрь алды елларында төрки халыкларның күп кенә әдипләре һәм шагыйрьләре Тукай әдәби мәктәбен үттеләр, аңардан әдәби осталыкка өйрәнделәр, туры мәгънәсендә аның шәкертләре булдылар. Башкорт язучысы Сәйфи Кудаш, казакъ әдипләре Солтан-Мәхмүд Торайгыров, Сабит Дунантаев һәм Бәимбәт Майлин, кыргыз язучылары Ишангали Арабаев һәм Касыйм Тнистанов, үзбәк язучылары Фитрат, Шулпан һәм Абдулла Кадыйри, таҗик язучылары Садриддин Айни һәм Рәхим Задә, төркмән язучысы Берды Кербабаев һәм башка бик күпләр әдәбияттагы беренче адымнарын Габдулла Тукайның шифалы йогынтысы астында башладылар»[1].

Чуваш халык шагыйре Педер Хузангайның иҗат практикасыннан түбәндәге эпизод та кызыклы: Бервакыт, туган авылына кайткач, ул колхоз идарәсендә Тукай белән Ивановның рәттән куелган портретларын күрә. Ике халыкның һәм әдәбиятның дуслыгын гәүдәләндергән бу факт Хузангайны нык дулкынландыра һәм ул үзенең шул вакытта туган хисләрен «Таңнан таңга» дигән лирик поэмасында да чагылдыра.

Хузангай фикерен дәвам иткәндәй, чуваш әдәбиятчыларыннан берсе болай ди: «Чувашиядә Тукайны бик яраталар һәм ихтирам итәләр. Еш кына: «Тукай — татарның Константин Иванов» иң улы»,— дигән сүзләрне ишетергә туры килә»[2].

---

[1] Габдулла Тукай. Сборник статей. 9 бит.
[2] Шунда ук. 141—142 битләр.

Тукайны, Ивановны һәм Чавайнны алдынгы рус культурасына тирән мәхәббәт тә үзара якынайта. Алар Пушкин белән Лермонтов таланты алдында баш иделәр. Әмма бу шагыйрьләрнең бөек рус классикларыннан өйрәнүе чын мәгънәсендә иҗади характерда булды. Гәрчә Тукай, Пушкин белән Лермонтовны кояш дип карап, үзен, «ай кеби, нурны алардан икътибас иткән... баш» итеп санаса да:

**Булмый Пушкин шигырене һич хаинәнә үз итеп,**
**Булса да «әлхәм» уку ул, өр-яңа бер сүз итеп,**

— дип белдерде.

Тукай шигырьләрендә ике кызыклы момент күзгә ташлана. Беришә әсәрләрендә ул үзенең Пушкин белән Лермонтов поэзиясен ничек аңлавын, аларга үз мөнәсәбәтен чагылдыра. Моңа мисал итеп «Пушкинә», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Җавап», «Кыйтга» дигән шигырьләрен алырга була. Икенче бер очракта исә татар шагыйре Пушкин белән Лермонтовтан ирекле тәрҗемәләр ясый. Бу тәрҗемәләрнең характеры турында рус әдәбиятчыларыннан берсе болай ди: «Пушкин поэзиясенә мөрәҗәгать итеп, Тукай күпчелек очракта үзенең оригиналь әсәрләрен тудыра, ул чыганакның структурасын, образларын үзгәртә, аларны шигырьгә милли колорит бирә торган детальләр белән баета. Кыскасы, биредә Тукай Тукай булып кала. Пушкиннан ул осталыкка өйрәнә, әмма үз милли поэзиясенә хыянәт итми, үз әсәрләрендә татар укучылары арасында прогрессив идеяләрне үстерүгә хезмәт итә торган моментларны үткенәйтеп бирә»[1]. Шушындый ук фикерне Тукайның Лермонтовтан ясаган тәрҗемәләренә карата да әйтергә мөмкин.

* * *

Идел һәм Урал буе халыкларының культура бәйләнешләре Совет власте елларында яңа баскычка күтәрелде, яңа сулыш алды. Илебездә социалистик җәмгыять төзү процессында алар тирән социаль һәм рухи яңарыш кичерделәр, үзләрен идеаллар һәм максатлар уртаклыгы белән ныгытылган яңа тип милләтләр берләшмәсенең тулы хокуклы вәкилләре итеп тоя башладылар. Шушы бердәм, тату семьяны тою хисе аларның бөтен уйларында, эшләрендә чагылды.

Әлеге хәлиткеч социаль-политик факторлардан тыш, Идел һәм Урал буе милли культураларының үзара бәйләнешләре ныгуда башка моментлар да үз рольләрен уйнадылар. Совет властеның беренче елларында бу регионның иҗтимагый-политик һәм культура тормышында Казан шәһәре һаман әһәмиятле урын тота. Менә кайбер фактлар: 1918 елда Казанда чувашларның беренче профессиональ театры оеша. Шул ук елда биредә чуваш телендәге беренче газета «Канаш», беренче иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал «Таң» (1919) һәм тагын бернично газета һәм фәнни-популяр журнал чыга башлый. 1918 елда Алабугада удмурт телендәге беренче большевистик газета «Яшен», ә Казанда 1919 елдан көндәлек удмурт газетасы «Кызыл сугышчы» чыга башлый.

Егерменче елларда күрше халыклар әдәбиятларының күп кенә күренекле вәкилләре Казанда укыйлар һәм эшлиләр. Бу хәл шулай ук халыкларыбыз һәм әдәбиятларыбыз арасындагы бәйләнешләрнең ныгуына булыша.

Революциядән соңгы рухи-мәдәни үсешнең яңа мөһим сыйфаты шунда: бу чорда милли культураны, әдәбиятны үстерү инде аерым халык эше генә түгел, ул процесста теге яки бу дәрәҗәдә башка милләтләр дә, бигрәк тә якын күршеләр катнаша башлый. Шушындый хезмәттәшлекнең ачык мисалы итеп түбәндәге фактны алырга була. Әйтик, башкорт җирендә күп кенә татар әдипләре дөньяга килде. Алар арасында Г. Ибраһимов, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, М. Әмир, Ә. Еники һәм башкалар бар. Башкортстан — шулай ук чуваш әдәбиятының күренекле вәкилләре К. Иванов һәм Я. Ухсайның да туган җире. Мордовиядә татар классикларыннан Ш. Камал, Һ. Такташ, Г. Әпсәләмов туган. Чуваш җиреннән Ф. Бурнаш үсеп чыкты.

Икенче яктан, күрше әдәбиятларның күп кенә вәкилләренең тормышы һәм иҗаты Татарстан җире белән бәйле. Совет власте елларында татар һәм башкорт әдәбият-

[1] Пехтелев И. Тукай и русская литература. Казань, 1966, 89 бит.

лары арасында аеруча тыгыз элемтәләр урнашты. Кайбер әдипләрнең иҗат мирасы исә бу ике халыкның уртак хәзинәсенә һәм рухи байлыгына әверелде. Моңа аеруча характерлы мисаллар булган М. Гафури һәм Ш. Бабич иҗатлары социализм заманы әдәбиятларында миллилек белән интернациональлек арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекле якларын өйрәнү өчен кызыклы материал да бирәләр.

Ике тугандаш әдәбиятның хезмәттәшлеге турында сүзне дәвам итеп, тагын башкорт совет әдәбиятына нигез салучылардан А. Таһиров, С. Кудаш һәм башкаларның татар әдәби мохитында иҗади чыныгу алуларын әйтәсе килә. Егерменче елларда алар хәтта татар язучылары булып исәпләнгәннәр.

Чуваш әдәбиятының да бер төркем вәкилләре безнең төбәк белән тыгыз бәйләнгән. М. Сеспельның комсомол яшьлеге Татарстанда үтә. Егерменче елларда ул Тәтештә укый һәм эшли. Н. Шелеби белән С. Эльгер хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Аларның беренчесе Татарстанда туа, икенчесе Казанда укый. Безнең республика белән аеруча нык бәйләнгән чуваш язучысы — әлбәттә, П. Хузангай. Биредә ул туа, укый һәм гомеренең ахырына кадәр бу җир белән элемтәсен өзми. Ул туган якларында еш була, татар язучылары белән якыннан аралаша. Хәзер күренекле чуваш әдипләреннән берсе булган А. Талвир да озак еллар Казанда яшәде һәм иҗат итте.

Әлбәттә, туган яклары бу әдипләрнең иҗатларында да чагылмый калмады, аларның әсәрләрендә шактый яктыртылды. Мисал өчен башкорт җире Г. Ибраһимов, М. Әмир һәм Ә. Еники иҗатларында әледән-әле күзаллана. Гомумән, XX йөз башы мәгърифәтчеләреннән үк башлап башкорт темасы татар әдәбиятында актив яктыртылып килә. Татар язучылары башкортлар турында һәрвакыт зур ихтирам һәм мәхәббәт белән язалар, бу халыкның күңел киңлеге, җор табигате, шигърилеге кебек сыйфатларын калку итеп гәүдәләндерәләр. Мондый мисалларны башка әдәбиятлардан да китерергә булыр иде.

Идел һәм Урал буе милли әдәбиятларының Совет власте елларында бәйләнешләре ныгуда язучыларның шәхси бәйләнешләре мөһим роль уйнады һәм уйный. Егерменче елларда мондый бәйләнешләрне булдыруда 1923 елда Мәскәүдә оештырылган СССР халыкларының үзәк нәшрияты (Централиздат) зур гына булышлык күрсәтте. Бу нәшрият матур әдәбиятны 32 телдә чыгара иде. Аның планнарында Идел буе әдәбиятларына шактый урын бирелде. Централиздатның милли секцияләрендә әлеге әдәбиятларның күренекле вәкилләре: татарлар М. Җәлил, Ә. Фәйзи, М. Максуд, М. Галәү, марилар М. Кузнецов, Н. Орлов, Ал. Ток, мордвалылар З. Дорофеев, П. Кириллов, удмуртлар А. Багай, К. Герд, чувашлар Я. Ухсай, П. Хузангай, А. Талвир эшләделәр. Соңрак П. Хузангай болай искә алды: «Минем буындашларым булган күп кенә милли язучылар өчен Централиздат үзенә бер трамплин булды. Коридорларда бертуктаусыз сөйләшүләр. Редактор бүлмәләреннән яңа шигырьләрен укучы шагыйрьләр тавышы яңгырап тора. Анда татарлар Муса Җәлил һәм Әхмәт Фәйзи, удмуртлар Кузебей Герд һәм Ашальчи Оки, марилар Яныш Ялкайн һәм Ал. Ток, чувашлар Иван Курак һәм Николай Шубоссини һәм Россия халыкларының башка күп кенә әдипләре очрашалар, танышалар, бәхәсләшәләр, бер-берсенең иҗатын зур кызыксыну белән күзәтәләр, дусларының уңышларына шатланалар, уңышсызлыклары өчен борчылалар иде. Зур бер дус семья иде бу»[1].

Егерменче елларда Мәскәү университетында укыганда Муса Җәлил мари язучысы Яныш Ялкайн белән дуслаша. Замандашларының әйтүенә караганда, Җәлил «Яныш Ялкайнның рухи үсешенә көчле йогынты ясый. Баерак тормыш тәҗрибәсенә ия булып, иҗтимагый эшчәнлек белән актив шөгыльләнеп, ул мари студентына тормыш кыенлыкларын җиңеп чыгарга, коллективта үз урынын табарга дусларча булыша»[2]. Аерым алганда, ВЛКСМ Үзәк Комитетының милли секторында эшләгәндә Җәлил Ялкайнны шунда эшкә тарта. Татар шагыйре белән дуслашу соңыннан Ялкайнның «Шәһәр» дигән повестенда чагылыш таба. Анда автор мари егете Ачин образында үзен, ә Ачинның якын дусты булган татар студенты Хәсән Рәшитов образында Җәлил сыйфатларын гәүдәләндерә.

---

[1] «Литературная Россия», 24 декабрь, 1965 ел.
[2] Васин К. Творческие взаимосвязи марийской литературы. Йошкар-Ола, 1969, 34 бит.

Бөек Октябрь тудырган яңа социалистик тормыш безнең әдәбиятлар алдына уртак проблемалар һәм бурычлар куйды. Егерменче елларда шуларның иң әһәмиятлесе — илебездә яңа кеше формалашуын күрсәтү иде. Әдипләр бу мәсьәләне иҗат фантазиясе ярдәмендә дә, тарихи шәхесләрне сурәтләү юлы белән дә хәл итәргә омтылдылар. Яңа герой идеалының тормышта иң тулы һәм иң күркәм чагылышын язучылар үзләренең бөек замандашлары Ленинда күрделәр. Шуңа күрә әлеге мәсьәләне сәнгатьчә хәл итү эшен алар революция юлбашчысы образын сурәтләүдән башладылар диярга мөмкин. Башкорт Д. Юлтый, марилар Н. Мухин һәм С. Чавайн, мордвалылар З. Дорофеев һәм И. Кривошеев, татарлар һ. Такташ, Х. Туфан, Ә. Фәйзи һәм Г. Кутуй, удмурт К. Герд, чувашлар С. Эльгер, Н. Шелеби һәм башкалар шул ук елларда бөек замандашлары Ленин турында әсәрләр иҗат иттеләр. 1924 елда Татарстанда һәм Башкортстанда бөек юлбашчының якты истәлегенә багышлап «Ленин» һәм «Траур җырлары» дигән җыентыклар чыгарыла. Аларда Ленин һәм аның идеяләренең үлемсезлегенә дан җырлана, юлбашчының һәм партиянең халык белән тыгыз бердәмлеге ачыла.

Ленинның кабатланмас образын гәүдәләндерү өчен шагыйрьләр әледән-әле үз халыкларының фольклорларына мөрәҗәгать итәләр. Башкорт Д. Юлтый, мәсәлән, «Ильичның авыруы» дигән шигырендә юлбашчыны кояш белән чагыштыра. Мари М. Иванов үзенең бер шигырендә Ленинны «көчле буранда юл күрсәтүче маяк, урман куелыгыннан дөрес юлга алып чыгучы аваз» дип атый. Икенче бер мари шагыйре О. Шабдар Ленинны борынгы фольклор каһарманы «Он» (кабилә юлбашчысы) дип бәяли.

Егерменче еллардагы Идел һәм Урал буе әдәби ленинианасының иң зур уңышын исә һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы (1924) тәшкил итте. Алай гына түгел, татар шагыйре үзенең бу әсәрендә, гомумән, шул чордагы бөтен совет поэзиясендә беренчеләрдән булып, Ленин образында яңа герой идеалын киң гомумиләштереп һәм зур шигъри көч белән гәүдәләндерә алды.

Революция һәм гражданнар сугышы темаларын, яңа герой тууын, яңа иҗади хезмәтне, халыклар дуслыгын һ. б. яктыртканда да республикаларыбыз әдипләре берберсенә шактый якын торалар иде. Бу темаларны сәнгатьчә гәүдәләндергәндә алар рус әдәбиятыннан, аеруча М. Горькийдан һәм В. Маяковскийдан актив өйрәнделәр. Егерменче еллар — поэзиянең гөрләп үскән заманы, шуңа күрә ул вакытта милли әдәбиятларда В. Маяковский йогынтысы нык сизелә иде. Республикаларыбызның яшь шагыйрьләре өчен аның новаторлык поэзиясе зур иҗат мәктәбе булды. Маяковскийдан өйрәнү байтак дәрәҗәдә аның шигырьләрен тәрҗемә итүдән башлана. Менә бер характерлы мисал. Төрле милләт шагыйрьләре бер үк вакытта диярлек Маяковскийның атаклы «Сул маршы»н тәрҗемә итәләр. Татар шагыйрьләре арасында бу эшне беренче булып Г. Кутуй, мариларда Ал. Ток, чувашларда П. Хузангай башкара. Маяковский үзе Казанга килгәч исә (1928 ел) аның тәрҗемәчеләре бөек шагыйрь белән очрашалар һәм аңа әлеге шигырьне үз телләрендә укыйлар. Күңеленә бик хуш килгән бу вакыйганы Маяковский «Казан» дигән шигырендә тасвирлый. Әле күптән түгел генә социаль һәм рухи коллыкта яшәгән халыкларның алдынгы улларының белемгә, дөнья культурасы биеклекләренә омтылуы Маяковскийны дулкынландырган, күрәсең. Әлеге шигырендә ул болай дип яза:

**Уралның бозына**
**терәлеп,**
**мохтаҗлык базында яшәгән**
**халыклар**
**бәреп керделәр ишекне,**
**һөҗүмгә күтәрелеп,**
**культура крепостен**
**алырга.**

Утызынчы еллар безнең әдәбиятларда эпик фикерләүгә, синтезга омтылыш көчәю белән характерлана. Поэзиядә бу хәл күләмле жанрларга, барыннан да элек, поэмага игътибар артуга китерде. Гомумән алганда исә, утызынчы еллар өчен прозаның зур темплар белән үсүе хас. Илебездә куәтле революцион кузгалышлар һәм дөньяны үзгәртеп кору заманының киң күренешләрен тудырган, шушы чорда халыкларыбыз-

ның социаль-рухи үсешен чагылдырган романнар, повестьлар языла. Шундый әсәрләрнең иң әһәмиятлеләре рәтенә татар язучыларыннан Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» һәм «Тирән тамырлар», Ш. Камалның «Матур туганда», М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр», башкортлардан Д. Юлтыйның «Кан», А. Таһировның «Кызылгвардиецлар» чувашлардан С. Эльгерның «Таң атканда» һәм «Сугыш көннәре», марилардан С. Чавайнның «Элнет» һәм М. Шкетанның «Эрэнгэр», мордвалардан В. Коломасовның «Лавгинов», удмуртлардан Г. Медведевның «Лоза кыры» һәм М. Коноваловның «Җәрәхәтле йөз» романнарын кертергә була. Аларның күпчелеге проблематикалары буенча бер-берсенә шактый якын торалар. Әсәрләрдә халык массаларының иҗтимагый аңы уяну, эшчеләр сыйныфының һәм крестьяннарының яңа тормыш өчен көрәшкә килеп кушылулары, социалистик төзелештә катнашулары күрсәтелә. Шундый киң тарихи фонда халык арасыннан чыккан геройларның дөньяга карашлары формалаша, һәм алар яңа тормыш өчен актив көрәшчеләргә әвереләләр.

Социалистик стройның ныклыгы, совет халыкларының какшамас бердәмлеге өчен тарихи сынауга әверелгән Бөек Ватан сугышы язучыларның да игътибарын шушы мәсьәләләргә юнәлдерде. Фашизмны җиңүнең төп чыганакларыннан берсе халыкларыбызның какшамас дуслыгы һәм бердәмлеге иде. Кырыс сугыш елларында язучылар бу көчне аеруча нык тойдылар. Шул сәбәпле, сугыш еллары әдәбиятында, бигрәк тә поэзиядә, халыклар дуслыгы темасына игътибар бермә-бер көчәйде. Мондый шартларда инде революциягә кадәр үк рус халкы белән дуслык идеясен яклап чыккан классикларыбыз авазы үзгә бер көч белән яңгырады. Аерым алганда, интернационалист шагыйрь Габдулла Тукай иҗаты.

Башкорт шагыйре М. Кәрим «Россиянмын» дигән шигырендә:

> **Хаклымындыр, димен, үземне әгәр**
> **Чагыл имәненә ошатсам,—**
> **Тамырларым бит дүрт гасыр элек**
> **Мәскәү белән барып тоташкан,**

— дип язды.

Х. Туфанның «Россияннар» шигырендә дә фашист палачлары җәлилчеләрне Мамай нәселеннән итеп күрсәтергә тырышалар, Чыңгыз ханны, Батыйны мактап, алардагы «милли җеп»не тартып карыйлар. Әмма җәлилчеләр үзләренең Рахметовлар нәселеннән булуын, аларда Рахметовлар «каны» агуын раслыйлар.

> **Бу кырыс һәм корыч кешеләр**
> **Басып тора илләр хәтерендә.**
> **Россияннар дигән исемне**
> **Раслый алган ирләр хәлендә.**

Татар шагыйренең шушы фикерен куәтләгәндәй, чуваш П. Хузангай «Хәсән Туфанга» шигырендә:

> **Без синең белән мәңгегә россияннар.**
> **Без синең белән мәңгегә волгарьлар!**

— дип белдерә.

Үзеңне бөек елга белән бәйләп, аның кешесе итеп карау — Идел буе халыклары поэзиясенең мөһим мотивларыннан берсе. Идел-анага балалык мәхәббәте һәм аны сагыну хисләре Х. Туфан белән П. Хузангай шигырьләрендә үзгә бер көч белән чагылдырыла. П. Хузангай, гомумән, үз тормышын бу елгадан башка күз алдына да китерә алмый:

> **Үзең туып-үскән Иделне, балыкчы учакларын,**
> **Көймәләрне, акчарлакларны күрмичәме,**
> **Үзебезнең җырларны ишетмичәме!..**

Әгәр Туфан һәм Хузангай Иделне һәрбер агачы һәм үләне бик кадерле туган як буларак яратсалар, мордва шагыйре А. Мартынов башкачарак планда кабул итә:

> **Идел-ана!**
> **Россиянең анасы дип**
> **Атыйбыз сине, тик сине.**

С. Хәким шигырьләрендә исә Идел образы Татарстан образы белән аваздаш итеп карала.

> **— Сез кайдан! — дип сорыйсыз.**

— Без Казаннан, Иделдән.
Идел — эчкән су булыр.
Иделдә иген иккән,
Яшәгән, көнен иткән
Татарстан шул булыр.

Россия анасы Иделгә мәхәббәт аның ярлгрында яшәүче халыкларга карата да шундый ук хисне тудыра. Мари халкына булган иң якты хисләрен С. Хәким, мәсәлән, болай аңлата: «Безнең якларда элек-электән татарлар марилар белән тыгыз аралашып яшиләр. Бу хәл ике халыкның тормышында бары безнең як өчен генә хас булган гореф-гадәтләр тудырган. Марилар татарлар белән бергә эшләгәннәр, авыр вакытлгрда бер-берсенә ярдәм иткәннәр. Һәр татарның мари ягында үз тосы (дусты) булган. Шулай булгач, нишләп болар барсы минем күңелдә, иҗатта эз калдырмасын? Мин бу хакта язмый булдыра алмадым! Мин бу дуслыкны, туган ягымны җырлап килдем һәм киләчәктә дә бу мәңге үлмәс темага шигырьләр багышлаячакмын». Һәм мари темасы С. Хәким иҗатында әһәмиятле урын алды. «Мари карты Филипп» шигырендә, мәсәлән, шагыйрь ике дус — татар Хәйрулла белән мари Филиппның үзара мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерә. Алар яшь вакытта ук дуслашалар һәм бу дуслыкларына гомер буе турылыклы булып калалар. Бәйрәм табынында очрашканда аларның «татарча башлаган җырлары күп вакыт марича очлана».

Әмма халыкларыбызның күптәннән килә торган мондый дуслыгы белән хәзергә әле шагыйрьләр генә күбрәк кызыксына. Тулаем алганда исә безнең әдәбиятлар бу дуслыкны әле аз яктырталар. Бу өлкәдә проза аеруча калыша. Мәгълүм ки, әлеге теманы гәүдәләндерү өчен безнең чорда эшчеләр сыйныфы тормышы аерата бай һәм кыйммәтле материал бирә. Чөнки һәр эшче коллективта — кечкенәрәк берәр предприятиеме ул, яисә КамАЗ һәм Чабаксар трактор заводы кебек гигант комплексмы,— анда төрле милләт вәкилләрен күп тәбарга була. Мисалга КамАЗны гына алыйк. КамАЗны төзүдә союздаш һәм автономияле республикаларның күбесе катнашты. Бер яктан алар төзелешне төзү материаллары, техника һәм җиһаз белән тәэмин итәләр. Икенче яктан, автозаводның төзелеш мәйданында һәм яңа шәһәрне төзүдә илебезнең төрле республикалары вәкилләре катнаша. Алар совет халкының хезмәттәге батырлыклары елъязмасына яңа күркәм сәхифәләр яздылар. Автогигант төзелешендә бердәм гаилә хисе белән ныгыган күпмилләтле коллектив формалашты.

Эшчеләр сыйныфы тормышы безнең илдә кешеләрнең яңа тарихи берлеге — совет халкы формалашу процессын гәүдәләндерү ягыннан зур әһәмияткә ия. Совет власте елларында илебез хезмәт ияләре күп кенә гомум сыйфатлар һәм традицияләр белән тыгыз үрелгән күпмилләтле коллективка берләштеләр. Бу уңайдан бер мисал китерәсе килә. Моннан берничә ел элек СССР Фәннәр академиясенең Н. И. Миклухо-Маклай исемендәге этнография институты Татарстанда комплекслы этносоциологик тикшеренүләр уздырды. Институт гглимнәре республика тормышын төрле яктан — экономик, политик, культура, психологик планда өйрәнделәр. Безнең илдә беренчеләрдән булган бу тикшеренүләрнең нәтиҗәләре «Социальлек һәм миллилек» дигән коллектив хезмәттә гомумиләштереп бирелде. Республикада яшәүче рус һәм татар хезмәт ияләренең төрле өлкәләрдәге үзара мөнәсәбәтләрен социологик өйрәнү аша әлеге китап авторлары илебездә яңа тарихи берлек ничек формалашуын конкрет тестә күз алдына бастыралар. Бу тарихи процесс хәзер әдәбиятта да үзенең җанлы гәүдәләнешен көтә.

Икенче яктан, хәзерге чорда әдәбиятларыбызның үзара бәйләнеше мәсьәләсе дә бик аз өйрәнелгән. Шушы ук фикерне музыка, театр һәм сынлы сәнгать өлкәсендәге бәйләнешләрне өйрәнүгә карата да әйтергә була. Хәлбуки, сугыштан соңгы дәвердә безнең күрше республикаларда әдәби атналыклар уздыру, театраль гастрольләрдә булу, сынлы сәнгать күргәзмәләре оештыру, тугандаш әдәбиятлардан тәрҗемәләр ясау мөһим роль уйнаган иделәр.

Дөрес, соңгы елларда әдәбият һәм сәнгатьләребезнең хәзерге этаптагы үзара бәгланышларын өйрәнү эшенә беркадәр игътибар грту күренә. Мәсәлән, 1973 елда һәм 1981 елда Казанда Идел һәм Урал буе әдәбиятлары һәм сәнгатьләренең үзара бәйләнешләрен өйрәнүгә багышлап зур фәнни-теоретик конференцияләр үткәрелде. Мондый эш, һичшиксез, милли культураларыбызның дуслыгы тагын да ныгуга, аларның социалистик реализм юлыннан уңышлырак үсүенә ярдәм итәчәк.

Ринат Мөхәммәдиев

# ИДЕЯ-ЭСТЕТИК ОФЫКЛАР КИҢӘЙГӘНДӘ

## Тәнкыйть кем өчен языла?

Әдәби тәнкыйть секциясенең чираттагы утырышы инде тәмамланып килә иде. Ул да түгел, көтмәгәндә-уйламаганда, яңа бер бәхәс кабынып китте. Тәҗрибәле ике тәнкыйтьчебез, бер-береннән ничек кенә булса да өскәрәк чыгарга теләгәндәй дөньяларын онытып, тәнкыйть кем өчен языла дигән сорауга өздереп җавап бирергә тырыша башлады.

— Тәнкыйть, иң элек, язучыга адресланган булырга тиеш,— диде исеме укучылар арасында яхшы мәгълүм тәнкыйтьче.

— Юк... — диде аларның өлкәнрәге,— тәнкыйть укучы өчен языла.

— Конкрет әсәр турында һәм конкрет авторга адресланып языла икән, тәнкыйтьнең укучы өчен түгел, ә язучы өчен булуы, ул үз иҗатындагы уңай һәм тискәре сыйфатларны аңласын, гыйбрәт алсын өчен язылуы болай да аңлашылып тора түгелме соң инде...

— Юк! Әдип өчен генә булса — тәнкыйтьне нигә газета-журналларда басып торырга?.. Бер кәгазь кисәгенә яз да, тоттыр язучының үз кулына!

«Тәнкыйть язучы өчен!.. Тәнкыйть укучы өчен!..»

...Инде ике ел чамасы вакыт узган. Хөрмәтле ике тәнкыйтьчебезнең кызып-кызып бәхәсләшүе әле дә булса күз алдында, диаметраль капма-каршы мәгънәле сүзләре әле дә булса колак төбендә яңгырап тора...

Шулай да тәнкыйть кем өчен языла соң? Гади генә булып тоелган бу сорау бәлки очраклы тумагандыр... Хикмәт тәнкыйтьнең укучы, яисә язучы өчен язылуында да түгел, әлбәттә. Тәнкыйть укучы өчен дә, язучы өчен дә язылса да кояш иртәгесен кире яктан чыкмас иде. Шундый гади генә мәсьәләне принципиаль бәхәскә әверелдергән тәнкыйтьче-остазларыбыз да моны гына аңларлык кешеләр, анысына һич шиксез юк... Эш нәрсәдә соң? Шул хакта бераз уйланып алыйк.

«Тәнкыйть — язучы өчен», дип чыккан әдип, үзенең оппонентына караганда, бүгенге әдәби процесска якынрак торучы, аның көндәлек мәшәкатьләрен ныграк белгән һәм кичергән автор. Шуңа күрә дә аның тәнкыйтькә мөнәсәбәтендә күпчелек шагыйрь, прозаик һәм драматургларыбызның сулыш кайнарлыгы ачык сизелеп тора. Сер түгел ич, әдәби тәнкыйтьнең мөстәкыйль жанр булуын, шундый ук җитди иҗат эше икәнлеген яхшы аңлаган әдипләр дә, аның принципиальлек һәм объективлык кебек какшамас таләпләре барлыгын хәтерләгән каләмдәшләр дә, үз иҗатлары һәм үз шәхесләренә кагылганда, бу хакыйкатьләрне еш кына хәтердән чыгаралар. Ул гына да түгел, матбугат битләрендә булсын, төрле чыгышларда булсын, тәнкыйтьне һәм тәнкыйтьчеләрне кыюлыкка, туры һәм принципиаль сүзгә өзлексез чакырып торган иптәшләр дә үз адресларына юнәлтелгән таләпләрне бигүк өнәп бетермиләр. Әйтик, көндәлек матбугатта дөнья күргән әдәби тәнкыйть мәкаләләренең һәм рецензияләрнең 95 проценттан артыграгы, нигездә, уңай бәяләрдән генә тора һәм аларның да яртысы диярлеге комплиментар тәнкыйтькә, димәк, урынсыз мактау һәм чамасыз күккә чөюләргә кайтып кала. Мондый тәнкыйть безгә кирәкме? Икеләнми расларга була, тавышка куя калсак, бертавыштан: «Юк, мондый тәнкыйть кирәкми!» — дияр идек. Әмма шул ук вакытта күпчелегебез, үз иҗатыбызга килгәндә, тәнкыйть әлегәчә аны тиешле дәрәҗәдә бәяләп, ачып җиткермәгән дип саный (җитешсезлекләрен түгел, әлбәттә, казанышларын)... Бәхәсләшмим, мондый фактлар да булырга мөмкин. Тик бу очракта сүз әле ул хакта түгел. 95 процент тәнкыйть продукциябез уңай бәяләрдән генә торган бер чорда «нигә минем иҗатны ул кадәр үк күккә чөеп

мактыйсыз»,— дип әйтүчеләр булмаса да, «урынсыз тәнкыйть, үч алу, күсәк белән сугарга ярамый» — дип, каравыл кычкыручыларның, үз иҗатындагы кимчелекләргә күрсәткән тәнкыйтьчене тереләй тотып ашардай булып йөргән авторларның күплеге гаҗәеп тоела. Бер карасаң, Ж. Рәхимов, А. Вергазов, Н. Әхмәдиев, Ә. Мәхмүдов кебек, әле әдәби иҗатта тәҗрибәләре алай ук зур булмаган шагыйрь һәм прозаикларга тәнкыйтькә колак салып, тиешле нәтиҗәләр генә ясарга иде дә бит... Ә алар уйлап-нитеп тормыйча, барлык чараларны эшкә җигеп, иҗатларын игътибарга алган тәнкыйтьчеләргә ташланырга ашыктылар... Янә бер тапкыр ялгыштылар!

Ләкин бу тактсызлык адымы аларның гаепләре генә түгел, ә бер үк вакытта бәлаләре дә иде. Төгәлрәге, күпчелек әдипләрнең әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтен ачык күрсәтеп торган гомуми бәланең хграктерлы чагылышы булды бу. «Тәнкыйть әдәбиятның һәм аерым язучыларның хезмәтчесе, тугрылыклы һәм талымсыз пропагандисты булырга тиеш»,— дигән, бер кая да һич кем тарафыннан да теркәлмәгән, әмма яши килгән хата карашның чираттагы бер җимеше иде ул. Тәнкыйтькә берәзлексез дәгъва белдереп торган әдәби җәмәгатьчелек артына яшеренеп, шуңардан оста гына файдаланырга омтылуның чираттагы бер мисалы иде бу. Чөнки мондый дәгъва, кагыйдә буларак, үзенең теләктәшләрен таба. Ә шул ук вакытта конкрет әсәрләрнең зәвыксызлыгы, йомшак яклары турында кузгатылган принципиаль фикер читтә кала.

Димәк, «тәнкыйть — язучы өчен» дигән тезисны яклаучылар хәзер яшәп килгән күренешләргә шактый якын тора икән. Чынлап та, язучы өчен генә язылган, язучыга гына йөз тоткан йомышчы тәнкыйть тә яши бирә, гөрләп чәчәк ата. Бездә еруча популярлык казанган юбилей мәкаләләре шуның гыйбрәтле мисалы түгелмени?! Бәйрәм хөрмәтенә дип инде аларына күз дә йомар идең, шул макташуларның шаукымы бөтен әдәби тәнкыйтькә, хәтта аның иң конкрет һәм аеруча принципиаль булырга тиешле жанры — рецензияләргә дә торган саен әрсезрәк үтеп керә бара. Әйтик, соңгы бер ел дәвамында Р. Сверигинның (А. Вергазов китабы турында), Н. Лаисовның (Г. Рамазанов китабы турында) «Социалистик Татарстан»да, Ә. Габидинең (Батулла китабы турында) «Казан утлары»нда, Р. Бикчуровның (Әсрар Галиев китабы турында), Я. Игнәйнең (Ш. Маннапов китабы турында), Д. Гайнетдинованың (Х. Әюпов китабы турында) «Татарстан яшьләре» газетасында басылган рецензияләрен һич икеләнмичә шундыйлар исәбенә кертергә мөмкин. Аларның нинди критерийлардан чыгып һәм нинди таләпләрдән торып язылуын аңлау җиңел түгел. Ә теләкләре ачык — яңа дөнья күргән җыентыкларның кимчелекләренә күз йомып, аларны әдәби процесстагы игътибарга лаек бер вакыйга янсә уңай күренеш буларак укучыга тәкъдим итү. Әлеге китапларның барысына да рәттән тискәре мөһер куярга кирәк дип әйтергә җыенмыйм, арада чын мәгънәсендә җитди сөйләшүне сорый торган, уңай бәягә лаеклары да бар. Бу очракта күп кенә авторларның китап рецензияләүгә алынып та, әдәби тәнкыйтьнең элементар кагыйдәләрен дә аңлап җиткермәве, әсәрнең идея-эстетик яктан ни дәрәҗәдә булуына игътибар да итмәстән, үз алларына мактарга, язучыга бер «игелек күрсәтергә» дигән максат куеп кына эш итүләре тирән борчу уята. Тәнкыйтьнең генә түгел, гомумән, әдәбиятның да бүгенге торышы һәм киләчәге өчен үтә зыянлы булган әлеге тенденциянең һаман яшәве уйландыра. Әдәбиятыбызны киң катлау укучылар арасында даими рәвештә пропагандалап килгән, әдәби тәнкыйтебез үсешенә гаять зур өлеш керткән республика газета-журналлары да моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле проблема булуын истән чыгармасалар иде?! Әдәби тәнкыйть фикере, мәгълүм булганча, ул — безнең хәрәкәттәге эстетикабыз. Матурлык турындагы фәннең закончалыкларын, аның гасырлар дәвамында формалашып килгән критерийларын аерым әдипләр мәнфәгатеннән чыгып кына үзгәртү мөмкин түгел!

...Алай икән! Димәк, тәнкыйть — укучы өчен булып чыгамы инде?.. Әлбәттә, әдәбиятның башка жанрлары кебек үк, тәнкыйть тә иң элек укучыга адресланып язылырга тиешледер. Әмма моны да бер яклы гына аңлау дөрес булмас. Чөнки укучы, беренчедән, әле ул, гомумән, абстракт төшенчә. Эшче һәм колхозчы гына түгел, галим һәм философ та — укучы. Үз чиратында язучыны да укучы дип атарга мөмкин. Шуңа күрә җанлы тел белән мавыктыргыч формада язылган һәр язманы, бер тип укучы күңеленә хуш килгән дип кенә, тәнкыйтьтә бердәнбер өлге итеп алсак, шулай

ук ялгышкан булыр идек. Тәнкыйть — укучы өчен диган карашны аяк терәп яклаучылар, һичкемнән сер түгел, иң элек әлегедәй — тышкы эффект һәм йөгереклеккә күз тоткан язмаларны өстен күрәләр.

Инде сүз чыккан икән, тагын «тәнкыйть — тәнкыйть өчен» диган сыман, язучыга да, укучыга да игътибар итми, колак салмый гына язылып килгән материалларның да байтак икәнлеген искәртү сорала. Болары, бигрәк тә, проблемалы һәм теоретик дип аталган мәкаләләргә, әдәбият белеме өлкәсендәге тәҗрибәләрне әдәби тәнкыйть рубрикасына көчләп тагарга азапланган очракларга хас күренеш. Киң катлам укучыга таныш булмаган, шулай ук язучыны да кызыксындырмаган катлаулы, специфик төшенчәләр, терминнар, кирәкле-кирәксезгә кулланылган цитаталар һәм башка шундый галәмәтләр белән шыплап тутырылган андый язмалар, «ни уму, ни сердцу» дигәндәй, адрессыз булалар. Дөрес, соңгы елларда бу тип тәнкыйть сан ягыннан күзгә күренеп кимеде, ләкин шулай да бөтенләй юкка чыкты дип әйтә алмыйбыз. Язылалар — тәнкыйтькә рухы белән тартылган укучының гайрәтен чигерә килләр.

Ниһаять, тәнкыйтьнең адресы хакындагы бу уйлануларның үзенә күрә бер йомгагы да булырга тиештер. Нигә соң әле әлегедәй берьяклылыклар һаман да яши килә бездә? Әлбәттә, һәр конкрет очракның үз сәбәпләре, үз җаваплары бар. Шулай да төп сәбәп — ул кайберәүләрнең әдәби тәнкыйтьне теләсә кем һәм теләсә ничек кереп бәя бирә торган, мактый һәм макташа торган иркәле бер мәйдан итеп күз алдына китерүе булса кирәк. Алай уйлаучыларга, рецензия якисә тәнкыйть мәкаләсе язам дип кулына каләм алганга кадәр, иң элек, КПСС Үзәк Комитеты моннан ун ел элек кабул иткән «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарны алып, игътибар белән өйрәнү урынлы булыр иде. һәм шунда ук Л. И. Брежневның XXVI съезд трибунасыннан әйтелгән сүзләре хәтергә төшә: «Профессиональ фикер йөртү — әдәби тәнкыйтьчеләр һәм сәнгать белгечләренең эше...» Олы ышаныч белән әйтелгән бу сүзләр, үз чиратында, тәнкыйтьчедән шул кадәрле үк җаваплылык та таләп итәләр.

Тәнкыйть мәкаләсе язарга алынган һәркем әдәби иҗат процессының катлаулы һәм күпбаскычлы булуын тирәнтен аңларга, тоярга тиеш. Тулаем бербөтенне тәшкил иткән бу катлаулы күренеш үзара бәйләнешле берничә буыннан тора. Беренче буын — ул тормыш чынбарлыгы. Икенче буын — шул чынбарлыктан илһам алып, аның конкрет күренешләре һәм шәхесләре турында җитди фикер әйтү, күңелендә туган хисләре, тойгылары белән уртаклашу максаты куйган әдип. Өченче буын — тормыш күренешләренә һәм кичерешләренә нигезләнеп художник хыялында туган һәм сәнгатьле формага салынган яңа чынбарлык — әдәби әсәр. Дүртенче буын — укучы якисә тамашачы. Бишенче һәм соңгы буын — чынбарлык: әдәби әсәрне укыгач, андагы уй һәм хисләрдән рухланган укучының мөнәсәбәтен һәм тәэсирен тоючы чынбарлык. Тәнкыйтьче үзенең иҗатында әлеге буыннарның һәркайсын бер дәрәҗәдә күз алдында тотарга, шушы катлаулы процесска юнәлеш бирүче һәм аны оештыручы булырга тиеш. Тәнкыйтьче бу күренешнең һәр буынына тәэсир һәм йогынты ясый белергә, аларның үзара нормаль бәйләнешләрен тәэмин итүгә омтылырга тиеш. Югарыда искәртеп узылганча, аерым буыннар белән генә мавыгу — язучыга гына якисә укучыга гына ярарга тырышу — тәнкыйтьне турыдан-туры берьяклылыкка, үз-үзен инкяр итүгә китерә. Әдәби тәнкыйть үзе дә күп баскычлы, метод һәм принциплары булган катлаулы иҗат эше.

## Димәк, иҗат эше...

Фикер йөртү үзенчәлекләре, методологик принципларга нигезләнгән булуы, махсус категорияләр белән эш итүен искә алсак — тәнкыйтьнең фәнгә шактый гына якынлыгын күрербез. Шуларга да карамастан, чынбарлыкны танып белү һәм аңарга тәэсир итү үзенчәлекләре, уй һәм фикерне укучыга җиткерү чаралары һәм әдәби иҗат процессына турыдан-туры катнашып, кушылып китү кебек принципиаль һәм хәлиткеч яклары белән, ул — иҗат эше. Менә шуңарга да әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләре өчен (дөресрәге, әсәрләр өчен буладыр) авторга гыйльми дәрәҗә бирмиләр, аны фәннәр академиясенә член итеп тә алмыйлар, ә СССР язучылары союзына кабул итеп алалар. Безгә — профессиональ тәнкыйтьчеләре санаулы гына булган

әдәбиятка, күпчелек тәнкыйтьчеләре фәнни оешмаларда эшләгән әдәбиятка — мәсьәләнең бу ягы хакында да махсус уйланырга туры килә. Чөнки, югарыда искәртелгәнчә, тәнкыйть — тәнкыйть өчен дигәндәй, әдәбиятка да, фәнгә дә мөнәсәбәте шул кадәрле генә булган күпчелек язмалар, нигездә, менә шушы җирлектә туа. Монысы бер хәл, әлегедәй «тәнкыйть»не таный һәм үз урынына куя, бәяли башладык бугай инде. Ә менә чын әдәбият фәне һәм әдәбият тарихы белән чын әдәби тәнкыйть арасындагы чикләр әле һаман безнең өчен ачыкланып җитмәгән. Һәрхәлдә, әдәби ел йомгаклары вакытында ясалган докладларда булсын, агымдагы әдәби тәнкыйтьне анализлаган хезмәтләрдә булсын, без беренче булып һәм авыз тутырып әдәбият фәне һәм әдәбият тарихы өлкәсендәге хезмәтләргә анализ ясарга, аларның уңай һәм кимчелекле яклары хакында бәйнә-бәйнә сөйләшергә, фикер алышырга күнеккәнбез. Әнә шулай итеп тәнкыйтьнең үзе турындагы сүз икенчерәк планга калдырыла килә, ә инде аның күләм ягыннан кечерәк формалары — рецензияләр һәм китап күзәтү хакында сүз булса була, булмаса юк. Тулы бер монографияләр хакында фикер йөрткән ораторлар ул хакта сүз кузгатуны үзләре өчен бигүк мәртәбә итеп тә күрми башладылар сыман.

Сүз галимнәр белән язучылар арасында, фән белән әдәби тәнкыйть арасында кытай стенасы торгызу турында бармый, әлбәттә. Аларның үзара файдалы йогынтысына һәм хезмәттәшлегенә дә каршы чыгу түгел теләгем. Фәннең үз сфералары булган кебек, әдәби тәнкыйтьнең дә үз предметы, иҗат төре буларак үз формалары булуын онытмаска иде безгә. Гыйльми оешмаларда эшләп, диссертацияләр хәзерләгән авторлар өчен, дөрес, бу бигүк җиңел эш түгел. Әле узган ел гына Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән хезмәтләр: Ф. Хатиповның «Духовный мир героя» һәм Ф. Әгъзәмовның «Үзәктә — кеше» китаплары шуны тагы бер кат раслап тора. Һәр икесе — житди хезмәт нәтиҗәләре, бүгенге әдәбиятыбызны өйрәнү юлында авторларның уңышы саналырга тиешле китаплар. Әйтик, Ф. Әгъзәмов хезмәтен бүгенге очеркыбыз турында моңарчы язылган барлык хезмәтләр арасында аерып куярга мөмкин — заманча актуальлеге белән дә, фәнни-теоретик аппараты байлыгы белән дә, бүгенге көн очеркына бирелгән анализның тирәнлеге белән дә. Шулай да, әлеге әһәмиятле хезмәттә вакыт-вакыт чикләр онытылып тора — әдәби очерк белән гадәти газета очеркы, журналист язмалары арасындагы чикләр югала. Фәнни стиль белән әдәби стиль арасындагы чикләр һәм галимнең фактик материалны анализлавы белән иҗатчының тормышка үз мөнәсәбәтен художестволы рәвештә белдерүе арасындагы чикләр онытыла. Хезмәт журналистика фәне белән әдәби тәнкыйть очрашкан, киҫешкән сызыкта туган.

Ф. Хатипов китабында да бүгенге прозабызны психологик анализ күзлегеннән өйрәнү юлында моңарчы күрелмәгән гомумиләштерүләр, нәтиҗәләр ясалган. Ләкин шунда ук аның әдәби тәнкыйть булудан бигрәк, диссертация хезмәте, фәнни эш булуы да күзгә ташланып тора.

Тагы критерийлар мәсьәләсе. Әлеге хезмәтләрнең һәр икесендә аны тою, үзең өчен ачыклау җиңел түгел. Авторга ышанган укучы татар әдәбиятында психологик анализга игътибары булган һәр язучы бер үк идея-эстетик югарылыкта яза икән, «һәркемнең тавыгы алтын йомырка гына сала икән», дип, гаҗәпләнергә дә мөмкин. Очеркларга килгәндә дә шундыйрак хәл — күтәрелгән проблемаларга һәм геройларның кылган гамәлләренә җитди игътибар булып та, ул проблема һәм геройларның ни дәрәҗәдә сәнгатьле итеп тасвирлануы алай зур әһәмияткә ия түгел кебек килеп чыга. Һәрхәлдә, күләмле тәнкыйть хезмәтләренең критерийларын киләчәктә тагы да ачыграк һәм югарырак итеп күрәсе килә. Шунда ук бик әһәмиятле тагы бер нәрсә онытылмасын иде: тәнкыйть — иҗат эше! Тәнкыйтьче һәр очракта үзенең иҗатчы икәнен — тормышның һәм әдәбиятның идея-эстетик сәламәтлеге, тазалыгы өчен көрәшүче булуын, яңаны тудыручы булуын онытмасын иде!

## Яңалык тойгысы

Узган ел «Казан утлары» журналы үткәргән түгәрәк өстәл янындагы әңгәмәләрнең берсендә бүгенге әдәбият һәм аның кичектергесез проблемалары хакында зур сөйләшү булып узган иде. Г. Бәширов, Ә. Еники, С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Ахунов,

Ф. Миңнуллин, М. Мәһдиев, Р. Мостафин, А. Әхмәдуллин кебек олы әдипләр һәм яшьләр катнашында узган шул сөйләшүдә тагы бер нәрсәгә аеруча зур игътибар юнәлтелде. Ул да булса: иҗат эшенең яңалык тойгысыннан аерылгысыз икәнлегенә.

Тәнкыйтьне дә иҗат эше дидек. Димәк, аның да нигезендә яңалык тойгысы ятарга тиеш. Дөньяда һәм илебездә барган үзгәрешләргә, әдәбиятта, иҗтимагый һәм көндәлек тормышта барган яңа сулышка үтә сизгер булу дип аңларга кирәктер моны. Ул гына да түгел, яңалыкка, яңарышка булган ихтыяҗны язучыларның үзләреннән дә алданрак күреп, тоеп алу һәм шуны әдәби җәмәгатьчелек алдында җитди проблема итеп куя белү сәләтенә ия булырга тиеш әдәби тәнкыйть.

...Тиеш икәнлеге күпләребезгә мәгълүм, әмма, кызганычка каршы, еш кына без тәнкыйтьнең бу функциясен онытканга сабышабыз. Дәрт бар, дәрман юк дигәндәй килеп чыга. Чөнки яңалыкка йөз бордың дисә, искергән, гайрәтне чигереп бетергән күренешләргә отпор бирергә дә туры киләчәк. Ә моңарга исә гөрым авторларның кәефен кырмый гына ирешүе мөмкин түгел. Кемнеңдер кәефен кырырлык принципиаль сүз әйтер өчен азмы-күпме батырлык һәм кыюлык кирәк. Әйтик, тәнкыйть өлкәсендә беренче тәҗрибәләрен генә ясаган Ф. Газизова балалар прозасында табигатьне саклау мәсьәләләре хакында күләмле мәкалә язып чыга. Бәхәсләшмим, игелекле тема, кызыклы проблема борчый авторны. һәм аның шактый күп прозаиклар иҗаты белән таныш булуы да күңелгә өмет һәм ышаныч өстәп тора. Әдәбиятка мәхәббәт хисе дә зур авторда. Ләкин бер нәрсә — яңалык тойгысы гына җитенкерәми. Нәтиҗәдә, табигатьне саклау мәсьәләләре тирәсендә сүз йөрткән мәкаләдә укучының күңелен кузгатырлык бер генә проблема да күтәрелми. Бу өлкәдә бар да ал да гөл генә икән. Табигать хакында язылган проза әсәрләре барысы да гаҗәп дәрәҗәдә һәм һәр яклап камиллеккә ирешкән икән. Мәкаләнең яртысыннан артыгы А. Хәсәновның «Тугрылык» җыентыгын мактаудан гыйбарәт. Җыентыктагы нәни хикәяләрнең барысы да һәм идея, һәм эстетик яктан соң дәрәҗәдә камиллеккә ирешкән — автор күз дә йоммыйча укучыны шундый бәягә ышандырырга азаплана.

Ф. Газизованы тәнкыйтьтә тәҗрибәсезлеге хакына гафу да иттек ди. Хуш... Тәҗрибәле тәнкыйтьчеләребез дә аңардан кимен куймыйлар. Мисал өчен, бәяләрдә чама хисен яхшы тойган тәҗрибәле һәм бик акыллы тәнкыйтьчеләребездән кемне (?!), узган ел иҗат активлыгын берме-бер арттыра төшкән Ф. Миңнуллинны алыйк. Аның «Хикәя һәм хикәячеләр» мәкаләсен («Казан утлары», 1981 ел, 10 сан). Бу — аерым жанр проблемаларына багышланган аналитик мәкалә. Таләпләр прозабыз классикасы югарылыгыннан торып куела. Әмма, эш анализга, конкрет авторларның конкрет әсәрләренә барып терәлгәч — критерийлар югала төшә. Әйтик, сүз яшь прозаикларыбызның беренче хикәяләре хакында барганда яңа буын алдында яңа таләпләр кую үзеннән-үзе соралып тора кебек. Ләкин... автор А. Ганиев, Р. Фәизов, Р. Кәрәми, Батулла, Ә. Гаффар, Ә. Гадел, М. Галиев, Н. Гыйматдинова, Х. Гайнетдинов, С. Шәмси һәм Ф. Хуҗиәхмәтова кебек дистәдән артык яшь прозаикның әсәрләрен укып та уртага салып уйланырлык җитди бер проблема да күрмәгән. Хикәяләр язылгалый тора, укучылар укыштыргалый бирә, дигән сыман бер нәтиҗә ясала. Ә бит тәнкыйтьче, Ә. Гаффар һәм М. Галиев кебек хикәячеләр белән Х. Гайнетдинов, С. Шәмси, Ф. Хуҗиәхмәтоваларны бер исемлеккә тезсә дә, алар алдында бүген төрле-төрле иҗади проблемалар торганлыгын, бу авторларга таләпне бер үк критерийлардан чыгып кую, гомумән, әлегә иртәрәк икәнлеген дә яхшы аңлый. Мәкаләдә ачык чагылыш тапкан канәгатьлек хисенә, югыйсә, һичнинди нигез юк иде кебек. Авыз тутырып хикәя дип атарлык әсәрләр берән-сәрән генә күренгәләп килгән чорда тәҗрибәле тәнкыйтьченең прозабыз алдында торган шундый җитди проблемага алынып та, мактапсыйпап кына узуы — аңлашылмый.

Яңалык тойгысы тәнкыйтьтә турыдан-туры принципиальлеккә барып тоташа. Менә шуңа күрә дә яңалык тойгысын тәнкыйтьнең туры сүзлелеге, кыюлыгы, сугышчанлыгы һәм объективлыгы белән үзара мөнәсәбәттә генә үстерә, арттыра бару мөмкиндер. Бу күзлектән карaганда яшь тәнкыйтьчеләр Ф. Галимуллинның «Зур таләпләр югарылыгына» («Соц. Татарстан») һәм С. Маннаповның «Дулкыннар ни сөйли...» («Казан утлары») мәкаләсе узган елгы тәнкыйтебезнең уңышлы үрнәкләре булып тора. Гомумән, принципсыз кешене хөрмәт итү, аңарга ышану, таяну мөмкин булмаган кебек,

принципсыз тәнкыйть тә әдәби җәмәгатьчелек игътибарына лаек түгел. Ә әлеге авторлар үзләрен раслау юлында бу мәкаләләре белән житди адым алга атладылар. Шушы урында күренекле совет тәнкыйтьчесе Игорь Золотусскийның яшь тәнкыйтьчеләргә мөрәҗәгать итеп язылган мәкаләсеннән бер фикерне китереп узу урынлы булыр: «Тәҗрибә һәм күзәтүләремнән чыгып әйтә алам,— дип яза ул,— кайчан да булса бер егетлек ясап, кемнән дә булса курыкмаска җөрьәт иткән тәнкыйтьчене әдәби җәмәгатьчелек таный һәм хөрмәт итә. Ул озак вакытлар язмый торса да аны онытмыйлар, менә ул теге чакта фәләнне әйләндереп салган иде, дип искә ала киләләр. Әлбәттә, «әйләндереп салу» үзмаксат була алмый, ләкин бу алымны да онытырга ярамый. Үзеңне тиешле формада тоту өчен генә булса да, әдәби атмосфераның сәламәтлеге, тазалыгы өчен генә булса да...» («Литературная учеба», 1981, 6 сан).

Бу сүзләр усаллыкка, кусәккә тотынырга чакыру түгел, ә принципиальлек, сугышчанлык һәм объективлыкка чакыру булып аңлашылсын иде. Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында куелган принципларның, ниһаять, безнең иҗат принципларына әверелергә тиешлеген яклау булып!.

Яңалык тойгысы һәм принципиальлек, әлбәттә, әдәби әсәргә чыгарылган кырыс хөкемгә генә кайтып калмый. Агымдагы әдәби тәнкыйтьтә дә моны раслап килгән хезмәтләр аз түгел. Әйтик, М. Вәлиевның «Сандугачлар, кыр казлары һәм кеше», «Шагыйрь уты» мәкаләләре, Т. Галиуллинның «Бизәкләр төрлелеге», Ф. Миңнуллинның «Өлгергән мәсьәлә», А. Әхмәдуллинның «Сәхнәгә — бүгенге геройлар» һәм Ф. Зөлкарнәевның «Иң мөһиме табыш» дип исемләнгән мәкаләләре. Быел Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган Н. Юзиевның «Шигърият дөньясы», Р. Мостафинның «Образ времени» һәм Р. Кукушкинның «Шигъри бишек» китаплары да шул уңайдан игътибарга лаек хезмәтләр.

Характерлы үз йөзләре булган бу өч китапның яңалыкка да үз мөнәсәбәтләре бар. Мисал өчен, Н. Юзиев китабы «Яңа чор — яңа җыр» дигән бүлек белән ачыла һәм тәнкыйтьченең уйланулары шундук яңа чор, яңа матурлык җырчысы Һади Такташ шигъриятенә килеп чыга. Дөрес, Такташ турында язу яңалык түгел, әмма тәнкыйтьче татар совет шагыйренең әдәбиятыбызга алып килгән яңалыгын билгеләү һәм тасвирлау юлында күзгә күренерлек ачышлар ясый. Һәм алдагы бүлекләрдә дә, сүз кайсы шагыйрь иҗаты хакында гына бармасын — М. Җәлилнең бөтен Европага каһарманлык нуры чәчкән поэзиясе турындамы, Х. Туфан һәм Ә. Фәйзи кебек сүздән чәчәкләр үстергән олы лириклар турындамы, бүгенге шигъриятебезнең горурлыгы булган С. Хәким һәм Ш. Галиевның эзләнүләре хакындамы — тәнкыйтьченең йөз тотканы яңалык, әлегедәй талант ияләренең татар совет поэзиясен үстерүгә керткән өлешен яңа көн югарылыгында торып анализлау һәм бәяләү. Шунда ук Н. Юзиев тәнкыйтенең җанлы һәм мавыктыргыч саф әдәби телдә, сәнгатьле формада иҗат ителүен дә искә алып узасы килә. Бу яктан ул күпләргә үрнәк булып торырга мөмкин. Яшеренбатырын түгел ич — кайбер тәнкыйть әсәрләренең теле укучыга гөлҗимеш куаклары арасына кереп буталу кебек тәэсир итә. Тәнкыйтьнең үзенә, бәлки, аерым очракларда чәчәктә утырган чәнечкеле гөлҗимеш куагына тиңләшә белергә дә кирәктер, әмма тел мәсьәләсендә түгел. Тел кытыршылыгы һәм ясалма катлаулылык һич кенә дә әдәби тәнкыйтьнең жанр үзенчәлеге түгел.

Р. Мостафин китабы исә кызыксыну объектларының төрлелеге һәм киңлеге белән җәлеп итә. Монда әдәбият тарихы проблемалары да, бүгенге тормыш һәм әдәбиятка багышланган мәкаләләр дә, аерым әдипләрнең иҗат портретлары да киң урын алган. Һәм, әйтергә кирәк, чын әдәби формада мавыктыргыч тел белән иҗат ителгән бу тәнкыйть — Р. Мостафин тәнкыйте — үзенә битараф калдырмый.

Авторның тарих проблемаларына караган хезмәтләре алай вакыйга булырлык ук яңалыкларга бай түгел, дөресен әйтергә кирәк. Алар, нигездә, пропаганда характерындагы күләм ягыннан зур булмаган рецензия һәм язмалардан гыйбарәт. Тарих һәм аның проблемалары — Р. Мостафин стихиясе түгел. Ә инде аналитик хезмәтләр, иҗат портретларына килгәндә, тәнкыйтьче бөтенләй башка яклары белән ачылып китә, ул чын мәгънәсендә иҗатчыга әверелә.

Дөрес, тәнкыйтьче аерым мавыгу һәм берьяклылыклардан да азат түгел. Әмма шуларга да карамастан берөзлексез һәм һәрвакыт яңалыкка омтылып иҗат иткән,

үзенең эмоциональ җегәре, художниклык сәләте белән аерылып торган бу тәнкыйтьчебез иҗат үрләрен яулавында дәвам итә.

Өченче хезмәт — яшь тәнкыйтьче Р. Кукушкинның «Шигъри бишеге». Әлегә тулысынча басыла алмаган булса да, бу хезмәт яшь тәнкыйтьчебезнең генә түгел, гомумән, әдәби тәнкыйтебезнең дә уңышы хисаплана ала. Сер түгел ич, соңгы вакытларга кадәр балалар әдәбияты тәнкыйть тарафыннан ятимлеккә дучар ителгән иде. Ниһаять, Р. Кукушкин шушы җаваплы миссияне үз җилкәсенә алырга җөрьәт итте.

«Шигъри бишек» җыентыгы авторның иҗади мөмкинлекләре хакында сөйләшү өчен дә нык җирлек булып тора. Тәнкыйтьче балалар әдәбиятын гына түгел, балаларның үз тормышын, чынбарлыгын да якын күреп, аңлап яза. Аның хезмәтенә монографик эзлеклелек һәм логик дәвамлылык хас, бу сыйфатлар китапка фундаментальлек төсмере бирә. Бер үк вакытта ул әдәби күренешләрне тормыш вакыйгалары белән янәшә куеп, үзара гармоник рәвештә аралаштырып килә һәм гыйбрәтле генә нәтиҗәләр ясый. Шулай да Р. Кукушкинга бер теләк белдерәсе килә: балалар әдәбияты тәнкыйтенең язылу рәвеше, формасы һәм стиле дә үзенчәлекле булырга тиештер кебек. Әйтик, ул мавыктыргычрак, гадирәк, самимирәк һәм җанлырак була барган саен яхшырак түгелме икән?.. Тәнкыйтьчегә шул юнәлештә дә яңа иҗат уңышлары теләү урынлы булыр.

Гомумән, бүгенге әдәби тәнкыйтебез яңалык тойгысына мөнәсәбәттә дә бер урында гына таптанмый, эзләнә, таба һәм акрынлап булса да алга хәрәкәт итә тора икән. Шулай да, әдәбият-сәнгатебезнең үсеше дәүләткүләм әһәмиятле проблема булып торган һәм партиябез тарафыннан даими кайгыртылып килгән бер чорда — татар совет әдәбиятының да идея-эстетик офыклары киңәйгәннән-киңәя барган көннәрдә — ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнеп калу дөрес булмас иде. Алда торган иң җитди бурычларның берсе — бөтенсоюз киңлегенә юл яру зарурлыгы.

## Бөтенсоюз киңлегенә...

«...Совет сәнгатендә яңа дулкын күтәрелә. Соңгы елларда — һәм барлык республикаларда — талантлы байтак әсәрләр барлыкка килде...» Л. И. Брежневның XXVI съезд трибунасыннан әйтелгән бу сүзләрен татар әдипләре дә, хаклы рәвештә, үз иҗатларына бирелгән югары бәя һәм ышаныч дип кабул иттеләр. Чынлап та, татар драматургиясе, поэзиясе һәм прозасында игътибарга лаеклы үсеш, үзгәреш, яңарыш процессы бара. Әлеге жанрларның бүгенге дәрәҗәсен һәм йөзен билгели торган әсәрләрдә күпмилләтле совет әдәбиятына һәм дөнья әдәбиятлары казанышларына хас сыйфатлар, тенденцияләр һаман саен ачыграк төсмерләнә бара. Әйтик, Т. Миңнуллинның совет патриотизмы, интернациональ дуслык һәм каһарманлык идеяләрен югары сәнгать чаралары аша замандашларыбызга җиткергән «Моңлы бер җыр» драмасы, И. Юзеевның батырлык һәм фидакарьлек, ватан һәм халык язмышын бер төенгә туплаган «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясе моңа характерлы мисал була алалар.

Бөтенсоюз күләмендәге югары таләпләргә омтылган һәм аерым очракларда шул югары критерийларны билгеләүдә актив катнашкан әдәбиятның (барыннан да элек Т. Миңнуллин һәм Д. Вәлиев драматургиясе, С. Хәким, И. Юзеев һәм Ш. Галиев, Р. Харис һәм Р. Фәйзуллин поэзиясе, Г. Бәширов, Ә. Еники, А. Расих, М. Мәһдиев һәм А. Гыйләҗевның соңгы еллар прозасы күздә тотыла) тәнкыйте алдында да үзенчәлекле һәм яңа бурычлар килеп баса. Нидән гыйбарәт икән алар?..

Беренчедән, әдәби тәнкыйть, әдәбият дөньясында барган үсешкә, хәрәкәткә тагын рәвештә, үз критерийларын һәм таләпчәнлеген даими күтәрә барырга тиеш. Югыйсә, без уртакуллыкка гына түгел, гомумән, йомшак әсәрләрнең булуына да инде гадәтләнә башладык төсле тоела. Идеясе томанлы гына булган, эстетик яктан да күзгә күренеп торган зәгыйфь әсәрләрне, кем тарафыннан язылуына да карамастан, үз вакытында принципиаль һәм килешмәүчән тәнкыйтькә дучар итә барганда гына, инде гадәтләнелгән уртакуллыкка, ниһаять, югары таләпләр белән килергә өйрәнгән тәкъдирдә генә — яңа критерийлар һәм ил күләмендәге әдәби-эстетик фикер югары-

лыгы, киңлеге хакында сүз алып барырга мөмкин. Ә безнең агымдагы тәнкыйтебезгә исә бу юлда әле шактый гына иҗади гайрәт һәм принципиальлек күрсәтәсе бар.

Икенчедән, тәнкыйть үз казаныбызда гына кайнаудан — вакыт һәм пространствода чикләнгәнлегеннән дә арынырга тиеш. Агымдагы тәнкыйть башка тугандаш әдәбиятлар үрнәкләренә дә игътибарлырак булсын, алардагы яңа һәм игътибарга лаек күренешләрне үз вакытында күрсәтеп бара белсен, әдәбиятыбыздагы һәр яңа күренешне дөнья һәм Бөтенсоюз аренасындагы казанышлар яктылыгында анализлап, аның шулар арасындагы урынын да билгели барырга гадәтләнсен иде.

Вакыт һәм пространствода чикләнгәнлек дигәндә, тагын тәнкыйтьнең үткәндәге әдәби җәүһәрләргә игътибары җитенкерәмәүне дә ассызыклау кирәк. Юкса, тәнкыйтьнең тарихка битарафлыгы киләчәктә күп кенә тискәре нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Р. Гамзатов әйткәндәй, без тарихка наган төбәсәк, киләчәкнең безгә туптан атып җавап бирүе бик ихтимал.

Өченчедән, бөтенсоюз аренасына активрак чыга барып, тәнкыйть үзәк матбугат битләрендә әдәбиятыбыз казанышларын ил күләмендә һаман активрак пропагандаларга, күрсәтә белергә тиеш. Моның белән ул үзе дә бөтенсоюз әдәби-эстетик фикеренә кушылу юлында бер адым алга атлаячак. Бу юлда озак еллар дәвамында нәтиҗәле эшләп килгән тәнкыйтьчебез Р. Мостафин иде. Р. Бикмөхәммәтов эшчәнлеге дә аерым билгеләп узуга лаек. Һәм менә соңгы елларда аларга Флүн Мусин килеп кушылды. Ф. Мусинның «Правда» газетасы сәхифәләрендә чыгып килгән мәкаләләр циклы һәр яктан тәкъдир ителерлек зур хезмәт. Мактаулы хезмәт! Аларда, беренчедән, татар әдипләре иҗат иткән әсәрләрнең тугандаш әдәбиятлар гаиләсендәге урыны күрсәтелү әһәмиятле булса, икенчедән, «Правда»да татар тәнкыйтьчесенең ил күләмендәге әдәби күренешләр хакында фикер йөртүе — әдәби тәнкыйтебезнең абруен бермә-бер күтәрә.

Шулай да тәнкыйтебез бөтенсоюз киңлегенә чыгып, әдәбиятыбыз казанышларын тиешле югарылыкта һәм дәрәҗәдә эзлекле итеп пропагандалый башлады дисәк, бик ашыккан булыр идек. Р. Мостафин, Р. Бикмөхәммәтов һәм Ф. Мусин хезмәтләре бу юлда беренче карлыгачлар гына әле. Шунда ук әлеге карлыгачларның да кайвакыт бер канатлырак булып чыгуын искәрми калу ярамас. Мисал өчен, И. Нуруллин һәм Р. Мостафинның «Литературная газета»да басылган мәкаләләрендә, нигездә, сүзне татар әдәбиятындагы кимчелекләргә генә кайтарып калдыру әдәби җәмәгатьчелектә уңай яңгыраш тапмады.

Гомумән, тәнкыйтебезнең бөтенсоюз әдәби-эстетик критерийлары белән коралланып, әдәбиятны һәм үзен дә үзәк матбугат битләрендә активрак пропагандалавы көн кадагына баскан иң җитди проблемаларның берсе булып кала. Чөнки әдәбиятыбызның күпмилләтле совет әдәбиятлары гаиләсендәге урынын ачыкламыйча торып аның казанышлары һәм проблемалары хакында фикер йөртү һәм нәтиҗәләр чыгару — телибезме-юкмы, безне берьяклылыкка һәм төрле чикләнгәнлекләргә китереп чыгарыр иде.

Дөньяга материалистик караш һәм тарихи оптимизм белән характерланган, партиялелек һәм халыкчанлык принциплары белән коралланган, тугандаш әдәбиятлар гаиләсендә лаеклы урыны булган татар әдәбияты бүген дә үсештә, өзлексез хәрәкәтә. Аның сокландыргыч бай тарихы булган кебек, киләчәге дә зур — идея-эстетик офыклары киңәйгәннән-киңәя бара. Шул офыкларга нисбәтле рәвештә, әдәбиятның узаңы булган тәнкыйть алдында да яңа һәм тагын да җаваплырак бурычлар тора.

Мәсгут Гайнетдинов

# БЕТМӘС ГАМЕМ, НИДӘНДЕР БУ?

*Әбелмәних Каргалыйның тууына 200 ел тулу уңае белән*

Бай мираслы татар әдәбияты тарихында шагыйрь Әбелмәних Каргалый исеме күренекле урын алып тора. Әдәбиятыбыз яңаруга борылыш ясаган чорда иҗат иткән, аңа сизелерлек өлеш керткән каләм иясе булганга, замандашлары ук инде аның иҗатына игътибар иткәннәр. «Җаһанның җаһ, малы...» («Дөньяның югары дәрәҗәсе, малы...») дип башлана торган газәле якташы Һибәтулла Салиховны «шигъри җавап» язарга илһамландырган. Каргалыйның «Тәндә җаным»... дип башланган газәле нәширләр тарафыннан «җавап шигыре»нә кушылып, Һибәтулла әсәре үк булып киткән. XIX йөз татар шагыйрьләреннән беренчеләрдән булып, аның ун «көйле хикәяте» «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» исеме белән 1845 елда аерым китап булып басылып чыга. С. Кукләшев тә шагыйрьнең кайбер шигырьләрен «Диване хикәяте татар» дигән хрестоматиясенә кертә. Бу китап 1859 елда басыла. Әбелмәнихнең тугыз лирик шигыре, 1884 елдан башлап, «Өммикамал» дигән китапның азагында (кушымта рәвешендә) берничә мәртәбә басыла. Сакланып калган язма ядкарьләр Ә. Каргалый әсәрләренең кульязма хәлендә дә киң таралганлыгы турында сөйлиләр.

К. Насыйри[1], Риза Фәхретдинов, Җ. Вәлиди[2] кебек галимнәр Әбелмәнихнең «мәшһүр шагыйрь», «чын шагыйрь» булуын ассызыклап үтәләр. Р. Фәхретдинов шагыйрь биографиясенә кагылышлы кайбер белешмәләрне «Асар» дигән мәшһүр хезмәтенең дүртенче кисәгенә урнаштыра, әсәрләреннән үрнәкләр китерә дә: «Бу урында язылган шигырьләр һичбер җирдә вә һичбер гасырда йөз кызартачак шәйләр түгелдер», [3] — дип соклануын белдерә.

Әбелмәних Каргалый иҗатын фәнни нигездә өйрәнү совет чорында яңа баскычка күтәрелде. Күп кенә мәкаләләрендә Г. Ибраһимов аның иҗатына да туктала, Г. Рәхим, Г. Газизләрнең «Татар әдәбияты тарихы» китапларында Әбелмәних иҗатын анализлауга аерым бүлек бирелә. Сугыштан соңгы елларда М. Гайнуллин хезмәтләрендә шагыйрьнең тормыш юлы яктыртыла, иҗатына күзәтү ясала, мирасыннан аерым үрнәкләр тәкъдим ителә. М. Гайнуллинның «Татарская литература XIX века» (1975) китабы аша Әбелмәних иҗаты белән рус һәм илебездәге башка халыклар укучылары танышты.

Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәләмов 1782 елда Оренбург янындагы Каргалыда (Сәгыйд бистәсе) дөньяга килә. Әбелмәнихнең бабасы Габдессәләм XVIII йөзнең танылган галимнәреннән санала. Күптән түгел аның үзе иҗат иткән шигырьләр дәфтәре дә табылды. Габдессәләм Уразмөхәммәт улы — Казан артындагы Олы Мәңгәр авылында туган, Ташкичү, Абаш авылларында мулла һәм мөдәррис (мәдрәсә

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр, т. 1. 1974, 119 б.
[2] Вәлиди Җ. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912, 91–92 бб.
[3] Фәхретдинов Р. Асар. 4 нче китап. Оренбург, 1903, 203 б.

тотучы) булган. 1744—1745 елларда Казан ягыннан яңа төзелгән Оренбург янына күчеп утырган 200 гаилә арасында Габдессәләм дә була. (1747 елгы халык санын алу исемлегендә ул инде Каргалы кешесе булып язылган). Габдессәләм ахун мәгърифәтче-педагог буларак та шөһрәт казанган. Аны «остазы көлл» (бөтен халык укытучысы) дигән мактаулы исем белән атап йөрткәннәр. Әбелмәних бабасының бу даны белән горурлана, «Сәяхәтнамә»сендә һәм тагын берничә шигырендә:

**...Атасы — Әбелфәез, җәдде, бәнам,**
**Дәүредә, «остазы көлл Габдессәләм».**
**[Әтисе — Әбелфәез, бабасы — дәверендә**
**«һәммәнең остазы» исемен алган Габдессәләм].**

Габдессәләмнең 1755 елдагы Батырша восстаниесен хәзерләшүдә катнашуын күрсәткән фактлар да бар. Мәсәлән, Батырша үзе «Тәгъризнамә»сендә («Патшага хат»ында) Габдессәләм ахун шәкерте Габдесаттар аша Каргалының күренекле кешеләре белән бәйләнештә торуын әйтә; баш күтәрергә чакыру мөрәҗәгатен дә Оренбург ахуннары («бәтчә» Ибраһим һәм Габдессәләмнәр күздә тотыла) кушуы буенча язылганлыгын искәртә.[1]

Оренбург губерния канцеляриясенең: «Габдессәләм ахун белән Оренбургның Ибраһим ахуннары Батырша үз ягына аударды»,— дип сенатка язган хаты сакланып калган.[2]

Шул характердагы гаилә традицияләре булачак шагыйрь Әбелмәних карашларына да тәэсир иткән, билгеле. Аның әтисе дә үзенчәлекле тормыш кичергән, зур укымышлы кешеләрдән булса да, муллалык белән шөгыльләнмәгән, сука сөргән, иген иккән.

Әбелмәних укыган елларда Каргалы мәдрәсәләренең даны бөтен Идел-Урал буйларына таралган булган. К. Насыйри сүзләренә караганда, хәтта кайбер мөдәррисләр (Сәгыйд бин Әхмәт Шырдани, Габдерәхим Утыз Имәни һ. б.) үзләренең йөзләгән шәкертләрен калдырып, Каргалыга укырга киткәннәр.[3]

Әбелмәних шул мәшһүр мәдрәсәләрдә уку белән генә канәгатьләнми, Көнчыгыш культура үзәкләреннән берсе саналган Бохарага укырга китә. Биредә ул Г. Курсави укыган Ниязколый Төркмәни мәдрәсәсендә белем ала. Бохарада зур бәхәсләр кузгаткан бунтарь якташы Г. Курсави белән һәм аның әсәрләре, фикерләре белән Әбелмәних һичшиксез таныш булгандыр. Бу фактор аның үзенчәлекле иҗаты формалашуда да зур роль уйнаган булырга тиеш. Г. Курсави һәм Әбелмәних иҗатын бер үк тәңкәнең ике ягы дип карарга мөмкин. Г. Курсави иҗаты — иске схоластиканы нәфрәтләнеп кире кагудан гыйбарәт булса, яңарак чор кешесе Әбелмәних схоластиканы инкарь итеп кенә калмыйча, аның урынына прогрессив Европа мәдәнияте тенденцияләре килүен куәтли. Ул бөтен гомерен, эшчәнлеген, Көнчыгыш өчен гаять әһәмиятле, прогрессив хәрәкәтнең көчәюенә багышлый. Бохарада укыган елларда аның бу омтылышы, башлыча, бай Көнчыгыш культура мирасын иҗади өйрәнүдә, шул юнәлештәге киеренке эзләнүләрдә күренә.

Әбелмәних Бохарада 34 яшькәчә укый, үз чорының зур укымышлыларыннан санала. 1816 елда Бохарадан Мөхәммәтйосыф исемле кеше җитәкчелегендә Төркиягә җибәрелгән илчелекнең секретаре итеп Әбелмәних билгеләнә. Бохарада укуы, Төркиягә, аннан Каһирә аркылы Мәккәгә хаҗ сәяхәте турында кайбер мәгълүматларны Әбелмәних үзенең шигъри «Сәяхәтнамә»сендә яза. Төркия аша ул яңадан Каргалыга кайта.

Унбиш-егерме ел Каргалыда яшәп, кабат хаҗ сәфәренә чыгып китә. Бу сәфәрнең датасы да, шагыйрьнең кайда, күпме яшәп кайчан үлгәнлеге дә хәзергә билгеле түгел. «Хаҗи Мөхәммәт байга» шигыре азагындагы: «Мең дә сигез йөздә утыз өчтә ирер ушбу саль, бәрҗе июль ун көнендә ушбу хәл» (Бу ел — 1833 иде, июльнең унында бу хәл булды) дигән юллар — шагыйрь гомеренең безгә билгеле соңгы датасы.

---

[1] ЦГАДА (Центральный государственный архив древних актов), ф. 7, с. 6, 1781, 2 китап, 12, 13 бб.

[2] ЦГАДА, ф. 248, т. 113, с. 6, 1582, 1035, 1036 бб.

[3] Насыйри К. Курсәтелгән хезмәт, 119, 120 бб.

Әбелмәних Каргалыйның иҗат мирасы күләм ягыннан зур түгел. Моны, өлешчә, ул мирасның вакытында барланмавы нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Бүгенге көндә шагыйрьнең яңа әсәрләре табылып тору да шуны раслый. Аның югарыда телгә алынган «Сәяхәтнамә»сенә кергән ун шигъри хикәятеннән башка, сакланып калган вак шигъри әсәрләре егермедән артык түгел. Шуңа да карамастан, Әбелмәних иҗатында XIX йөз татар әдәбиятының төп тенденцияләре билгеләнә.

Әбелмәних Каргалый иҗатының үз тема-проблематикасы, үз аһәңе бар. Ул үзенчәлекләр шул чорның тарихи хәлләре белән бәйләнештә, конкрет җирлектә тикшергәндә ачыла.

Аның мәшһүр «Сәяхәтнамә»се бу яктан аеруча әһәмиятле. «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних...» китабының өченче хикәятенә кушымта итеп бирелгән бу өзек хәзерге хрестоматияләрнең һәммәсендә бар. Студентларга ул әдәбиятның дөньяви сюжетларга күчү үрнәге дип тәкъдим ителә. Мондый «хаҗнамә»ләр (хаҗ сәяхәтнамәләре) Әбелмәнихка кадәр дә, аның заманында да язылганнар. Әбелмәних әсәрләренең популярлыгы кемнеңдер аны үз вакытында әдәби әйләнешкә кертеп җибәрүеннән дә, аңарда тарихи-географик детальләр чагылудан да түгел. Бу «Сәяхәтнамә» — шул чор татар әдәбиятының күп кенә яңа мотивлар алып килгән кыйммәтле бер үрнәге. Әсәр авторның ватанын, нәселен хөрмәтләү сүзләреннән башлана:

**Шәһри Каргалый — фәкыйрең мәүлиди,**
**Өммәте Әхмәт, рәгъяти Мәскәви.**
**Атасы — Әбелфәез, җадде, бәнам,**
**Дәүредә, «остазы көлл Габдессәләм».**

Бу юлларда инде гадәти «хаҗнамә»ләрдә булмаган яңалык бар. Шагыйрь күренешләргә шәхси мөнәсәбәт мотивын көчәйтеп, традицион әсәрне яңа заман лирикасына таба бора. Бу — ул чор өчен зур казаныш. Ләкин «Сәяхәтнамә»нең әһәмияте моның белән генә чикләнми. Автор үзен «ислам илләре» (Төркия, Мәккә һ. б.) үзәгенә куеп сөйләгәндә, «Әхмәт (Мөхәммәт) өммәте» икәнен билгеләгәндә, әһәмиятле бер факт итеп, «Мәскәү рәгъяте» (Мәскәү иле гражданы) икәнен дә ассызыклап үзә. Бу — Россияне уртак ватан итеп тану идеясенең, яңа патриотизм хисенең татар әдәбиятында күзгә күренеп көчәюен раслаучы факт.

«Сәяхәтнамә» дә шундый ук мөһим тагын бер яңалыкка игътибар ителә. Шагыйрь үзенә Бохара илчелеге вәкиле буларак, Төркиядә зур илтифат күрсәтелүен сөйли (бу аңа Каргалыдагы Гобәй бай, хаҗи Мөхәммәт бай кебек обывательләр алдында үзенең абруен раслау өчен дә кирәк. Әмма ул төрек солтанына мәдхия җырламый; киресенчә, Төркиягә буйсынудан баш тарткан Мисыр хакиме Мөхәммәтгалигә мәдхия (мактау) язә. Мөхәммәтгали (1769—1849) Төркия армиясе составында Мисырда Наполеон яуларына каршы сугышта катнаша. 1805 елда, Төркия хакимлегенә каршы күтәрелгән восстаниегә таянып, Мисырда властьны үз кулына ала, 1807 елда инглизләрнең Мисырга һөҗүмен кире кайтара. Мөхәммәтгали хөкүмәте ил эчендә дә нык тәртип урнаштыра.

**Рәи тәдбире илә, ул хуш хисал**
**Мисыр милкен забыт кыйлмыш. Туп мисал**
**Кичерүбән тыйгыдин баш-башларын,**
**Әйләмеш рам һәб гарәп сәргәшләрен,**

ягъни: тәвәккәллек күрсәтеп, ул күркәм кеше Мисыр дәүләтен үз кулына алган. Башларын кылыч белән туп шикелле тәгәрәтеп, гарәп буйсынмаучыларын (феодалларын) һәммәсен буйсындырган,— дип Мисыр хакименең бу кыюлыгын яклап чыга. Әбелмәних Мисыр аша узган елларда Мөхәммәтгали илне артталыктан чыгару юнәлешендә актив эш алып бара. Моңа ул Европа казанышларын үзләштерү аша ирешмәкче була: Европа гыйлемен, техникасын, сугыш фәнен үзләштерер өчен, күп Мисыр яшьләрен, дәүләт хисабына, Европа илләренә укырга җибәрә; Европа завод-фабрикаларына охшаш завод-фабрикалар кордыра һ. б. Әбелмәних Мөхәммәтгалинең бу чараларын артта калудан котылуның реаль юлы итеп күрә. Фәндә,

техникада Европага йөз тоткан кешене яклап язып чыга. Бу Г. Курсави тәнкыйтьләгән урта гасырчылык схоластикасын тормышта нәрсә белән алыштырырга соң? — дигән борчылулы сорауга конкрет җавап иде. Татар әдәбиятында бу алдынгы фикер, мәдәниятне, җитештерү көчләрен европалаштыру проблемасы рәвешендә, Г. Чокрый хаҗнамәсендә (1879), М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестенда сиксәненче елларда гына бөтен кискенлеге белән кабат калкып чыга.

Әбелмәних шул чорда җәмгыятьчелекне борчыган һәрбер проблеманың реаль, тормышчан чишелеш рәвешен табу һәм гәүдәләндерүне эстетик максат итеп куя.

Мәсәлән, Әбелмәнихнең ватанына кайтуы татар укымышлылары арасында кызу бәрелешләр барган чорга туры килә. Әлеге бәрелешләрнең башлануына Екатерина II нең 1789 елда мөселман дин оешмалары һәм руханилары белән җитәкчелек итү өчен «Диния назараты» дигән оешма төзүе сылтау була. Укымышлылар мулла булыр өчен шул Диния назаратына барып, патша билгеләгән мөфти, мөфти куйган казыйлар алдында имтихан бирергә тиеш булалар. Ә имтиханга барыр өчен, мулла булырга, торган җирдәге бар халыктан имзалар белән беркетелгән карар һәм өяз полиция башлыгыннан ризалык кәгазе алу кирәк. «Бу чаралар муллаларны полиция шымчысына әйләндерү өчен кертелгән» дип, күпчелек руханилар («абыз агайлар») указ алуга барудан баш тарталар. Халык указ алып килгән муллаларны кабул итми, абыз агайларны яклап чыга. Шул рәвешчә, укымышлылар арасындагы каршылык халык азатлык хәрәкәтенең бер күренешенә әйләнә. Аның башында Г. Утыз Имәни, Т. Ялчыгол кебек язучы укымышлылар торган. Г. Утыз Имәни указ алган муллаларны «наданнар», «җинаятьчел элементлар» дип фаш итеп шигырьләр яза. Мөфти исә мондый каршылык күрсәткән укымышлыларны имамлыктан куа. Шул хәрәкәттән читләштерер өчен, унынчы елларда күп санлы кулга алулар, юк сәбәпләрне бар итеп хөкемгә тартулар башланып китә... Менә шундый шартларда ватанына кайтып төшкән Әбелмәних әтисе кебек үк, указ алырга бармый, абыз агайларга кушыла. Аның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних...» китабына кергән «көйле хикәят»ләре дә абыз агайларны яклап язылганнар.

«Хикәят»ләрнең проблематикасы түбәндәгечә:

I хикәят (дөресрәге, бер бүлек: ул үзе дүрт-биш мәсәл-хикәяттән тора). Чорга поэтик характеристика. Автор акчаны дәһшәтле көч итеп сурәтли (ике мәсәл-хикәят), комсызлыкны фаш итә, юмартлыкка өнди.

II хикәят.— Шәмсунның үтерелүе. Беренче хикәяттәге проблеманың дәвамы: акчаның тиңсез көчләрне дә богаулата, үтертә алуы турында.

III хикәят. Саба шәһәре һәлакәте. Бозыклык юлына баскан җәмгыятьнең котылгысыз һәлакәткә юлыгуы турында.

IV хикәят. Габделкадир Киляни һәм мөрите. Гадәттән тыш галимлек кенә кешеләрне (бу шартларда) хакыйкать юлына тарта ала дигән фикер үткәрелә.

V хикәят. Зөннун Мисри һәм мөрите. Шул типтагы гыйлемгә ия җитәкченең бар сүзенә, боерыгына колак салу тиеш, чөнки ул яхшы нәтиҗәгә китерәчәк.

VI хикәят. Габделкадир Киляни һәм ятимә карчык. Мондый җитәкчеләр кешегә тормыш авырлыкларыннан да, фаҗигадән дә котылуда ярдәм итә алалар.

VII хикәят. Ибраһим Әдһәмнең патшалыктан ваз кичүе. Бу галимнәр эшчәнлеге нәтиҗәле булсын өчен, алар боерыгына тулы буйсыну тиеш. Тик бу буйсынуның гадәттән тыш авыр эш икәнлеге бәян ителә.

VIII хикәят. Рум (Византия) һәм Чин (Кытай) осталарының ярышы. Автор тыштан гына «яхшылык белән бизәнү»не («әһле заһир» булуны) фаш итә, мондыйларны — «күңелләре — таш, колаклары — саңгырау нәрсәләр» ди, ихлас күңелдән яхшы булуны яклый.

IX хикәят. Шәех Мансур Гомәр һәм патша. Тормыштан йөз чөереп тулысынча аскетлык юлына китү гөрләп торган шәһәрне харәбәгә әйләндерә.

X хикәят. Яман кәсеп белән мал табучы чибәр хатын һәм аңа гашыйк изге ир турында. Изгелеккә турылыклы калу бозык хатынны яхшылык юлына чыгара.

Хикәятләрнең унысы да дини-мифологик сюжетка корылган. Бу яктан караганда, шагыйрьнең әсәрләре әле урта гасырчылык чикләрендә кала. Аның дөньяга карашы да дини-идеалистик. Бу сюжетларның дини чыганаклардан — «Тәфсире кәбир» (Корьән

аңлатмасы) һәм имам Газалинең (1057—1111) «Мишкат-эл-әнвар» («Нурлар чыганагы») дигән китапларыннан алганлыгын автор үзе дә билгеләп үтә; тыйнаклык күрсәтеп, бу әсәрләрен «тәрҗемә» дип атый. Бу «тәрҗемә»не хәзерге мәгънәдә аңларга ярамый. Ул бирелә, әлбәттә, сюжетларның чыганагын күрсәтүче искәрмә генә. Әбелмәних иҗатының татар әдәбияты өчен әһәмияте — Көнчыгышның традицион, популяр сюжетларын шул чор татар тормышындагы билгеле хәлләргә киная итеп эшләвендә, шул рәвешле, тормыш, көн проблемалары тирәнлекләренә үтеп керүендә.

Төп әдәби проблемаларда Әбелмәних шулай ук эзләүче, табучы, искәртүче шагыйрь булып кала. Г. Утыз Имәни шигырьләрендә, бәхәс кузгаткан мәсьәләләргә үз карашын дәлилләү рәвешендә, әсәрнең сәнгатьчәлеген күләгәле торган күп детальләр һәм детальләштерүләр китерелә, шигырь-трактат төсен ала иде. Шигъри әсәрнең сәнгатьчәлеген болай тоныкландыру белән Әбелмәних килешә алмый. Ул проблеманы атау, дәлилләү кебек моментларны әсәргә кертми, аны киная, лирик мөнәсәбәт аша гына төсмерләндерә. Әсәрдә сюжет мөмкинлекләре шактый тулы файдаланыла. Шундый эзләнүләр нәтиҗәсендә шагыйрь яңа заман лирикасына якынлаша.

Әбелмәних — кеше рухының тынгы тапмас бөеклеген җырлаучы шагыйрь:

**Бөтен дөнья бәнем улса**
**Гамем бетмәс,— нидәндер бу!**
**Әзәлдә гамь торабилә**
**Яратылмыш бәдәндер бу!**[1]

Аракчеев реакциясе елларында бөек Пушкин: «Товарищ, верь, взойдет она — звезда пленительного счастья»,— дип, якты киләчәккә ышаныч белдерә.

Нәкъ шул чорда, Декабристлар күтәрелешеннән соңгы кара реакция елларында, Әбелмәних тә үз халкына (билгеле сәбәпләр тәэсирендә, берникадәр дини төсмер кертеп) шундый ук сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

**Холус үзрә йөре,— мөшкелләре асан идән — улдыр.**
**Тәвәккәл әһленә ихсан ки, мәүля би хисап әйләр.**
**Сакын, бәхре гамь — аләмә гавас улма, сабыр әйлә,**
**Ходай — мөстәган, әлбәттә, бер көне фәтхе баб әйләр.**
**Хәзин улма бу дөнья кимлегенә гамь белә, әй яр,**
**Хода бер көн кара бәхетең синең һәм мәһитаб әйләр.**

Мәгънәсе: «ихлас (саф) күңел белән йөр, авырлыкларны җиңел итүче — алла (гына ич), тәвәккәлләргә ярдәмен ул хисапсыз бирә. Саклан, гамь — хәсрәт диңгезенә чумма, сабыр ит, ярдәм өмет иткән ходаң бер көн «бәхет» капкаларын ачар. Бу дөнья кимчелекләреннән бу кадәр кайгылы-гамьле булма, дус-хода бер көн синең дә кара бәхетеңне тулган ай кебек (тулы һәм якты) итәр».

Әбелмәнихнең лирикасы — катлаулы, каршылыклы күренеш. Аның лирик әсәрләрендә дә, нигездә, урта гасыр традицияләре әле нык сизелә. Ул мәдхиләр, мәрсияләр яза, газәлгә тартым шигырьләре исә суфичылык лирикасын хәтерләтә. Шул ук вакытта бу әсәрләрдәге яңа замана авазлары да укучыларга ачык ишетелерлек яңгырыйлар. Мәсәлән, «Мәдхе расүл» кебек үтә традицион әсәр дөньяви ызгыш сүзләре белән тәмамлана. Замана байларын «таш бәгырьле үлексәләр» дип атап, шагыйрь үзенең әсәрен:

**...Бу гарибе коллары бабына мохтаҗ кыйлмая,**
**Җөмлә өммәт нитняҗыны дешермая хода,**
**Кем хосусән таш бәгырьле би хиссият мордая!**

— дип бетерә.

---

[1] Сүзлек: эзәл — мәңгелек, торабилә — туфрагыннан (туфрагы белән).

Авторның суфи әдәбиятына тартым фәлсәфи лирикасы гасыр урталарында көчле шигъри яңгыраш тапкан Ш. Зәки лирикасының аккордлары булып тора. Бу әсәрләре белән ул яңаруга йөз тоткан татар лирикасына (аның Ш. Зәки этабына) шигъри-эмоциональ дулкынын, аһәңен, сурәт-образлар системасын табып бирә. «Шикаят» («Зар») шигыре моңа ачык мисал.

**Җаһанның җаһ, малы нәфсә гаять тә хәсәндер бу,—**
**Вәли, мәгънән,— җәһәннәм суига каид рәсәндер бу.**
**Үзене дөхтәри душизә кеби күстәреп, дөнья,**
**Фркфтә әйләев чуклары, мәгәр-пирәзәндер бу.**
**Горусе нәү идеб кәнден, нәчә дөрлү виреп тәзиин,**
**Нәчә данае дәменә грифтар әйләяндер бу.**
**Боның мәкр илә эленә иремшәз фикре фазыйллар,**
**Нәчә галимнәрнең гыйльмен һәбая иргезгәндер бу.**
**Боның тәзвиренең бере-беренә биңзәмәз, һәр гиз,**
**Нәчә заһидларың әгъмалене бадә вирәндер бу.**
**Боның җаһ илә малына, гаҗәп, алданамы гакыйл! —**
**Сәрасәр, робгы мәскүнне дотанлардан кичәндер бу.**
**Әя, мискин Мәних, үммә сафа бу бивафадан сән,**
**Сорурың беренә — бең җәфа бәхш әйләяндер бу!**

Хәзерге әдәби телдә юлга-юл тәрҗемәсе:

**Дөньяның дәрәҗәсе, малы нәфсегә гаять гүзәл күренә,**
**Ләкин, асылда, җәһәннәмгә сөйрәүче җепләр алар.**
**Үзен яшь кыз кебек күрсәтә дөнья,**
**Күпләрне алдап, ләкин карчык бит ул.**
**Яшь килен итеп үзен, ничә төрле бизәкләр бизәнеп,**
**Ни кадәр акыллыларны итәгенә тоткын иткән ул.**
**Моның мәкеренә-эшенә галимнәр акылы җитми,**
**Күпме галимнәрнең гыйлемен бу үзе тузанга очырган.**
**Моның алдаулары бер-беренә охшамас һич тә,**
**Ничә изгеләрнең гамәлен җилгә очырган бу.**
**Гаҗәп, акыллы кеше моның дәрәҗәсенә, малына алданамы!**
**Бөтен җир шарын кулында тотканнардан да йөз чөергән ич ул.**
**Әй, мескен Мәних, рәхәт өмет итмә бу ышанычсыздан син,**
**Бер шатлыкка мең җәфа бүләк итүче ич ул.**

Шагыйрь үзе яшәгән, шәфкатьсез реакция аяк астында тапталган дөньяны, аның хәтта дәрәҗәләрен, малын-рәхәтләрен дә кабул итә алмый, намуслы кешеләр исеменнән шул хакта аваз күтәрә.

Әбелмәних идеалга омтыла, тормыш гармониясен тели, эзли, әмма аны үзе яшәгән җәмгыятьтән таба алмый. Авторның идеалга якты ышанычын табигать гүзәллеген сурәтләгән «Сәхрәдән кайткач» дигән шигырендә күрергә була. Гүзәллекне сурәтләүдә тормыштан (табигатьтән) мисал табу аны урта гасырчылык традицияләре тоткынлыгыннан азат итә, яңа заман лирикасы киңлекләренә чыгара. «Сәхрәдән кайткач» шигырен, дөрестән дә яңа әдәбиятыбызны башлаган әсәрләрнең берсе дип атарга мөмкин.

**Ушбу көн вармыш идем сәйран өчен сәхрә тараф.**
**Күп гүзәл улмыш чәмәннәр, ләләзар улмыш шәрәф.**
**Бер тарафта, куке: «Кәк-кук!» диюбән нәлан идәр,—**
**Әһле дәртнең хушыны гарт идәр, талан идәр.**
**Суфи-тургайлар дәмә-дәм күкләре җәүлан идәр;**
**Бүдәнә — җирдә торып, үрдәк — суда тайран идәр.**
**Торналар — тормас, очар; казлар — карар итмәс, качар.**
**Былбылы — диваналар гөлләр өчен яшен сачар.**

Күл эчендә бакалар: «Бак!» — дию җәүлан идәр,
Бер тарафтан, дәхи, тартай: «Тарт!» — дию налән идәр.
Үлән эчендә, чикерткә төрле авазын чалыр;
Черки илә сури чебен «тыз» лаюб мазаң алыр.—
Һәм бере — нәгъмә, нәвасыны кылып авазын чалыр,
Сәрви кад дилбәрләрең кальбендәге назын алыр.—
Шуйлә дилкәш, буйлә хөррәм, моңча гыйззәтле һава,—
Бәс, моныңдик дилкәшәдә чикмәсеннәрме нәва!! [1]

Зур шагыйрь буларак, реакция елларын Әбелманих бик авыр кичерә. Реакция аның иҗатына аеруча көчле басым ясый: ул азатлык хәрәкәте белән бәйләнешле зур темалардан китәргә мәҗбүр була. Әмма бу китү белән дә ул әдәбиятка хезмәт итәрлек рухи көч тапкан. Ә. Каргалый интим хисләрне җырларга керешә: «Галәм әйванында...», «Лятифә» («Мәзәк,— берәүнең хатыны белән сөйләшүе») кебек мәхәббәт шигырьләре, «Сәхрәдән кайткач» кебек пейзаж лирикасы әсәрләре иҗат итә. Шагыйрьнең мондый әсәрләре кеше хис-кичерешләрен сурәтләү юнәлешендә яңа традицияләр формалашуында әдәбиятыбызның мөһим казанышларын чагылдыра. Мәхәббәт лирикасы XVIII—XIX гасыр татар әдәбиятында шәкерт фольклорына тартым формада яшәп килә. XIX йөзнең 20—30 елларында (ягъни Әбелманих белән бер вакытта), Г. Кандалый кебек шагыйрьләр дә мәхәббәт лирикасына мөрәҗәгать итәләр. Г. Кандалый бу өлкәдәге иҗатында, башлыча, шәкерт фольклорына тартым традицияләргә таяна. Аңардан аермалы буларак, Әбелманих мәхәббәт һәм пейзаж лирикасын үстерүдә классик поэзия традицияләре юнәлешендә эзләнүләр алып бара.

Яңа идеалларның эчтәлек төсмерләрен ачыклау, билгеләү, шул юнәлештә эзләнүләр — шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләрен башка замандаш әдипләреннән аера торган сыйфат. Аның бу өлкәдәге казанышлары әдәбият һәм иҗтимагый фикер тарихында җитди әһәмияткә ия.

Ә. Каргалый шулай ук искелекне тәнкыйтьләү, инкарь итү өлкәсендә дә зур, нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтә. «Тәрҗемәи хәжи Әбелманих...» китабының беренче хикәятендә шагыйрь акчаның (байлык хаким көч булган җәмгыятьтә) дәһшәтле көч икәнен фаш итү юнәлешендә зур бер адым ясый. Аның бу казанышы да, Заһир Бигиев романнарына кадәр, кабатланмас очрак-уникаль күренеш булып кала.

Кыскасы, XIX йөз азагы, XX йөз башы татар әдәбиятында көчле яңгыраш тапкан күп проблемалар, башлап, ялгыз-берә рәвешендә, Әбелманих Каргалый иҗатында күренәләр. Шагыйрь шул чор татар тормышындагы мөһим тарихи тенденцияләрне тирән сиземләп яши, татар иҗтимагый хәрәкәтенең уртасында кайный, шул тарихи тенденцияләр һәм иҗтимагый дәртләр чагылышын шигъри образга, шигъри әсәргә әверелдереп бара. Бу үзенчәлекләр җәмәгатьчелек игътибарын кабат-кабат аның мирасына юнәлтә, аның иҗатын татар әдәбияты тарихының нигез күренешләреннән берсе итеп таныта.

Борчылып, тарихи үсеш-прогресс юлын эзләгән, халкын шул юлга чыгару өчен көрәшкән, шул олы максатларны үзенең кешелек бурычы итеп — дөнья бәясе торырлык гүзәл гамь итеп яшәгән батыр җанлы шагыйрь ул Әбелманих Каргалый. Шуның өчен дә аның исемен без бүген зур ихтирам белән телгә алабыз.

---

[1] Сүзлек: чаманнәр — болыннар, шәрәф улу — асыллану, налән иду — [illegible], тарт иду, талан иду — талау, дәм-дәм — туктаусыз, җәүлан иде — гизү, тайран иду — очу, дахи — шулай ук, авазын чалыр — аваз белән көйләр, нәгъмә-нава — җыр-моң, сәрви кад — зифа [illegible], дилбәрләрең — гүзәлләрең, дилкәш — җанга хуш, хөррәм — хуш, шат.

# ҮЗ ЙӨЗЕН САКЛАП

Казакъ язма әдәбиятына нигез салучы Абайның исеме инде күптән милли чикләрне атлап узды һәм дөньяның төрле тарафларында танылды, әсәрләре дистәләгән телләргә тәрҗемә ителде.

Югары социаль катлам вәкиле Конанбай гаиләсендә тууына һәм үзе дә күпмедер вакыт волость башлыгы хезмәтен башкаруына карамастан, шагыйрь яшьтән үк гади халыкка тартыла, наданлык һәм җәбер-изүләргә каршы көрәшә башлый. Аның шигъри таланты искергән гореф-гадәтләрне, зарарлы дини кануннарны фаш итә, хатын-кыз иреген бууга протест белдерә, комсыз байларны, ришвәт сөюче икейөзле түрәләрне камчылый. Шагыйрьнең волость башлыгы Көлембай исеменнән язган:

**Көчлеләрем сүз әйтсә,**
**Баш изим чебен кугандай.**
**Ярлы сүзен җик күрәм,**
**Күңелем кабул кылаалмый,**

— кебек юлларында турыдан-туры сыйнфый тигезсезлек фаш ителә. Абай һәрвакыт хезмәт ияләрен мәхәббәт белән сурәтли, аларның бәхетен эштә һәм белем алуда күрә. Иҗаты һәм халыкны кайгыртуы белән ул әзербайҗанның Ахундовы, грузинның Чачавадзесе, әрмәннең Абовяны, безнең Тукаебыз шикелле атаклы демократ язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре сафына баса.

Казагыстанның үз иреге белән Россиягә кушылуына 250 ел тулу тантаналары алдыннан, шушы бердәмлеккә чын күңелдән бирелеп хезмәт иткән зирәк фикер иясе, кыю җәмәгать эшлеклесе Абай белән тагын да киңрәк кызыксынуыбыз табигый. Бу ихтыяҗны канәгатьләндерү һәм әдәбиятларыбыз бәйләнышын ныгыту йөзеннән Татарстан китап нәшрияте укучыларыбызга тәкъдим иткән күләмле җыентык бик вакытлы һәм күркәм бүләк булды.

Дөрес, Абай әсәрләре элек тә татар телендә басылды — вакытлы матбугатта, җыентыкларда дөнья күрде, 1947 елда исә аерым китап итеп тә чыгарылды. Әмма газета-журналларда һәм нәни генә китапта бирелгән ул тәрҗемәләр бөек шагыйрь иҗатын тулы һәм дөрес күзаллау ягыннан да, халыкларыбыз арасындагы дуслыкны тиешенчә үстерү җәһәтеннән дә безне канәгатьләндерми иде. Бигрәк тә казакъ кардәшләребез татар әдәбиятын даими һәм

[1] Абай. Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз. Казан, 1981

кулләп чыгарган вакытта. (Алар Тукай әсәрләрен генә инде алты мәртәбә китап итеп бастырдылар: балаларга сурәтләр белән бизәп, олыларга күләмле сайланмалар рәвешендә җыйнап. Тагын аерым басма итеп, аннары Сәгъди, Шиллер, Петефи, Мицкевичләрне эченә алган «Бөек шагыйрьләр китапханәсе» сериясенә кертеп...)

Абай — казакъ әдәбиятында әле бүген дә кәндәше күренмәгән шигырь остасы. Ул милли шигъриятне яңа эчтәлек белән генә түгел, яңа формалар белән дә баета. Казакъ әдәбиятына алты һәм сигез юллыкларны беренче мәртәбә Абай кертә. Шагыйрь үз әсәрләренең үлчәме төзеклегенә, музыкаль яңгыравына нык игътибар итә, бай эчке рифмалар барлыкка китерә. Казакъ телендә инверсия дә бездәгегә караганда активрак һәм күп баскычлырак. Абай моңа аеруча оста. Менә шунлыктан, телләр үзара якын булса да, бай һәм нәфис ритм-рифмалар файдаланып, югары шигърият үрнәкләре тудыра алган Абайны татарча лаеклы төстә яңгырату тәрҗемәчеләр өчен бер дә ансат эш түгел...

Шунысы күңелле, китаптагы тәрҗемәләрнең барысы да төп нөсхәдән эшләнгәннәр. Мәхмүт Максуд, Әхмәт Исхак, Нури Арслановлар бу өлкәдә мул тәҗрибә туплаган кешеләр. Нури Арсланов һәм Мәхмүт Хәсәен үзләре дә Казагыстанда туып үскәннәр, кардәш халыкның телен, моңын ана сөте белән диярлек сеңдергәннәр. Башкалар да тугандаш республикада булып, дала тормышы, казакъ әдәбияты белән күптән танышлар.

**Мин язмыймын җырларымны ирмәк өчен —**
**Юк-бар әкият-фәлән сөйләп бирмәк өчен.**
**Язам күңеле уяу, сизгер, теле йөгерек**
**Чичән яшьләргә фәкать бер үрнәк өчен...**

**Хәйләсез, күзгедәй саф күзләр кара,**
**Баккан саен йөрәккә ялкын сала,**
**Ак төнле, ачык йөзле, энҗе тешле...**
**Очрадымы сиңа шундый бер кыз бала!**

«Мин язмыймын җырларымны ирмәк өчен», «Аркасында беләктәй кара толым» шигырьләреннән китерелгән югарыдагы өзекләр татарча яңгырау белән бергә, Абайның уйлау хасияте, рухи халәте, сурәт «коюы» үзенчәлеге саклануга да мисал. Оригинальгә тиң мондый нәфис, оста тәрҗемәләрне Нури Арсланов байтак эшләгән. «Киң илем, казагым-ай, хәйран йортым», «Нинди үкенеч, күп гомерләр киткән үтеп» кебек шигырьләрне укыганда чын-чыннан канәгатьләнү хисе кичерәсең. Аларда мәгънә төгәл сакланган, ритм-рифма һәм моң да колакка ятышлы, авторның стиле дә бозылмаган. Бу урында өлкән шагыйрьләребез уртак хәзинәбезгә кергән, әмма соңгы чорда бездә сирәгрәк кулланыла башлаган кайбер төрки сүзләрне кире әдәби телебезгә кайтаруын да әйтеп китәргә кирәк.

**Сәламем ал, каләм каш,**
**Фида сиңа мал һәм баш.**
**Өзелеп сине сагынганда**
**Ага күздән кайнар яшь.**

**Акылсыз би булмас,**
**Шәүләсез өй булмас,**
**Йөрәге сап-салкын**
**Кешедә ми булмас.**

«Егет сүзе», «Күземнең карасы» шигырьләреннән китерелгән югарыдагы мисаллар Мәхмүт Максуд тәрҗемәләренең дә оригинальгә тиңлеген раслый ала. «Кыз сүзе», «Бай бик саран», «Үлсәм, миңа салкын гүр тыгыз булыр» әсәрләре дә рәхәтләнеп кабул ителә. Мондый уңышлы юллар башка тәрҗемәчеләр эшендә дә җитәрлек табыла. Бу урында, мәсәлән, Мәхмүт Хәсәен әйләндергән «Абдрахман авырып ятканда» шигырен дә Абай иҗатының татарча матур яңгырашы итеп билгеләп узасы килә.

**Мин язган хат бассын**
**Әрнүен җанының.**
**Тилмертмә, кайт тизрәк,**
**Яхшырса саулыгың.**

**Без сине көтәбез**
**Иртән дә, кичен дә.**
**Син газиз, син якын**
**Барыбыз өчен дә!**

Тәрҗемәләре белән кайбер чәчмә әсәрләрен истә тотмаганда бу китап классик язучының барлык иҗатын диярлек үз эченә ала. Тулаем бәяләсәк, акынның шигырьләре һәм поэмалары авторга зур мәхәббәт һәм ихтирам күрсәтеп, профессиональ югарылыкта башкарылганнар. Аларда үткән гасырдагы казакъ тормышының кайнар сулышы сизелә, ярсу йөрәкле шагыйрьнең дәртле хисләре, хәсрәте һәм нәфрәте, юанычы, куанычлары безне дулкынландыра. Шагыйрьнең җорлыгына, тапкырлыгына, сүзләрне асылташлар кебек балкыта белүенә, кабатланмас сурәтләр ясый алуына сокланабыз. Әче сатирасы,

йомшак юморы күңелне били, гүя татар шагыйре иҗат иткәнмени, аңлап, якын күреп укыйбыз.

Абайның прозасын җыентыкны төзүче Лирон Хәмидуллин татарчалаштырган. Ул әсәрләрнең берничә редакциясен, шул исәптән, русча басмаларын да күздән кичергән, авторның хикмәтле сүзенә аваздаш татар мәкальләрен, әйтемнәрен дә яңадан карап чыккан. Үзенчәлекле фикер иясенең тапкыр сүзләрен, йөгрек уйларын төп нөсхәдәгечә бирергә тырыша һәм шактый уңышка ирешә.

Әлбәттә, тәрҗемәне тагы да яхшыртасы җирләр бар әле. Төгәлрәк, шигъри прозаны оригинальгә якынрак һәм, бигрәк тә, автор стилен саклабрак тәрҗемә итү, сүзне бәрәкәтле куллану җәһәтеннән Л. Хәмидуллин тарафыннан барысы да эшләнгән дип әйтеп булмый. Әмма, шул ук вакытта, күп яшәгән ил агасының гыйбрәтле тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы, белеме һәм әхлакый төшенчәләре чагылган Абай прозасы татар укучысына барып җитәрлек итеп һәм аның уйларына азык, хыялына җим, тойгыларына тәм бирерлек дәрәҗәдә тәкъдим ителгән.

«Абайның шигъри мирасына өстәп прозасы бирә торган, һәр заманда бәһасе җуелмый торган бер зур кыйммәтле хәзинә бар,— ди Мохтар Әүэзов.— Ул — Абайның шушы прозаны язган теле. Шигырьләрендә үзенең барлык матурлыгы, яңалыгы, осталыгы буенча казакъ теленең сыйфатын әдәби тел дәрәҗәсенә күтәргән олы тарихи хезмәте нинди булса, прозасының теле белән дә Абай шушындый ук хезмәтне безнең мәдәният тарихыбызга мул сеңдерде». Хәзер татар укучысына да мәшһүр казакъ язучысының әнә шул мускуллы, җыйнак, сыгылмалы, образлы теленең куәтен чәчмә әсәрләр аша да тоярга мөмкинлек туды.

Туган телебезгә хәзер инде байтак классик шагыйрьләр тәрҗемә ителде. Пушкин, Руставели, Нәваи, Мәхтүмколый, Шевченко, Туктагол һ. б.... Болар — рус һәм дөнья әдәбияты осталары. Туган телебездә икенче тормыш тапкан менә шул әдәбият җәүһәрләре сафына куеп карасак, Абайның яңа томы чын мәгънәсендә куандыра. Шагыйрьне барлыкка китергән халыкның хәяте, иксез-чиксез дала табигате, төсләр балкышы, теленең кабатланмас бизәкләре һәм «хуш-исе» саклану һәм аны түкмичәчми, уңдырмый, суытмый татар укучысына китереп җиткерү ягыннан да, «киң иле, казагы-әй, хәйран йорты» өчен йөрәге ачыргаланган, аның шатлыгына куанып, кайгысына хәсрәтләнеп яшәгән олы җанлы Абайны бөтен барлыгы белән күз алдыбызга бастыра алуы җәһәтеннән дә бу китап тәрҗемә сәнгатебезнең җитди казанышы.

Китапны ябып куяр алдыннан тагын бер мәртәбә ике тугандаш халыкның күптәнге үзара багланышлары турында уйланасың. Абай тормышы үзе генә дә моңа бик матур мисал була ала. Абай Семипалатинскида Әхмәт Риза мәдрәсәсендә өч ел буе татар мөгаллиме Габделҗаббардан белем ала һәм бу — шагыйрьнең үз гомерендә укыган берләнбер уку йорты. Туган авылында ул тагын якташларыбыз Габитхан, Мөхәммәткәрим һәм аның улы Мәхмүт белән дуслаша, алардан гыйлем ала, җөмләдән, татар теле һәм әдәбиятын да өйрәнә. Менә шушы кешеләр аның әсәрләрен язып алып, киләсе буыннарга тапшыруда күренекле роль уйныйлар. Акынның беренче җыентыгын 1909 елда Петербургта, икенчесен Октябрь революциясеннән соң Казанда татар нәширләре бастыра. Абай көйләренең иң яхшы язмаларын якташыбыз Латыйф Хәмиди халыктан теркәп ала, соңыннан ул Ә. Җобанов белән бергәләп беренче казакъ милли операсы «Абай»ны иҗат итә. Икенче якташыбыз — СССР халык артисты Ришат Абдуллин гомере буе Абай үләңнәрен җырлый һәм югарыда телгә алынган операда Абай образын гәүдәләндерә. М. Әүэзовның «Абай» романына беренче сурәтләрне дә танылган рәссамыбыз Бакый Урманче иҗат итә, алар татар телендә ике мәртәбә басылып чыга. Һәм менә хәзер, СССРның 60 еллыгы алдыннан, Абай әсәрләре туган телебездә яңадан дөнья күрде. Аңа М. Горький һәм Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким кереш сүз язган, Надыйр Әлмиев пөхтә, зәвыкълы итеп авторның портретын ясаган, җыентыкның тышлыгын бизәгән.

Тәрҗемәчеләребез һәм китап нәшриятыбызның уртак тырышлыгы белән барлыкка килгән бу китапны мәшһүр казакъ шагыйре иҗатын меңләгән укучыларыбызга танытуда уңышлы адым дип, тугандаш халыкларның дуслыгын һәм хезмәттәшлеген үстерүгә кертелгән күркәм өлеш итеп, багланышларыбызның логик дәвамы һәм җимешле нәтиҗәсе итеп санарга тиешбез.

Тәүфикъ ӘЙДИ.

# ТӨСЛӘР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

Әхәт Гаффарның яңа китабы[1] дөнья күрде. Анда егерме хикәя тупланган. Яшь язучы укучыга егерме очрашу вәгъдә итә.

Ә. Гаффар күренешнең күзгә кинәт кенә чалынмый торган якларын, хасиятләрен, сурәтнең нечкә нәкышләрен күрергә теләүче, төпченеп, кайтып-кайтыбрак караучыларга исәп тота. Ул ашыккан җиреңнән туктатып, әйләнә-тирәнә, тормышның күп төрле бизәкләренә күз салырга, уйланырга чакыра. «Ак каен дегете», «Кояшның салкын чагы», «Пәрәвезле көзнең бер чите», «Ләкләк», «Бер йотым су» — бу исемнәр очраклы сайланмаган, алар автор прозасының тышкы билгеләре.

Җыентык язучының иң яхшы хикәяләреннән берсе — «Әҗәт» белән ачыла. Дөрес, бу яңа хикәя түгел — моннан элегрәк җыентыкка да кертелгән иде ул. Әмма әсәр яңадан эшкәртелгән, яхшыртылган, шигъри сурәтләр, буяулар куертылган.

Андагы козгын сурәте үзе генә дә ни тора! Мәрьям әбинең төшенә килеп кергән ач козгын, әлбәттә, фаҗигале төннең беренче хәбәрчесе буларак тәсмерләнә: «Каурыйлары тузгып беткән шул козгын каралтыдан каралтыга, баганадан баганага, тупылдан тупылга куча-куча... кирпеч морҗасына килеп кунды. Ә карчык яшел чирәмле ишегалдында тавык-чебеш ашатып йөри, имеш. Козгын, кан баскан ач күзләре белән ялварып, аннан ашарга теләнде. Суга чылатқан арыш ипие кисәге ыргыткач, алмады — агы кирәк, диде. Аннары тавышсыз гына кузгалды да төпсез караңгылык упкынына кереп югалды».

Бу шомлы сурәт ни өчен кирәк булган? Шунысын онытмыйк — хикәядә сугышта үлеп калган улы хәсрәтен кичерүче Мәрьям әби тормышының соңгы бер көне тасвирлана. Әлеге шомлы сурәттә моңа ишарә бар. Әмма шуннан артыгы юк. Әсәрдә ачы үлем хәсрәтеннән тыш, кешеләр алдында йөз аклыгын саклый белү, изгелек, сафлыкның бер буыннан икенчесенә түгелми-чәчелми күчә баруы идеяләре дә ачык билгеләнгән. Бәлки әнә шулар бу хикәягә ниндидер яңа сафлык, күтәренкелек, оптимизм өсти торганнардыр? Мәрьям әби изге юлда — кешеләргә икмәк күтәреп барганда үлә. Әйләнә-тирәдә яз шатлыгы, табигать уяну матурлыгы, шат күңелле яшьләр...

Яшь язучының геройлары гомерләренең иң кискен мизгелләре янына бүгенге хәлләрен янәшә куеп карап үз вөҗданнары каршында сыналалар. Күп очракта Ватан сугышы көннәре искә төшерелә. Карт артист Хәмзә Уразаев өчен дә шулай («Җан тынычлыгы»). Башкалар өчен тырышып йөреп, авылга сирәк килә торган театрны күрә алмыйча калган шофер егет аңа бик кызганыч булып тоела. Фронтта вакытта концерттан соң кайтып барганда ерганакка төшеп, машиналары баткач, аларга бер татар егете булышкан икән. «Әллә кайта бу туган ягына, әллә юк, татар моңын кабат ишетәмс-юкмы» дип, шул егеткә берничә җыр җырлап күрсәткәннәр, хәтта биегәннәр иде... Ул чагында Уразаев «дөньяда шул егетнеке кебек шатлыктан яшьләнгән күзләр күрер өчен генә булса да яшәрлек икән» дип, үз һөнәре белән шөкер генә горурланган һәм ул күзләрнең дымсу зәңгәрлеген гомере буе хәтерендә йөртә иде».

Һәм менә шуңа охшаш вакыйга яңадан, тыныч шартларда кабатлана. Бүгенге көннең фидакарь хезмәте — ул да батырлык түгелмени? Карт артист безгә бик мөлаем һәм сөйкемле булып тоела:

«Хәмзә Уразаевның колак сөяге тирәсендәге ярчык бимазалавын искә алмаганда бөтен тәне, җаны тыныч иде.

Беренче бүлектән соң пәрдә ябылгач, аның йөрәген кайнарлатып, залда кул чабу ишетелде. Әйтерсең лә су өстеннән нидәндер өреккән кыр үрдәкләре көтүе күтәрелде дә ерак-еракларга очып китте».

Кинәт туган алкышлар һәм дәррәү өркеп күтәрелгән кыр үрдәкләре... — Ә. Гаффарның кечкенә генә, ләкин тәэсирле ачышы!

Ә. Гаффар прозасын «төсле проза» дип атыйсы килә: «Иңкүлеккә сөт күбегедәй ак томан иңгән. Табигатьне күзләрен генә бупа торган тынлык баскан. Ара-тирә очкыннар чәчеп, учакта коры ботаклар чатный.

Әсфән рюкзактагы җете кызыл баланнар арасыннан иң йомшагын сайлап каба да, әчкелтем тәмнән йөзен чыта...

Хәдичәнең алга сузылган уч төбенә, әйләнбәйлән атынып, алтынсу-кызгылт өреңге яфрагы куна» («Кояшның салкын чагы»).

[1] Әхәт Гаффар. Бер йотым су. Хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Хикәяне укыганда, гүя үзең дә шул көзге табигать кочагына, аның ямена-төсләренә сокланган шул ике кешенең берсе хәлендә каласың. Әмма кайсысы? Кайсысы булса да ярыймы? Юк икән. Берсен сайламый булмый.

Көзге күктән казлар, торналар агыла. «Әсфәнне ау дәрте биләп алды. Мушкадан казлар якынаеп, дәвәеп күренә. Алар томшыклары һәм канатлары белән иркәләнә, сөйләшә кебек тоелды. Кешеләр шикелле сөешәләрдер әле... Кем белә? Матурлар,— дип сокланды Әсфән.— Горурлар!..

Әсфән мылтыгын Хәдичә белән ике арага төшерде:

— Кул бармый. Җәл.

Бу нинди әкәмәтең тагы диген төсле, тегесе Әсфәнгә текәлде...» һәм Хәдичә казны атып төшерә. «Кыр казы, җирдә тыпырчынган иптәшен чакыра-чакыра әйләнгәләде дә, ыңгырашуга охшашлы тавышлар белән очып китте.

— Менә ничек аталар аны, Әсфән! Мылтыгың шәп ата!»

Соңгы фразада кәпрәю катыш тантана ишетелә. Язучы каләменең бер-ике хәрәкәте белән образдан симпатия пәрдәсе алып ташлана. Табигатьне сөю билгесе тагын бер тапкыр кешенең әхлак сыйфатларын үлчәү чарасы рәвешендә кулланыла.

«Әсфән... эскерт турысына җиткәч, казның инде суына башлаган гәүдәсенә иелде:

— Гафу ит, кыр казы...

«Мылтыгың шәп ата, мылтыгың шәп ата»...

Әсфән борылды да читкә, әле генә каз очып киткән, инде җирне әз җылыткан кояш ягына атлады. «Кояшның да, кешеләрнең дә салкын чагы бар».

Хикәя катлаулы сурәт белән тәмамлана: «Әсфән, тынычланырга теләп, болыт тауларына карады. Алар Хәдичәнең йөзе кебек ачык, якты. Аның болытларга кагылысы килде. Ләкин алар ерак иде».

Олы җанлы классикларыбыз Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еникиләрнең пейзаж традицияләре яшь язучы иҗатында эшкәртелеп, яңа форма, яңа рәвешләргә керә. Шулай да Ә. Гаффарның үзе тапкан ачышлары да аз түгел. Яңага омтылу, үзеңчә әйтергә тырышу — бүгенге көндә Ә. Гаффарның иң үзенчәлекле язучылык сыйфаты шуңа кайтып калмыймы икән? һәм яшь авторга оригиналь булам дип әдәбиятыбызның таза җирлегеннән, нигезләреннән аерылып китү куркынычы янамыймы? Әнә шундый сораулар да туа.

Чыннан да, Ә. Гаффар прозабызда хикәяләренең яңа төрен башлап җибәрде. Алар моңа кадәр язылган татар хикәяләренең берсенә дә охшамаганнар. Аерма нәрсәдә соң? Бәлки төп фикер, идеянең без күреп гадәтләнгән хикәяләрдәгегә караганда тирәнгәрәк яшерелгән булуындадыр? Әгәр шулай икән, укучыдан бер нәрсә — әсәрләрнең образлылыгына игътибарлырак булу сорала. «Ак каен дегете», «Төш», «Бер йотым су» кебек хикәяләрдә чыннан да образ-сурәтләрнең күп акцентлы булулары ачык сизелеп тора. Ә. Гаффар образлы сурәтне чишү, аңлауны укучыга, аның зәвыгы-культурасына, интеллектуаль мөмкинлекләренә калдыра, шуларга исәп тота. Бу очракта, әлбәттә, укучы элекке гадәти алымнардан читләштерелә. Димәк, Ә. Гаффар хикәяләре иҗади кабул итүне сорый. Ә. Гаффар яңалыкка сусауга һәм тормыш күренешләрен үзенчәлекле сәнгать чаралары аша бирергә омтыла, характерлары бераз сәерлерәк була аның.

Ир уртасы кеше, авыл механизаторы Шәймәрдән Касыймханов («Ак каен дегете») көзге эшләр тәмамлангач, күңеле җилкенеп, шәһәргә музыка тыңларга, «Луи Армстронгны ишетергә» дип чыгып китә. Әгәр Шәймәрдән яшьтән көнбатыш музыкасы тыңлап, яратып үскән булса бер хәл иде. Җыр-музыка белән болай алыш-биреше дә юк сыман. Тик, әгәр дә Шәймәрдәннең күңелендә әзлексез яңгыраган бу көйнең сугыш елларында башыннан үткәннәрне хәтерләтүен искә алсак, аның кыланышлары гаҗәп тоелыр микән?..

Ә. Гаффар хикәяләренең үзәгедә бүгенге көн мәсьәләләре тора. Язучы кешеләрнең әхлак сыйфатларын сынардай күп төрле хәлләргә мөрәҗәгать итә. Колхоз председателе Исрафил Бакиров үз малаен — тракторчы Заурны сабан туе мәйданын бозган өчен иптәшләр судына бирә («Керәшчеләр»), күчеп киткән авыл урынында калган, онытылган, иске җил тегерменен председатель Каюм төзәттерергә була («Тегермән»). Әнә шундый көнкүреште сирәгрәк очраган гаҗәбрәк тоелган күренешләр бик күп бу җыентыкта. Язучы тормышның иң четрекле, иң катлаулы яклары хакында фикер йөртергә тырыша.

Туган якка мәхәббәт, табигатьнең гүзәллегенә соклану, шул матурлыкны сакларга чакыру, кешелек һәм кеше тарихына ихтирамлы мөнәсәбәт, башкалар хәленә керү

һәм алар өчен кайгыра белү — Ә. Гаффар хикәяләре шул тенденцияләр белән сугарылган. Мещанлыкның төрле формаларына ул кискен каршы чыга.

Ә. Гаффар — шигърияткә бай проза тарафдары. Күрәсең, аның прозасын бәяләгәндә беренче чиратта сәнгатьнең образлылыкка, художестволы суратка нигезләнүен истә тотарга кирәктер.

Кайвакыт: «Шартлылыкка нигезләнгән проза яши аламы?» — дип сорыйлар. Бу турыда бәхәсләшәләр. Безнеңчә, Ә. Гаффар әсәрләре шартлылыкның татар прозасында яшәргә хокукы да, җирлеге дә бар икәнлеген исбат итә. Бу хәл яшь язучының прозада үз юлын, үз йөзен эзләнүләре белән дә нык бәйләнгән. Ә. Гаффарның әлеге юнәлештә уңышлары аз түгел. Әгәр Мөхәммәт Мәһдиев, Әхсән Баянов кебек талантлы каләм ияләренең дә эзләнүләрен кушсак, шартлы проза дип аталган юнәлешнең прозада шактый тамыр җибәрүен күрергә була.

Сүз дә юк, бу алым белән эш иткәндә чама тойгысын саклый белү аеруча мөһим. Фәкать башкаларга охшамау өчен генә яңа юллар эзләү, әлбәттә, үсеш перспективаларын чикләргә яисә ялгыш юлга каерырга да мөмкин. Мәсәлән, бу җыентыктагы берничә хикәяне кыскартырга да, җиңел карап чыгарга да мөмкин булыр иде. «Уен», «Инде мәңгегә» кебек хикәяләрне бигрәк тә. Артык вак деталь-сурәтләр, күпсүзлелек, ул хикәяләрнең тәэсир көчен киметә. Сүзнең үтемле, җөмләләрнең ачык, рельефлы булуына омтылучы Ә. Гаффар, әлбәттә, мондый кимчелекләрдән котыла ала.

**Рифат СВЕРИГИН.**

## Укучының күңел дәфтәренә

**Инглиз мәкаләләре һәм әйтемнәре**

*Йомырка яратсаң, тавык кыткылдаганга ачуланма.*

*Сыерын саткач, кем сөтле булсын?*

*Зур кран белән чебен күтәртә.*

*Ялган дуска тап булганчы, чын дошман белән очраш.*

*Озак яшәргә кирәк, картаерга ярамый.*

*Африкада шулай: энә урлаган — төрмәдә утыра, тимер юл урлаучы — сенатка сайлана.*

*Ялтыравык һәр әйбер алтындыр дип уйлама.*

*Капчыкны тулар-тулмас чагында бәйләү кирәк.*

*Һәр пешекче үз ашын мактый.*

*Җимеш кабасың килсә, куакка үрмәли бел.*

*Минем бүрек бик шәп дисәң, гомер буе шуны ки.*

*Ялганчыга яхшы хәтер кирәк.*

*Тирән су шаулап акмый.*

*Бармагың бирсәң, кулыңны тешләр.*

*Йөземен ул чүпләде, пирогы бүтәннәргә.*

*Чиклэвек ватар өчен пар машинасы ясый.*

Гарәф Шәрәфетдинов,
Татарстан китап нәшрияты директоры,
РСФСРның атказанган культура работнигы

# КИТАП — ЧОРЫБЫЗ КӨЗГЕСЕ

Китапка карата һәр заманның үз таләпләре була. «Китап кайсы җәмгыятьтә туса, шул җәмгыятьнең рәвешен ала»,— дип әйтеп калдырган бөек фикер иясе А. И. Герцен. Дөнья барышы моны тулысынча раслады.

Китап безнең тормыштагы югары дәрәҗәсенә килеп җиткәнче үз тарихында бик күп язмышларга очраган, гаять катлаулы юл үткән. «Диннең явыз дошманы», «халыкны котыртучы» кебек гаепләүләр ишетергә дә, учакларда янарга да, җиргә күмелүләрне, суга батыруларны, «мәңгелеккә» зинданнарга ябылуларны күрергә дә туры килгән аңа. Әмма ул утта да янып, суда да батып бетмәгән — зиндан ишекләрен дә ачып чыккан, яшәвен дәвам иткән, үскән, үрчегән һәм, ниһаять, үзен дөньяга китергән халыкка хезмәт итүгә ныклап керешкән...

Китап басу эшендә яңа эра безнең илдә Совет власте урнашу елларыннан башланды. Коммунистлар партиясе, Октябрьның даһи юлбашчысы В. И. Ленин матбугатны үстерүгә, китап басуны яңача оештыруга үтә олы, үтә изге бурычларның берсе итеп карадылар. Шуның нәтиҗәсе рәвешендә, иҗат үсеше, аның бер чагылышы булган китап басу эше чын мәгънәсендә яңа баскычка күтәрелде. Китап хәзер безнең көндәлек тормышыбызга шул кадәр ныклап кереп урнашты, ул совет кешесенең иң якын киңәшчесенә әверелде. Ул — яңалыкка өйрәтә, ул — аң-белем бирә торган аерылмас дус, ул — безнең яшәвебез өчен иң кирәкле рухи азык чыганагы. Укучы бала мәктәпкә барамы, аңа китап кирәк. Галим кеше үзе китап язса да, аны китапкына галим итә. Белгеч яңалык эзлиме — китапсыз берни эшләп булмый. Эшчеме, колхозчымы — аның кулыннан китап төшми. Кыскасы, ул — кешелекнең акыл мирасын үзенә туплаган бик тә кадерле хәзинә, кыйммәтле байлык. Совет кешесе китаптан үткәндәгесен дә, бүгенгесен дә өйрәнә, шуның белән киләчәккә дә хәзерләнә. Ягъни безнең илдә китап кешелекнең иң олы идеалларына — социалистик җәмгыять алдына куелган бөек максатларга хезмәт итә.

Миңа илебез башкаласы Мәскәүдә үткәрелгән беренче, икенче һәм өченче бөтендөнья китап күргәзмәләренә барып кайту мөмкинлеге туды. Бу күргәзмәләрдә бик күп илләрнең дөнья күләмендә танылган нәшриятлары, китап фирмалары үз продукцияләре белән катнаштылар. Шунда китапка карата мөнәсәбәтнең кайсы илдә ничек булуын күрдек, китап басу эшенең үсеш тенденцияләре белән таныштык. Мәсәлән, 1977 елда үткәрелгән беренче күргәзмәдә аерым илләр, бигрәк тә шәхси фирмалар чыгарган китапларның артык гадилеге күзгә бәрелеп тора иде. Йомшак тышлык, тыйнак бизәкләр, форматлары да кулда яки кесәдә йөртүгәрәк исәпләнгән. Күрәсең, фән-техника прогрессы шулай куша, тормыш ритмы тизлекне, җитезлекне, әйберләрнең стандартлылыгын таләп итә. Полиграфия һәм нәшриятлар шушы таләпне беренче планга куеп эш иткәннәр булса кирәк. Янәсе, бүгенге заман кешесенә информация, белем чыганаклары болай да күп, барысы белән дә танышып барырга, өлгерергә кирәк, шуның өчен китап тиз укылырга тиеш һәм заманы үтү белән, бәлки әле куллану сферасыннан төшеп тә калыр... Әлеге фирмалар шулай уйлый төсле иде.

Ләкин 1979 елдагы икенче һәм 1981 елдагы өченче күргәзмәне карагач, китап дөньясы барышында башкачарак үзгәрешләр туа башлавы сизелде. Ягъни китап организмында, китап структурасында, фән-техника прогрессы таләпләрен һичшиксез искә алган хәлдә, аның гомер-гомергә сакланып килә торган үз традицияләренә, үзенчәлекләренә ныграк игътибар ителә башлады.

Икенче төрле әйткәндә, газета, радио, телевидение кебек информация чыганаклары күбрәк оператив бурычларны хәл итәләр. Без иртән радио тыңлап яки газета укып, дөнья барышы турында яңа хәбәрләр алабыз. Алар аша дөнья сулышын тоеп торабыз, шатланасына шатланабыз, борчылесына борчылабыз. Көндәлек тормышыбызның көзгесе кебек алар.

Ә китапның бурычы башкачарак. Ул көндәлек яки айлык вакыйгаларны укучыларга җиткереп тору бурычын гына куймый. Китап — безнең җәмгыять өчен чорыбыз көзгесе кебегрәк ул. Гадие генә дә түгел, үзенчәлеклесе, тылсымлысы. Анда бөтен культура үсешенең дәрәҗәсе чагыла. Аңа вакытлы әйбер, замана бизәге дип кенә карарга һич мөмкин түгел. Шуңа күрә китап эчтәлеге белән дә, формасы, кыяфәте белән дә озак гомергә, күп буыннарга җитәрлек һәм гасырларга калырлык итеп эшләнергә тиеш. Бигрәк тә өченче бөтендөнья күргәзмәсендә катнашканнан соң, алдынгы нәшриятларда китап басу эшенең шушы юнәлешне алганлыгын күрдек.

Сүз дә юк, китап үз укучысына дип языла һәм аңа адресланып эшләнә. Хәзер күп нәшриятлар китапларны темасы, эчтәлеге буенча, бер-берсенә якынайтып, туганлаштырып, сериялән эшлиләр. Производство кешесенә белешмә китабы кирәк икән, димәк, ул аңа куллану өчен уңайлы булырга тиеш. Ул үзенең китабын башка китаплар арасыннан тышкы кыяфәтенә карап ук бик тиз эзләп алырлык булсын.

Яки фән ачышлары турында китапларны бер төрлерәк итеп эшләү кирәкме? Әлбәттә, шулай кирәк. Хәтта матур әдәбият өлкәсендә дә китап сөючеләргә, укучыларга эш җиңеләеп бара. Шигырь китапханәсе, роман-повесть басмалары, шулай ук тышкы рәвешләре белән үк башкалардан аерылып торалар.

Шулар өстенә, китапның тагын бер искиткеч олы вазифасы барлыгын онытып буламы соң! Иҗатның һәр төре: сынлы сәнгатьме ул, театр яки музыка сәнгатеме, графика, скульптура, архитектура яки фоторәсем сәнгатеме — аларның һәркайсы китапка кереп берләшә. Һәркайсы дип әйтерлек китапның формалашуында, барлыкка килү процессында катнаша, китапка кереп киләчәк өчен мәңгеләшә, бәяләп бетергесез хәзинәгә әверелә.

Безнең ил нәшриятларының бүгенге эшләре белән танышканда китап басу культурасы үсешенә карап чыннан да сокланасың, китапның инде үзенең дә хикмәтле бер олы сәнгать булып үсеп өлгергәнлегенә ышанасың.

В. И. Ленин Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңүенең беренче көннәреннән үк ил язмышын хәл итү, революция казанышларын саклап калу өчен халыкка икмәк һәм мылтык кебек үк яңача эчтәлекле матбугат булдыру кирәклеген кайгырткан. Илнең экономик хәле нинди генә авыр булмасын, ашыгыч эшләр рәтендә дәүләт нәшриятлары оештырылган, китап басу эше җайга салынган. Шул чорда басылып чыккан китапларны бүген кулга алып карасаң, аларны дулкынланмыйча гына укый алмыйсың. Каян кәгазен, катыргысын таба алганнар! Хәрефләрен ничек койганнар! Кытлык дип тормаганнар — тышлаганнар, тегеләгәннәр. Язу танучы һәр кешегә үтемле итеп эшләгәннәр. Ә эчтәлекләре нинди! Ил сулышы, киләчәк турында кайгырту, халыкка мөрәҗәгать-өндәү — һәммәсе бар. Өстәвенә, элеккеге китаплардан аермалы буларак, һәммәсе гади. 1919 елда Казанда беренче китаплар булып В. И. Ленинның «Социализм һәм сугыш», «Коммунистларның урта хәлле крестьяннарга мөрәҗәгате» дигән хезмәтләре татар телендә басылып чыккан. Тәрҗемә әсәрләренең үзләрендә, хәзерге әдәби тел дәрәҗәсе белән чагыштырганда аерма бар, әлбәттә. Ә чорына, заманасына күрә хезмәт кешесе өчен һәр сүзе аңлаешлы.

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм публицист Галимҗан Ибраһимов — дәүләт нәшриятын оештыруга үзенең бик күп энергиясен, талантын биргән кешеләрнең берсе. Шул чорда беренче китапларның ничек дөньяга килүен сурәтләп, ул 1921 елны басылып чыккан «Әдәби ярдәм мәҗмугасында (җыентыкта) болай дип яза: «һәммә язучылар әсәрләрен бу мәҗмуга өчен буш бирделәр. Хәреф җыючы

иптәшләр, үзләренең дә ярым ач хәлдә яшәүләренә карамастан, мәҗмугабызның күбрәк өлешен «Җомга өмәсе» ясап җыйдылар. Татар социаль Советлар җәмһүриятенең дәүләт нәшрияты кәгазь белән, полиграф шөгъбәсе мәтбагә көче белән ярдәм итте. Шулай итеп, бу мәҗмуга үзенең бөтен тудымы белән Казанның язучы-басу хезмәтчеләре һәм оешмалары тарафыннан ачлык белән һәлак булып барган эшче, крестьян кардәшләребезне коткару юлында кулдан килгән кадәрле ярдәмгә тырышуларының җимеше булып чыкты».

Бу мисалларга аңлатма биреп тору кирәкми, минемчә. Гомумән, безнең китап тарих өчен гаҗәеп тә үзенчәлекле булып чыкты. Баштагы чорда «Совет власте озак яши алмас, аның белән бергә китаплары да юкка чыгар», дип юраучылар, безнең китаптан үч алырга кетеп торучылар да булды. Капитал илләре хәтта совет китапларын үткәрмәү өчен чикләрен «гомерлеккә» бикләп куярга маташып карадылар. Совет идеяләре турында язылган китап укучыларны иң зур җинаятьче дип исәпләп, аларга иң каты җәза бирүне төп законнарына кертеп маташтылар. Ләкин Җир шарының әйләнешен туктатып, күктәге якты нур балкышын җәза бирү юлы белән генә сүндереп буламыни! Совет иле үзенең көч-куәтен арттырган саен аның китапларының абруе да, йогынтысы да үсте. Без хәзер җир шарында ел саен 50 миллиард данә чамасы китап чыгып килә дибез икән, шуның өчтән бере безнең ил китаплары бит! Бәясе белән — иң арзанлысы, эчтәлеге белән — иң кыйммәтлесе!

Шул кадәр ташкынны, яңалык бөркелешен туктатырга, томаларга, сүндерергә һәм сүрелдерергә мөмкинме соң?! Бүген бөтендөнья китап күргәзмәләрендә йөргәндә, киресенчә, иң алдынгы дип исәпләнгән илләрнең китап фирмалары вәкилләренең совет павильоннарыннан күзләрен ала алмыйча йотылып-йотылып карауларын, безнең нәшриятларның эш тәҗрибәсен кызыгып өйрәнүләрен ачык күрдек.

Бүген шулай. Ә киләчәге нинди китапның?! Партия съездлары үтәме, пленум яки конференцияләр буламы, идеология эшен оештыруда партиянең иң якын ярдәмчеләре төсендә совет журналистларының олы бурычы телгә алына. Партиянең XXVI съезды халык хуҗалыгының барлык тармакларында, шул исәптән нәшрият һәм полиграфия эшчәнлегендә нәтиҗәлелекне тагын да күтәрергә, сыйфатны бик нык яхшыртырга чакырды. Партия Үзәк Комитеты «Идеология, политик-тәрбия эшен тагын да яхшырту турында» махсус карар кабул итте. Бу карарда куелган бурычларның бик җаваплы өлеше матбугат хезмәткәрләре җилкәсенә төшә. «Жанрларны төрлеләндерергә, стильгә, телгә аеруча игътибар бирергә, күп сүзлелекне, казенщинаны бетерергә,— диелә карарда,— чыгышларның оператив, ышандырырлык һәм аңлаешлы булуы турында кайгыртырга. Күпчелек семьяларның кимендә өч газета алуын, даими рәвештә телевидение тапшыруларын каравын һәм радио тыңлавын исәпкә алып, матбугат басмаларының бер-берсен кабатламавына ирешергә».

Бу карарларның һәм чакыруларның мәгънәсе безне, китап бастыру өлкәсендә эшләүчеләрне, аеруча уйландырырлык. Совет китабының язмышы, киләчәге, җәмгыять алдындагы миссиясе хакында сүз бара дип кабул итәбез без бу сүзләрне.

Китап дөньясындагы хәлләр турында болай зурдан кубып, тәфсилләп сөйләвемнең үзенә күрә бер максаты бар. Татарстан китап нәшриятының эшен әнә шул бөтендөнья, бөтен ил китап океанына, китап дәрьясына килеп кушыла торган бер инеш яисә бер кушымта кебек итеп карарга кирәк безгә. Ул инешнең дә мул сулы, саф сулы булуын, кешеләргә рәхәт һәм ләззәт бирә алырлык көче барлыгын күрсәсе һәм шуны кайбер мисаллар аша булса да күрсәтәсе килә.

Былтыр Мәскәүдә узган өченче бөтендөнья күргәзмәсендә безнең нәшрият рус һәм татар телендә чыгарган СССР Конституциясе, кечкенә форматлы итеп эшләнгән Татарстан АССР Конституциясе, «Трудящиеся В. И. Ленину», «Цвети, мой Татарстан», Муса Җәлилнең «Красная ромашка» дигән җыентыгы, «Татарская кулинария», «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» томнары, «Әлифба», «Рус теле» дәреслекләре, кечкенә форматлы итеп чыгарылган Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Галиәсгар Камал, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким китаплары, «Советский Татарстан», «Сабантуй» альбомнары һәм башка байтак китаплар экспорт рәвешендә күрсәтелде. Аларның күбесе тамашачыларда зур кызыксыну тудырды. Күргәзмә нәтиҗәләрен гомумиләштерү һәм йомгаклау документларында киләчәктә милли нәшриятларның бу юнәлештәге эшләрен тагын да көчәйтү кирәклеге күрсәтелде.

Шуңа күрә 1982 ел безнең өчен унберенче бишьеллыкның икенче елы булып кына түгел, ә 1983 елда үтәчәк дүртенче бөтендөнья китап күргәзмәсенә хәзерләнә башлау елы, эш сыйфатын һәм культурасын тагын да яхшырту елы төсендә дә башланып китте.

Хәзер инде безнең гадәткә керде: яңа көн туа, көн белән бергә яңа китап туа. Безнең нәшрият узган ел 350 гә якын исемдә китап һәм брошюра чыгарды. Ел тәүлегенең һәр көненә бер китап туры килә дияргә мөмкин. Аларның уртача тиражы 20 мең данәдән күбрәк. Димәк, һәр яңа китап шул кадәр кешенең, сатып алучының, укучының кулына барып керә дигән сүз. Эчтәлеге белән танышып чыкканнан соң, укучы аны тагын берәрсенә бирүен яки китапханә аша китапның кулдан-кулга йөрергә чыгып китүен күз алдына бастыра башласаң — меңнәр янына тагын меңнәр килеп өстәлә. Китапка карата җаваплылык тагын да үсә.

Безнең нәшрият үзенең яшәү дәверендә рус, татар һәм чуваш телләрендә 30 меңгә якын исемдә 350 миллион данә чамасы китап һәм брошюра чыгарган. «Аларны ничә кеше укып чыкты икән?» дип уйлап карарга мөмкин. Бүген инде кайберләрен, хәтта күпләрен китапханәләрдә дә табып булмавын, аларның тузып бетүен исәпкә алсаң, безнең китапларның илебездә культура революциясен тормышка ашыруда ничек катнашуларын бераз чамалау кыен түгел.

Бездә тормышның һәм белемнең байтак тармакларына карый торган китаплар чыгарыла. Алар арасында фәнни коммунизмга нигез салучыларның, марксизм-ленинизм классикларының, шулай ук партия һәм Совет дәүләте җитәкчеләренең хезмәтләре дә һәм тагын партия-оештыру, идеология мәсьәләләренә багышланганнары да, фән-техника, экономика, производство-хезмәт казанышлары, танылган кешеләрнең алдынгы тәҗрибәсе хакында язылганнары да бар. Безнең нәшрият алтмыш елдан артык яшәү чорында марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләреннән 400 дән артыграк исемдә татарча китап чыгарды. Аларның тиражы 3 миллион данәгә якын. В. И. Ленин әсәрләренең 45 томлык дүртенче басмасын татарчага тәрҗемә итеп чыгаруны тәгәлләү республикабызның культура тормышында зур вакыйга булды. Бу эштә нәшриятка иҗат кешеләре аеруча ярдәм иттеләр. Галимҗан Ибраһимов үз вакытында бөек юлбашчыбыз Әсәрләренең тәрҗемә ителгән беренче томына керeш мәкалә язып, тәрҗемәчеләр, редакторлар алдына менә мондый бурычлар куйган иде: «Үзенең тарихы буенча ике катлаулы җәбер астында изелгән татар эшче-крестьян халкы алдында бу хәзинәнең ишекләре ачык булырга — татар телендә Ленинның һич булмаса, иң алда торган мәсьәләләр турындагы фикерләре, әсәрләре, ленинизмның иң төп материаллары тәрҗемә кылынып таралырга, һәрбер татар эшчесенең, крестьянның, хезмәт кешесенең кулында, өстәлендә, китапханәсендә булырга, аңа юлбашчылык итәргә тиешлеге, әлбәттә, мәгълүм». Һәм нәкъ әдип әйтканчә булды да: марксизм-ленинизм классикларының әсәрләре чыннан да хезмәт кешесенең иң кадерле китабына әверелде.

1982 ел китапларына иң беренчеләрдән булып Л. И. Брежневның «Истәлекләр» дигән хезмәте юл ачты. Узган ел безнең республика хезмәт ияләре Л. И. Брежневның «Кече җир», «Яңарыш» һәм «Чирәм җир» дигән әсәрләрен дә татарча аерым китап итеп чыгаруны бик җылы каршыладылар. Л. И. Брежневның «Ленинизм юлыннан» дигән күп томлы әсәрләренең җиде китабы шулай ук халыкка җиткерелде.

Лектор, пропагандист кебек партия хезмәткәрләренең дә иң якын булышчысы китап. Шуңа күрә нәшрият үз планнарында масса-политик әдәбият тематикасын елдан ел киңәйтергә, укучылар теләгенә туры китерергә тырыша. Быел юлбашчыбыз В. И. Ленинның «Коммунистик әхлак турында» һәм «В. И. Ленин, КПСС күп милләтле Совет дәүләте турында» дип исемләнгән әсәрләр, документлар җыентыклары дөнья күрәчәк. «Правда» и Татария» дигән китап безнең республика тормышының үзәк матбугатта ничек чагылып баруын сурәтли. Укучыларның, хезмәт ияләренең үтенечен исәпкә алып, ниһаять үзебезнең танылган якташларыбыз Советлар Союзы Геройлары турында өч томлы тулы җыентык эшләнә һәм быел аның беренче томы дөнья күрер.

Илебез халкы олы бәйрәмгә — СССР төзелүгә 60 ел тулуны тантана итеп үткәрергә хәзерләнә. Бу уңайдан без рус телендә «Чудесный сплав», татар телендә «Без

яшибез Совет илендә» дигән җыентыклар эшлибез. Аларның беренчесендә тугандаш халыкларның бердәмлеге, ленинчыл милли политиканың казанышлары, тату гаиләдә яшәүнең яме сурәтләнсә, икенчесендә илебезнең милли әдәбиятларыннан шигъри үрнәкләр бирелә.

Якын киләчәк өчен нәшриятның тагын бер зур планы бар. Галимнәр һәм журналистлар шактый еллардан бирле күп томлы «Татарская лениниана» дигән серия булдыру турында сүз алып баралар. Ул чынга ашып килә. Тиздән, Казан университеты сходкасына 100 ел тулуга багышлап, бу сериянең беренче китапларын редакцияләү башлана. Укучылар даһи юлбашчының Казанда яшәү чорына караган әһәмиятле материаллар белән танышырлар.

Иҗат кешесе өчен хәзер мөмкинлекләр бик киң. Күпме газета-журнал, радиотелевидение... Әмма иҗат кешесе, һәм бигрәк тә язучы, нәшриятка бик еш мөрәҗәгать итә, үзенең яңа әсәрләрен китап итеп күрергә тели. Шулай итеп, язучы һәм китап чыгаручы бер максатта берләшә. Чорыбыз таләбеннән чыгып, нәшрият иҗат оешмалары белән якын элемтәдә эшләргә тырыша. Иҗат оешмаларында еллык эшкә йомгак ясаганда, иҗат процессының, бигрәк тә әдәби хәрәкәтнең уңышлары һәм кимчелекләре хакында сөйләшү вакытында нәшрият эшчәнлегенә дә бәя бирелә. Кайсы әсәрнең нинди китап булып дөньяга чыгарга тиешлеге гадәттә шул сөйләшү вакытында ук формалаша башлый.

Безнең нәшрият татар әдәбияты классиклары әсәрләрен пропагандалауда, дөнья һәм илебез халыклары әдәбиятлары әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп халыкка җиткерүдә шактый нәтиҗәле эшләп килә. Республикада алтмыш елдан артыграк вакыт эчендә рус әдәбияты классикларының һәм рус совет язучыларының әсәрләре 10 миллион данә чамасы тираж белән меңнән артык исемдә китап булып чыкты. Хәзер инде без бөек рус әдәбияты классикларыннан бер яки берничә әсәре татарчага тәрҗемә ителмәгән кеше юк дип иркенләп әйтә алабыз. Хәтта бөтендөнья әдәбиятының ил күләмендә иң популяр булып танылган классикларының да күбесенең әдәби үрнәкләрен татарча укырга мөмкин. Бу факт бер үк вакытта милли әдәбиятыбызның дәрәҗәсен дә билгели. Шуңа күрә киләчәктә тәрҗемә иҗатының сыйфатын яхшыртуга һәм аның колачын киңәйтүгә игътибар арта гына барачак.

Унберенче бишьеллыкта совет әдәбиятының иң яхшы җәүһәрләрен русча һәм татарча бастырып чыгару белән бергә, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, Һ. Такташ, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Г. Бәширов, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин әсәрләренең күп томлыклары дөнья күрәчәк. Күренекле татар шагыйрьләренең сайланма әсәрләре «Шигырь китапханәсе» сериясе белән чыгып килә. Бу сериядән 20 гә якын том укучылар кулына тапшырылды. Рус телендә шулай ук «Библиотека татарского романа», «Волжские просторы» серияләрендә татар әдәбиятының күренекле әсәрләре киң массага җиткерелә. «Мәктәп китапханәсе» сериясе белән русча һәм татарча китаплар чыгару арта. Яшь авторларның беренче китаплары, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть китаплары елдан ел күбрәк күренүе шулай ук әдәби иҗат процессының көчәя баруы хакында сөйли.

Моңарчы без нәни баланың беренче китабы «Әлифба» дип әйтергә күнеккән идек. Ләкин тормыш барышы бу фикергә дә «төзәтмә» кертә бара. Дөрес, «Әлифба» балага мәктәптә беренче хәрефләрне танырга өйрәтүе белән арада иң якыны, гомеренә хәтерендә саклана торганы булып калыр калуын. Әмма бүгенге нәни балалар бик яшьли кулларына китап ала һәм шактый гына «сайлана» да башладылар. Аларга хәзер тәти уенчыклар ничек кирәк булса, матур китаплар да шул кадәр үк кирәк. Әле ниндиләре кирәк! «Укы» да «укы» дип бәгыреңә төшеп теләкләренә ирешү генә түгел, «анысын укыма, монысын укы» дип китапны тою, төсмерләү галәмәтләрен күрсәтүдән дә тайчанып тормыйлар алар.

Безнең нәшрият кече һәм үсмер яшьтәге балаларга атап ел саен алтмышка якын исемдә китап чыгара. Әмма аларның ни дәрәҗәдә үтемле булуларын өйрәнеп карагач, шундыйрак нәтиҗә туа: безнең китаплардан иң күп укылганнары — үсмерләргә багышланганнары. Алар тышкы кыяфәткә бераз талымсызрак. Аларга күңелне яуларлык яки хыялны кузгатырлык китаплар гына булсын. Ә кече яшьтәгеләр өчен башкача: художество эшләнеше, тышкы рәвеше һәм иллюстрациясе игътибарны тартырлык, күңелгә охшарлык булганда гына бала эчтәлеккә үтә башлый.

Балалар өчен китап бастырып чыгарганда нәшриятка заман үзгәлешләрен, таләпләрен искә алырга туры килә. Ләкин безгә бу өлкәдә әлегә күп эшлисе бар әле. Тематиканы киңәйтү, художество эшләнешен, полиграфиядә башкарылу сыйфатын яхшырту — беренче дәрәҗәле мөһим эш.

Мәктәпләрдә укучыларны дәреслекләр белән бушлай тәэмин итү тормышка ашкач дәреслекләрне бастырып чыгару сыйфатына да таләп бик нык үсте. Һәм ул шулай булырга тиеш тә: китапка мөнәсәбәт, аңа изге итеп карау кайда тәрбияләнә? Мәктәптә, билгеле. Мәктәптә укыганда бала китапның кадерен, кыйммәтен бәяләргә өйрәнә.

Авторларның һәм бастырып чыгаручыларның уртак куанычы итеп әйтергә кирәк: татар мәктәпләре өчен басылган берничә дәреслек соңгы елларда бөтенсоюз һәм бөтенроссия күләмендәге конкурсларда дипломнар белән бүләкләнде. Моннан җидесигез ел элек бары 10 лап кына дәреслек төсле итеп һәм офсет ысулы белән басыла торган булса, хәзер аларның саны 40 тан артты. Укытучыларга ярдәмлек китаплары, уку программасына өстәмә материаллар бирү дә елдан ел күбәя бара.

Шушы уңайдан аерым фәннәр буенча сүзлекләр чыгаруны аерып әйтәсе килә. Быел, ниһаять, мәктәпләр өчен орфография сүзлеге кулланууга керәчәк. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре белән берлектә өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген» чыгару тәгәлләнде. Шул ук институт ярдәме белән унике томлык татар халык авыз иҗаты җыентыгын чыгару дәвам итә, алты томлык «Татар әдәбияты тарихын» рус телендә бастырып чыгару эшенә керешелде. Якын елларда татар теленең фразеологик сүзлеген эшләп чыгару безнең культура тормышыбызда шулай ук әһәмиятле урын алыр.

Безнең Казанда гына да ел саен йөзләгән яңа китап чыгып тора дибез икән — бу язучылар, иҗат итүчеләр күплеген дә, шулай ук язганны, иҗат иткәнне китап итеп тизрәк дөньяга чыгаручылар сафының зурлыгын да аңлата. Менә нәшрият редакторларының бүген нинди эш белән мәшгуль булуларын гына карыйк. Әйтик, берәве язучының әле генә машинкадан чыккан кулъязмасын укырга керешкән булса, икенче берәүләре китап кулъязмасын редакцияләп утыра, өченче берләре корректураны карый яки бит-бит итеп типографиядә бөкләнгән басма табакларны укый башлаганнар. Озын коридор буйлап калын ишекле бүлмәләр тезелеп киткән. Бер карыйсың — тып-тын да кебек. Күңел салыбрак икенче карыйсың — машинкалар тыкылдый, пышылдап уку, карандаш, ручка тавышы, хәтта кәрсенү яки тирән сулыш алып куя тавышлары да ишетелеп куя. Күпме хәрәкәт, күпме энергия, күңел көче, хис-кичерешләр, шатлык-куанычлар, борчылулар монда! Ул типографиядәге хәрәкәтне әйткән дә юк.

Нәшриятка көн дә кулъязма артыннан кулъязма, хат артыннан хат, гариза-үтенеч керел тора. Автор зур өмет һәм тәмле хыялы белән ишек ача. Язучыларның олысыкечесе, яше-карты үзенең иҗат планнарын тизрәк нәшриятка җиткерергә ашыга...

Бөтен иҗатын, гомерен халыкка багышлаган Габдулла Тукайның төн йокысы күрмичә язган шигырьләрен китап итеп бастырырга нәшер таба алмыйча йөрүен, алтыннан да кыйммәт торган кулъязмаларын юк кына бәягә биреп җибәрүен искә төшерә башласаң, бүгенге иҗат көченең нинди ирек алуын әйтеп тә, бәяләп тә бетереп булмый.

Инде дә килеп, иҗат итү һәм тормыш шартларын алыйк. Кәримовларның яки Харитоновларның табәнәк бинага урнашкан элекке типографияләре янына Бауман урамындагы бүгенге мәһабәт Матбугат йортын, аның Полиграфия комбинатын, тагын Казанка буендагы Пресса йортын һәм аның типография комплексларын янәшә куеп, чагыштырып карагыз әле! Вакыт арасы да күпме генә, ә никадәр үсеш! Алдагы гасырлар өчен зур мирас эшләячәк никадәр мөмкинлек!

Мондый мөмкинлектә, мондый бөтенлектә хезмәт, иҗат илһамсыз була алмый, әлбәттә. Китап укучылар бик хаклы рәвештә нәшрияттан әйбәт китаплар гына чыгаруны сорыйлар, шуны көтәләр. Ә Татарстан китап нәшрияты коллективы үз чиратында укучыларның өметен аклау өчен барысын да эшләргә әзер тора.

Елизавета Коздоба

# ЧИШМӘ ҖЫРЫ

*Җырчы Ренат Ибраһимовның иҗат портретына штрихлар*

Чүл уртасында адашып калган кәрван турында шундый бер риваять сөйлиләр... Имеш, тәүлекләр буе бер тамчы суга тилмергән кешеләр һәм дөяләр хәлдән таеп бетәләр. Аларның кояш һәм ком бураны көйдерепкыздырып бетергән күзләренә һаман шул бер манзара күренә икән, ди. Күктән кояш зурлыгындагы, тирә-юньгә салкынча һава сирпеп торган су тамчысы тамарга тора икән. Бу татлы газап бик җәфалый юлчыларны.



Шул чак дөя куып килүче яшь егет алга чыгып баскан. Өметләрен өзгән кешеләргә, хәлдән тайган дөяләргә карап үзәге өзелгән дә, җырлап җибәргән егет. Юлчылар аның ни турында җырлавын да аңлап бетерерлек хәлдә булмаганнар инде. Тик яшь егетнең көчле тавышын алар су эчкәндәй рәхәтләнеп тыңлаганнар. Тыңлаган саен тәннәренә көч-дәрт керә барган. Җыр тавышына ком катлаулары астыннан чишмә булып салкын су бәреп чыккан. Ә егет җырлаган да җырлаган. Кешеләр, сусауларын басып, малларын да эчергәч, егетне исләренә төшереп, аңа рәхмәт әйтмәкче булганнар. Ул басып торган урында инде көмештәй чишмә генә челтерәп агып тора икән.

Сабый чакта ук ишетелгән бу риваять бик озак вакытка Ренат Ибраһимовның күңелен сихерләп ала. Үзенең тирәнлеге һәм таныш булмаган серле яктысы белән аның йөрәгенә җылы биреп торгандай була ул.

Терек чишмәседәй халык җырларын ул Казаннан ерак түгел бер авылда торучы әбисе янына кунакка кайткач, яшьтәш малайлары белән эрәмәдә яшьләрнең әйлән-бәйлән уенын карап торганда ишетә. Йолдызлары җемелдәп күренгән кап-кара күк, шушы күккә ашып югалучы учак чаткылары, тирә-якны чорнап алган караңгы төн һәм тынлык. Риваять кебек үк серле һәм җанлы булып җыр ага. Кызлар-егетләр җырлыйлар да бииләр. Аларның кайгылары да, шатлыклары да шул җыр-уенда чагыладыр кебек.

Җыр риваятьтән тормышка, тормыштан риваятькә әверелгәндәй тоела. Авазлардан матур төсләр һәм сурәтләр туа, төсләр яңгырый башлагандай була. Ул чакта Ренат дөньяны иҗат көзгесендә чагылдыру ысулларының бик күп төрле икәнлеген

белми әле. Скрябинның «төсле музыка» серләрен ачу алдында торганлыгын да, Чурленисның яңгырап торган төс-буяулары да, Блокның күз алдында төсле таплар пәйда булып, шулар «сөйләшә башлагач» шигырь язарга тотынуын да белми әле ул. Олы дөнья музыка белән төсләр йомгагы кебегрәк кабул ителә. Кулы пумала, буяуга сузыла, ә колагы әллә нинди серле көйләр ишеткәндәй була. Авазлар бер көчәя, бер тына — риваятьтәге чишмә тавышы тынгы бирми. Тылсымлы тавышлар аны дулкынландыра башлый, үзенә тарта.

Күңел сихри тавышлы җырчыларны сайлый башлый. Марк Бернес, Георг Отс, Муслим Могамаев... Әтисе скрипкада, я булмаса мандолинада үзе уйнап үзе җырлый... Аннары — музыка мәктәбендәге бер-ике укытучы тавышы... Әмма үз тавышың чишмә булып чылтырасын иде ул!

Соңыннан, күп еллар узгач кына, ул риваятьтәге мәгънәнең тирәнлегенә төшенер Ренат. Ул хәтта тавышны рәсемгә дә төшерергә мөмкин икәнлеген аңлар. Марк Бернес тавышы — ул тезелешеп очып барган торналарга охшый, ә Георг Отс тавышы «Арлекин» фаҗигасен искә төшерә икән. Ә кешеләргә аның үз тавышы нинди булып тоелыр?

Ренат Ибраһимов тавышы... Бала чакта аның бу хакта уйлаганы булмады: җаны теләгәндә җырлый — күкрәгенә шатлык тулганда, я булмаса сәбәпсез сагыш-моң басса, яки дуслары бик сораса. Хәзергә әле ул дөньяны иҗади чагылдыруның матдиррәк, күзгә күренеп торырдай ысулын гына белә: әй әче буяулар, натюрмортлар, төрледән төрле рәсемнәр белән тула. Шуңа күрә музыка мәктәбеннән соң Ренат сәнгать мәктәбен дә тәмамлый.

Хыялында — кояш нурына чумып, күзне чагылдырып торган шәһәрләр һәм кешеләр. Аның натюрмортлары йомшак гәрәбә сыман ачык төсләре белән аерылып торалар. Саргылт тап, яшькелт лимон төсе белән кушылып, ниндидер ут яктысыннан җанланып киткәндәй була. Төсләрнең бу гаммасында күләмле әйберләр дә һәрбер штрих, һәрбер сызык та ике-өч күләмле булып тоела башлый.

Ренат музыка белән сынлы сәнгать арасында кала. Мәктәп кичәләрендә вокаль-инструменталь ансамбльгә кушылып җырлый, ә буш вакытларында, аеруча ял көннәрендә, этюднигын алып, Идел буена, кояш әле ал төсләре белән офыкны буяган җирләргә ашыга.

Кояш чыгышларын ясый ул. Алсу булып та чыга аның кояшлары, кызгылт булып та, алтынга манчылып та. Теләсә нинди сәнгатьтә табигать серенә төшенү, аңа мөмкин кадәр якынрак килү әһәмиятле. Ренат кар өемнәре һәм бураннар, күз күрмәгән давыллар, язгы бөреләр ачылуын ясый. Табигать стихиясен аңларга тырыша ул һәм кешенең рухи дөньясын бик җете, гайре табигый төсләр белән яза.

Ике музадан берсенә — рәсем сәнгатенә торган саен күбрәк игътибар бирә бара. Ренат рәссам булырга карар кыла. Урта мәктәпне тәмамлагач, бизәүче рәссам булып эшли һәм Казан төзүче инженерлар институты архитектура бүлегенең хәзерлек курсына йөри. Язмышына туганы композитор Рафаэль Билалов катнашмаган булса, кем белә, кайсы юлдан киткән булыр иде әле ул. «Ренат, син җырларга тиешсең!» — ди Рафаэль. Җыр җиңеп чыга. Ренат Ибраһимов консерваториягә документларын имтиханнар башланырга торганда гына биреп калырга өлгерә.

...Консерватория. Ишек төбендә дулкынланган абитуриентлар пышылдаша. Кабул итү комиссиясе членнарының йөзләре кырыс. Әмма Ибраһимов дигән егет композитор Свиридовның бөек инглиз шагыйре Роберт Бернс сүзләренә язылган «Робби»сын җырлап җибәргәч, сынаучыларның йөзләренә җылылык йөгерә. Җәүдәт Файзинең «Урман кызы»н башкаруга аудиториядә битараф кеше калмый инде. Шул чак Ренат беренче тапкыр үз тавышының мөмкинлекләре барлыгына ышаныч тойгандай була.

Аннары консерваториядә уку еллары. Бик җаваплы һәм бәхетле биш ел. Киеренке хезмәт һәм эзләнү чоры. Ул чордагы процессны скульптор эше белән чагыштырып булыр иде. Скульптор да бит, әзерләнгән материалның сыйфатын тикшерә-тикшерә, беришен юкка чыгарып ташлый, икенчесенең балчыгына нидер куша, аның үзлелеген арттыра яки барысын да яңадан башлый. Ренатның вокал белән ничек шөгыльләнгәнен класс педагогы Светлана Нәҗип кызы Җиһанова, җыр сәнгатенең тәҗрибәле остасы Җиһанованың үзен укытып чыгарган Валентина Андреевна Васько карап, тикшереп торалар. Үзенең уңышлары өчен яшь җырчы аларга рәхмәт хисе

саклый. Аларга иң күп мәшәкатьне тудыручы да, бәлки ул булгандыр әле. Ренат гадәти кысаларга гына сыя алмый, режимны да тулысынча үтәп бетерми ул, кайвакыт лекцияләр дә калдыргалый — иҗатка булган тыелгысыз омтылыш комачаулый: һәркайда өлгерәсе, һәммәсен беләсе килә. Әмма нәкъ менә шушы тиктормаслыгы, әшкә гаять сәләтле һәм талантлы булуы аркасында аның күп кимчелекләре арткы планга күчә.

Күп кенә күренекле җырчылар әзерләп чыгарган консерватория 1972 елны дүртенче курс студенты Ренат Ибраһимовны М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына стажировка үтәргә тәкъдим итә. Шушы елны консерваториянең әле беркемгә билгеле булмаган студенты үз көчен «Кармен» һәм «Евгений Онегин» операларында эпизодик рольләрне сынап карый. Ә бер елдан ул С. Бабаевның «Бөркет каласы»нда төп рольне башкара. Бу опера консерватория студентларының диплом эше була һәм җырчылар ярминкәсендә — тәмамлап чыгучыларны эшкә билгеләгәндә — эстрада җырлары башкаруы белән дә инде танылып өлгергән Ренат Ибраһимовка бик күп кызыклы тәкъдимнәр әйтәләр. Ул үз театрын сайлый.

Театрда биш ел эшләү дәверендә җырчы төрле характердагы күп образлар тудыра. Доницеттиның «Мәхәббәт шәрбәте»ндә Белькоре, «Фауст»та Валентин, «Бөркет каласы»нда Рубен, «Кармен»да Эскамильо һәм, ниһаять, Евгений Онегин. Моңа иҗат максатыңа тайпылмыйча омтылганда гына, зур киеренкелек белән эшләп, вокаль диапазоныңны даими киңәйткәндә генә ирешергә мөмкин. Артист тудырган һәр образ — сәхнә героеның эчке дөньясына, характеры нюансларына, язмышлар йомгагына мавыктыргыч сәяхәт ясау ул. Төрле дәверләр, цивилизацияләр, кеше язмышлары һәм табигатьләре буйлап сәяхәт итү дисәң дә урынлы булыр иде. Җырчының иҗади үсеше өчен берни белән дә алыштыргысыз терәк чишмәсе дә ул. Башкаручы үзе дә тоеп бетермәгән, бик тирән яшеренеп ята торган мөмкинлекләрне ачканы, үстергәне, системалы һәм фидакарь эшләргә өйрәткәне өчен ярата операны Ренат. Һәм әгәр опера системалы эшләргә, билгеле бер вокаль системага, дәверләр тирәнлегенә үтәргә өйрәтсә, җанга киңлекне, күңелгә бушануны җыр китерә.

Әле консерваториядә укыган чагында ук Ренат үз көчен җыр ярышларында сынап карый. Ул республика күләмендәге берничә җыр конкурсында катнаша һәм җиңеп чыга. Минскида 1973 елда булып узган Бөтенсоюз совет җыры конкурсы лауреаты була. Мәскәүдә узган эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурс лауреаты исеме яшь җырчыга солдат киеме кигәч кенә килеп җитә, сәхнәдән ул туп-туры хәрби хезмәткә китеп бара. Ә хезмәт срогы бетәргә берничә көн генә калганда Ренатка үзенең вокаль мөмкинлекләрен сынап карарга тагын бер мөмкинлек туа. Ул солдат гимнастеркасы белән итекләрен тиз генә сәхнә киемнәренә алыштыра да, Лученокның Виктор Хара истәлегенә багышлап язылган җыры белән «Кызыл канәфер» халыкара конкурсында катнаша. Ренат анда беренче премияне һәм лауреат исемен ала.

Ренат Ибраһимовны Мәскәүдә бик еш очратырга мөмкин: ул Бөтенсоюз радиосында һәм Үзәк телевидениеда — үз кеше. Анда ул үзен киң таныткан программаларын яздыра, тапшыруларда катнаша. Ибраһимов башкаруында рус һәм татар халык көйләре, опералардан арияләрне һәм камера әсәрләрен үз эченә алган пластинка күз ачып йомганчы таралып бетә. Төрле елларда Ренат Ибраһимовның соло концертлары Кремльнең Съездлар Сараенда һәм Дәүләт Концерт залында, спорт сарайларында булып узды. Җырчы еш кына Ю. Силантьев, Б. Карамышев, Г. Гаранян һәм Н. Некрасов җитәкли торган оркестрлар белән чыгышлар ясый. Бөек Октябрьның 60 еллык юбилее елында Ренат Ибраһимов Ю. Силантьев оркестры белән удар комсомол төзелешләре буйлап иҗади сәяхәттә булды, БАМ төзүчеләре алдында чыгышлар ясады, аның җырлавын Курск магнит аномалиясе эшчеләре тыңлады. Яшь җырчы башкаруында совет җырларын Болгариядә һәм ГДРда, Австралиядә һәм Польшада, Италиядә һәм Кубада, Америка Кушма Штатларында тыңладылар.

Җырны киң диапазонлы матур баритон тавыш белән, эмоциональ тирәнлекләр, психологик нюанслар белән башкаруы Р. Ибраһимовның үзенә бер осталыкка ия булуы турында сөйли. Аның репертуарындагы М. Фрадкин һәм В. Мигуля, М. Ножкин һәм Д. Тухманов, А. Пахмутова, Р. Паулс һәм А. Бабаджанян, татар композиторлары С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Р. Яхин, Р. Еникеев, Ф. Әхмәтов һәм Р. Билалов әсәрләре тыңлаучы күңелендә бик озакка яңгырап калалар.

Ренат Ибраһимовның концерт программалары халык җырларын да үз эченә ала.

«Ай былбылым, ай былбылым!» — Каяндыр әрәмәлектән сандугач сайравы ишетелә... Кие, бер тондагы авазларга иртәнге чык, инештән саркыган дым кунган кебегрәк. Ул авазлар канатларын талгын җилпеп иркен киңлекләрне әйләнәләр дә сандугач сайравы булып әйләнеп кайталар сыман.

«Ай былбылым» — Ренат Ибраһимовның иң яраткан җырларыннан берсе. Ул аны халыкчан рухы, моңы, күз белән күреп булырдай киңлеге, рельефлыгы өчен ярата. Һәр авазында, сүзендә, паузасында ул җырчы алдында күләмле булып килеп баса.

Консерваториядә укыган чагында әле Ренат бер тапкыр В. П. Соловьев-Седойның «Җыр — ул музыка сәнгатенең чишмәсе дә, тау түбәсе дә» дигән сүзләренә юлыга. Камера һәм опера сәнгате биекләренә ярен ялаучы яшь егетне бу фикер уйга да калдыра, шул ук вакытта куандыра да: ул бит бала чактан бик күп халык көйләрен отып калган һәм үзенә юлдаш иткән. Әмма ничек итеп ул гап-гади җыр, халык җыры, әйтик, әбисе әйткән такмаклар музыка иҗатының тау түбәсе була алсын ди?

Әле күп вакытлар узып, бары тик зур иҗат концертын әзерли башлагач кына Ренат композиторның нәрсә әйтергә теләгәнлеген аңлар. Концерт программасы тиз генә тумый. Башта җырлар туплана, җырчының талантын танучылар ишәя, концерт сорап, үтенечләр килә башлый, һәм, әлбәттә, аудитория белән турыдан-туры очрашу, аның пульсын тою, җыр тудырган чаткыларны, шатлыклы йөзләрне күрәсе килү теләге күкрәккә сыймаган чак була... Репертуарны ул күп төрле итеп төзи. Анда борынгы романслар һәм опералардан арияләр да, татар һәм рус халык җырлары да, совет композиторлары җырлары һәм хәзерге заман чит ил шлягерлары да керә.

Җырчы чын күңеленнән җырлаганда, хәтта иң катлаулы драматик әсәрнең дә тыңлаучы йөрәгенә юл таба алачагын белә Ренат. Шуңа күрә ул, аудитория нинди генә булмасын, аңа халык җырларын да, шулай ук махсус әзерлек таләп итә торган катлаулы әсәрләр дә тәкъдим итә. Халык авыз иҗаты актерның һәрвакыт игътибар үзәгендә. Халык иҗатыннан үзенең җыр сәнгатенә яңа куәтле импульс килгәнлеген тоеп яши Ренат.

Р. Ибраһимов татар шагыйрьләре һәм композиторлары әсәрләре, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре үткәрә торган экспедицияләрнең нәтиҗәләре белән бик якыннан танышып бара. Онытылган җыр һәм көйләрне ул шулай ук гастрольләр вакытында да җыеп йөри.

Иске татар китапларында, архив язмаларында, фольклорчылар тикшерүләрендә Ренат инде онытылган текстларның һәм җырларның көйләрен генә түгел, ә бәлки онытылган һәм вакыт тәэсирендә милли культурадан бөтенләй төшеп калган халык музыка коралларының ясалу ысулларын да эзли. Аның фикеренчә, 70 кә якын музыка коралыннан файдаланган татар халкы. Һәм җырчы чын күңеленнән ышана: алар халыкка кире кайтырга, үзләренең икенче тормышларын башларга тиеш. Онытылган никадәр авазларны, көйләрне яңадан яңгыратырга мөмкин булыр иде ул кораллар белән! Никадәр генә мәшгуль булмасын, борынгы музыка коралларын яңадан торгызу буенча Ренат Ибраһимов тирән тикшеренү дә алып бара.

Татар халык җырларын башкарганда, җырчы үзенә ярдәмгә татар гөсләләрен, тальян гармунын, курай, кубыз кебек уен коралларын чакыра. Ә рус халык җырларын ул гармун, балалайка һәм гөслә башкаруында да җырлый: һәр җыр, Ренат фикеренчә, үзенчәлекле музыкаль төскә ия булырга тиеш. Бары тик якты музыкаль бизәк булганда гына ул табигый, гүзәл яңгырый.

Зур иҗади эзләнүләре нәтиҗәсе буларак, җырчы халыкта да танылып өлгерә: 1977 елда аңа Татарстан АССРның атказанган артисты дигән исем бирелә. 1978 ел Р. Ибраһимовка тагын бер шатлыклы вакыйга бүләк итә — ул республиканың Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты була. Җырчы бу премиясен дөнья балаларын яклау фондына күчерә. Яңа концерт программалары, туктаусыз эзләнү һәм һәрвакыт репертуарын яңартып тору аңа янә бер үрне яуларга мөмкинлек бирә: хәзер Ренат Ибраһимов — РСФСРның халык артисты.

Җырчы даими ярышта, даими эзләнүдә. Ул үзенең концерт программасын яңа җырлар белән генә баетып калмый, ә бәлки конструкциясен дә үзгәртә: мәсәлән, ике бүлек урынына ул өч, яртышар сәгатьле блоклар әзерли. Аларның һәркайсының үзе-

нең шартлы исеме дә бар. Әйтик, әйдәүче җыр (фольклор, халык җырлары) фикер-җыр (камера бүлеге) һәм халәт-җыр (эстрада җырлары).

Концерт программасының шундый күптөрлелеге аудитория таләпләренең күптөрлелегенә җавап бирә һәм шул ук вакытта җырчы иҗатының төрле якларын ачып бирә ала. Уйландыра торган җырлар белән аудиториягә мөрәҗәгать иткәннән соң концерт якты, кояшлы авазлар симфониясенә күмелә — хәзерге заманның иң матур көйләре яңгырый башлый.

Җырчының үз фикеренчә, концертның өченче өлешендә төсле музыка җайланмасы куллану да яхшы булыр иде.

Ренат Ибраһимов өчен концерт — ул үзара аралашу, баетылу процессы. Аудитория — җырчы өчен гади тыңлаучылар төркеме генә түгел, ә халык күңеленең көзгесе дә. Авазлар, төсләр, ритмнар күңелгә сеңдереп барыла. Ул җырчының канына, йөрәгенә сава һәм иҗади бушануны сорап, җыр булып кире халыкка әйләнеп кайта. Ул җырның сурәтен эзли, сурәт күренә торган авазлар да һәм төсләр дә булырга мөмкин... Иң мөһиме үз заманының кабатланмас тәэсирләрен халыкка җиткерергә кирәк.

Ренатның бер матур хыялы бар. Ул — заманыбызның иң кояшлы түбәләрен, илебезнең иң зур җиңүләрен, үз тормышының иң шатлыклы мизгелләрен күккә ашып баручы спиральләр рәвешендә ясарга тели. Ләкин мондый тойгылар Ренатның күңелендә күп җыелган һәм аларны сурәтләү гади эш түгел шул.

...Әнә балалар бакчасында кара күзле, шат күңелле малай йөгереп йөри. Менә хәзер аны алырга дип әтисе килеп җитәр, һәм алар, «зурлар кебек кулны артка куеп», шәһәр урамнары буйлап кайтып китәрләр. Әтисе бакча капкасыннан менә-менә килеп керер дә Ренат шатлыгыннан сикереп куяр, әтисе аның мәктәпкә киеп барачак костюмына яңа каеш сатып алган икән. Бер-ике айдан Ренат та беренче класска укырга барачак бит...

...Музыка мәктәбендә сольфеджио дәресе. Кинәт ишек ачылып китә, һәм шатлыгы йөзенә чыккан завуч: «Репродуктор янына!» — дип эндәшә. Ә репродуктордан Левитанның куәтле тавышы яңгырый: «Космоста беренче кеше — Юрий Гагарин!» Бу исем Ренат өчен иң югары биеклекләрнең берсе булып кала, һәм ул әнә шундый биеклекләргә омтылырга кирәк, дигән максатны үзалдына куя.

Аларның беркадәренә ул инде менде дә. Спиральнең аскы бөтерелмәләрендә калганнары бар, ә ирешергә тиешлеләре өстә әле. Аларга ирешү өчен һәрвакыт эзләнүдә, җиңүләргә ирешү юлында булырга кирәк. Ә иң әһәмиятлесе армый-талмый иҗат итү. Фикерләреңне әйтү өчен буяулар һәм көйләр генә җитмәсә, ярдәмгә шигырь юлларын чакырырга мөмкин.

Ренат Ибраһимов үзенең беренче шигырен Николай Рубцов поэзиясе тәэсирендә яза. Поездның ниндидер бер тукталышында ул аны киосктан сатып ала, һәм гастрольдәге артист үзенә бөтенләй таныш булмаган яңа шигъри образлар иленә чума. Соңыннан күп кенә шигъри юллары аның ил буйлап гастрольләре вакытында туа. БАМда вакытта ул, мәсәлән, «Эзләр», «Сиңа», «Хушлашу» дигән шигырьләр яза һәм алар матбугатта басылып чыга. Еш кына шигырьләр көе белән бергә күңелгә киләләр. Шул рәвешле «Кызыл кавалерия», «Бишек җыры», «Язмышым тегермәне» дигән җырлар туа.

Халык иҗаты һәм заман — Ренат Ибраһимовның иҗатын даими рәвештә сугарып, тукландырып торучы, аны күп яклы, җанлы һәм яңарып тора торган итүче ике чишмә. Шуңа күрә дә бу иҗат заманыбызның үзенә охшаган.

Шигырьләрендә дә Ренат чишмәләр турында язарга ярата. Нинди чишмәләр соң алар? Эссе чүл уртасында һәлакәткә дучар ителгән кәрванны коткаручы чишмә турындадыр бәлки? Зур талантлар иҗатын туендырып торучы халык чишмәсе турындадыр, иҗат чишмәләре турындадыр...

# КЕМ УЛ САБИР ШӘРИПОВ?

Моннан унике ел элек, ерак Алма-Ата шәһәренә юлга чыкканда, мин бу кеше турында бик аз белә идем. Кулымда аның 1943 елда Тегеранда төшкән фоторәсеме, гарәп хәрефләре белән кулдан язылган китап һәм өзек-өзек мәгълүматлар гына иде. Боларны миңа Сабир Шәриповның Әгерҗедә һәм шул районның Барҗы авылында яшәүче туганнары биреп торды. Аларның сөйләүләре буенча, бу кеше үз башыннан күп вакыйгалар кичергән, олы-олы эшләр башкарган һәм кайдадыр, кемнәр өчендер бик таныш, күренекле шәхес булырга тиеш. Әмма анык кына билгеле түгел — кем соң ул Сабир Шәрипов?

Менә хәзер — беренче мәртәбә бу исемне ишетүемә һәм ерак Алма-Атага барып кайтуыма байтак кына гомер үткәннән соң — «кем ул Сабир Шәрипов?» дигән сорауга күп санда җаваплар телгә килә:

— Иң элек ул — безнең данлы якташыбыз. Сабир Шәрипов Әгерҗе районының Барҗы авылында туып үскән. Быел — 1982 елның июль аенда аның тууына 100 ел тула;

— Сабир Шәрипов — Казагыстанда Совет властен урнаштыру өчен көрәшкән иң зур революционерларның берсе, 20-30 елларда анда җитәкче урыннарда эшләгән;

— Сабир Шәрипов — казакъча, русча һәм татарча күп әдәби әсәрләр язган. Ул казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе, Алма-Атада басылган том-том китапларның авторы;

— Сабир Шәрипов — утызынчы елларда Иранда Совет республикасы вәкиле, андагы зур акционерлык җәмгыятенең директоры;

— Сабир Шәрипов — яшь Совет экономикасын аякка бастыру өчен бик күп көч куйган шәхес. Ул — егерменче елларда Каспий буендагы «Эмбанефть» трестының башлыгы, күп кенә яңа нефть чыганаклары ачкан җитәкче һәм үзе дә фәнни китаплар язган кеше. Аның «Нефть» исемле фәнни хезмәте аерым китап булып та чыккан;

— Сабир Шәрипов — Казагыстан компартиясе Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм институтында гыйльми хезмәткәр булып эшләп, казакъ халкының тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертүче, зур-зур мәкаләләр бастырган галим...

Аның хакындагы сүзләрне әле тагын да дәвам итеп булыр иде. Чөнки бу кешенең тормышы, чыннан да, бик бай. Бу кеше, чыннан да, көчле шәхес, купкырлы шәхес булган. Язмышының аерым урыннары легендага да охшап китә хәтта... Ләкин, башта әле аның балачагына, үсү елларына күз салыйк.

Кайбер әңгәмәләрдә һәм, кайчагында, хәтта әдәбият-сәнгать әсәрләрендә дә көчле, зур шәхесләрнең барлыкка килүен ниндидер гадәттән тыш очрак итеброк күзаллау сизелеп куя. Янәсе, алар менә шушы гади тормыштан түгел, ә ниндидер бүтәнрәк шартлардан килеп чыгалар. Янәсе, көчле шәхесләрне югары культурага ия булган социаль катламнар гына тудыра ала... Мондый фикерләр, минемчә, гади тормышның үзендәге потенциаль көчне, мөмкинлекләрне санга сукмаудан туа.

Сабир Шәрипов — минем өчен авылдаш кеше.

Хәзер мин аның легендар шәхес булуын, өкиятка тиң эшләр эшләгәнен беләм. Ләкин, барыбер, мин бу язмышны гади тормыш җимеше дип, шуның үсешенең бер нәтиҗәсе дип карыйм. Сабир Шәрипов гомере ул — гадәттән тыш хәл түгел. Аның көче дә шунда. Һәм икенче яктан, без бүген зур шәхесләр тормышын нәкъ менә шуның өчен — гади кешеләр белән алар арасында уртак җепләр табу, замандашларыбызны шул җепләргә таянып матур итеп тәрбияләү өчен өйрәнәбез дә... Сокланып калу өчен генә түгел!

Сабир Шəриповның туган авылы Барҗы табигатьнең бик матур урынына урнашкан. Бу авылның язларын диңгез кебек киңəюче, җəелүче Иж суы бар, Камага да җидесигез генə чакрым. Төрле-төрле киеккə бай урман да янəшəдə генə. Күллəре дə күп аның, шулай ук җаның телəгəндə менеп китəрлек таулары да бар... Билгеле, ярлы гаилəдə туган Сабир бу гүзəл табигать эчендə бик рəхəт чигеп йөри алмаган, аңа кечкенəдəн үк дөнья арбасына җигелергə — ə инде унөч яшендə, түгəрəк ятим калгач, бу авыр «арба»ны үзенə генə тарта башларга туры килгəн. Шулай да, соклангыч табигать Сабирның матур күңелле кеше булып формалашуында зур роль уйнагандыр, дип ышанасым килə минем. Барыбер, дөньясы нинди генə авыр булса да, үз туган җиренең матурлыгы күзенə күренмичə, күңелен сөендермичə калмагандыр аның. Галимҗан Ибраһимовның «Кетүчелəр» хикəясендəге яшь малай сымач, ул да:

« — Йа хода, дөньяң нинди матур! Ник соң без генə шулай бəхетсез?!» — дип бер генə мəртəбə инəлеп дəшмəгəндер тормышка.

Соңыннан, ерак җирлəргə барып чыгып, зур язучыга əйлəнеп киткəн икəн — безнең як табигатенең тəэсире бередə шулай ук аз булмагандыр... Югыйсə, туганнары сөйлəве буенча, бик күп җирлəр, иллəр күргəннəн соң туган авылына кайткач, ул соклана-соклана елга-су буйларын карап, урманнарга чыгып, тауларга менеп йөрмəс иде! Үзен һəм бик күп авылдашларын тудырып үстергəн табигатьне — онытылмас яшел бишеген сагынганга күрə шулай йөргəндер Сабир Шəрипов.

Югарыда искə алынган гарəп хəрефлəре белəн язылган китапта Сабир Шəрипов балалык елларын бик истə калырдай итеп тасвирлый. Мəсəлəн, мəдрəсəдə укып йөрүе турында ул мондый юллар яза: «Монда бит утыз ел укыйлар. Барысы да мулла булмакчы. Ə бер авылга бер генə мулла кирəк. Миңа чират кайчан җитəр?» Шушындый уйлар һəм авылдагы үтə ярлы тормыш аны читкə алып чыгып китə. Уналты яшендə Сабир, бер юлаучының чанасына утырып, Алабуга ягына кузгала. Лəкин бу юл үтə озын һəм бик урау булып чыга — ул Сабирны күз күрмəгəн, колак ишетмəгəн ерак Павлодарга ук китереп ташлый.

Менə шушы яклар инде яшь Сабирның килəчəктə кем булуын хəл итə. Сабир бередə ул еллар өчен гадəти булган яшəү авырлыгын да күрə һəм, шуның белəн бергə, авыл малаеның күзе дə ачыла башлый. Нахак бəла ягылып төрмəгə утыртылган Сабирны шунда эшлəүче Ольшанский дигəн чиновник үзенə тəрбиягə ала, ул аларда тора башлый. Аннары Ольшанский Сабирны шул шəһəрдəге авыл хуҗалыгы мəктəбенə урнаштыра. Бередə ул биш ел укый һəм шул елларда патша министрын үтерүдə гаеплəнеп Павлодарга сөргенгə сөрелгəн студентлар белəн таныша. Алар Сабирны əкрен-əкрен дөнья хəллəре белəн таныштыра башлыйлар, сүз тыңлаучан һəм төпле егеткə бүтəн серлəрен дə ачалар. Шулай итеп, аның күңеленə беренче революцион идеялəр килеп кагыла...

Аннан соң Сабир Шəрипов казакъ авылларында укытучылык итеп йөри һəм тагын Павлодар төрмəсенə элəгə. Бу юлы инде нахакка түгел, ə сəяси ышанычсызлыгы өчен. Төрмəдəн соң Сабир төрле шəһəрлəрдə эшлəп йөри, əмма Атбасардагы чор аның тормышын аңлау өчен аеруча мөһим. Бередə ул революцион фикерле интеллигентлар һəм эшче сыйныф вəкиллəре белəн таныша, алар арасына керə... Листовкалар, таратылган китаплар... Халык өчен кичəлəр үткəрəлəр, концертлар, театрлар куялар. Əмма, зур дəрт белəн янып йөри башлаган Сабирда тиздəн үпкə авыруы ачыла. Аңа, кымыз белəн дəвалану өчен, далага китəргə туры килə. Бу елларда казакъ арасында писарь-тылмач булып эшлəп йөреп, Сабир Шəрипов гади халыкның тормыш-көнкүреше белəн бик якыннан таныша һəм, əлбəттə, хəленнəн килгəн кадəр ярлыларга булыша.

Казакъ халкының Бөек Октябрь социалистик революциясенə килү юлында 1916 ел аерым бер урын алып тора. Бу елны бөтен казакъ җирен диярлек зур баш күтəрү — коралллы восстание билəп ала. Баш күтəрүчелəр патша гаскəрлəренə каршы озак вакыт һəм нык каршылык күрсəтəлəр, аларның бер өлеше хəтта Октябрь революциясенə кадəр корал ташламый. Башка революционерлар белəн бергə Сабир Шəрипов та бу коралллы чыгышны оештыруга һəм əзерлəүгə зур өлеш кертə.

Февраль революциясе көннәрендә Сабир Шәрипов Күкчәтауда була. Бирегә дә ул көрәшнең алгы сызыгында, митингларда халыкка казакъча да, русча да, татарча да ялкынланып сөйли, большевиклар партиясенең төп максатларын үтемле итеп аңлата.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң Сабир Шәрипов яңа тормышны ныгыту көрәшенә башы-аягы белән чума: ул кызыл гвардия отрядлары төзи, байларның маллларын ярлыларга өлешә, төрле курслар, мәктәпләр оештыра. Ә инде Мәскәү һәм Петроград эшчеләренең ачыгуы турында хәбәрләр алынгач, ул бөтен көчен биреп икмәк табу һәм аны үзәккә озатуны оештыра.

Сабир Шәрипов гражданнар сугышы елларында күп мәртәбәләр Колчак тылында разведкада була. Аннан кайткач ул В. В. Куйбышев һәм башка җитәкчеләр белән очраша. Сабир Шәриповның бу эшләре турында атаклы революционер һәм язучы Сәкен Сәйфуллин үзенең «Тар юл» исемле мемуарлар китабында: «Сабир Шәрипов белән булган хәлләр легендага охшаган»,— дип яза. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: алар Сабир белән бик якын дус булалар.

Сабир Шәриповның бу еллары турында сөйләгәндә аның кыюлыгына, тәвәккәллегенә сокланмыйча мөмкин түгел. Берсен генә әйтеп үтик: башкала эшчеләре ачыга башлагач, теләсә нинди юл белән икмәк табу бурычы килеп баса. Моңарчы зур гына постларда эшләгән Сабир тәвәккәлләп шушы эшкә үзе алына һәм кырык тартмачыныкы сыман кием киенеп, берничә атта Колчак тылына — икмәкле якларга китеп бара. Ул анда үзен татар бае итеп таныта һәм танышлары аркылы товар алып, акча булдырып, «Колчак армиясенә» дип бодай җыя башлый. Бу эше уңышлы килеп чыга аның. Ул меңләгән пот ашлык җыя һәм таныш-белешләре аркылы ачыгучы шәһәрләргә икмәк озата. Менә шушындый кыю эшләре бер генә булмый Сабир Шәриповның. Ә бервакытны, документсыз йөрүче бу революционерны, Колчак агенты дип уйлап, үзебезнекеләр үк чак кына атмыйча калалар. Очраклы рәвештә килеп чыккан бер танышы гына коткара аны нахак үлемнән.

Еллар тынычлана төшкәч, Сабир Шәрипов — яңадан җаваплы урыннарда. Башта Атбасар өязе Хезмәт комитеты председателе, аннан Акмулла губернасының Башкарма комитет председателе. Шул ук вакытта ул Казагыстан партия Үзәк Комитетының һәм Казагыстан хөкүмәтенең члены да була.

Ә 1924 елда Сабир Шәрипов ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан «Эмбанефть» трестына башлык итеп җибәрелә һәм бирегә дистә елдан артык эшли.

1933-34 елларда Сабир Шәрипов Иранда Советлар республикасының сәүдә вәкиле булып тора.

Менә болар — минем данлы авылдашымның тормыш юлы баскычлары, андагы иң төп борылмалар һәм биеклекләр. Ә мондый кыска язмаларга кереп бетә алмаган, ләкин кеше язмышы өчен үтә мөһим башка вакыйгалар күпме әле!

Алда әйтеп үтелгәнчә, Сабир Шәриповның әдәби мирасы да зур. Ул — казакъ совет әдәбиятына нигез салучы язучыларның берсе. Аның әсәрләре Казагыстанда бик еш басылып тора. Мәсәлән, 1959 елда Алма-Атада аның ике томлык әсәрләр җыелмасы (повесть һәм хикәяләре) басылган. Соңгы елларда да аның әсәрләре төрле-төрле исемнәр белән дөнья күрделәр. Шулай ук Сабир Шәриповның Иран тормышыннан алып язылган «Рузи Иран» һәм «Ләйлә» дигән әсәрләре дә бар.

Гомумән, Сабир Шәриповның исеме Казагыстан халкы өчен зур хөрмәтле. Аның рәсеме дәүләт музеенда тора, иҗаты урта мәктәп дәресләрендә һәм югары уку йортларында өйрәнелә. Сабир Шәриповның тормышына һәм иҗатына багышланган фәнни хезмәтләр языла, диссертацияләр яклана. Якташыбыз тормышын һәм иҗатын ныклап өйрәнүче галимнәрнең берсе — Казагыстан дәүләт университетында эшләүче филология фәннәре докторы Турсунбәк ага Какишев икән. Сабир Шәриповның ике томлык әсәрләренә кереш сүз язган кеше, «Дәвер сурәтләре» исемле монографиясендә бу иҗатка зур урын биргән галим. Бер хезмәтендә ул: «Казакъ совет әдәбиятының нигезен салуда катнашкан Сабир Шәриповның иҗатын халыкка җиткезү... безнең интернациональ бурычыбыз булырга тиеш»,— дип яза.

Сүз уңаеннан әйтеп үтик: бу галим соңгы елларда да шушы бурычны үтәү буенча күп эшләр башкара. Узган ел ул безнең республикабызда һәм Сабир Шәриповның ту-

ган ягында, Әгерҗе районында булды, күп кенә кешеләр белән очрашты, яңа мәгълүматлар алды.

Казагыстан китап нәшрияты безнең якташыбыз турында «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә махсус китап та бастырып чыгарды. «Сабир Шәрипов» дигән бу китапның авторы — Ермәк Өтебаев. Бүген Казагыстан матбугатында, радио-телевидение тапшыруларында Сабир Шәрипов исеме еш күренә һәм ишетелә.

Казагыстан Фәннәр академиясендә Сабир Шәриповның рус телендә язылган «Сәлия» исемле романы саклана. Әлегә кадәр табылмаган башка күп кулъязмалары булганлыгын да искә алсак — якташыбызның әдәби мирасы зурлыгы тагын да тулырак күз алдына килер.

1980 елда Алма-Ата шәһәрендә Сабир Шәриповка һәйкәл ачылган. Моңа, әлбәттә, без — аның якташлары — чын күңелдән сөенәбез!

Быел Сабир Шәриповның тууына 100 ел тула. Бу еллар эчендә, әлбәттә, тормышыбыз бик нык һәм күп яктан үзгәрде. Сабир Шәрипов һәм аның кебек ялкынлы йөрәкле революционерларга карата булган халык рәхмәте дә — әнә шул үзгәрешләр кебек үк күп һәм шулар кебек үк тирән. Алар — бүгенге матур тормыш өчен көрәшне башлаучылар иде. Аларның исеме дә, эшләре дә онытылмаячак!

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# НӘҖИП ГАЙНУЛЛИН

*Туума 70 ел тулу уңае белән*

Нәҗип Гайнуллин театр техникумында укыганда ук Татар академия театры спектакльләрендә катнаша, танылган осталарның тәҗрибәсен өйрәнә, актерлык осталыгы серләренә төшенергә тырыша. 1936 елда кулына диплом алу һәм театр бусагасын атлап керү, аның тулы хокукы членына әверелү — яшь артист тормышындагы иң зур бәхетләрнең берсе була. Бу елларда академия театрын талантлы режиссер Гомәр Исмәгыйлов җитәкли. Ул яшьләр белән эшләүгә бик зур игътибар бирә, алар белән Станиславский системасы буенча профессиональ укулар алып бара. Техникумда уку һәм театр сәнгате институтын (ГИТИС) тәмамлаган Исмәгыйлов дәресләрен тыңлау эзсез югалмый: Нәҗип Гайнуллин тиздән театрның зур артистларыннан берсе булып китә.

Булачак останың иҗаты формалашуда ГИТИСның режиссерлык факультетында укып кайткан Шириязданан Сарымсаков һәм Кәшифә Тумашева да мөһим роль уйныйлар. Спектакльләрдә бергә уйнаган партнерлары, актерлык сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белгән Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов, Шакир Шамильский, Габдулла Уральский да аңа нык тәэсир итә. Аларның уйнавын өйрәнү Нәҗип Гайнуллинга сәхнә иҗатын тирәнрәк аңларга, образ өстендә эшләү процессын нечкәрәк үзләштерергә ярдәм итә. Шулар булышлыгы белән ул тормышны да тирәнрәк танып-белергә өйрәнә.

Йөзләрчә роль уйнаса да, Н. Гайнуллин тудырган образлар ул кадәр күп түгел. Чөнки һәрбер роль дә актер эшендә этап булып тормый. Әмма бу артист уйнаган образлар арасында милли театрыбыз тарихына кереп калырдайлар да бар. Иң элек Ә. Фәйзинең «Тукай» драмасы буенча куелган спектакльдәге Галиәсгар Камал образын искә алырга кирәк. Спектакльнең режиссеры Шириязданан Сарымсаков актерга беркемне дә уйнамаска, ә үзе булып калырга киңәш итә. Чөнки, «Бәхетсез егет»нең авторы Тукай белән очрашканда нәкъ Нәҗип Гайнуллин яшендә була. Шулай итеп режиссер башкаручыны әкренләп язучының рухи дөньясына алып керә һәм аның Камалга хас булган кичерешләрне күңеленнән үткәрүенә ирешә.

«Тукай» спектакле 1938 елда куела. Г. Камалның үлүенә әле биш кенә ел, аны һәммәсе дә белә, хәтерли. Әлбәттә, һәркем белгән мәшһүр тарихи шәхес роле өстендә эшләү актерга кыен була. Репетицияләрнең берсендә режиссер, ничектер шулай сүз арасында гына, Гайнуллинның Г. Камал белән охшаш булуын әйтеп ала. Һәм шул моменттан роль алга китә. Н. Гайнуллин Г. Камал ролен бик дулкынланып, тасвирланган вакыйгаларга нык ышанып уйный.

Нәҗип Гайнуллинның икенче зур роле Бөек Ватан сугышы елларында уйнала. М. Гали һәм Х. Уразиковның «Каюм Насыйри»ында ул төп рольне уйный. Автор тарихи образны — караңгылыкка һәм наданлыкка, гаделсезлеккә һәм хокуксызлыкка каршы көрәшкән гуманист кешене данлый. Татар совет театры сәхнәсендә сугыш елларында бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри турында куелган спектакльнең көче, әһәмияте бәя биреп бетергесез булды. Фашизм кешелек культурасын таптый, һәйкәлләрне җимерә, китапларны яндыра, ә совет культура эшлеклеләре прогресс һәм иҗади төзелеш юлында торган бабаларына дан җырлыйлар. Актер һәм режиссер Х. Уразиков үзләренең уртак фантазияләре белән шундый бөек затларның берсен — мәгърифәтче Каюм Насыйрины күз алдына бастыралар.

Ниһаять, Гайнуллин тудырган өченче әһәмиятле образ — Н. Погодин пьесасы буенча куелган «Мылтыклы кеше» спектаклендә Владимир Ильич Ленин образы. Актерлардан кайсысы гына революция юлбашчысы ролен уйнарга хыялланмагандыр! Гайнуллинның да шундый зур хыялы була. Ул үз ролен төннәр буе йокламыйча уйлап ята. Актер Ленин турында әллә никадәр материал укый. Махсус рәвештә Мәскәүгә, В. И. Ленинның Үзәк музеена барып кайта. Ильичның портретларын, скульптураларын өйрәнә. Менә шунда артист тирән дулкынлану кичерә. Ленин образын иҗат итү, чыннан да, гаҗәеп олы эш. Бөек революционерның эчке тормышы турында сөйләү, чыннан да зур җаваплылык йөкли! Һәм Нәҗип Гайнуллин кыенлыкларны җиңеп чыга, үз хыялында йөргән рольне уңышлы башкара.

Нәҗип Гайнуллинның сәхнә образлары галереясе төрле дә, үзенчәлекле дә. Ул Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» комедиясендә Шмаганы, Л. Рахмановның «Тынгысыз картлык» дигән пьесасында матрос Куприяновны, украин драматургы И. Карпенко-Карыйның шул исемдәге комедиясеннән Мартын Боруляны, Шекспирның «Ромео һәм Джульетта», «Король Лир» трагедияләрендә Меркуцио һәм герцог Корнуэльский, М. Фәйзинең «Галиябану»ында Бәдри, Т. Гыйззәтнең «Шомлы көннәр»ендә Мирвәли рольләрен уйный. Рольләрне тагын да санап булыр иде, тик алар арасыннан икесен аерым телгә аласы килә. Болар — Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында Җиһангир һәм Мостай Кәримнең «Кыз урлау»ы буенча куелган спектакльдә Әҗмәгол.

«Хуҗа Насретдин» спектакле гаҗәеп ямьмышлы булды. 1957 елда татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында мәскәүлеләр аны таң калып карадылар.

1940 елда язылган рецензиясендә Муса Җәлил яшь Н. Гайнуллинның уйнавына да югары бәя бирә. Ул актерның рольне табарга, персонажның характерын реалистик буяулар белән ачып бирергә омтылуы турында яза (М. Җәлил. 4 том, 463 бит).

Гайнуллин үз героен — ханны эчке темперамент, активлык белән уйный. Тамашачы аңа тулысынча ышана: Җиһангирның бөтен кыланышлары, хәрәкәтләре дөрес һәм табигый. Актер әз генә дә арттырмый. Җиһангир-Гайнуллин һәм Хуҗа-Әбҗәлилов дуэты һәрвакыт киеренкелек, эчке һәм тышкы сурәтнең тигезлеге белән үтә. Аларның бәрелеше чыннан да ике оста бәрелешенә әверелә, тамаша залының давыллы алкышлары белән тәгәлләнә.

Татарстан АССРның халык артисты Нәҗип Сәмигулла улы Гайнуллинның соңгы рольләреннән берсе Әҗмәгол карт роле булды. Бу рольне актер зур ләззәт белән, дәртләнеп һәм канатланып уйный иде. Сәхнәдә гүя артист түгел, җанлы кеше үзе! Ул хәйләкәр дә, шук та, зирәк тә, тапкыр да! Актер дөньяны, тормышны яратучы оптимист образын тудырды. Бу рольне башкаручы артист Нәҗип Гайнуллин үзе дә әнә шундый кеше иде.

**Хәлит КУМЫСНИКОВ,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# ИСЕМНӘРНЕҢ СЕРЕН АЧУЧЫ

*Гомәр Саттаровка 50 яшь*

Антропотопонимика, топонимика, ономастика, зоонимика, космонимика, гидронимика һәм тагын әллә никадәр -нимикалар... Бу сүзләрнең барысын да без, Казан университетының татар теле кафедрасында укытучылар, беренче тапкыр Гомәр Саттаровтан ишеттек. Әле хәзерге көнгә хәтле татар бүлегендә кайберләрен төгәл, дөрес әйтеп бетерә алмаучылар очраштыра, бигрәк тә антропотопонимика дигәнен... Нинди фән соң бу? Каян һәм кайчан барлыкка килгән? Аны татар тел белемендә кем формалаштырып җиткергән? Бу сорауларга җавап бирү өчен иң беренче университет профессоры филология фәннәре докторы Гомәр Фәизович Саттаров исемен телгә алмыйча мөмкин түгел.

Республикабызда һәм татарлар яши торган башка өлкәләрдә бу исем күпләргә таныш. Чөнки галим һәр кешегә кызыклы, кирәкле, һәр кешедән аерылгысыз булган исемнәр — ялгызлык исемнәрен тикшерү белән шөгыльләнә.

Гомәр Саттаров 1950 елда Норлат рус-татар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килә. Өченче курстан башлап ул Г. Тукай исемендәге стипендиягә лаек була һәм 1955 елда университетны кызыл диплом белән тәмамлый. Аны Тобол педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасына ассистент итеп җибәрәләр.

Тобол институтында укытканда Г. Саттаров Себер татарларының үзенчәлекле сөйләменә игътибар итә. 1956—57 елларда Саз ягы татарларына фәнни экспедиция оештырып, шуларның нәтиҗәләре буенча фәнни хезмәтләр яза башлый. Татар телен тагын да тирәнрәк белү, өйрәнү теләге анда нәкъ менә шушы чорда туа. 1959 елда бу теләк аны яңадан Казан университетына алып килә. Г. Саттаров аспирантурага кабул ителә. Җитәкчесе итеп аңа сәләтле яшь галим М. З. Зәкиев билгеләнә. 1963 елда Г. Саттаров «Җирле диалект шартларында V—VIII класс укучыларының татар тел культурасын үстерү» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Татар телен укыту методикасы буенча язылган хезмәтләр, укылган лекцияләр яшь галимнең киләчәк фәнни эшенең тагын бер тармагын билгелиләр. Киләчәктә басылып чыгачак «Мәктәптә тел культурасы», «Татар телен укыту методикасы» (Ф. Вәлиева белән берлектә язылган), күп санлы мәкаләләр, университетта татар телен укыту методикасы буенча лекцияләр уку — болар аның кандидатлык диссертациясенең дәвамы.

Хәтерли торгансыздыр: алтмышынчы елларның урталарыннан башлап республика вакытлы матбугатында авыл, район исемнәренә, төрле географик атамаларга, аларның килеп чыгышына, мәгънәсенә караган күп санлы мәкаләләр басыла башлады. Бер үк вакытта телевидениедән дә шундый ук тапшырулар оештырылды. Боларның авторы Г. Саттаров иде. Менә шуннан соң инде «боз кузгалды»: газета-журнал редакцияләренә, радиога — «Тел күрке — сүз» тапшырулары адресына йөзләгән сораулар кәа башлады: безнең авылның исеме каян килеп чыккан? Бу сорау бик күпләрне кызыксындыра. Авторга ярты меңнән артык хат килгән. Аларны укучы балалар, укытучылар, механизаторлар, пенсионерлар, картлар, эшчеләр, колхозчылар яза. Г. Саттаров шул хатларга җавап рәвешендә даими рәвештә матбугат аша җавап бирә килә. Хат язучыларның һәрберсе бу эшнең кирәкле, әһәмиятле булуын әйтеп, галимгә зур рәхмәт сүзләре дә язалар.

Соңгы елларда мәктәпләрдә, авылда туган якны өйрәнү музейлары оеша башлады. Моның өчен иң беренче чиратта авылның исемен ачыклау кирәк. Шул эшне башлап җибәргәндә киңәш сорап галимгә мөрәҗәгать итәләр.

Күп санлы архив материаллары, рус елъязмалары, риваятьләр өйрәнеп, меңләгән ялгызлык исемнәреннән гыйбарәт картотека туплап, экспедицияләрдән алып кайткан материал җирлегендә татар тел белемендә әле моңа хәтле исеме дә булмаган уникаль фән юнәлеше барлыкка килә: антропотопонимия.

1975 елда Г. Саттаров «Татарстан АССРның антропотопонимиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Күренекле тюрколог галимнәр профессор Э. Р. Тенишев, профессор М. З. Зәкиев, профессор Р. Г. Кузеев Г. Саттаровның эшенә югары

бая бирәләр, башка төрки телләр өчен дә үрнәк булырлык эш икәнен билгеләп үтәләр. Хезмәт бай фактик материалга нигезләнгән, археологик, тарихи, этнографик, географик мәгълүматлар белән тыгыз бәйләнгән, лингвистик һәм экстралингвистик факторларга тирән фәнни анализ белән аерылып тора. Хезмәтнең беренче бүлегендә төп нәтиҗә мондый: Татарстан АССРдагы торак атамаларының иң борынгы өлеше кеше исемнәренә һәм кушаматларына нигезләнеп барлыкка килгән. Икенче бүлегендә автор VII—XIV гасырларга караган болгар ялгызлык исемнәрен тикшерә һәм 200 болгар сүзе билгели. Бу — искиткеч зур сан, чөнки болгар теле — тел буларак сакланып калмаган, ә болгар теленнән калган һәр сүз алтыннан да кадерлерәк бит. Шулай итеп, әлеге хезмәт татар халкының килеп чыгышы, тарихи мәсьәләләрен билгеләү өчен дә фәнни әһәмияткә ия. Шул исемдәге китап чыгу уңае белән язылган бер рецензиядә филология фәннәре докторы Г. Ахунҗанов, тарих фәннәре кандидаты С. Алишев болай дип яздылар: «Тел фактлары тагын бер тапкыр болгарлар белән Казан татарлары арасында турыдан-туры күчемлелек-варислык булганлыгын объектив рәвештә исбат итәләр. Шуңа күрә дә авторның әлеге лингвистик хезмәте тарихчылар өчен дә билгеле бер кыйммәткә һәм әһәмияткә ия».

Г. Саттаров ел саен дистәләрчә курс һәм диплом эшләре белән җитәкчелек итә. Бөтенсоюз, региональ, республика, университет конференцияләрендә фәнни докладлар белән катнаша, диссертацияләр яклауда оппонент булып чыгышлар ясый. Ул төзегән «Татар исемнәре сүзлеге» 25 меңлек тираж белән чыкты һәм тиз көндә таралып та бетте. Сүзлек генетик принципка корылган һәм борынгы төрки, иске татар, гарәп, фарсы чыгышлы кеше исемнәренә бүлеп аңлатылган.

Г. Саттаров исеменә сүзлек чыгу уңае белән рәхмәт әйтеп язган хатларның берсендә бик мәгънәле бер фикер бар: сүзлекне сез төзедегез, басылып чыккач, ул инде — безнең дә сүзлек. Чыннан да, сүзлек — татар халкының үзенчәлекле визит карточкасы, халыкның тарихын үзенчә ачып сала торган китап, һәм, иң әһәмиятлесе, һәркем өчен дә — карты өчен дә, яше өчен дә бик кирәкле. Яшьләр өчен бигрәк тә, чөнки тормыш дәвам итә, бәбиләр туып тора, һәм китап һәрвакыт зур иҗтимагый функция башкарачак: кешенең гомерлек юлдашы — исем кушуда катнашачак.

Төрки телләр буенча күренекле галимебез Ә. Р. Тенишев, Г. Саттаровның фәнни хезмәтләренә югары бәя бирә, аларның халык тарихы һәм этногенезын тикшерүдә әһәмиятен билгели. Күренекле совет топономасты Э. М. Мурзаев, ЮНЕСКО каршындагы ономастика фәннәренең Халыкара комитетының почетлы члены В. Н. Никонов, мари галиме Ф. И. Гордеев, Болгария галимәсе Мәфкүрә Моллова һ. б. галимнәр хәзер Г. Саттаров хезмәтләренә дә таянып эш итәләр. Гомәр Саттаровның «Татарстан этнотопонимнары» дигән докладлы Польшада, Краков шәһәрендә үткәрелгән XIII Халыкара ономастик конгресс программасына да кертелде. Галим 1974 елда чыккан «Татарстан АССРның антропотонимнары» китабы өчен Казан университетының иң яхшы фәнни эшләргә бирелә торган бүләгенә лаек булды.

Г. Саттаров шөгыльләнә торган фән өлкәсе бик катлаулы, күп төрле өлкәләрдән мәгълүматлы булуны таләп итә һәм ахыр чиктә ул халыкның тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән. Сүзләргә, исемнәргә аңлатма бирү, аларның килеп чыгышын тикшерү зур фәнни багаж сорый. Этимология шундый фән: бер үк сүзнең килеп чыгышына төрле карашлар янәшә йөри. Моның ачык мисалы — Казан шәһәренең исемен аңлату. Бер дистә караш булуын күрсәтеп, Г. Саттаров үзенең тагын бер яңа этимологиясен тәкъдим итә. «Казан утлары» журналын алучылар күптән түгел галимнең бу гипотезасын кызыксынып укыганнардыр дип уйлыйбыз. Этимолог вакыт-вакыт ялгыша да, ләкин өзлексез эзләнү ялгышларны вакытында төзәтә барырга мөмкинлек бирә.

Г. Саттаровның тынгысыз каләме һаман эштә. Аның «Туган як ономастикасы», «Казан урамнары исемнәренең килеп чыгышы», «Татарстан топонимиясе» кебек китаплары нәшриятка тапшырылган. 2000 машинка бите күләмендәге «Татарстанның топонимик сүзлеге»нең корпусы да әзер. Сүзлеккә 50 мең топонимик берәмлек тупланып, шуларга тарихи-лингвистик аңлатма бирелгән.

Илле яше тулган коллегабыз Гомәр Саттаровка тагын да зуррак иҗат уңышлары теләп калабыз.

**Флера САФИУЛЛИНА**

# ӘБРАР ШӘМИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әбрар Шәмин матур-матур хикәяләре һәм повестьлары белән әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Ул Татарстанның Апас районы Олы Кайбыч авылында 1912 елның 20 июнендә туа. Ярлы крестьян улы Әбрар бик яшьли авыл кулакларына ялланып эшли башлый, авыр хезмәтнең ни икәнен үз җилкәсендә бик иртә татый. Октябрь революциясе алып килгән азатлыкның кемнәр өчен булуын бик тиз аңлап ала һәм шул чор яшьләренә хас ашкыну белән яңа тормышны яклаучылар сафына баса. Тирәнрәк белем алу, илгә-көнгә файдалырак кеше булу теләге аны авылдан Свердловск шәһәренә алып килә. Биредә барган төзелешләрнең берсенә җир казучы булып урнаша. Эштән бушаган арада бар вакытын төпле белем алу өчен файдалана.

1931 елдан Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр, юстиция органнарында халык тикшерүчесе, халык судьясы, Үзбәкстан ССРның Верховный суды коллегиясе члены булып эшли. 1941 елны КПСС сафларына член булып керә. Үз тормышын яшьтән үк ил язмышы белән бәйләгән Әбрар Шәмин гади солдаттан Совет Армиясе полковнигы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Аның әдәбияттагы беренче тәҗрибәләре 1938—1939 елларда башлана. Беренче хикәяләрен ул үзбәк телендә бастыра. Ә 1939 елда үзбәк телендә «Батыр» исемле хикәяләр китабы басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы елларында Ә. Шәминнның әдәбият белән шөгыльләнү өчен вакыты булмый диярлек. Аның чын иҗат юлы Казанга кайткач, тыныч төзелеш елларында башлана. Язучы берничә хикәяләр җыентыгы бастырып чыгара. «Ике язмыш», «Яңа язлар» дигән повестьлар яза. Иң яхшы әсәрләре тупланган «Күңел күзе» дигән күләмле китабы дөнья күрә.

Лирик бизәкләргә бай тормышчан хикәяләрендә, повестьларында язучы туган илебезне дошманнардан саклаучы яшьләребез, олы төзелешләр каһарманнары һәм иген кырларында эшләүче уңган игенчеләрнең романтик тормышларын, уй-тойгыларын үзенә бер матурлык белән сурәтләде.

Зур тормыш юлы узган язучы үзенең күңелендә йөрткән бик күп яңа әсәрләрен кәгазь битләренә күчерә алмый калды. Яшьтән үк бик киеренке тормыш белән яшәү, сугыш елларында кичергән авырлыклар аның исәнлеген какшатты, гомере вакытсыз өзелде.

Әбрар Шәмин әсәрләре халкыбызның рухи хәзинәсенә матур бер җыр булып кушылды.

# ДОЛМАТОВСКИЙ ТАТАР СУГЫШЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

Мәскәүдә курста укыганда мин берничә тапкыр күренекле шагыйрь Евгений Долматовский белән очраштым. Шагыйрь Бөек Ватан сугышының күп көннәрен татар сугышчылары белән бергә үткәргән, генерал-майор Зәки Котлин дивизиясендә дә булган. Бу вакытта армия газетасы редакциясендә шагыйрь Джек Алтаузен да эшли. Ул да, алгы сызыкта еш булып, дивизия командиры белән еш очраша һәм әңгәмәләр үткәрә.

...1942 елның кышында безнең гаскәрләр Харьковка һөҗүм итәләр. Башта бу һөҗүм бик уңышлы бара. Котлин дивизиясе сугышчыларының күпчелеге руслар, украиннар, татарлар, башкортлар була. Фронт газеталары алар батырлыгы турында шулай ук күп язалар. Аларга багышланган шигырьләр һәм җырлар иҗат ителә. Джек Алтаузенның «Котлинчылар килә» дигән зур поэмасын армия газетасы бастыра. Менә аның кайбер юллары:

**Үзән, елга, тарлавыклар аша,**
**Днепрга илткән юлларда**
**Котлинчылар уза сугышларга,**
**Автоматлар кысып кулларга!**

**...Элек монда кошлар сайрап торды,**
**Челтерәп акты салкын чишмәләр...**
**Шунда үтте безнең матур яшьлек,**
**Пионерга кергән кичәләр!**

Шагыйрь Евгений Долматовский язган «Котлинчылар» җырын да дивизиядә бик яратып җырлаганнар. Ул да фронт газетасында басылып чыга.

**Кемнәр алар котлинчылар! Һәркем белә моны:**
**Котлинчы диеп атыйлар батырны, кыюны!**
**Беркемгә дә мондый исем бирелми юкка,**
**Сугышта яулап алмасаң, ташланып утка!**

Дивизиядә кайчан, ничек булуы һәм бу җырның ничек язылуы турында сорап язган хатка Евгений Аронович түбәндәгечә җавап бирде:

...Генерал Зәки Котлин дивизиясендә мин ул чакта фронт Политидарәсе хезмәткәре, политрук Василий Котов белән бергә 1942 елның башында булдым. Дивизия дошманга уңышлы һөҗүм итә иде: немецлардан, мәсәлән, Лозовая станциясен һәм шәһәрен сугышып алды. Шунда кинооператор Евгений Мухин да булды. (Хәзер ул документаль фильмнар студиясендә эшли. Минемчә, анда генерал Зәки Котлин һәм аның дивизиясе турындагы фотопленкалар да саклана торгандыр.)

Ә дивизиядә мин язган җыр үземдә сакланмаган, ләкин ул Татарстандагы мәктәпләрнең берсендә — генерал Зәки Котлин музеенда бар... Джек Алтаузен дивизиягә шул ук 1942 елда килә. Башта без бергә булдык, соңыннан... аерылдык.

Әйе, соңыннан... гитлерчылар контрһөҗүмгә күчәләр һәм совет сугышчыларын камап алалар. Искиткеч каты сугышлар башлана. Дивизия сугышчылары утлы боҗраны өзеп чыгу өчен баһадирларча көрәшә. Ләкин кара тәреле танклар алгы окопларга бәреп керә... Окопларда, землянкаларда һәм блиндажларда кул сугышлары башлана.

Генерал Зәки Котлин үзе дә бу сугышларда турыдан-туры катнаша һәм җиңел машина белән барганда снаряд ярчыгы тиеп һәлак була... Немец танклары алгы окопларга бәреп кергәч, безнең офицерлар һәм солдатлар, аларга каршы яндыргыч шешәләр һәм гранаталар ыргытып, дошманның алга баруын туктаталар. Ләкин икенче, өченче төркем танклар һөҗүме вакытында батырларча һәлак булалар. Джек Алтаузенны да үкереп килгән бер танк таптап уза...

Евгений Долматовский белән күптән түгел генә Мәскәүдә яңадан очраштык. Ул миңа сугышта үзе күргән-белгән кайбер сугышчыларның батырлыклары турында әле дә булса дулкынланып сөйләде. Мәсәлән, шундыйлардан өлкән сержант Гази Заһитовны бик яхшы хәтерли икән. Бу кыю егет Башкортстанның Мишкә районы, Яңагыш авылында 1921 елда туган. Бик яшьтән үк сабантуйларында көрәшкән, соңыннан үз авылында һәм район күләмендә батыр булып танылган. Җырга да бик оста булган, колхоз эшендә дә макталган, язгы чәчү, урып-җыю чорларында алдынгылыкны бирмәгән... Берлинны алу һөҗүмендә ул рейхстагка Җиңү флагы элүчеләрнең берсе була. Дөрес, рейхстагка төп Җиңү байрагын грузин егете Кантария һәм рус егете Егоров мендереп кадыйлар. Ләкин андый байрак берәү генә булмый. Менә шуларның берсен элүче әлеге Гази Заһитов икән. Аның турында Е. Долматовский күп кенә материаллар, фоторәсемнәр туплаган, аны күреп белүчеләр белән дә сөйләшкән, Газиның туганнарына хатлар язган. Шагыйрь үзе дә Берлинны алуда катнашкан, рейхстаг янында бөек Җиңүгә багышлап шигырь язган һәм аны митингта сугышчыларга сөйләгән. Шунда Гази Заһитов та булган.

Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 27 ел тулу уңае белән фронтовик-шагыйрь Е. Долматовский «Җиңү автографлары» дигән китап чыгара һәм Гази Заһитов турында бик җылы итеп язылган мәкалә урнаштыра. Анда мондый юллар да бар:

« — Рейхстагны штурмлау өчен кемнәр үзләре теләп соңгы атакага барырга теләгән?

Алар тиз генә алга атладылар: капитан Владимир Маков, өлкән сержант Гази Заһитов, өлкән сержант Александр Лисиминко, сержант Михаил Минин һәм тагын уннарча солдат һәм офицер.

29 нчы апрельдә артиллерия полкы сугышчылары — барысы егермеләп кеше, шул җөмләдән Гази Заһитов та, рейхстагка төзәп атканнан соң, пехотачылар белән бергә штурмга күтәрелделәр. Соңыннан алар дүрт кеше калды. Ләкин кызыл флагны рейхстаг өстендәге бронза атлар янындагы сугыш алиһәсенә беркетеп куйдылар. Флагны иптәшләренең ярдәме белән Гази Заһитов алып менә һәм гөмбәзгә ул беркетеп куя».

Арыслан йөрәкле Гази, күкрәгенә һәм кулына пулялар тиеп, рейхстаг өстендә яралана. Шулай да әле аяк өсте йөри, иптәшләре белән фоторәсемгә төшә. Соңыннан гына ул госпитальгә керә. Врачлар аның күкрәк читлеген рентгенда карыйлар һәм бер-берсенә карап гаҗәпләнәләр:

— Йөрәккә тимичә бер миллиметр гына ара калып, пуля күкрәк читлеген тишеп чыккан!

Ахырдан, истәлекләренә йомгак ясаган төсле итеп, Евгений Долматовский болай ди:

— Мондый батырлар онытылмаска тиеш!

Самат **ШАКИР**.

# СӨЕНЕЧЛЕ ЮЛЛАР

Күк төбеннән караучыга күк бәләкәй, энә күзеннән караучыга дөнья бәләкәй дигән сүз бар халыкта. Дөньяны танып-белүгә карата әйтелгән бу мәкаль тиктомалдан гына хәтергә килмәде. Фотожурналист хезмәте турында уйлаганда искә төште ул. Баксаң, фотоаппаратның объективы — «тәрәзәсе» дә әллә ни зур түгел. Ә ул иксез-чиксез күкне әнә ничек колачлаган, матур һәм киң дөньяны тулаем үз тасмасына сыйдырган. Сүз дә юк, җиһанның әлеге күркәмлеге һәм киңлеге үзеннән-үзе генә тасмага уелмаган. Аңа кешенең дөньяны матур итеп күрә белү, кабатланмас мизгелләрне оста тотып алу кодрәте салынган. Күрер күзгә

гадәти тоелган елгалар, урман-кырлар рәсемгә кучкач сөйкемлерәк төс алганнар. Күзгә артык бәрелеп тормаган тыйнак кына савымчылар, җир җимертеп эшләүче механизаторлар, ничәмә-ничә километр тау токымнарын тишеп, шуннан «кара алтын» чыгаручы нефтьчеләр рәсемдә чын баһадирлар булып гәүдәләнәләр. Ни өчен шулай?

Фотожурналист Мидхәт Шакирҗанов төшергән рәсемнәрне карасаң, әлеге сорауга тиз җавап табасың. Ул туасы көннең тагын да матуррак буласын белгән халда иҗат итә, эзләнә һәм таба белә.

20 меңгә якын рәсем. Мидхәт Фәйзелхак улының 20 ел буена газета-журнал битләрендә әнә шул кадәрле хезмәте дөнья күргән. Ул ел саен кимендә 25—30 районда булырга өлгерә, заманыбыз тарихын язуга, хезмәт алдынгыларын, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тынгысыз дөньясын чагылдыруга үзеннән лаеклы өлеш кертә.

Үзе авылда туып-үскәнгәме, туганнарының язмышы игенче хезмәте белән бәйле булгангамы — ул ару-талуны белмичә республика авыллары тормышын өйрәнә, аларның социаль, экономик тормышын газета-журнал битләрендә, телевизор экраннарында күрсәтә.

Фотохәбәрче КамАЗ һәм Түбән Кама нефть-химия берләшмәсе эшчеләренең, Әлмәт нефтьчеләре һәм Алабуга тукучылары, Казан мехчылары һәм Зеленодольскидагы агач эшкәртүчеләрнең хезмәтенә дан җырлый. Промышленностьның кызу темпларына ияреп ул Төмәнгә юл ала — Татарстан нефтьчеләре белән ярышучылар турында репортажлар әзерли, Нурек ГЭСын төзүче якташларыбыз, Томск өлкәсеннән илебезнең Европа өлешенә газ торбалары сузучы каһарманнарның портретларын иҗат итә. Туган төбәген чиксез яратканга да ул теге яки бу шәһәрдә, өлкә яки республикада булганда якташларыбызны эзләп таба, иң беренче тәэсирләрен алар белән уртаклаша. Аның Целиноград һәм Донбасс, Рига һәм Оренбург шәһәрләреннән әзерләнгән «Якташлар» цикллары бар. Татарстан даньн еракларда да югары тоткан, тырыш хезмәте белән шөһрәт казанган якташларыбызның рәсемнәренә карагач, халкыбызга карата күңелдә горурлык хисе уяна. Донбасс шахталарында күмер чыгарамы, әллә Рига предприятиеләрендә үтә нечкә һәм катлаулы транзисторлар җыямы, Целиноградта балалар укытамы, әллә Төмәндә нефть чыгарамы — кайда һәм кем генә булып эшләсәләр дә — якташларыбыз үзләренең чын интернационалист буларын кылган эшләре белән раслыйлар. М. Шакирҗанов әнә шул рухлары нык булган батыр кешеләрне бөек эшләренә тиң итеп чагылдырырга омтыла.

КамАЗ гигантын сафка кертү үзе ни тора! КамАЗның беренче үрнәген «Правда» газетасы аша илебез укучысына да Мидхәт Шакирҗанов ирештерде. Фотожурналистның КПССның XXIV—XXV съездлары эшен яктырткан тарихи рәсемнәре китап, альбом битләренә уелды.

Алдә булса зур теләк, эштән ял таба йөрәк, дигәннәр элгәргеләр. М. Шакирҗанов та үз хезмәтенә гашыйк. Рәсемгә аласы объектын алдан ныклап өйрәнә, урынга баргач партия, совет, хуҗалык җитәкчеләре белән киңәшләшә, өстәмә мәгълүматлар туплый. Хезмәт алдынгысы турындагы гади генә дип исәпләнгән портрет әнә шуннан соң гына газета яки журнал битенә тәкъдим ителә...

...Мидхәт бик яшьли күпне белергә ратучан малай булып үсә. Сугыштан соңгы авыр еллар. Авылга кино килсә, ул шул кино күрсәтүче агай янында чуала, киноаппаратның серенә төшенергә омтыла. Көннәрнең берендә агай әйтә моңа: «Энекәш, районнан бер кешене Казанга киномеханиклыкка укырга җибәрәләр. Теләгең юкмы?» Теләк барын бар да бит, Алабугада педучилищеда да укый ич әле ул. Агайның сүзләре уйга сала. Хәзер ул ике ут уртасында. Нишләргә? Кинонын тылсымлы тәэсире көчлерәк булып чыга. Егет тәвәккәлли. Казандагы кыска сроклы курсларны тәмамлагач, 1945 елда аны Сарманда беренче мәртәбә тавышлы кино күрсәтергә җибәрәләр.

Мидхәтнең дөньясы да яңа бизәкләр белән бизәлә. Һөнәр. Гаилә. Балалар. Һөнәрен шундый нык ярата, хәтта үзенең бу шөгыленә хатынын да өйрәтә. Шулай итеп, икәүләшеп кино күрсәтәләр болар. Әмма Мидхәтне бу хәл генә канәгатьләндерми. Үзенең кино яки фотога төшерәсе килә.

Казан телестудиясенең яңа гына ачылган чагы. Бик тә кирәк андый тынгысыз, эзләнүчән егетләр студиягә. Һәм М. Шакирҗанов Казанга күчеп килә. Телевизордан кино да күрсәтә, үзе дә тапшырулар өчен фоторепортажлар әзерли, газеталарда ара-тирә рәсемнәре басыла. Алтмышынчы елдан башлап аның иҗаты «Социалистик

Татарстан» газетасы, аның эшчәнлеге белән бәйләнә. Еллар, юллар бу тырыш кешегә гел сөенеч китерә, ул бөтен матурлыкны кешеләр күңеленннән эзләп иҗат итә.

Югарыда сөйләгәннәргә өстәп тагын бер сөенечле вакыйга турында да әйтәсе килә. Сүз М. Шакирҗановның күптән түгел оештырылган шәхси күргәзмәсе хакында бара. Күргәзмәгә авторның 200 гә якын хезмәте куелган. 20 еллык иҗади хезмәтне үзенә сыйдырган 200 рәсем. Автор бу иҗат җимешләрен иң беренче булып якташларына — Тукай районының Түбән Суыксу авылы халкына күрсәтте. Аннан аны шушы районның башка авыл кешеләре, КамАЗ төзүчеләр карады.

Туган-үскән җиргә, аның сөйкемле табигатенә, хезмәтчел халыкка мәдхия җырлана аларда. Дан казанган игенче белән янәшәдә генә без яшь механизатор портретын күрәбез, танылган галимнең үз шәкерте белән фән серләрен уртаклашуын, галиҗәнаб эшче сыйныфының горур эшләрен чагылдырган рәсемнәр йөрәккә матур бизәк булып уелалар. Күргәзмәдәге рәсемнәр арасында әдәбият һәм сәнгать әһелләре — Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим, Бакый Урманче, Харис Якупов, Нәҗип Җиһанов...

Шагыйрь дөньясының бер мизгелен, рәссам тормышының катлаулы һәм үзенчәлекле якларын фотога төшерү өчен журналистка күп эзләнергә, күп өйрәнергә, күпне белергә, үзенә күрә бер ачыш ясарга кирәк.

Шундый ачышлар рәтенә мин авторның «Карт һәм диңгез» дигән әсәрен кертер идем.

Исеменнән үк күренгәнчә, сүз диңгез һәм карт балыкчы турында. Әлеге исем, үзеннән-үзе Эрнест Хемингуэйның шул исемдәге атаклы әсәрен, андагы мәрхәмәтсез диңгезне һәм шул диңгез, ерткыч балыклар белән көрәшүче картны искә төшерә. Әмма Мидхәт Шакирҗанов иҗат иткән образ, характер Э. Хемингуэй картына капма-каршы. Фотожурналистның бу хезмәтендә без табигать стихиясен генә түгел, ә бәлки сугыш гарасатын җиңеп, туган төбәгенә җиңү яулап кайткан баһадир совет кешесен күрәбез. Әнә ул — балыкчы карт. Көймәгә утырган. Кәрәк чаклы куллары ишкәкләргә тотынган. Менә-менә ул диңгез иркенә чыгып китәр сымак... Күкрәгенә сугышта яулап алган орден-медальләрен таккан. Яхшы костюмын кигән. Кая бара ул болай? Бәлки давыллы елларда үткән кайнар яшьлекләрен искә төшерү өчен ветераннар очрашуына чакырылгандыр ул? Ә бәлки яудан кайтмаган дусларын хәтерләү нияте белән портка юл тотадыр. Кайчандыр шул диңгез портыннан алар сугышка киткәннәр иде. Ак пароходка утырып... Нинди генә максат белән юлга җыенса да, карт балыкчы үзенең язмышыннан зарланмый, киресенчә, ул киләчәккә зур өмет белән карый, узганы һәм бүгенгесе белән чын-чынлап горурлана.

СССР төзелүнең 60 еллыгына багышлап М. Шакирҗанов фоторепортажлар сериясе әзерләде. Репортажларның исеме үк аның киң иҗат мәйданы турында сөйли. «Фотоаппарат белән ил буйлап», «Университет — Казанның горурлыгы», «КамАЗ: җитмеш милләт бер язмыш», «Дружба» нефтьүткәргече башланган җирдә...»

Фотоаппаратның бәләкәй «тәрәзәсе» аша дөньяның әнә ничаклы мизгеле күренгән. Фототасмаларда әнә никадәрле күренекле шәхесләрнең, каһарман эшчеләрнең, игенчеләрнең батыр эшләре күренә. Хәрәкәттәге һәм үсештәге заманның кабатланмас мизгелләрен тотып калып, Мидхәт Шакирҗанов туасы буыннарга истәлек әзерли. Ул бүгенге матурлыкны җырлаучы, киләчәкне якынайтучы замандашларыбызның берсе.

Сәмигулла **ХӘЙРЕТДИНОВ**.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан язучыларының 28 апрельдә үткәрелгән ачык партия җыелышында яшьләрнең «Идел» әдәби альманахы турында сөйләшү булды. Альманахны әзерләүдәге уңышлар һәм проблемалар, алдагы бурычлар турында аның редакторы Х. Хаиков чыгыш ясады. Альманах редколлегиясенең эшен тагын да яхшырту, анда басылган әсәрләрнең сыйфатын күтәрү турында эшлекле сөйләшү булды. Фикер алышуларда Татарстан китап нәшриятының баш редакторы В. Нуруллин, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, язучылар Р. Мостафин, М. Шабаев, яшьләрдән К. Кәримов, С. Маннапов һ. б. катнашты.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Республикабызда халык шагыйре Габдулла Тукай туган көннәрдә традицион әдәби бәйрәмнәр үткәрелде.

23 апрель көнне С. Хәким, Ә. Исхак, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Ф. Миңнуллин, М. Хөсәен һәм башка язучылар Арча эшчеләр поселогына шигъри митингка килделәр. Кунакларны КПССның Арча район комитеты беренче секретаре Д. К. Каюмов каршы алды, район хезмәт ияләренең уңышлары белән таныштырды, язучыларга иҗат уңышлары теләде.

Шул ук көнне шагыйрьләр Г. Афзал һәм Р. Миңнуллин Тукай-Кырлайдагы әдәби очрашуда катнаштылар.

* * *

26 апрельдә Г. Тукай һәйкәле янында үткәрелгән шигъри митинг республикабыз күләмендәге бәйрәмгә әверелде. Бәйрәм В. И. Ленин, Г. Тукай, А. С. Пушкин һәм М. Горький һәйкәлләренә чәчәк салудан башланып китте. Митингны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов ачты. С. Хәким, М. Садри, Г. Латыйп, Г. Афзал, А. Волков (Мәскәү), Р. Харис, Р. Гатауллин, Г. Рәхим (Мәскәү), Зөлфәт, Р. Миңнуллин, Р. Бохараев (Мәскәү), З. Мансуров, Л. Шакирҗанова һәм 1982 елгы Тукай бүләге лауреаты И. Нуруллин чыгышлары көчле алкышлар белән каршыланды.

Шигырь бәйрәме шәһәребезнең культура сарайларында, клубларда һәм предприятиеләрдә дәвам итте.

* * *

Идел буендагы иң зур шәһәрләрнең берсе булган Куйбышевта да 24 һәм 25 апрель көннәрендә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган зур кичәләр оештырылды. Аларда Г. Тукай әсәрләре, тугандаш республикаларның әдипләре тарафыннан Г. Тукайга багышланган шигырьләр һәм шагыйрьнең үз сүзләренә җырлана торган җырлар яңгырады.

Бу кичәләрдә катнашкан мең ярымнан артык тамашачы В. И. Ленин исемендәге металлургия заводының Культура сарае каршындагы үзешчән сәнгать осталарының чыгышын бик яратып кабул иттеләр. Коллектив белән уникe ел инде инженер-конструктор Илгиз Ибраһимович Колючев җитәкчелек итә. «Ялкынлы яшьлек» ансамбле оештырган әлеге кичәләр СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланды.

* * *

Халкыбызның бөек шагыйренә багышланган кичәләр шәһәребез клубларында һәм тулай торакларда уздырылды. Шундый кичәләрнең берсе Киров исемендәге СК заводының тулай торагында үткәрелде. Анда шагыйрь Р. Фәйзуллин, музыка белгече Ф. Вәлиева, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев һәм музыкант Р. Халитов катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясендә филология фәннәре докторы И. Г. Нигъмәтуллина белән очрашу булды. Ул «Шигырьдә сәнгатьчәлек критерийлары» дигән темага испанча, русча, украинча, әзербайҗанча шигырьләр һәм татар әдипләре әсәрләреннән мисаллар нигезендә кызыклы әңгәмә уздырды.

Секциянең икенче утырышына бөек инглиз шагыйре Байронның дүрт томлыгын төзеп, кереш сүз һәм искәрмәләр белән дөньяга чыгарган галимә — Казан культура институтының кафедра мөдире, филология фәннәре кандидаты Р. Ф. Усманова чакырылган иде. Ул Байронның иҗади мирасы, аның бүгенге шагыйрьләргә тәэсире, татар әдәбиятында бер чагылышы буларак, Такташның «Җир уллары» трагедиясе белән бәйләнеше турында бик үзенчәлекле чыгыш ясады.

*
* *

Балалар әдәбияты секциясенең «Ялкын» журналы редколлегиясе белән берләштерелгән утырышы булды. Анда барлыгы утызга якын язучы катнашты. Утырыш «Ялкын» журналының быелгы биш санын тикшерде. Журналда басылган проза әсәрләре хакында М. Галиев, балалар иҗаты турында Р. Мингалим сөйләде.

«Ялкын» журналында В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының төзелүенә 60 ел тулуга багышлап ябык конкурс игълан ителгән иде. Конкурс нәтиҗәләренә ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Сафин йомгак ясады. Жюри конкурска килгән хикәяләр арасында икенче премия — М. Мәһдиев белән К. Кәримовка, өченче премия М. Хуҗинга тапшырылды. Р. Низамиев һәм Г. Сәлимов хикәяләре кызыксындыру бүләкләренә лаек булды.

*
* *

Тәнкыйть секциясенең чираттагы утырышы Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты галимнәре тарафыннан чыгарылган «Әдәбият теориясе» китапларын тикшерүгә багышланды. Анда Ф. Хатыйпов, Н. Исәнбәт, Х. Госман, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Б. Гыйззәт һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

Бу утырышта шулай ук тәнкыйтьче Н. Хисамов иҗаты турында сөйләшү булды, ул секция исеменнән СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

Республикабызда һәр елны ленинчыл сәнгать фестивале үткәрелә. Язучылар һәм сәнгать осталары укучылар һәм тамашачылар алдында чыгыш ясап, үзләренең иҗатлары белән таныштыралар. 23 апрель көнне язучылар клубында шагыйрьләр М. Садри, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Гыйззәтуллина, Ә. Рәшитов, Х. Әюпов, Г. Садә, композитор Ә. Бакиров, җырчылар В. Гыйззәтуллина, Н. Теркулова, М. Галиев, Л. Хәсәнова, музыкантлар М. Хәбибуллина, Л. Маслова һәм А. Миркина катнашында зур кичә булды.

*
* *

Ел саен үткәрелә торган «Юмор кичәсе»нең инде даими тамашачылары бар. 2 апрель көнне дә язучылар клубы халык белән шыгрым тулы иде. Шагыйрьләр Ә. Исхак, М. Хөсәен, Р. Миңнуллин, Ф. Шәфигуллин, драматург Т. Миңнуллин һәм артистлар И. Баһманов, Х. Җәләлов, Д. Нуруллина, Р. Шамкаевлар чыгыш ясаганда тамашачылар йөзендә елмаю сүнмәде.

«Юмор кичәсе»н язучы Р. Батулла алып барды.

## 400 НЧЕ ТАПКЫР

4 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында шатлыклы вакыйга булды: драматург Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакль 400 нче тапкыр күрсәтелде.

## АКТЕРЛАР ЙОРТЫНДА

21 апрельдә Актерлар йортында шагыйрь Ренат Харисның иҗат кичәсе үткәрелде. Анда РСФСРның атказанган артисты Э. Җәләлетдинов, ТАССРның халык артистлары В. Гыйззәтуллина, Х. Бегичев, яшь композитор Р. Әхиярова, музыкант Д. Әхмәтов һәм нәфис сүз остасы Р. Сабиров катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЧАЛЛЫ БҮЛЕГЕНДӘ

Күптән түгел Чаллының йортлар төзү комбинатына караган «Төзүче» культура сараенда яшь әдәбиятчылар студиясе оештырылды. Аңа 35 яшькә җитмәгән башлап язучылар кабул ителә. Ләкин моңа кадәр алар үзләренең иҗат үрнәкләрен күрсәтергә, конкурста катнашырга тиешләр. Студиягә йөрүчеләр белән Чаллы язучылар оешмасы вәкилләре шөгыльләнәчәк.

*
* *

Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда драматург Т. Миңнуллин иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда драматург пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, авторның юмористик хикәяләре укылды, җырлар һәм шигырьләр яңгырады. Соңыннан Т. Миңнуллин тамашачыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде.

Шундый ук кичә Түбән Кама шәһәрендә дә үткәрелде.

*
* *

Чаллыда халык шагыйре Габдулла Тукайга 96 яшь тулуга багышланган җыр һәм шигырь бәйрәме зур хәзерлек белән уздырылды.

Быелгы шигырь бәйрәме үзенчәлекле булды, чөнки Әлмәттә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр Чаллыдагы каләмдәшләре белән очрашты. Тамашачылар Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Г. Афзал һәм шагыйрьләр Ә. Маликов, К. Булатова, Э. Мөэминова, яшьләрдән Р. Рәкыйпов, Н. Габдрахманова, язучы һәм драматург Ә. Гаффар, Чаллы әдипләре Разил Вәлиев, М. Газизов, К. Сибгатуллин, Н. Мадъяров, Г. Кашапов, Х. Хөснуллин, һәвәскәр җырчылар, үзешчән композиторлар, вокаль ансамбльләрнең чыгышларын яратып кабул иттеләр.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

## КИЛӘСЕ САНДА

*Проза*

М. Хәбибуллин. **Сулар үргә акса да.** Роман.

М. Мәһдиев. **Исәнме, Кәшфи абый!** Повесть.

*Драматургия*

Ю. Сафиуллин. **Менә без дә үсеп җиттек.** Комедия.

*Поэзия*

Зөлфәт. **Йөрәкләрдә — үлмәс дастан.** Поэма.

Рәшит Әхмәтҗанов. Шигырьләр.

*Очерк*

И. Зарипов. **Дуслар тугрылыгы.**

*Әдәби мирас*

**Тakташ хатлары.**

**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии